# Казан утлары

7

июль · 1971

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**7**

ИЮЛЬ
1971

## Бу санда:

ПОВЕСТЬ, ДРАМА, ХИКӘЯЛӘР, ШИГЫРЬЛӘР

**ФАТИХ ХӨСНИ. Мәйдан.** Повесть . . . . . . . 3
**МАРС ШАБАЕВ. Җикән камыш.** Икенче дәфтәрдән. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 72
**ГАРӘФИ ХӘСӘНОВ. Имән.** Этюд . . . . . . . 76
**ХӘЙ ВАХИТ. Күк капусы ачылса...** Комедия . . . 78
**МӨНИР МАЗУНОВ. Яшь каләмдәшкә. Хәлимә. Ак күгәрченнәр.** Шигырьләр . . . . . . . 94

КЫРГЫЗ ЯШЬЛӘРЕ ПРОЗАСЫ

**ЧЫҢГЫЗ АЙТМАТОВ. Яшь буын иҗаты** . . . . 96
**МУРЗА ГАПАРОВ. Тургай.** Хикәя . . . . . . . 98
**КЕНЕШ ҖУСУПОВ. Иске рәис.** Хикәя . . . . . 102

**ЭДУАРД МОСТАФИН. Югалган углан монологы. Без бәхәстә. Сулар ага да ага... Мин ант иттем... Юеш канатларын кагып... Скрипка елый.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 109

ДУСЛАР ҖЫРЫ

**ЗӨЛФИЯ. Җил. Сагыш. Үземә. Йөрәгем калды сездә. Айлы төн. «Түрдән узыгыз». Һавада... Минем таңым. Кайда сәламең! Шарлавык.** Шигырьләр. Үзбәкчәдән тәрҗемә . . . . . 112

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

**ТӘҮФЫЙК СӘГЫЙТОВ. Галимулла аганың истәлекле көне.** Очерк . . . . . . . . . . . . 119

ТӨРЛЕСЕННӘН

**МӨНИР ЮСУПОВ. Сүриядә очрашулар** . . . . 125
**С. ПИСАРЕВА, Д. БАҺАУТДИНОВА. Музейның әдәби филиалында** . . . . . . . . . . . . 132

КЫЗЫКЛЫ БИОГРАФИЯЛӘР

**Р. ХӘЙРЕТДИНОВ, Г. КӘРИМОВ. Комиссар каны** . 135

ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА ШАГЫЙРЬ

**М. САДРИ. Көчле ихтыяр җырчысы** . . . . . . 140

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

НӘБИ ДӘҮЛИ. Бизәк өчен түгел, кирәк өчен . . 142

ТӘРҖЕМӘ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

ГАЛИЯ ХАНТЕМИРОВА. Беренче адымнар . . . 150

ФОЛЬКЛОР

Пермь татарлары иҗаты . . . . . . . . . . 154

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

СӘВИЯ ЛАТЫЙПОВА. Борынгы кульъязмалар һәм Ибраһим Хәлфин эшчәнлеге . . . . . . . 158
МӨХӘММӘТ ГАЙНУЛЛИН. Габдрахман Сәгъди . 164

ХАЛЫК ТАЛАНТЛАРЫ

РӘХИМ САБИРҖАНОВ. Бер җирдә юк андый ак каеннар . . . . . . . . . . . . . . . 169

КИТАП КҮЗӘТҮ

МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ. Чишелеш... нульгә бетми. 175

ТАГЫН БЕР ЯҢА СҮЗЛЕК

ГАЛИМҖАН АХУНҖАНОВ. Телебезнең фразеологик сүзлеге . . . . . . . . . . . . 178

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

ХӘКИМҖАН ХАЛИКОВ. Кояшбикә чөлтәре. Барый. Нишләдем мин!.. Әле төште хәтергә. Әллә инде беләләр... Бәбкә санаганда. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 182

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

ЗӘКИ НУРИ. Бу уклар кемгә тияр! Шигырьләр . 185
РАДИК ИСАЕВ. Җор малай . . . . . . . . 186
АЗАТ ВЕРГАЗОВ. Тәнкыйть . . . . . . . . . 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

**Редакциягә килгән кульъязмалар кире кайтарылмый**

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор: **Зәки Нури.**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сулейманова, К. Корбангалиева.*

Производствога бирелде 1/IV-1971 ел. Басарга кул куелды 21/V-1971 ел. ПФ 09050. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 79046 экз. Заказ И-198. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1971 ел.

## ФАТИХ ХӨСНИ

# МӘЙДАН

ПОВЕСТЬ

## Ык суында казлар



Пароходлар йөри торган мул сулы дүрт елгасы, шулар янында күп кенә бүтән кечерәк елгалары, таулары һәм урманнары, тугайлары һәм чишмәләре белән Татарстан җире илебез уртасында кояшка күкрәген киереп җәйрәп ята. Бу кечерәк елгалар арасында иң күп сулысы һәм ярларындагы, тирәюньдәге бай табигате, уңдырышлы иген басулары, кызлары һәм казлары, җыры һәм моңы белән дан тотканы, әлбәттә, Ык елгасы булса кирәк. Һәрхәлдә, бу очракта минем шулай уйлыйсым килә. Чөнки, чыкса-чыкмаса, мин Ык буенда яшәүче кешеләр турында сөйләргә җыйналдым.

Әйе, шул тирәдәге авылларның берсендә, төгәлрәге, берничә авылны берләштергән «Алсу алан» колхозында, басулары вак-вак кына урманчыклар, чокыр-чакырлар, ташлы сыртлыклар, әрәмәлекләр белән бүлгәләнеп беткән, аларыннан да бигрәк, җитәкчелекне ничек тә ныклап куя алмаган бу хуҗалыкта кызыклы да, гыйбрәтле дә булган хәлләр әледәнәле кабатлангалый тора. Авыл аркылы узып китүчеләр, яки шуннан ерак түгел тау башыннан чаптырып ага торган, халык телендә «Шифалы чишмә» дип даны чыккан чишмәгә юынырга, суын алырга йөрүче карчык-корчыклар, бигрәк тә җәй башында сабан туйларына кунакка кайтучы шәһәр кешеләре, әлеге вак-вак урманнарны, Ык буеның ямьле тугайларын, андагы үрдәк-казларны күреп, елгасында су коенып, комында кызынып, дымык кичләрендә балык каптырып, уха пешереп, уха алдыннан чак кына төшереп алгач, бу яклардан, әлбәттә, сәрхуш калалар, монда яшәүчеләр, бигрәк тә кунак иткән кардәш-ырулары алдында куштанланып: «Дөнья җәннәтендә яшисез икән, абзыкайлар. Кадерен белеп кенә торыгыз!» — дип бик тә сырпаланалар. Әмма «дөнья җәннәте»нең үзендә даими яшәүчеләр, ай-һай ла, беләләр. Белмәскә соң! Сүзе бар, районның тигез кара балчыклы колхозларыннан ни сорасалар, болардан да шуны ук сорыйлар, ә хуҗалык үзе, Тукай әйтмешли, бара «абыныр-абынмас».

Ә моннан җиде-сигез еллар элек... Дөрес, мондый бай табигать кочагында утыручы авыллар ул чагында да корып калганнардан булмаган. Казлары да, кызлары да үсә торган. Казларын суя, ашый торганнар, кызлары буй җиткч белән кияүгә чаба булган. Әлбәттә, торып-ныгып калганнары да күп, әмма дөнья булгач арада шундый ук иләслек белән йөгереп этисе өенә кире әйләнеп кайтучылары да булгалый торган.

Шундыйлардан берәрсе түгелме икән әле, әнә нечкә билле, җиңел сөякле берәве, кичкә каршы һичнидән шикләнмичә, япа-ялгыз Ык буена таба төшеп бара. Адымнарны тиз тезә, аягы тигән җиргә тия, тимәгән җиргә тими. Тукта, игътибар итик, бераз баргач, нидер тыңлагандай, туктап, тынып калды бу. Ахрысы, Ык буендагы казлар тавышына сагаеп колак салды булса кирәк. Аннары янә китте, хәтта адымнарны тагын да ешрак тезә башлады. Барган шәпкә кулындагы чыбыкны селтәп, сукмак буендагы ялгыз әремнәрнең, алабуталарның башларын кыйгалап төшерә. Әле ярый, алла саклаган, синең яки минем баш ул чыбыклы чибәр бара торган сукмак буенда тәгәрәп үсмәгән, әгәр шулай булган булса, белмәссең, җиңел кулдан безнең башны да кыеп төшерергә күп алмас иде.

Чынлыкта исә болай селтәнүе дә җирендә икән шул. Башка бөтен кешеләрнең дә казлары, кич җиткәч, бүксәләрен тутыргач, тәүфыйклы рәвештә өйләренә әйләнеп кайтканнар. Ә боларныкы, көн белән төнне аера алмагандай, кайдадыр адашып калган. Ә бит Ык буендагы әрәмәлекләрдә бүре, төлке ише ерткычлар да сирәк кунак түгел. Төнгә каршы казларыңны анда калдырсаң, төн чыкканчы берме, икеме бәбкәсеннән колак кагуың да мөмкин. Аннары тагы көзге мәлдә бу якларга ау сылтавы белән төрле яклардан чит-ят кешеләр дә килеп чыккалый, киеккошларга тидерә алмаган ачудан аларның да, төн карангылыгында белмәмешкә салышып, синең кайтмый калган тәүфыйксыз казларыңны чүкеп алулары мөмкин. Ни генә булмас дисең бу иксез-чиксез дөньяда. Дөресрәге, узып кына китүчеләргә «дөнья җәннәте» булып күренә торган бу «Алсу алан» тирәләрендә!

Шулай да чыбык селтәп баручы ул ачулы хатын-кызның, казларын суда исән-сау күрү белән үк, ачуы басылды, чыбыгын читкә атып бәрде, ярда, беравык нидер уйлагандай, тынып калды. Як-ягына карангалап, тирә-юньдә кеше яки бүре-әхрәт юклыгына күңеле тәмам ышангач, казлары белән бергә үзе дә бер йөзеп карарга булды, ахры, өстен үк чишенә башлады.

Озак та үтмәде, аның чупылдап суга сикергәне ишетелде. Казлары, бу тамашага гаҗәпләнешкәндәй, үзара каңгылдашып куйдылар. Тын су буе бер мәл җанлана төшкәндәй булды. Вакыт көзгә авышкан, төнгә каршы су яхшы ук салкынча иде, югыйсә. Ләкин, бер тәвәккәлләгәч, салкынлык белән исәпләшеп торамы соң шундый кызу канлы замана кызы. Бераздан инде ул, каерып колач сала-сала, каршы ярга таба йөзеп бара иде. Ярга чыгып җиткәч тә, туктап ял итеп тормыйча, кире бу якка борылды — бер су күрсә, хәер, бу җаный үзе дә казларыннан болайрак йөзә икән. Шуннан, әйтик, әрәмәлек арасыннан искәрмәстән генә ике аяклы бүре килеп чыкса соң! Күрәсең, инде ул мондый хәвеф-хәтәрдән куркып торуларны узган, бер рәхәтен сизгәч ике дә уйламый, тәне суда, озын чәч толымнары, сүгелеп, су өстеннән сибелеп ага... Хәер, бу иркен дөньяда кемдә кемнең нинди эше бар? Йөзәсе килде Ыкта — әнә йөзә. Җырлыйсы килсә, чыккач менә кычкырып җырлап җибәрер. Торасы килмәде күрше авылда кияүдә, йөгереп үзенең туган авылына — Баланлыга кайтты. Белмәгән кеше белеп торсын, ул сиңа «иске тормыш калдыгы» түгел, ул Ык буендагы кошлар кебек иреклe. Үзенә үзе хуҗа. Кияүгә киткәндә дә үзенә үзе хуҗа иде, кияүдән кайткач та үзенә үзе хуҗа. Ләкин шулай да ул «ирекле кош» белеп житкермәгән һәм хәлне шактый ук катлауландыра торган әкәмәт бер чынлык бар: ничек кенә

ирекле кош булмасын, аның оясы агач башында-җилдә түгел, аның оясы җирдә булырга тиеш. Чөнки ул кеше. Шуның өстенә, тагын аның, әгәр карап йөрмәсә, соныннан үз башына бәла булып төшү ихтималы булган чибәрлеге дә бар. Боларның барысы турында да уйларга тиеш иде ул, югыйсә.



## Ахунҗанов ике ут арасында

Ә моннан алты-җиде еллар элек... Баланлы авылын һәм шул тирәдәге берничә кечкенә авылны берләштергән «Алсу алан» колхозы, районнарны әле алай, әле болай бүлгәләү нәтиҗәсендә, Ык буе районнарының берсеннән икенчесенә күчә. Һәм, әйтергә кирәк, хуҗалык ягыннан тарткау булуы аркасында, берсен дә әллә ни шаккатырмый. Читтә, урманнар, чокыр-чакырлар арасында «онытылып калган» бу колхозда, аптырагач, бияләй алыштыргандай, председатель арты председатель алыштырырга тотыналар. Сидоров, Салахов, Кадерматов, Һадиев — болар менә булыр-булмас бер ел эчендә председатель урындыгын җылытып, кирәккә-кирәкмәскә кычкырынып йөреп, алай барып чыкмаса, үзләре чабып, кыскасы, матур-матур вәгъдәләр һәм өметләр белән килеп тә, эшне җайга сала алмыйча китеп барган «бер көнлек хәлифәләр» булалар.

Кемнедер корбан итеп чалулар, икенче берәүне райүзәккә чакырып «эшкәртеп җибәрүләр», яки райүзәкнең үзеннән вәкил җибәреп, «галстугы белән билен будырып», чыбыркы шартлатып йөртүләр белән генә эшне төзәтеп булмаслыкны төшенеп, яңа районның яңа җитәкчеләре, ниһаять, ныклап уйлана башлыйлар. Һәм менә монда шобага шул районның гади бер авылында карт әнисе, хатыны Хәдичә һәм аннары берсеннән-берсе кечерәк, берсеннән-берсе гаугалырак дүрт баласы белән мәш килеп яшәп яткан утыз дүрт яшьлек Ахунҗанов Сәлим башына төшә. Ник бүтәнгә түгел, ник нәкъ менә Ахунҗановка дисәкме? Моның аңлатмасы ул кешенең үзе белән үк: Ахунҗанов — үз колхозында бригадир булып та, парторг булып та эшләгән кеше. Ахунҗанов — яхшы механизатор, техниканы белә, беренче класслы шофер. Өмет баглата торган иң ышанычлы ягы: Ахунҗанов, яшь булуына карамастан, кешеләрне, тормыш рәтен белә. Шунлыктан булса кирәк, авылларында аны танып-яратып өлгергәннәр һәм, әлбәттә, мондый кешене район җитәкчеләре дә күреп алганнар, күздә тотканнар булса кирәк. Шулай итеп, җайнең көзгә борылган бер чорында, өенне рәтләп, балаларының өстен-башын карап, утын якларын кайгыртып, кышка әзерләнәсе бервакытта, үзе һич аны-моны уйламаганда, Ахунҗановны райкомга чакыртып алалар.

— Утырыгыз, иптәш Ахунҗанов,— дип, аяк өсте торып каршы ала аны райком секретаре Мөхәммәдьяров. Шунда ук райбашкарма комитеты председателе Хәсәновның да булуын һәм райком секретаре хәтле райком секретареның үтә ачык йөз күрсәтеп каршы алуын күреп, Сәлим Ахунҗанов эшнең уен түгеллеген чамалап ала: «Юк, бирергә түгелдер. Бирергә булса, болай кыланмаслар иде, нинди дә булса берәр эш кушаргадыр»,— дигән уй үтә аның күңеленнән. Ләкин серне бирми. Тәкъдим ителгән урынга тыныч кына килеп утыра, «Мин сезне тыңлыйм, иптәш Мөхәммәдьяров!» дигәндәй, күзләренә карый.

Секретарь үз чиратында Хәсәновка күз ташлап ала, берьюлы эш турында сүз башларга ашыкмыйча, уйный-көлә әйткән булып сүз башлый:

— Безгә, кем, иптәш Ахунҗанов, газеталарның баш мәкаләләрендә язылганча, бер-беребезгә гел генә фамилия белән эндәшү килешмәс. Иң

әлек шуны белеп китик: исемнән чыккан, әтиегезнең исеме ничек әле сезнең?

Күзләреннән күреп тора Ахунҗанов: белә ул моны, белә торып, юри сорый — белгәнне янә бер кат ачыклап китүне кирәк таба, күрәсең. Димәк, чакыртып алулары тикмәгә түгел, бу хәтле тәфтишләп тору тикмәгә буламы соң! Бик үк очынма, егет, шулай үк зря генә мәлҗеп төшәргә дә ашыкма.

Секретарь куйган сорауга Ахунҗанов үзе түгел, райбашкарма комитеты председателе Хәсәнов җавап бирә:

— Бик озын аның имя-отчествосы, телеңне сындырырлык: Сәлимҗан Садриҗиһанович. Үзе дә шуны сизеп эндәшми утыра торгандыр әле. Шулай ич, Ахунҗанов?

Ахунҗанов аны-моны әйтеп өлгергәнче, сүзне тагын секретарь ялгап китә:

— Ә без аны, әгәр үзе каршы килмәсә, русына-татарына момент аңлашыла торган итеп, кыскартып, Сәлим Садриевич дип кенә йөртербез. Эш кешеләренең — безнең алай озак сузып торырга вакытыбыз юк. Минем болай дуамал гына «кисеп ташлауга» үзегез каршы түгелдер ич, Сәлим Садриевич?

Шунда шул, күрәчәккә каршыдыр инде, Ахунҗанов авызыннан да җор сүз ычкына:

— Миңа ни... ник шунда «Чүлмәк» дип йөртмисез, бары тик кызу мичкә генә илтеп тыкмагыз.

— Нәкъ менә кызу мичкә илтеп тыгарга җыйналабыз да без сезне, иптәш Ахунҗанов.

Секретарьның тавышында баштагы уенчанлык шундук югалды һәм ул, җитдиләнгәннән-җитдиләнә барып, «Алсу алан» колхозының аянычлы хәлдә калганлыгын кыска гына итеп аңлатты да, җилкә кашып торырга һич вакыт калдырмыйча, шундук тәкъдимен дә ясады:

— Без менә бюро члennары белән уйлаштык та сезне шул колхозга председатель итеп тәкъдим итеп карарга булдык. Сайлау-сайламау, әлбәттә, колхозчылар эше. Әгәр сайлый калсалар, без ышанабыз, партия сезгә ышана, иптәш Ахунҗанов, сез ул йөкне тарта алырсыз бит?

Сүз башлангандагы кебек, бераз хәйләкәрлек кушып, салпы ягына салам кыстырыбрак торсалар, авыл тумасы, хәйләкәрлекне Сәлим үзе дә белә, җавабын, койрыкны тоттырмау ягын, әлбәттә, тапкан булыр иде. Ә менә болай кистереп куйгач, партия исеменнән үк тотынгач, ул телсез калды. Эшнең уен түгел икәнлеген берьюлы сизсә дә, каршы килеп, ни дә булса әйтә алмады.

— Бәй, мин ул «Алсу алан» якларын ишетә генә беләм, алар мине ишетеп тә белми торганнардыр. Белмәгән-күрмәгән якка... ничек булыр икән соң ул? Ни дип әйтергә дә белгән юк,— дип, авыз эченнән бутка пешерергә тотынды бераздан. Чынлыкта исә бу зур эшне үзенә тапшырырга торулары, аны шул эшкә лаек санаулары өчен ул, икеләнү катнаш, горурлык хисе дә кичерә башлаган, ләкин шул ук вакытта өйдәгеләр: дүрт балалы Хәдичәсе, моңа хәтле беркая да чыкмаган, инде үлем якасына якынлашып килгәндә, туган нигезен ташлап китәргә, әлбәттә, риза булмаячак карчык әнисе турында уйлап, яхшы ук аптырап та калган иде.

— Бүген үк дигән кеше юк. Бүрегең белән киңәш. Бүректән дә бигрәк, өйдәгеләр, инәең, җәмәгатең, бала-чагаң белән сөйләш,— дип, аның уйларын белгән кебек, өстәп куйды секретарь. Шундук барлык икеләнүләрне күмеп китәрлек ачыклык белән болай дип тә өстәде:— Мәсьәләнең җитди икәнлеген без дә чамалыйбыз. Эшләргә кирәк булачак һәм, әлбәттә, семьяны да таркатмау кирәк. Кыскасы, Сәлим Садриевич, барысын да уйлап, өйдәгеләрең белән киңәш-табыш итешеп килү өчен сезгә өч көн срок бирәбез. Бүген менә дүшәмбе...

Секретарь өстәл календаренең битләрен ачкалады, берсенә билге салды.

— Җомга көнгә хәтле уйлашып-киңәшеп өлгерерсездер бит?

— Сез болай, үзегез бик атеист кеше булсагыз да, татарның җомгасын онытмаган икәнсез әле, Камал Шагиевич,— дип кыстырып куйды Хәсәнов һәм бу шуклык урнашып өлгергән тартынкылыкны чак кына бушатып җибәргәндәй булды.— Җомга башланган эш хәерле була, дип әбиләр элек?

— Тем более, әбиләр дә безнең яклы икән, алайса,— дигән булды Мөхәммәдьяров, шуклыкка каршы шуклык белән. Һәм, сүзнең хәзергә шуның белән беткәнлеген аңлатып, аякка калыкты. Моннан соң чыгып китәргә дә мөмкин иде инде, ләкин Ахунҗанов, ишеккә барып җиткәч, чыкмыйча, чак кына тоткарланып калды. Аның нәрсәдер әйтәсе калган кебек күренә иде. Моны шундук сизеп алган секретарь:

— Сезнең әйтеп бетермәгән сүзегез бар кебек, Садриевич. Әйтәсе сүзегез, аргументларыгыз калган булса, барысын да әйтеп бетерегез. Әле соң түгел,— дип, аңа якынлаша төште. Ләкин Ахунҗанов күңелендәге икеләнүләрне әйтүне кирәк тапмады. Чөнки өйдәгеләр белән сөйләшеп карамыйча, күңелендәге шикләрен селкеп, секретарь алдында мәлҗеп торуны урынсыз саный иде. Хәлбуки, өйдәгеләрнең бу зур эшкә каршылыксыз гына риза булуларын ул башына да китерә алмый иде.

— Әле муеннан батканчы өч көн вакыт бар, саламга ябышырга ничек тә өлгерербез,— диде ул, сер сынатырга ашыкмыйча.

— Батарга түгел, бата башлаганны чыгарырга, Сәлим Садриевич,— диде секретарь, аның кулын кысып. Һәм иптәшләрчә кисәтеп куюны кирәк тапты: — Моны алдан ук сөйләшеп керешик.

— Сөйләшәсе кешеләр әле булыр, үзем белеп торам, Камал Шагиевич.

Бу — Ахунҗановның хәзергә соңгы сүзе иде һәм ул, кабинетның авыр ишекләрен җиңел генә ачып, чыгып китте. Аның бу кискенлеге, сүзне вакытында өзә белүе секретарьга ошады. «Бу ир-егет, чын-чынлап тотынса, эш чыгарачак», дигән уй үтте аның күңеленнән.

## Тышта җил, өйдә буран

Бергә утырып килгән авылдашларының район учреждениеләрендә эшләре бетмәгән булып чыкты. Алар җаен җайлап һәм, бер уңайдан, олы улына тун туры китереп булмасмы дип, магазиннар ягын чамалабрак йөргәндә, обедка кайтып баручы Мөхәммәдьяров аны янә очратты.

— Өч көн күп түгел, Сәлим Садриевич,— дип сүз башлады секретарь, уенын-чынын бергә кушып,— сез тизрәк өегезгә кайтып, семьягыз белән әлеге эш турында сүз башларга ашыксагыз икән.

Ахунҗанов авылдашларының җаен көткәнлеген әйткәч, Мөхәммәдьяров шундук тәкъдимен дә ясады:

— Мин сезне авылыгызга үз машинамда озатып куярга әйтермен. Хәзер менә тамак кына ялгап килим дә...

Секретарь хәтле секретарь үз машинасын тәкъдим итеп торгач, сүзгә урын каламы соң! Аннары икенче яктан да шәп булып чыкты: әле хәл ителмәгән эш турында кызыксынучан авылдашлары алдында капчык авызын чишеп торырга туры килмәячәк. Хатын алдында да берьюлы базар күтәреләчәк: райком машинасында дөбердәп кайтып төш әле син! Чынын гына әйткәндә, үзе өчен ул инде бу эшне хәл ителгәнгә саный. Партия шулай кирәк таба икән, яшь партия члены, ул инде әлбәттә, каршы килә алмаячак. Аннары бу эш күңелне дә ничектер җилкендереп тора, яңа — зуррак кулда йөзәргә туры киләчәк бит, канаткаурыйлар чыдармы, көч-куәт җитәрме? Шул ук вакытта өйдәгеләрнең

бу эшкә ничек караячагы да аның өчен хәзергә әле табышмак иде. Әни карчык риза булмаячак та булмаячак — гомер иткән, картын кабергә озаткан нигезен ташлап, әллә кая, чит-ят авылга күчеп китәме соң? Хатыны Хәдичә болай үзе дөнья күргән кеше кешелеккә. Совет мәктәбендә укыган, комсомолда тәрбияләнгән, үзе дә колхоз эшенә катнашкан, заманында тракторда да эшләгән, анда инде «бусы — үз авылым, бусы — үзгә авыл» дип торырга туры килмәгән, кайсы авылда эшләргә кушсалар — шунда эшләгән. Сәлимен яратып тора, шәт, тартәгә типмәс. Ә тартәгә типмичә генә ризасызлык белдерсә? Муенына мунчак салдырган кебек кенә ияреп китсә?

Шундый каршылыклы уйлар белән, әмма шулай да машинаны капка төбенә чаклы ук китереп җиткермичә, колхозда карыйсы эшләрен карап, өенә кич кенә кайтып керде ул. Балаларның олыраклары әле уеннан кайтып җитмәгән, ике яшьлек Хәлил аны-моны чамалаудан ерак, әни карчык намазлык өстендә — икенде-ахшам намазын башкара, күңелендә дөнья гаме түгел, Ахунҗановка аптыраткыч беренче сорауны бирүче, әлбәттә, хатыны Хәдичә булды.

— Мә, тиз генә аягыңа киеп куй,— диде ул, иренә җылы оекбашлар китереп. Шул арада үзе болай гына кызыксынган, ир эшенә тыкшынырга һич теләге юк бер кыяфәт күрсәтеп сорап та куйды:

— Ник чакырганнар соң?

— Бар инде шунда, дөнья булгач бетәмени.— Ахунҗанов тиз генә чишелеп ташлауны урынсыз тапты булса кирәк, бу очракта бераз күпертүне дә хәрамга санамыйча, тезәргә тотынды:— Кичкә каршы яман әче җил чыкты, туңдым, ачыктым, ардым, бөтенесе бергә. Тизрәк ашыңны-чәеңне өстәлгә куй.

Табын янында да әллә ни җәелеп китмәде, сөйләшмичә генә ашадыэчте. Ашап туйгач, бәләкәй улы Хәлилне тез башына утыртып сөйде. «Да, бар иде, улым, әтиең-артистның «Галиябану»дагы Хәлилне уйнап, Мәргәнтауны дер селкеткән чаклары. Бар иде!» — дип, хатыны Хәдичәгә һич югы «җеп очын» гына булса да сиздерергә тырышкандай, тирән генә бер көрсенеп куйды. Ләкин Хәдичә бернигә дә игътибар итмәгәндәй күренергә тырыша, өстәлдән савыт-сабаны җыя, балаларының — әле берсенең, әле икенчесенең — көндез күрсәтеп өлгергән егетлекләрен, әйткән кызыклы сүзләрен җиткереп, шатлыгын ире белән бүлешмәкче була, ләкин ире тарафыннан әллә ни уртаклашу, очыну күрмәгәч, шундук анысы да телсез кала иде.

Шул көнне килгән район газетасына аннан-моннан күз төшергәләп алу белән, Ахунҗанов хатынына урын җәяргә кушты.

— Бернәрсә дә күземә күренми, арылды, әнисе,— диде ул, болай иртә куначкларга җыенуның сәбәбен аңлатырга бик ашыкмыйча.

Балаларның зурракларын, җылырак-мамыклырак булганы өчен, аш өендә — әбиләре янына түшәп салып, үзләре янына яңа өйгә әлеге шул кадерле Хәлил төпчекне генә алалар иде. Ә бу кичне Ахунҗанов, сөекле төпчеген дә йокы алдыннан тезенә утыртып бер сөю белән чикләнеп, нишләптер, җылырак, мамыклырак өйдә — абыйлары һәм апасы янында калдырырга кушты. Димәк, әти кешенең бүген аеруча аулакта каласы килде булса кирәк...

Әлбәттә, бер тын дөнья сүзләрен катнаштырмый тору кирәк булды — кемдә генә булмый андый хәл. Алда зур сүз көткәнлектәнме, Ахунҗановка бу кичне Хәдичәсе аеруча сөйкемле, илгәзәк, күенга үлчәп яралган кебек нәфис булып күренде һәм, шунлыктан, кузгатылачак зур сүз аны аеруча куркыта, ул көтә, хатыны үзе берәр ничек башламасмы, дип көтә иде. Хатыны башламый да, шул ук вакытта дөнья мәшәкатеннән арган-алҗыган кешеләргә хас сәламәт йокы белән изрәп йоклап киткәне дә сизелми иде.

— Ник берсүз дә дәшмисең? Сорамыйсың, апаем? — дип, аптырагач үзе сүз кушты Ахунжанов һәм, хатынын үзенә табарак тартып алып, бала-чага ишетү ихтималы булмаса да, пышылдап ялгап китте: — Алайса, тыңлап тор, мин үзем сөйлим. Бая куйган соравыңа җавап булсын, әйтим: бик зур эш йөкләргә торалар җилкәгә, инәкәйгенәсе. Йомшак җаеп, каты утыртырга маташуларымы, элек мактадылар: фәлән дә төгән, зря дә шәп, ышанычлы, бик тә булдыклы кеше икән ләбаса синең бу картың, инәсе... Тагын шуны да китереп куш: райком секретаре, бер-ренче үзе үз машинасына утыртып Мәргәнтауга хәтле озаттырды. Кешедән уңайсызланып кына борып җибәрдем машинаны авыл башыннан.

Хәдичә бу сүзләргә ни дип тә җавап бирмичә тыңлап яткач, Ахунжанов уратып торуны кирәксез санап, турыдан-туры әйтеп бирергә булды. Пышылдауны онытып, шул ук вакытта тавышын да күтәрмичә, чишеп салды:

— Райком мине «Алсу алан» колхозына председательлеккә димләмәкче. Мин, конечно, әлегә ачык кына бер җавап та бирмәдем. Ә җавап бирмичә булмас, рас райком шулай китереп куя мәсьәләне.

Хәдичә: «Үземнеке син! Димләмичәрәк торсыннар!» — дигәндәй, ире куенына елышарак төште, ләкин тел кузгатып ни дә булса әйтергә — хәбәрне хуплап алырга да, чәчрәп каршы чыгарга да — ашыкмады. Бер мәл сүзсез генә яттылар. Бу сүзсезлек, хатынның, беренче кавышу кичәсендәге кебек, сулышын еш-еш алып, кочакка сеңгәннән-сеңә баруы ирне бер үк вакытта изрәтә һәм шик-шөбһәгә дә сала бара иде.

Ниһаять, түземлеге бетеп һәм шул ук вакытта инәлгәндәй итеп, кабаттан кузгатты Сәлим:

— Миңа синең сүзең кирәк, Хәдичә. Әйт, син ни әйтәсең, мин шулай эшләячәкмен.

Шулай диде дә үзе эченнән генә уйланып калды: әлбәттә, әйтергә генә җиңел алай дип. Аны барыбер сындырачаклар. Райком хәтле райком тотынсын да, имештер, башлаган эш ярты юлда тукталып калсын. Шул ук вакытта, хатыны Хәдичәнең сүзсезлеге дә борчый иде. Һич югы, каршы төшеп булса да берәр сүз әйтсен иде. Ниһаять, тагын бер, бу юлы инде ачуланыбрак эндәшеп карады:

— Ник телеңне йоттың? Әллә йоклап та киттеңме?

Тагын беравык борчулы тынлык дәвам итте, һәм шуннан соң Хәдичә, берничек уйларга да юл калдырмый торган тоныкһәм басынкы тавыш белән:

— Кайда соң ул «Алсу алан» дигәннәре? Ишеткәнем дә, күргәнем дә юк,— дип, сораүга каршы сорау белән җавап бирде.

Ахунжанов өчен хәзергә бу чаклысы да ярап куйды, телен тешләп эндәшми торуга караганда, ничек тә бер сүз иде бу. Хәтта ул моны: «Ярар, бик орып бәрелмәде, күнми булдыра алмас!» дип, үз файдасынарак юрап куярга да өлгерде.

Юрап куйды һәм, эшнең җитди торуына хатынны ныграк ышандырырга тырышып, райкомда булганнарны, райкомда әйтелгәннәрне түкми-чәчми, ятышлырак чыксын өчен кайберләрен хәтта чак-чак кына күпертә дә төшеп, тезәргә тотынды:

— Һәй, апаем-җаным, каршы килеп карамадым түгел, аягына баскан, түшенә шуган дүрт бала, дип санап күрсәттем, берсе быел мәктәпкә йөри башлады, мин әйтәм, аның укуын бүләбезмени, уйлап карагыз, дим. Уйлап куйганнар, апаем, райком кешеләренең сүзе безнекенә караганда очлырак чыга: «Анда да Совет власте, мәктәп анда да бар, курыкма!» — диләр. Алай барып чыкмагач, инәй карчык итәгенә ябышып карадым: «Әнә, кабер якасына баскан карчык белән үзегез сөйләшеп карагыз, мин әйтәм, житмеш алты белән бара, картайган көнендә нигез туфрагын алыштырырга риза булырмы? — Ул хәтлесен инде, иптәш Ахунжанов, синең үзеңә ышанып тапшырабыз, әниең синеке, ничек тә

уртак тел табарсыз,— дип авызны капладылар. Кыскасы, шул, Хәдичә: ачык җавап белән килергә өч көн срок бирелде, уйнап сөйләшергә вакыт юк.

Бу «сайраулар» белән генә хатыныннан ачык бер сүз дә ала алмагач, Ахунҗанов, тактиканы бераз үзгәртергә булып, борыны белән хатынының чәч арасына чумды:

— Әллә ислемай сөртеп яткансың, төлке. Болай да баш чуалган бер чакта чәчеңнән ислемай исе аңкып башны әйләндерә,— дип мәтәштереп карады. Ләкин Хәдичә ире әйткән яңа хәбәрне күңеленә үтә җитди алган, аны юк-бар сүзләр белән генә шаккатырып булырлык түгел иде. Иренең кич буена әйткән бөтен сүзләрен — җитди сүзләрен дә, иркәләүләрен дә — дәшми-тынмый гына тыңлап ятканнан соң, ул кинәт, ирен аптырашта калдырып, көтелмәгән нәтиҗә чыгарып куйды:

— Райком юлын мин дә беләм,— дип башлады ул, бер дә тавыш күтәрмичә генә,— барып, үзем үз телем белән сөйләшеп карармын: партия члены дигәч тә, ирне хатыныннан, бала-чагасыннан, карчык анасыннан аерып, әллә кая, җәһәннәм астына олактырырга дигән закон юктыр. Булмаска тиеш андый закон.

Чынлап та шулай эшләрме — хәер, ул чаклыга ук барып җитәр дип ышанмый иде Ахунҗанов,— әллә өркетүе генәме?

Бу чаклысында бәхәскә кереп тормастан, эшләнәчәк эшләрнең барысын да иртәнге көнгә калдырып, икенче ягына әйләнеп ятты һәм шундук изрәп йоклап та китте.

## Киенде, җыенды, әмма китмәде

Иртәгесен Ахунҗановлар өендә әкәмәт хәлләр булып алды. Иртә торып үзен тәртипкә китерүгә үк, Хәдичә, тәртәгә дә тибеп түгел, шулай ук бик эреп тә китмичә, каенанасы Мәгъмүрә карчыкка:

— Әнкәй, балаларны йортта бүген синең карамакка калдырам, минем барасы җирем бар,— дип, юлга җыена башлады. Барысы да бер мәл аптырабрак калдылар. Бәләкәй Әнисә:

— Инәй, мин дә синең белән барам,— дип, итәккә килепябышса да, йомшаганы сизелмәде әни кешенең. Баланы сүзсез генә күтәреп алды да олыраклары янына илтеп куйды. Еларга авызын кыйшайта башлаган кызчыкны әтисе күтәреп алды.

— Елыйсы түгел, нәнәм, зур үскән кыз ич син, абыеңның иңбашына җитеп барасың, кичә генә үлчәнештегез,— шул ук вакытта ул эндәшмитынмый гына хатынын да күзәтә иде,— барасы җире булгач, тимик инәйгә, барсын. Безне сагынгач кайтыр.

Бала белән сөйләшкән атлы булып, болай юмалап торгач, Хәдичә үз чиратында шулай ук уңайсызланыбрак калды. Бер җыена башлагач тугарылып ташлау да әллә ничегрәк, шул ук вакытта кәҗәләнү чире дә басылмаган иде әле.

— Кайтырмы, кайтмасмы — анысын әле күз күрер.

— Һич югы, әйтеп сөйләш, әннәсе, кайчанрак көтә башларга булыр сине? Без монда самовар куеп, аш пешереп торыр идек.

Иренең болай теленә салынуы хатынның канын кыздырды. Күңеленнән: «Кузгалган-кузгалган, әллә барыргамы? Кызык итәргәме бу чукынчыкны. Тора торгач безне ташлап, икенче авылга олагырга йөрмәсен».— дигән тупас кирелек үтте Хәдичәнең күңеленнән. Шунда ул, ялгыш кына күзе төшкән атлы булып, бер читтә бала күтәреп торган иренә текәлебрәк карап куйды: әле юынырга да, чәчен тарарга да өлгермәгән Сәлиме, никадәр генә уйнап-көлеп сөйләшкән кебек кыланмасын, ничектер тар-

калып калган һәм, әнә шул таркалып калган хәлендә, моңарчы һичбер вакытта да күренмәгәнчә, чибәр, якын, жан-дус булып күренә: әнә аның, хәзергә әле таракка чират житмәгәнлектән, берсе чәршәмбегә, икенчесе дүшәмбегә торып баскан куе кара чәче, әнә аның тигез ак маңгае, моңсу-тирән күзләре, бераз калынрак, ләкин кирәк чагында калынлыгы да, юкалыгы да сизелмичә Хәдичәнең кайнар иренендә эреп бетә торган иреннәре — юк, юк, аныкы Сәлим, сәламәт кенә булсын, Хәдичәнеке Сәлим. Бер жиргә дә китми, бу ояны, бу елтыр күзле балаларны ташлап китә алырмы соң! Шуна күрә Хәдичәнең каядыр «терәк эзләп» барырга жыенуы, әлбәттә, урынсыз. Райкомга барып ул нишли алыр, әгәр райком хәтле райком чынлап та шулай кирәк тапкан булса... Шулай да бер жилкенә башлагач тиз генә басыла алмый, иренең күңеленә вәсвәсә салу өчен генә булса да, үзенең бу көтелмәгән эшкә тыныч карап кала алмаганлыгын сиздерү өчен генә булса да, барган атлы булып күренәсе килә иде. Ахыр чиктә, анда райком өстәле артында утыручы дәү абзыйлар Ахунжановны белү белән генә чикләнмәсеннәр. Ахунжановны белү өстенә тагын шуны да белсеннәр: иренә карап туймый торган кара тутлы хатыны, Хәдичәсе, шул кара хатыннан туган елтыр күзле ак балалары бар аның. Ничек инде ул, тора торгач, дигәндәй?

Әбиләре Мәгъмүрә карчык моңа хәтле «кашык-аяк шалтыратуны» һич сиздермәгән йорт жанлы килененең бүген иртән болай жилъякланып каядыр жыенуын, ире белән дә тырт-пыртрак сөйләшүен күреп, бераз аптырабрак йөрсә дә, ир белән хатын арасына тыгылып, юкны-барны төпченүне кирәк тапмый иде. Килене, аңарга әйткән булып, ләкин сүзенең очлы ягын иренә тидерергә тырышып, янә башлады:

— Әнкәй, белмәсәң белеп тор,— дип башлады ул бу юлы, сүзләрен китаптан укыган кебек, бик ачык итеп,— безнең менә бу өйгә буйбирмәс Сәлимебез безне ташлап, әллә кая — жәһәннәм астына китәргә ризаланып кайткан. Имештер, райком шулай куша. Янәсе, аны «Алсу алан» колхозына председатель итеп куясылары. Күрәсең, начальник буласы килә малаеңның. Син дә, мин дә, балалар да бер тиен дә тормыйбыз булып чыга бу килештән.

— Бәй, мин сине танымыйм, Хәдичә. Әни алдында әллә ни әйттерерсең.

— Мин дә сине соңга калыбрак таный башлаганмын икән шул.

— Әле бит баскыч төбендә алмага килгән ат көтеп тормый, ник шулай кызарга?

— Ат заманы түгел хәзер. Машинага утыртырлар да алып китәрләр, дүрт балаң белән калырсың утырып.

Чынлап ачулануымы бу аның, әллә театр уйнавымы? Аера алмый азаплана Сәлим. Шул ук вакытта, нәкъ менә шулай тузынган чагында, Хәдичәсе аның бераз бала сымак күренә.— Тотып аласы иде дә артын чабәклисе иде. Чабәк соңыннан ук, бөтен кирелеген сытып чыгарганчы кысып кочакларга иде. Өйдә әни бар, томырылып карап торучы балалар бар, булмый алай тилереп. Мөмкин булганы — хәзергә аңлату-төшендерү эшләре:

— Әле бит, апаем, сүз кузгатып карау гына бу. Курыкма, мин үзем дә сикереп тормыйм, андагылар да башсыз кешеләр түгел, алдын-артын уйламыйча эш итмәсләр.

Бу кадәр тырышып, «аңлату эшләре» алып барганнан соң, Хәдичә чак кына басылырга тиеш иде, югыйсә. Һәрхәлдә, Ахунжанов хәзергә хәтле аны чынлап киреләнә дип һич уйламый, шул ук вакытта күңеленең кайсыдыр яшертен бер почмагы белән: «Ай-һай ла, чынлап киреләнсә генә ярар иде. Сыер дуласа, аттан яман, мина кузгалмый калырга бер сәбәп, Мөхәммәдьяров белән аяк терәбрәк сөйләшергә сүз булыр иде»,— дип тә уйланып алгалый иде.

Моңа хәтле иренең сүзләрен, «аңлату-төшендерү эшләрен» ишетмәгән дә кебек кыланган Хәдичәсе, киенеп-ясанып беткәч, Сәлимнең күңеленә чак кына көнчелек «тараканы уроләтү» нияте белән булса кирәк, килешмәгәнен белеп торганы хәлдә, кара тутлы битенә кершән-иннек тә сылап куйды. Инде кузгалгач, ишеккә килеп җиткәч, кинәт борылды да, бераз аптырабрак калган, ләкин шундый дуамал адымны ясар дип әлегә хәтле ышанып җитмәгән Сәлименә:

— Барам бит, малай, райкомыңа. Соңыннан, хатыныңны йөртәсең дип, үзеңне кызартмаслармы? — дип үчекләгән кебек, ак тешләрен елтыратып карап торды.

— Бар соң, райком ишеге бөтен кеше өчен дә ачык,— диде Ахунҗанов, урыныннан кузгалырга артык ашыкмыйча.

Шундый җилъякмы соң Хәдичә! Авызы тулы кара кан булганда да кеше алдында төкерми торган ир җанлы, семья җанлы, бала җанлы Хәдичә, шуның өстенә тагын, бәлки, алардан да элегрәктер, үз дәрәҗәсен үзе яхшы белүче, ире китә калган суратттә дә, ояны таркатмыйча, канат астында җылытып тотачагына нык ышанган горур җанлы бу хатын шулай вакланып йөрерме соң!

— Барыгыз әле, чыгып торыгыз, эттәгезгә сез югында әйтәсе сүзләрем бар,— диде ул, балаларын тышка куып. Каенанасы моны үзенә әйткән сүз дип тә аңлады. Бераздан алар — ирле-хатынлы — икәве генә калдылар.

— Ник туктатмадың? Ник, юкка йөрмә, дип аяк тибеп кычкырмадың?

Хәдичә, тиз генә чишенеп, өс киемнәрен кайсын кая атты да, балачага кайтып кергәнче дигәндәй, кабаланып, иренең күкрәгенә капланды, аны кысып кочып алды. Аның кара күзләрендә сизелер-сизелмәс кенә яшь елтырый, бусы инде театр түгел, бусы — тыеп калып булмаслык чынлык иде.

— Җүләрем син минем, картым син, үземнеке син,— дип, тыны бетәбетә кабатларга тотынды ул. Үзе, песи баласы кебек, иренең кочагына елышканнан-елыша бара иде.— Мин сине аяк тибеп кычкырырсың дип көткән идем. Гомер итеп бер кычкырганың да юк, ничек яшәмәк кирәк синең белән...

Бу берничә минутлык «тилереп алу», күрәсең, әлеге яңа хәбәрдән соң кинәт тартылып калган күңел кылларын бушату өчен кирәк булгандыр. Аннан соң алар алда торган эшнең җитдилеген икесе дә бердәй аңлап, ир белән хатын булып кына түгел, балалар атасы, балалар анасы булып, шул ук вакытта Сәлим Ахунҗановның партия члены икәнлеген дә истән чыгармыйча, салкын кан белән һәм кызмага бирелмичә сөйләштеләр. Ахунҗанов, әлбәттә, райкомга икенче барганда китерәчәк дәлилләрен дә әйтте — председатель булып китү аның күңелен алгысытса да, ул «Алсу алан» колхозының бик алай алсулардан түгел икәнлеген ишетә белә, әлбәттә, хәтфә палас җәеп куймаганнар анда. Шул якларын искә төшереп, егет эчтән генә шүрли, бер үк вакытта, китә калса, бу зур «ояны» ничек кузгату ягы да уйландырмый түгел иде.

— Кузгалган-кузгалган, син дә барып кайт иден райкомга, мин моны, билләһи, ихлас күңелдән әйтәм, Хәдичәкәем,— дип, сабыр гына әйтеп куйды Ахунҗанов бераздан,— миңа иптәш Мөхәммәдьяров алдында аяк терәбрәк сөйләшергә җиңелрәк булыр иде, әгәр син шулай дулап барсаң.

— Ә минем, бәлки, председатель хатыны буласым килә торгандыр,— диде тегесе, сүзне тизрәк уенга борырга ашыгып. Әле эш хәл ителмәгән, райкомда тагын бер сатулашып карыйсы бар, аннары икесен дә тынычрак карарга мәҗбүр итә торган икенче мәсьәлә дә бар: тәкъдим итү яки мактаулы Ахунҗановның теләү-теләмәве белән генә эш бетми, ин хәл итә торганы — колхозчылар: сайларлармы алар Ахунҗановны председатель итеп, юкмы?

Санаулы көннәр тиз үтеп китте. Ахунжановны тагын райкомга чакырып алдылар. Хәер, бу юлы инде ул озак сөйләшергә урын калдырмады — тәвәккәлләргә икән тәвәккәлләргә, райком синең белән уйнап сөйләшми торгандыр. Өйдәгеләре белән билгеле бер дәрәҗәдә уртак тел табылган, әни карчык бу эшне чынга алына торган эштер дип башына да китерми, вакытлы бер командировка гынадыр, «барыр да эшен бетергәч кайтыр» дибрәк карый, хатыны Хәдичә исә күңеленнән төрлесен уйласа да, хәзергә күнгән, яки шулай күренергә тырыша, дөнья күрмәгән кеше түгел, белә: райүзәктән председатель итеп колхозга күчерүләр яки, райүзәктә торып, бара-кайта председатель булып чабулар булмады түгел. Ире Ахунжановны район читендәге колхозга алып китүләренә дә Хәдичә әнә шундый вакытлы берәр чара гынадыр дип карый иде. Кем белеп бетергән, бәлки, бу эшне уйлап тапкан, кузгаткан кешеләрнең үзләренең күңелендә дә, еракта, күңелнең яшерен бер почмагында шундыйрак тирбәлү булмыйча калмагандыр: «Барсын, эшләп карасын, эш чыгара алмаса, аннан күз күрер...»

Ничек кенә булмасын, Ахунжановны «Алсу алан»га алып киттеләр. Әле ничек кенә алып киттеләр! Электә кияү егетләрен дә алай зурлап алып бармаганнардыр. Райбашкарма машинасында. Булачак председательнең бер ягында райбашкарма комитеты председателе Хәсәнов үзе бара. Икенче ягында районның производство бүлеге начальнигы Гыйлаҗ Саттаров.

Сөйләшеп бара торгач, көннең кичкә авышканын, шактый еракларга җәелгән «Алсу алан» басуларына барып житүләрен сизми дә калдылар. Машина тәрәзәсеннән карап, покоста килеш янып ята торган борчак теземнәрен, комбайн ташлап калдырган урында җыелмыйча җиргә ябышып калган вак-вак салам өемнәрен күреп баручы Ахунжанов эндәшмәс җиреннән:

— Чыкканым юк иде бу якларга. Бар икән әле, агаем, пошынмас колхозлар,— дип сузып куйды.

Саттаров белән Хәсәнов икесе рәттән утырган булсалар, ихтимал, сиздермичә генә янтыкларына төртешеп, ымлашып та алган булырлар иде. Шунда ук Ахунжанов чекерәеп утыргач, алар сүзне кыскарак тоту ягын каердылар:

— Баргач та өлгерерсең пошынырга, хәзергә без пошынгач шул житкән,— белән бетерделәр. Хәлбуки, хәзергә сүзне ул турыда куертмаска, сайланачак председательне башта ук өркетеп куймаска теләүләре булгандыр инде.

Әлбәттә, яңасын сайлау, элеккесен алып ташлау майлаган кебек кенә узмады, ай-һай ла, бик озакка хәтле төерләре чыга, терсәк очлары бәрелгәли торды. Турысын гына әйткәндә, әле хәзер дә чыга тора, бәрелгәли тора... Хәер, яшь булуына карамастан, Ахунжановның тормышны дөрес сиземләү куәсе бар, ул «безгә — бөтенесе нипочем!» кешесе түгел, эшне шома гына кузгатып алып китеп булмаслыгын алдан ук чамалаган, шуңа әзерләнеп килгән иде.

Колхозчылар, бигрәк тә идарә тирәсендәрәк чуалучылар, алдан ук беркадәр хәбәрдар иделәр, шуңа өстәп районның ике зур житәкчесе дә кодалый килгәч, сайлау алды һәм сайлау эшләре әллә ни зур шау-шу кузгатмады. Иң элек колхозның коммунистларын җыеп сөйләштеләр. Бу сөйләшүдә эндәшми калучылар да булды, сагаеп сорау бирүчеләр дә табылды һәм, бу эшне бик хуплап һәм форсаттан файдаланып, райком, райбашкарма исеменә мактау яудыручылар да булмады түгел. Арада тегеләй уйларга да, болай юрарга да урын калдыра торган итеп:

— Үзебездә мәйдан тотардай батыр чыкмагач, батырны күрше авылдан китерергә туры килә шул, батырга дигән сарык китсә китә инде, нишлисең,— дип, мәгънәле реплика кыстыручылар да табылды. Хуплаучылар һәм шул уңайдан районның «ерактан күреп эш итүче зирәк житәкчеләренә» рәхмәт яңгыры яудыручыларның берсе, бөтенесенең гажәпләнүенә каршы, элекке председатель Һадиев булды. Үзенең председатель булып эшли алмавы, моңа «грамотасы да, менәтерәк, кирәк чагында чыгарып сала торган сәләте дә житмәве» белән хәтта чак кына мактангандай сүзгә керешкән Һадиев, югарыдан килгән житәкчеләр алдында шулай да үзенең бөтенләй үк төшеп калганнардан түгел икәнлеген күрсәтергә тырышып булса кирәк, дәррәү кызып, халыкара политикага кереп китте. Американың Вьетнамдагы сугыш чукмарларына йодрык селкеде һәм, еракка китеп буталмас өчен, шунда ук үзенең Ык буйларына әйләнеп кайтып, район житәкчеләрен мактарга кереште, аларның «Алсу алан»дагы чын хәлне төшенеп, житәкчелек эшенә «иптәш Ахунжанов кебек яшь, энергичный, бөтен яктан грамоталы» кешене тәкъдим итүләре өчен үзенең шатланып бетә алмаганлыгын белдерде.

Сайланачак яңа председательне партком утырышында шулай кызыпкызып мактаган Һадиев, шуннан соң салкын клубка жыелган колхозчыларның гомуми жыелышында, бая сөйләгәннең киресен ычкындырганлыгын үзе дә абайлап житкермичә, берничә генә сүз әйтте, ләкин үзенчә берәгәйле итеп әйтергә тырышты:

— Район кушкач, кәнишно, без сайлыйбыз, сайларга обязан. Ну, иптәшләр, белеп торыйк: чебешне көзен саныйлар, дигән сүз бар халыкта.

Тамагы кипкән иде булса кирәк, шунда торган стаканны күрмәгәнгә салышып, графинны күтәреп су эчте, кузгалып урынына китә башлады, туктап һәм авылдашлары белән үз кешеләрчә шаярткандай итеп өстәде:

— Көзгә хәтле тилгән күтәреп алып китмәсә, кәнишно!

Бу сүзләрдә, аларның әйтелешендә Һадиевның тышкы бизәкләре югалган, ул шыр ялангач үзе, һәм председательлеккә тәкъдим ителә торган Ахунжановны өнәмәгәнлеге ачыктан-ачык ярылып ята иде. «Итәк астыннан ут йөртә торган кешегә охшый бу, белеп торыйк!» — дигән уй үтте Ахунжановның күңеленнән.

Һадиев кузгаткан жиңелчә-шук тонга бирелепме, әллә бу «председатель төшереп, председатель куеп» уйнауларга ышанычы беткәнлектәнме, урта рәтләрдән берәү торып, сүз сорамыйча гына, сөйләп китте:

— Мин үзем, жәмәгать,— дип башлады бу хәйләкәр крестьян, башын бер якка юри кыңгыр сала биреп,— бияләй алыштыргандай, прсидәтел алыштырулардан гына әллә ни чыгар дип уйламыйм. Прсидәтелләр киләләр дә китәләр, без үзебезнең көлсу туфраклы өзек-өзек «аю табаннарыбыз»да утырып кала бирәбез. Лучше мин, жәмәгать, болай итим, лучше мин бу «Алсу алан» колхозыннан үзем китим. Бирегез миңа шушы палнамочный жыелышта үз паема тигән жирне кисеп, мин күрше Вахитов колхозына күчәм. Анда, ичмасам, акчалата да түлиләр, әпәе дә күбенгәнче...

— Кайсы иңең белән күтәреп китмәкче буласың, Биктаһир абзый? Иңбашларың берсе биек, берсе тәбәнәк ич синең.

— Әсхапжамал апа сыерны бирмәсә, сөткә нишләрсең?

— Ерак жирмени, тиле. Кайтып, имеп китә.

— Сыернымы, Әсхапжамалнымы?

Шул рәвешле, бер тын «базар ясап», шаулашып алдылар. Шул ук вакытта эштән кайткан кешеләрнең бик сузасылары да килми иде. Районнан килгән «кодаларның» шактый ук пафоска бирелеп һәм яңа председательне һәр яктан мактап сөйләгән нотыкларын хөрмәт йөзеннән тавышсыз-тынсыз гына тыңладылар — бик үк ышанып та бетмәделәр, кире кагарлык дәлилләре дә юк иде. Ниһаять, сүзне туй башы кешегә —

Ахунжановка биргәч, бөтенесе зур игътибар белән тынып калды. Сынау да, сагаю да, кызыксыну да, кешегә сиздермәскә тырышып кына көнләшү дә бар иде бу тынып калуда. Ә иң көчлесе: «Тукта, алдан күп сайрама! Эшли алырбызмы? Нинди рәк кош син?» — дип көтеп калу бар иде. Нәкъ менә шуны сизгән кебек, Ахунжанов бик аз сөйләде. Кеше белән эшләмәгән кеше түгел, әйтәм дисә, сүзләрен тапкан булыр иде, югыйсә. Шулай да күп сөйләмәде, чак кына каушады да булса кирәк, ак йөзеннән дулкын-дулкын кызгылт таплар узды. Кыска гына «тәхет речен» ул үзе дә тиешенчә уйламаган һәм ул арада гына уйлап та булмаслык, күрәсен, кешеләргә ышанудан, ышанырга тырышудан туган самими иман белән болай дип очлады:

— Мин сезне өйрәтергә дип түгел, мин сездән өйрәнергә дип килдем, иптәшләр. Эшнең тоткасы сездә. Сез тырышып эшләсәгез, шуңа минем бәләкәй тырышлыкны да китереп өстәсәк, без колхозны хәзерге хәленнән ничек тә чыгарырбыз. Без чыгармыйча аны кем чыгарсын. Я, әйтеп карагыз.

Әйтеп караучы булмады, әйтергә әле иртә: берсе килә, икенчеләре аны тик каршылыйлар гына иде.

## Шул көнне кичен

Кеше күңелен кеше белеп бетерүе мөмкинме? Бер караганда, һич логикасы юк: төшкән председатель Һадиев тыкрык кына аерып тора торган күршен ягындагы Андрей дәдәйләр өендә ярыйсы гына табын әзерләткән. Әлбәттә, мине тотып атучы кешеләрне колхоз исәбеннән сыртларын ярганчы бер сыйлыйм әле, дип түгелдер инде! Күрәсен, «район агайлары» алдында шушы яктан гына булса да күренеп калыйм, бер файдалары тимәсә, икенче файдалары тияр, дию булгандыр. Кем белсен, «тәгәрәткән» ачудан, бәлки, үзенең дә бер сыйланып каласы килгәндер. Беренче планы ул көткәнчә барып чыкмады. Хәсәнов белән Сатторов, төнгә калуны, юлның бозык булуын сылтау итеп, Һадиевнын чакыруын кабул итмичә кайтып киттеләр. Китканче алар Һадиевны бер читкәрәк чакырып алып, кат-кат кисәттеләр, тату эшләргә, яңа килгән кешегә, эшендә булсын, тормышында булсын, һәрьяклап булышлык күрсәтергә куштылар. Һадиев үз чиратында: «Әйе, шулай! Кәнишно, сез әйткәнчә кирәк!» — дигәндәй, тыйнак кына баш селкеп торды. Ләкин, ай-һай ла, риядан гына булган икән бу баш селкеп торулар.

Дусларча сөйләшеп, киңәш-табыш итешкән, колхозчылар җыелышында мактау сүзләрен һич жәлләмичә тырышып-тырышып «кодалаган», мәсьәлә хәл ителгәннән соң да өлкән туганнарча арка кагып сөйләшкән, ярдәмләшеп торырга сүз биргән, кыскасы, шул аз гына вакыт эчендә иңләшеп, үз булып өлгергән «район агайлары» киткән юлларыннан китеп баргач, монарчы күрмәгән бу чит-ят авылда, чит-ят кешеләр янында көзге караңгы төнгә каршы ялгыз гына торып калу Ахунжановны бер мәл ике кулсыз иткәндәй булды. «Шулай ук булдымыни? Бу соң кире сүтеп булмаслык фактмыни инде? Кайсы баштан, кемнәр белән башларга соң бу зур эшне?» — дигән уйлар йөгереп узды аның башыннан. Дөресен әйтергә кирәк, килгәндә ул сайлау-сайлану эшенең болай ансат кына хәл ителәчәгенә ышанмыйчарак килгән иде, ә колхозчылар аңарга ышандылар, димәк, хәзер тартәгә тибәргә, әйле-шәйле уйларга урын юк, хәзер тик бер генә юл бар: җиң сызганып эшкә керешергә!

«Әллә җиң сызганып эчә башларгамы?» — дип тә уйлап куйды ул, эченнән генә көлеп. Чөнки Һадиевның, кешегә күрсәтмичә генә кай арададыр ирен чылатырга да өлгергән ул төшкән председательнең, һәм аның «яраннары»ның табын тирәсендә уйный-көлә мәш килүләре хәзергә эшнең шуңа таба барганлыгын ачык күрсәтеп тора иде.

[illegible], туганнар, әйдәгез, безнең яңа председателебез иптәш Ахунҗанов хөрмәтенә күтәрик,— дип, тост игълан итте Һадиев. Һәм эчеп җибәргәннән соң, Ахунҗановтан бүтәннәренә барысына берьюлы хәйләкәр караш ташлап, шаяртткандай күз кысты,— бик тә бугазны өтеп алды бу нәмәстәкәегез: әллә аракысы шулай әче булды? Әллә, Митрафан дәдәй әйтмешли, әпәй шүрлеге шулай әчи башлаган?

— Әллә председательлектән егылып төшү ачысымы икән? — дип, кешенең авырткан җиренә кагылды арадан берсе: усаллык белән түгел, дуслык белән, ләкин шулай да кырмыска оясын чак кына бер болгатып алу булды бу. Һәм таш нәкъ урынына барып төште.

— Егылып төшкән, башын тишкән, тишек баштан кайгы киткән,— дип, чак кына көйли-көйли кырлы стаканнарга аракы коюын белде Һадиев. Коеп чыкканнан соң, үз стаканын шундук кулына алып, өскәрәк күтәрде,— менә бездән соң килгәннәрнең башы тишелмичә күпмегә чыдар икән? Шуны карап торыйк без.

Һәм берәүне дә көтмичә, берәү белән дә чәкештереп тормыйча, дәррәү авызына чөйкәлтеп, голт-голт йотып та җибәрде. Моны табында утыручылар кем ничек аңлагандыр — ничек аңлау алар эше, әмма Ахунҗанов моны үзенчә аңлады: «Һадиев агайның теле чишелә башлады. Безнең баш тишелгәнне көтәргә исәбе!»

Болай уйлау аны кинәт айнытып җибәргәндәй булды, шулай ла беренче көннән үк араны артык киереп ташларга исәбе юк иде. Шул ук вакытта алты кырлы стаканнар да тик тормый, колхоз исәбеннән сыйланырга җай чыкканда кыстатып торуны кирәксенмиләр, агай-эне инде берсен-берсе макташырга ук керешкән иде. Ләкин Ахунҗановка килеп житкәч, аның алай тугарылып китмәгәнлеген күреп, уңайсызланыбрак калалар: яңа кеше белән арка сугып сөйләшүне, теге үзе эчмичәрәк утыргач, авызына ук коюны килештермиләр иде. Хәер, хәзергә әле ул «яңа кеше» дигәнебез мондагылар өчен капчыкка салып китерелгән песи кебегрәк иде: кара песиме ул, ак песиме? Тырнаша торганмы, май күрсәткәч, алам дип тыпырчынучы ач күзле комагаймы? Бу чаклысын белмиләр һәм, моны белмичә торып, артык якланып китәргә уңайсызланалар иде.

Мәҗлестә хөкем сөргән бу тартынкылыкны чамалап, Ахунҗанов сиздермичә генә чыгып сызу ягын карады. Ялгыз башы авылны карап йөрде, авыл башындагы ферма каралтылары ягына барып чыкты, тычкан утыдай гына ут күреп, терлек караучылар өенә сугылды. Кеше-карадан элек, каравылчылар алып барып иләштергән эт — Буян өреп чыкты. Эт тавышын ишетеп, йокыдан айныр-айнымас, каравылчы Хәтмулла карт та чыгып житте.

— Син кем буласың, апаем? Бер дә күзгә-башка чалынган әдәмгә охшамыйсың,— дип, гаҗәеп тыныч һәм бер дә исе китмичә сорау куйды карт.

— Керик әле, бабай. Танышу өчен ут яктысы яхшырак,— диде Ахунҗанов, бусагадан эчкә атлап. Хәтмулла карт сорашырга ашыкмады, шул ук вакытта бик алай калтырап та төшмәде.

— Ник алай хәйран калдың, апаем? Әллә безнең гүрнәчә сиңа бик ошамадымы?

— Әйе, бик алай шаккатар җирегез юк икән шул, бабай.

Почмак якта берничә җиреннән сүрүе ертылып, талкышланган саламы коела башлаган салам түшәк өстендә, малахай бүрекләренә күмелеп, ике малай йоклап ята, өй эче тәтәп утырган сукыр ут сөреме һәм мичтә пешкән бәрәңге исе белән тулган, әлбәттә, йоклап ятучы теге ике малай да бераз «хуш ис» өстәгән иде булса кирәк.

Сүзне нидән һәм кайдан башларга белмичә ишек төбендә тапганып торган Ахунҗанов, бабайга якынрак килә төшеп, ләкин аны өркетергә һич теләмичә, киресенчә, бик тә үз иткәндәй күреп, янә сүз башлады:

— Утыгызның җаны чыгарга тора. Төнлә терлек карарга нәрсә белән йөрерсез соң сез?

— Ә без вакытлы-вакытсыз чыгып, терлек-туарны мазасызлап йөрмибез, апаем.

Карт, артыграк ычкындырдым бугай дигәндәй, сүзен ашыгып төзәтергә булды:

— Әйтмәдек түгел, әйттек правленжәгә, ферма мөдире Шакирга да кабат-кабат җиткердек, лично үзем күреп берничә кат тукыдым, колакка элмәгәч, без аларны нишләтик?

Хәтмулла карт, нәчәлникләр өстеннән сөйләргә ярамаганны, соңыннан моның үз башына бәла булып төшәчәген сизеп булса кирәк, бераз ык-мык килеп торды, лампаның утын рәтләгән булды, йоклап ятучы малайларны күздән яшереп тору өчен, ике арадагы пәрдәне тартты. Тик шуннан соң гына, үзенең кирәк-кирәкмәсне ычкындырып ташлавы өчен үзенә-үзе ачуланган кебек, шактый кырыс тавыш белән сорап куйды:

— Ә син, апаем, гел әйтмәдең: үзең кем буласың соң? Бездән сораштырасың да сораштырасың.

— Колхозчыларның гомуми җыелышына бармаганлыгың күренеп тора, бабакай. Барсаң, мондый сорауны бирмәгән булыр идең.

Бактың исә, бүген кич колхозда шундый әһәмиятле җыелыш булганлыгын Хәтмулла карт бөтенләй белмәгән, бу турыда аңарга әйтүче дә булмаган икән.

— Әйткән булсалар, шөкер ходайга, барып, колак читен генә булса да салып утырган булыр идек,— дип, авыз эченнән мыгырданып куйды карт. Шундук, үзен тыеп кала алмастан, ихтимал, җыелышка дәшмәүләренә ачуы чыгыптыр, кырыс кына өстәп куйды:— Әйтсәм, туры әйтә торган алама гадәт бар минем, мөлким шуннан да шикләнүләре. Факт — җыелыш булганын менә синнән ишетәм.

Күрәсең, эшнең тикмәгә түгеллеген, кызыксынып сораштыручы бу төнге кунакның әлеге шул Хәтмулла карт катнашмаган колхоз җыелышында «өлгертелгән» берәр баш кеше булырга тиешлеген чамалап, картыбыз эчендәгесен бушатып калырга керешкән иде. Ә Ахунҗанов исә уйламаганда килеп чыккан бу очрашудан үзенчә нәтиҗә ясады: «Күрәсең, шулай тора икән монда эшләр, терлекләргә генә түгел, кешеләргә дә күз җитми икән кайчак!»

Авылны күзәтеп, анда-монда кагылгалап йөреп кайтканда, сәгать төнге унбер якынлашып килә иде. Бу Андрей дәдәйләр өе вакытлыча аның фатиры итеп тә билгеләнгән булганлыктан, аңарга инде кая булса да баш куярга да бик вакыт иде, югыйсә. Ләкин кунаклар таралышмаган, киресенчә, алар тәмам кызып җиткәннәр иде. Ахунҗанов ишектә күренүгә аны шаулап каршы алдылар.

— Син, яңа председатель, хәзер үк безне сангa сукмый башладың,— дип, болагайланып сөйләнә-сөйләнә, аңа каршы килде Һадиев һәм ишек төбендә Ахунҗановны тәкәллефсез рәвештә муеныннан кочып алды,— алай борын чөяргә ярамый, энекәш. Мин моны сиңа абзый кеше буларак и, әйтергә кирәк, яхшымы-яманмы, шушы алама колхозда сина хәтле байтак кына чиләнгән кеше буларак әйтәм. Ярамый алай борын чөяргә. Изгелек теләп әйткән сүзнең кадерен бел, егет.

Шулай да бу «изгелектән» тайпылу ул хәтле читен булмады. Кузгалмый утырган кунакларның мәлҗерәүләре, ә Ахунҗановның яңа тәэсирләрдән аруы чигенә җиткән иде. Җайлап кына гафу үтенеп, мәҗлесне һич бозмыйча, борылып чыгып китәргә мәҗбүр булды ул.

Инде урамда артык буталып йөрисе килми, чыгып киткәч, тагын әйләнеп кайтыр исәбе юк, авылның башка өйләрендә ут сүнеп беткән, чынлап та, баш кую өчен кайдадыр бер җылы почмак табарга бик вакыт иде. Озак аптырап тормады Ахунҗанов — беренче көннән үк аптырый башласаң, анннары башны элмәккә тыкмак кирәк. Барды да кичтән

... клубның ишеген тартып карады. Клуб ишегенә аркылы салынган тимер болай гына тыгып куелган булган икән, бер тартуга ук күгәне-йозагы белән суырылып чыкты. Шул арада клуб эче суынып өлгергән, ләкин талымлап торырга туры килмәде — вакыт соң иде. Яңа председатель клубның иске диванына башын куеп, чишенмәгән килеш, бу авылдагы беренче йокысына чумды.

## Күчәр башлары орына башлады

Яңа җирдә, иске диванда йокы тәмле булды булса кирәк, Ахунҗанов әле уянмаган да иде. Идарә йортын һәм клубны җыештыручы Фәриха, яктырыр-яктырмаста ук килеп җитеп, яңа председательгә иске председательдән кабинет ачкычы һәм идарәнең печатен тапшырды.

— Ничек инде бу, йокы да туймас борын? — дип шаярткан булды Ахунҗанов. Чынлыкта исә аның бер дә шаярасы килми, шаяртырлык сәбәп тә күренеп тормый иде. Киресенчә, иртә таңнан бик тә ачу китергеч факт иде бу.

— Шулай ансат эшләнә, алайса, сездә эшләр? — дип куйды аптырагач.

— Миңа ни. Бирергә кушты Һадиев абый, китереп бирдем.

Артык сөйләшеп торырга урыны да, кешесе дә түгел, күзен ертып аякка басуга, мондый күңелсез факт алдында калган Ахунҗановның озак сөйләшеп торырга теләге дә юк иде. Киемен каккалап киде дә тизрәк фатирына ашыкты. Андрей дәдәйләр инде торганнар, селкенәләр, ләкин йокылары ачылып җитмәгән, кичтән җыелмый калган табын тирәсендә, кайсы башыннан кагылырга белмәгәндәй, буталып йөриләр иде. Уйламаганда яңа фатирчылары кайтып кергәч, кинәт йокысы ачылып киткән карт, аптырау катнаш кызыксыну белән:

— Син соң кайда төн уздырдың, апаем? Әллә гел йокламадыңмы? — дип сорап куйды. Картына кушылып, карчыгы Дүсәй түтәй дә керәшенчәрәк тезеп китте:

— Икенче этәчкә кәтле утырдылар дөмегеп. Бер авызы тисә, безнең прастуй калык соң туктала беләме. Карыннары янар дип тә курыкмыйлар алагаемлар.

Ахунҗанов, тиз генә битен-кулын юып, өстен-башын тәртипкә китерде дә, болардагы тәртипне белеп житкермәсә дә, әллә кайчандагы үз кешедәй булып:

— Евдокия әби, миңа бер-ике стакан кайнар чәең булса, бүтән сыен кирәкми, — дип сөйләнә-сөйләнә, әлеге җыелып бетмәгән өстәл кырына килеп утырды.

Хуҗа карчыкның чәе өлгермәгән иде әле, аңарчы Андрей дәдәй юатып тормакчы булды:

— Монда менә калган нимәкәй дә бар, баш төзәтәм дисәң.

— Башның әлегә ватылганы юк, Андрей дәдәй.

Яңа фатирчы тотрыклы адәм күренә, бик алай күп сүзле дә түгел шикелле. Ә менә Андрей дәдәйнең, әллә кичтән салганныкы, сөйләшәсе, кемнедер мактыйсы, форсаттан файдаланып, кемнедер әләкләп аласы килә иде. Шулай гәпләшә-гәпләшә, яңа председатель белән үз кешеләрчә чак кына баш төзәтеп алганда да, әлбәттә, бик яраган булыр иде. Кешесе андый булып чыкмады бит, шайтан алгырысы. «Авызга үзе керергә торган сыйга арт куйгач, нинди прсидәтел бу? Озакка сузмаслар моны!» дигән уй үтте күңеленнән. Аптырагач, «тизрәк кыймылда!» дип, карчыгын тыкырдата башлады. Һич югы, шул яктан гына булса да, ирлекле, хуҗа кеше икәнлекне күрсәтергә кирәк ләбаса! Шул арада яңа председательгә киңәшләр бирергә дә өлгерә иде:

— Син, апаем, безнең күтәрәмгә калып бара торган «Алсу алан» колхозын аякка бастырырга дип килгәнсең икән, бастыр аякка, килеп чыксын бер тамаша,— дип, чишелеп китте карт. Күренеп тора: тел төбендә атылып чыгарга торган сүзләре бар, тик хәзергә әле яңа фатирчысы алдында берьюлы тугарылып китәргә чак-чак кына шүрли иде.

— Әллә ни тамаша чыгарып булмас, шулай да тотынып карарга исәп. Әгәр кул астында таянырдай кешеләр табылса.

— Кешеләрме? Безнең Баланлыдамы? — дип бердән кабынып китте Андрей дәдәй. Аны хәзер тотам дисәң дә тотып булырдай түгел иде, — әйттең сүз, апаем. Поп юк, мулла юк, чиркәү юк, мәчет юк, ә кешеләр бар бездә. Этәреп җибәрә генә бел. И аннары менә бу азгын су белән дус булмавын да ару икән. Но анысыннан бөтенләй качу җарап бетмәс... Кешеләр дигәннән, первом делом, менә Андрей дәдәңне чут төймәсенә тартып куй. Балта да тота беләм и кыр эшендә дә бөтенләй үк годтан чыккан кеше түгел. Бездә моңа тиклем хуҗа юклыгы кулныаякны тотты. Сызгырып җил кузгатучысы булса, биеп китүчеләре табылыр аның.

Бәлки, теленә салынган бу керәшен карты иртәнге якта баш «тәзәтеп алырга» инде өлгергән үк булгандыр, бәлки, теле белән генә тегермән тартучыдыр — дөнья булгач андый кешеләр дә бетәсе түгел. Ничек кенә димик, бу иртәнге сәгатьләрдә — ә без аны хәерле сәгатьләр булсын иде дип юрыйк! — ачык чырайлы, шат күңелле бу картның үз каршында шулай гөрләп торуы ярап куйды, Ахунҗановның күңелен ачып, канатландырып җибәргәндәй итте.

Шуның янына тагын Дүсәй түтәй ясап китергән ике чынаяк куе чәй дә ярап куйды. Колхоз идарәсенә барып кергәндә ул үзен яхшы сизә, һәрхәлдә, бу колхоздагы беренче көнен артык кызмыйча һәм шулай ук адәм көлкесенә дә калмыйча башлап җибәрерлек кенә дәрман сизә иде үзендә. Идарә йорты җыештырылган, өстәлләр, кара савытлары үз урынында, ләкин председательне сәламләп каршы алучы әлегә күренми иде. Исәп-хисап эшчеләре председатель килеп байтак вакыт узганнан соң гына килә башладылар, анда да төрлесе төрле вакытта килде һәм, яңа хуҗаның болай иртә чекерәеп утыруын күреп, бераз аптырабрак калгандай булдылар. Ахунҗанов алар белән берәм-берәм исәнләшеп чыкты. «Ник болай соңга калып, төрлегез төрле вакытта киләсез?» — дип кызартырга ашыкмады, киресенчә, аларның үзләреннән гафу үтенгән кебек: «Мин сезнең мондагы тәртипләрне белеп җиткермим икән шул, бераз ашыгыбрак килгәнмен», — дип шаяртkan булды.

Ләкин аның нәзакәтлелеге шуннан да ары китмәде. Бераз көтеп тә Һадиев үзе килеп чыкмагач, ул инде нәзакәтләнеп уйнауның артык йөк икәнлеген тәмам төшенде, дежурныйны җибәреп, тиз генә Һадиевны алып килергә кушты. Чөнки тапшыру-кабул итү, танышу-мәслихәтләшү эшләрен, элеккеге председатель, хәзер зам булып калган Һадиевтан башламыйча, кемнән башламак кирәк! Теге бераз көттереп килгәч, Ахунҗановның матур кара кашлары аеруча салынгандай итте.

— Ачкычны, пичәтне кеше артыннан биреп җибәргәч тә, шуның белән эш бетте дип уйладыгыз, ахры, иптәш Һадиев. Кеше җибәреп алдырганны көтеп ятасыз.

— Ә ник кеше йөртәсең? Мин бит кирәкле кеше түгел хәзер.

Икесе дә «Әтәч Фәхри» иде бу минутта. Бу килештән бер-берсенә очып кунудан да ерак китмәсләр кебек күренгән иде. Шуны сизеп алып, бигрәк тә үзенең әле эшкә керешеп кенә баруын, мондагы кешеләр белән — аларның кем һәм нинди характерлы булуларына карамастан — алда әле кабат-кабат очрашырга туры киләчәген уйлап, Ахунҗанов шулай да кикрикне артык кызартмаска булды.

— Күреп торам, баш төзәтергә өлгермәгәнсез, Бакый абый,— диде

хата, кешенең йокысы туйганын, баш төзәткәнен көтмәгәнбез.

— Авыз җырмый гына сөйләш, эш нәрсәдә?

Һадиев үзе кырыс торгач, Ахунҗанов та, әлбәттә, уен корып вакыт уздыра алмады.

— Эш шунда, иптәш Һадиев: безгә «алдым-бирдем» ясарга кирәк.

— Кемне өйләндерәбез? Синеме, минеме?

Һадиев айнып җитмәгән баштан сүзне уенга борырга маташа башлагач, Ахунҗанов тонын үзгәртергә мәҗбүр булды:

— Безнең уйнап торырга вакытыбыз юк, Бакый абый: сез миңа эшне тапшырырга тиеш. Кайдан башлыйбыз? Хуҗалыктанмы, документларданмы?

— Син миңа, һич югы, берәр чынаяк чәй эчеп килергә рөхсәт ит. Чәйсез-мәйсез минем башым эшләми.

Чәй эчәргә дип киткән Һадиев ул көнне бөтенләй күренмәде. Кабат дәштергәч, өйдәгеләре: «Иртән чыгып киткәннән кайтканы юк»,— дип җавап биргәннәр, ә чынлыкта исә ул өендә берүзе, җырлый-җырлый, эчеп яткан, имеш. Күрәсең, «алдым-бирдем»сез генә башларга туры килердер Ахунҗановка. Колхоз балансында булган мал-мөлкәт һәм керем-чыгым яклары белән танышу өчен баш бухгалтерга тиешле документларны әзерләп куярга кушканнан соң, Ахунҗанов партком секретаре Тәлгать Хәкимовичны, авыл советы председателе Зиннәт Фәрдиевне алып, колхозның якын-тирәдәге каралты-кураларын, складларын, анда булган байлыкның ничек саклануын күздән кичереп, танышып йөрде. Аннары алар, Фәрдиев белән икәве, авыл советы атына утырып, басуга чыгып киттеләр. Озак гизделәр алар басуны. Кыйпылчык-кыйпылчык урманнар, елга-чокырлар арасында кысылып калган аю табанындай кыйпылчык-кыйпылчык басулар, чәчү мәйданы, болынлыклар — барысын бергә җыя торгач, дүрт мең алтмыш гектарга җыела, аларны бер көнне генә әйләнеп чыгу, әлбәттә, мөмкин эш түгел. Белеп бетерү бигрәк тә мөмкин түгел иде. Шулай да Ахунҗанов ачы бер хакыйкатьне белеп кайтты: килешли аркылы үткән кырлар, җыелмыйча покоста череп ята торган борчак теземнәре, каһәр генә төшсен, «Алсу алан» колхозыныкы икән ләбаса! Киңәш сорап торасы юк, иртәгә үк бер бригаданы шул эшкә кушарга: әйләндерсеннәр, киптерсеннәр, һич югы, калган хәтлесен бөртеген дә югалтмыйча җыеп алырга. Митинговать итеп тору кирәк түгел, моның өчен кул гына кирәк!

Янә тагын урман култыгындагы бер басуда «СК-4» комбайны «онытылып» калган. Кызыксына торгач, оятка каршы, бу ташландык мал да «Алсу алан»ныкы булып чыкты.

## «Берсүзсез эшләнгән булыр...»

«Бер бригаданыкы» түгел, сораша торгач, иясе килеп чыкты ул онытылган борчак җиренең — Әшрәпов Миргасыйм дигән бригадирның «биләмәләре» икән. Кырдан кайтуга, Ахунҗанов чакыртып китерде ул кешене. Менә, ичмасам, кеше! Ыспай киенгән, аяк та пычрак түгел, тузан әсәре дә юк — һәрхәлдә, кырда күп йөреп йөдәгән аякларга охшамыйлар. Үзе нечкә генә мыек җибәргән, шул мыек астында гел елмаеп торучы иреннәр, исерек тә түгел, айнык та түгел, шул ук вакытта, бөтен кешене кочакларга торгандай, шат күңелле күренә. Беренче күрүдә Ахунҗановта мондый тәэсир туды: «Бераз гамьсезрәккә охшый бу адәм, әмма яшь кеше — чи чыбык, кирәкле якка бөгәргә булыр!»

Формасына китереп, исәнлек-саулык сорашкан булды һәм шундук «үгез»не мәгезеннән эләктереп алды:

— Сезнең авылга килешли Гыйлаҗ Хәмдиевич күрсәтте. Балан-куак буендагы җыелмаган борчак гектарлары ул безнең бригаданыкы, имеш, иптәш Әшрәпов,— болай кырыс башлап бу сөйкемле «яшь мыек»ны берьюлы өркетеп ташламагаем тагы дип, арага чак кына юмор кыстырырга булды.— Сез, панимаешь, шушы авылныкы булсагыз да, житмәсә тагы, бригадир була торып, оныткансыз, ә район житәкчеләре беләләр икән...

«Яшь мыек» яңа председательнең тел төбен төшенә алмый аптырабрак калды,— әллә шаяртуы, әллә ачулануы, шайтан белсен. Ә үзенең әлеге сөйкемле йөзе һаман җәенке, юка иреннәре гел көләргә торган кебек, калган борчак турында, ичмасам, исендә дә юк. Егетнең болай сүзсез-гамьсез басып торуы Ахунҗановның ачуын кузгатты, тел очына бик усал сүзләр килде аның. Ләкин — яхшымы-яманмы — бригадир кеше, аның алдында берьюлы кабынып китәргә ашыкмады. Шулай да уткәрә торган итеп әйтте:

— Уен корып торырга вакыт калмаган, Әшрәпов. Оныткан булсаң, исенә төшерим: басуга октябрь килде. Кар астыннан бөрәм-бөрәм чүпләргә димәсәң, иртәгә үк бөтен бригаданны шул борчакка куш. Элек әйләндерегез, җиллэтегез, и шундук икенче баштан комбайн җибәр. Ишеттеңме нәрсә әйткәнне?

Тик шунда гына әлеге «Яшь мыек»ның моңарчы җәелергә дә, җыелырга да белмичә ярым ачылып торган көләч иреннәре бердән хәрәкәткә килде — ләкин егет каушап калган кешегә охшамый иде әле.

— Ишетмичә,— диде ул, бер сүз белән өзеп. Һәм шуннан соң әллә ихластан шулай канатланып, әллә шаяртып, өстәп куясы итте,— председатель хәтле председатель әйтсен дә, ишетмә, имеш. Миңа иртәгә наряд шул, алайса?

Һәм яшьләргә хас яңгыраулы тавыш белән берьюлы ярып салды:

— Непременно эшләнгән булыр, то есть сез әйткәнчә эшләнгән булыр, иптәш председатель. Гафу итегез, хәзергә мин сезнең исемегезне дә, фамилиягезне дә белеп җиткермәдем, анысы өчен бигайбә.

Шундук аякны аякка шак-шок бәреп, солдатларча төгәллек белән борылды, ишеккә таба атлады. Ләкин чыгып китәргә өлгермәде. Ахунҗанов аны туктатты — бу юлы ул кәнфитләнеп түгел, шактый кырыс итеп кисәтте:

— Минем хәтер нык, иптәш Әшрәпов. Иртәгә үзем барып, эшегезне карармын. Көн аяз торганда җыеп бетергән булыйк ул койрыкны.

Әйтүен әйтте, ләкин күңеле утырмый, ышанычы нык түгел иде. Чөнки үтә җиңел җавап бирде теге Яшь мыек, уйлап җиткердеме икән, төшендеме икән яңа председательнең әйткәнне онытмый торган кеше икәнлеген? Гомумән, Ахунҗанов үзенең азмы-күпме тормыш тәҗрибәсендә, үзенең Мәргәнтавында бригадир булып эшләгәндә — кешеләр белән аралашу практикасында сынаган-күргән: андый үтә оптимист кешеләр күп вакытта кәкре каен терәтүчән булалар...

Монда да шундый берәр хәл булмагае дип, бигрәк тә Әшрәповның кичә кисәтүен искә алып, икенче көнне, төштән соң, кеше-карага хәбәр итеп тормыйча, җәяүләп кенә ул әлеге «гөнаһ шомлыгы» борчак кырына үз күзләре белән күреп кайтырга дип китте.

Һәм ни күрде?.. Көннең чалт аяз торуына карамастан, тузанга катып җиргә ябышкан борчак покосларын әйләндереп маташучы биш-алты хатын-кызны һәм, бәхеткә каршы, теге шат күңелле Мыекны күрде.

— Шушымыни синең бөтен бригада дигәнең? — Бу юлы председатель тәкәллеф саклап торырга булдыра алмады һәм аны кирәк дип тә тапмады.

— Әйтеп чыктым кешеләргә, бар булганы шунда,— диде Әшрәпов, бүген инде яңа председатель белән авыз ерып сөйләшүнең үтмәслеген

сизенә төшеп. Ул арада чаярак бер хатын «кызу ташка» су өстәп җибәрергә ашыкты:

— Җүнләп әйтергә теле әйләнми аның, безнең Миргасыймның. Аты-юлы белән сүгенергә генә белә. Кычкыргандыр да тәрәзә төбендә, киткәндер.

Кешеләр белән сөйләшә башлагач шуны ачыклады Ахунҗанов, адәм әйтеп адәм ышанмас: начальниклар белән сөйләшкәндә ай-кояш була белә торган шушы япь-яшь Мыек үз кул астындагы кешеләр белән эш иткәндә «һау-һаулап» җибәрә һәм еш кына үлгән кешеләрнең «кабер такталарына» ук барып җитә, имеш.

Моны аяк өсли генә калдырырга ярамаганны төшенеп, Ахунҗанов бригада кешеләре белән үзе сөйләшергә булды һәм бригадирга бүген кичкә, наряд бирү алдыннан, кыска гына вакытта бригаданың бөтен кешесен идарә йортына җыярга кушты.

Җыелдылар, сөйләштеләр — бу кыска, эшлекле сөйләшүдән шул мәгълүм булды: бригадир Миргасыйм Әшрәпов, яшьлек аркасында булса кирәк, чынлап та кешеләр белән тиешенчә эшли белмәгән икән. Моны җыйнаулашып егетнең мыегына урадылар. Ахунҗанов исә, мыекка урау белән генә чикләнмичә, киләчәктә искә алу өчен блокнотына ук теркәп куйды.

Шушы җыелудан файдаланып, кырда «онытылып калган» борчак турында да житди сүз кузгалды. Әлбәттә, озак сөйләшеп торырга урын юк, барысы да кызардылар — эчләреннән тындылар. Бу җитди сөйләшүнең күренеп торган файдасы иртәгесен булды. Көне дә кояшлы, аяз туган иде, хәер, сүз биргән кешеләре дә сынатмаганнар — бригаданың эшкә яраклы барлык ире, хатыны, яше-карты — барысы да Балан-куак буендагы борчакта иде. Бер яктан кичә әйләндереп салган һәм инде кибеп өлгергән теземнәрне комбайн «чәйни» торды, икенче яктан әйләндереп, киптерә, комбайнга әзерли тордылар. Шулай итеп, ике ай «онытылып» яткан хәсрәт-борчакны, әлбәттә, шытмыйча исән калганын, җыеп алу өчен ике-өч көн вакыт җитте.

## Көпә-көндез, кояш яктысында

Һадиевны тагын чакыртырга, урынбасар булып калганы хәлдә, болай тәртәгә тибеп йөрүе өчен кызартырга-оялтырга мөмкин булган булыр иде. Инде кызара белүдән дә узган икән, ах алла, белмиме соң Ахунҗанов кешене камырга әйләндерә торган чараларны — парткомга чакырткан булыр иде. Ләкин кılә-килүгә кеше белән әчелешле булып йөрүне яки кеше өстенә сөйләүне килештермәде. Хәер, колхозда Һадиевтан башка кешеләр дә җитәрлек иде. Яңа председательнең тавыш-гаугa күтәрмичә, җыелышлар белән мавыкмыйча, кешеләр арасында булырга, һәр эш мәйданында үзе күренергә омтылуы, иртә-кич белән исәпләшмичә, искәрмәстән генә әле фермага, әле күрше бригадаларга килеп чыгып, өйрәтергә ашыкмыйча, җайлап кына сөйләшә белүе, сөйләшеп кенә дә калмыйча, кайбер агрегатларда, машина астына үзе кереп, тирсәк тиктен майга буялып булса да, «кәҗәләнүче» тракторны яки зернопультны ходка җибәрешүе, барыннан да бигрәк сөйләшкәндә авызыннан спирт исе аңкып тормавы колхозчыларда аңарга карата шул беренче көннәрдән үк хөрмәтле караш уятты. Бригадирлар барысы да тигез түгел, әлбәттә, тиз генә ачылып китә алмадылар — алар арасында калын тирегә шытып чыккан нечкә «Мыеклар»да, элеккеләр белән озак кына бергә эшләп каешланганнары, «мы сами — с усами»га әйләнгәннәре дә юк түгел иде. Шулай да урман култыгында «адашып» калган комбайн паркка кайтты. Шул унайдан яңа председатель паркны да барлады, машиналарның байтагы эшкә чыгарылмый ята, дөресрәге, эштән чыгарылган килеш ята иде. Әлбәттә, район производство бүлеге

начальнигы Сәттаровның да ишегеп кагарга туры килде. «Ярдәм итәрбез»,— диде ич куйганда, менә хәзер, рәхим итеп, запчастьлар табарга ярдәм ит инде! Тунга сөрүне бетереп машиналар кайтуга ремонт хәстәрен күрә башларга кирәк булачак. Әлегә төрле сәбәпләр аркасында тунга сөрелеп бетми калган урыннар бар иде әле, табылган хәтле запчастьлар белән вакытлыча гына булса да тракторлар да кузгалып киттеләр... Беренче көннәр, беренче адымнар өчен бу, әлбәттә, ярыйсы башлангыч иде.

Инде беркөнне, колхозның исәп-хисап, учет-баланс эшләре белән танышырга булып, баш бухгалтер Мөстәкыймов белән өстәл артына барып утырганнар гына иде, ишектә майланган кепкасы бер якка кыйгыр киткән, икенче якка көлтәдәй чәче бүлтәеп чыккан, шулай ук иреннәр дә, күз кабаклары да яхшы ук шешенке, кыскасы, иләс-миләсрәк бер баш күренде. Баш, гәүдә, ике аяк, ике кул һәм жил уйнап торган буш кесә булып чыкты бу. Кергәч, узарга да, узмаска да белмичә, бер мәл тартынып торды. Кепкасын рәтләбрәк киде, иреннәрен ялмаштырды, шуннан бераз кыюлык җыйгандай, бер-ике адым алга үтте. Тагын туктады, тагын кепкасына кагылгалап куйды — сүзне ничек башларга белмәгәнлеге, яна председательдән чак кына өркебрәк торганлыгы әллә кайдан күренә иде.

— Ни йомыш, дус кеше? — дип, үзе ярдәмгә килде Ахунжанов, артык каты бәрелмичә генә. Ләкин бер дә бәрелмичә калдыра алмады, мыскыллау тоны белән шундук өстәде,— сезнең урамда бәрәр бәйрәм качып калмагандыр ич? Ничек болай, көпә-көндез, бөтен кеше эштә чагында сез генә кәефләнеп йөрисе иттегез? Мәктәп балалары күрер бит, адәм көлкесе.

— Яна председатель шушы буламыни инде? — Әлеге кеше бу сорауны председательнең үзенә түгел, Мөстәкыймовка бирде. Ләкин шул ук вакытта председательне дә бөтенләй үк игътибарсыз калдыруны килештермәде булса кирәк,— дус дисен икән, агайне, менә нәрсә: баш төзәтергә өч сум акча кирәк миңа, бир команданы, чыгарып бирсеннәр миңа өч сум акча.

Ахунжанов бухгалтер Мөстәкыймовка, Мөстәкыймов Ахунжановка карашып алдылар, ә «башы ватык» кеше бер үк вакытта аларның икесенә дә мөлдерәп карап тора иде.

— Шулай, баш төзәтергә дә колхоз чутыннан бирер торгалыйсызмыни?

Ахунжанов эшне әле һаман төшенеп житмәгән кебек кыйлана, сүзне чынга аласы килми иде. Бухгалтер да аның жаенарак ятып, ярым житдилек, ярым шаярту белән:

— Булгалагандыр инде дөнья булгач,— дип көлемсерәп куйды. Тагын бераз тынлык урнашып алды, ни дә булса әйтергә берсенең дә теле әйләнми иде. Шул ук вакытта әлеге «башы ватык» кеше дә чыгып китәргә ашыкмый, тел кузгатып бер сорагач, күрәсең, ничек тә өч сумны эләктереп китәсе килә иде булса кирәк.

— Булмый дисеңме? Булмаса әйт, булмый, диген. Яна себерке яначә себерә. Без алай икәнен дә беләбез, төшеп калганнардан түгел.

— Шулай да без дә белик, ниндирәк бәндә була соң бу? Колхозчымы?

— Колхозчы булмыйча кем булсын. Читтә акча күрәп йөри торган бәрәр шабашник-мазар булса, безнең каршыга килмәс тә иде.

Ахунжанов әле бу агайның колхозда ничек эшләве, күпме хезмәт көне төшергәнлеге белән дә кызыксынмакчы иде, кинәт аңарга әллә ничек уңайсыз булып китте.

— Өч сум акча теләнеп йөрергә... Сез колхозчыны кем дип беләгез? — диде ул, яхшы ук кыза төшеп. Ләкин кемгә: акча сорап кергән бу «ватык баш»камы, бухгалтергамы, үзенәме ачуы чыкканлыгын үзе дә

оформить итәрбез.

Эшкә әле тик керешкән генә кеше өчен, кассаның җаен сорашып тормастан, болай юмартлану шактый зур тәвәккәллек иде. Шулай да колхозчы дип атала торган кешенең абруен саклап ясалган бу тәвәккәллекнең соңыннан файдасы да тиде, кызык яклары да чыккалап куйды.

Файдасы шул булды: шушы факттан башлап сөйләшә, аңлаша торгач, «Алсу алан» колхозында элекке житәкчеләр вакытында мондый яраксыз практиканың зур гына урын алып килгәнлеге беленде. «Баш төзәтергә» дә, «төзек башны ватар өчен» дә, әлбәттә, үз кешеләренә өч сумлап та, биш сумлап та әледән-әле биргәли торганнар. Председатель рөхсәте белән дә биргәннәр, идарә членнары имзасы белән дә җибәргәннәр, кем белә, мондый киң күңеллелектән файдаланып, бәлки, бөтенләй имзасыз киткән чаклары да булгандыр. Әҗәткә, «баш төзәтергә» дип алынган бу өч сумнар, биш сумнарның кайтканы кайткан, кайтмаганы кала-кала шулай сеңгән. Бу, һичшиксез, колхоз кассасына суккан.

Бер сүз ачылгач, бухгалтер Мөстәкыймов моны бик әрнеп, зур борчылу белән сөйләде: «Минем бунт күтәреп караган чакларым булды, эш шулай куелгач, ялан берүзем мин нишли алам!» — дип акланырга тырышты ул. Ләкин соңга калып уянган бу үкенү белән Ахунжановны эретергә мөмкин түгел иде.

— Менә хәзер без икәү,— диде Ахунжанов, яхшы ук кабынып китеп,— андый башбаштаклыкка юл куймабыз. Минем имзамнан башка колхоз кассасыннан беркемгә дә бер тиен дә җибәрәсе булмагыз.

— Ә бүгенге «юмартлыкны» кайчан, ничек җыеп алырбыз икән?

Бухгалтер тавышындагы иронияне ошатып житкермәгән Ахунжанов, икеләнергә урын калдырмыйча, өзеп әйтте:

— Алырбыз. Яңа елдан да соңга калмыйча безнең колхоз да хезмәт көненә акчалата түләүгә күчәргә тиеш. Шул чагында без колхозчылар белән ике араны өзәргә: бирәчәгебезне бирергә, биргән әҗәтләребезне кайтарып алырга тиешбез.

Колхозда акча якларының ташып тормаганлыгын белә бухгалтер. Бөтен исәп-хисап, алган бурычларны түләү дәүләткә сатылган икмәктән килгән яки киләчәк акчага салынырга тора, бүтән бер тиен килер юк, шул килеш яңа председательнен бу хәтле өзеп әйтүе бухгалтер Мөстәкыймовны беркадәр аптыраштарак калдырды. Күрәсең, Ахунжановның үз планнары бардыр. Хәлбуки, бу — яңа председательнең үз башында туган план гына, ләкин дөньяда юк нәрсә түгел, күрше колхозларда — күбесендә — акчалата түләүне инде кертканнәр, файдалы икәнен дә әйткәли торалар иде. Шулай булгач, «Алсу алан» колхозы гына — исеме шундый яңгырап торганы хәлдә — нишләп шулай койрыкта сөйрәлеп барсын ди?

Файдасы тагын шул булды: бу факт яңа председательдә кире кагып булмаслык тәвәккәллек, үз көченә ышану уятты: «Чарасына керергә, кабып карарга кирәк... кабып карамыйча, бернәрсәнең дә тәмен татып булмый»,— дип уйлап куйды ул.

Кызык ягы шунда: өч сум сораганга утыз сум эләктереп киткән «ватык баш» соңыннан кем очраса шуңа яңа председательне мактап, аның авторитетын күтәреп йөргән. Янәсе, вәт председатель, ичмасам, бу Ахунжанов дигән адәм — өч сум сорап кердем, утыз сум биреп чыгарды.

Шул коткыга бирелеп булса кирәк, кичкә хәтле акча сорап, тагын өч кеше керде. Тәвәккәлләргә икән тәвәккәлләргә: аларын да буш кул белән озаттырмады Ахунжанов.

Ә кич белән һич көтмәгәндә өченче тамаша: иртә белән утыз сум алып киткән агайның хатыны Фәхрениса чабып килеп житкән. Бусы председательне мактар өчен түгел, бусы председательнең өстенә карчыга

булып очып куну өчен. Ишектән керә-керешкә үк чәр-чәр чәрелдәргә тотынды. Янәсе, кем бирде, ник бирдегез минем ул исерек башка шул хәтле акча? Кайчан, нәрсә белән түләр дип бирдегез?

Хатын, әлбәттә, исерек түгел, алган акчаны кайчан да булса түләргә кирәк булачагын чамалап килгән. Айнык кеше белән айнык сөйләшмичә булдыра алмады Ахунҗанов:

— Син апа, зинһар, кызмыйча гына сөйләш, монда чукрак кешеләр юк,— дип башлады ул, башкаларының да колагына керсен өчен сүзләрен үтә ачык, үтә сендерә торган итеп,— әгәренки колхозчы идарәгә нинди дә булса гозер белән килә икән, без, конечно, булдыра алган хәтле аның гозерен үтәргә тиешбез. Дөрес, синең Борһаның, апа, утыз сум сорамады, ул баш төзәтергә дип өч кенә сум сораган иде, ә без колхозчыны андый түбәнлектә калдырырга теләмәдек, өч сум сораганга утыз сум бирдек. Җырып чыгып булса, тиздән менә колхозда трудка акчалата түләү кертергә уйлап торабыз. Күбрәк, тырышыбрак эшләрсез, апа җаным, курыкмагыз, сезнеке колхоз өстендә, колхозныкы сезнең өстә калмас. Ничек тә исәпләшербез. Шушы җавап белән канәгатьме?

Шушы хәтле аңлатып әйтсен дә, бар, канәгать булмыйча кара! Әле җитмәсә, кайтышлый, очраган бер кешегә, үзенчә яңа председательнең гайбәтен саткан булып, чынлыкта аны мактаганлыгын үзе дә аңышмастан, шаулап кайткан:

— Кеше түгелдер, төлкедер ул яңа председателегез. Минем Борһаныштансызга өч сум сораганга утыз сум биргән дә койрыгын бозга катырып куйган тегенең. Җаен булса, аягына резинка-кәвеш киеп, кибет яныннан кайтты юк ие, хәзер менә сал инде резинка-кәвешеңне, апаем, йөгер колхоз эшенә. Йөгерерсең нибуч, алдан әҗәткә алып, койрыгыңны бозга катырып куйгач.

## Өй бар, өй искә төшә...

Акчалата түләү белән дә кызыктыргач, председатель үзе дә көнне төнгә ялгап чапкач, колхозчылар эшкә яхшы ук дәртләнеп йөри башладылар, ә бу үз нәүбәтендә Ахунҗановны тагын да канатландыра төшкән иде. Беркөнне йокыдан торышлый моңарчы искә дә килмәгән хәлне сизеп алды Ахунҗанов: карагыз әле, өс-башы керләнеп бара икән бит яңа председательнең. Шундук тәне дә кычытып куйгандай итте. Кинәт үзәкне өзгәндәй булып өе, балалары, хатыны искә төште. Һәм бу, бәлки, арка кычыта башлаганнан гына да түгелдер. Гел чукердәшеп, күзгә-күз карашып утырырга вакытлары булмаса да, менә хәзер, аерым яши башлагач сизде бәндәгез: бик зур, кеше тормышы өчен алыштыргысыз бер шарт икән ул гаилә булып оешып яшәү. Өс-баш керләнүдән яки арка кычыта башлаудан гына күңелгә килгән сүз түгелдер бу, арка кычытса, Андрей дәдәйләрнең мунчасы лапас артында гына — әйтсән, ягып кертерләр иде. Ә менә өй, хатын, бала-чага чыр-чуы, әллә нидә бер үз кешеләрчә әрләшеп алулар, кич арып кайткач, хатыныңның ачык чырай белән каршылавы, ыгы-зыгы арасында ялгыш кына ычкындыргандай әйтеп куйган җылы бер сүзе, көндәлек тормышта кабатланып торган тагын башка бик күп, бик күп гадәти генә көнкүреш хәл-әхвәлләре — аларны соң бүтән берни белән алыштырырга мөмкинме! Кемнәр өчен булса да, бәлки, мөмкиндер, ә менә Ахунҗанов элек башка да китермәгәнне монда килеп эшли башлагач сизде: юк, аның өчен мөмкин түгел икән, мөмкин түгел икән!

— Карагыз әле, Дуся әби,— дип, сәер генә итеп, хуҗа хатынга эндәшеп куйды ул шул ук иртәнге сәгатьләрдә,— арка кычыта башласа, нишләргә кирәк, сезнеңчә?

— Мунча керергә, каен себеркесе белән бик каты чабынырга кирәк,— дип, карчыгына бирелгән сорауга үзе җавап кайтарырга ашыкты Андрей дәдәй. Карчыгы кычына башлаган кешене аңлауда шулай да Андрей дәдәйдән зиһенлерәк булып чыкты.

— Чирнең нинди төшә бит мужик башына,— диде анысы, үзе белән үзе сөйләшкән кебек итеп кенә,— бер ише чирне каен себеркесе белән генә каулап чыгарырсың, бар.

Аннары Ахунҗановның нәкъ үзенә төбәп, бер дә тел яшермичә әйтте:

— Кайтып кил соң катының җанына. Качкан җирмени? Машина барында.

Бер дә боргаламый әйтелгән бу сүздән дә дөрес сүзнең булуы мөмкин түгел: «Синеке дөрес, Дуся әби, кайтып килми булмас!» — дип уйлап куйды Ахунҗанов. Ә телдән, бик үк ышанып җитмәсә дә, шулай да әйтте:

— Кайтып килү генә нәрсә ул, үзләрен алып кил, бергә оешыгыз, диген син, әби җаным.

«Әби җаным»ны бик ихлас күңелдән әйтсә дә, карчык та, Андрей дәдәй дә бу юлы дәшми калуны хәерлерәк санадылар. Чөнки башта ук: «Ялгыз үзеңне генә кертәбез, картлык көнебездә кеше мазасы белән баш катырасыбыз юк»,— дип өзеп сөйләшкәннәр, фатирчыларын хәзергә үз уллары кебек яратсалар да, хатынын, бала-чагасын китертүгә ризалык бирер кебек күренмиләр иде. Шулай да өс-баш каралуның да бер файдасы тияр икән: әнә нинди сүзләр килеп чыкты бит шул көнне иртән. Һәм Ахунҗанов нәкъ шул көнне, бераз эшләрен карау белән, Мәргәнтауга кайтып килергә булды.

Эшләрен караганнан соң, аннары, механик белән бергәләп, утырып юлга чыгасы машинаны озак кына карарга туры килде. Җиңелгә йөрергә билгеләнгән бердәнбер «ГАЗ-69» машинасын, җиңелен-авырын тикшереп тормыйча, күрәсең, байтак куганнар, моңарчы утырып караганы юк иде яңа председательнең, утырып карарга дип янына килгәч, машинаның нык кына какшаганлыгы беленде. Кыскасы, утырудан элек астына кереп ятарга, боргалыйсы җирләрен боргаларга, рессорларын ныгытырга туры килде. Бу да, әлбәттә, күп кенә вакытны алды. Инде эш бетте, утырырга да баранканы боргалый башларга дип кенә торганда, кесәсендә папиросы беткәнлеге билгеле булды. Димәк, кибеткә сугылырга кирәк диген сүз, хәерсез.

Моңарчы Баланлы авылы кибетенә кергәне юк иде. Ахунҗановның, ничектер, туры килмәде, йомышы төшмәде. Хәер, әллә ни шаккатар урыны юк икән, гадәти генә бер авыл кибете: прәннек, конфет, чәй-шикәр, ситсы, крепдешин, йөгән һәм сабын, кайрак һәм лампа куыгы... Шул имгә ярарлык товарлар арасында тагын, өстәге шүрлектә, кеше күзе төшмәслек караңгы бер почмакта, тышлык катыргылары калҗаеп беткән берничә дистә китап — матур әдәбият китаплары... Аракы, тәмәке — алары инде үзләре сикереп авызга керергә тора. Күрәсең, тәҗел генә кереп, тамак чылатып чыгучылар күздә тотыладыр, аракы шешәләре янәшәсендә үк, аларның якын кардәше кебек, алты кырлы стаканы да утырып тора иде.

— Бер пачка «Беломор»,— диде Ахунҗанов, сатучының күзенә туры карамыйча гына. Бәлки, болай коры эндәшергә кирәк булмагандыр, бу авыл өчен яңа кеше шул, кайдан бөтен келәүне берьюлы белеп бетерсен. Ә менә сатучы, күзләре ут уйнап торган яшь, сөйкемле, буе-сыны килгән һәм буе-сынына килешә торган итеп киенә дә белгән купшы хатын — хәйләкәр адәм икән — Ахунҗановның сүзен бөтенләй ишетмәгән булып кыланды. Шунда — Ахунҗановның күз алдында, унбиш тиен акча учлап кереп, йөз грамм пыяла конфет үлчәткән бәләкәй кызчыкның Мөршидә апа дип юаш кына эндәшүен ишеткән бу илгәзәк Мөршидә апа нишләп

соң председатель хәтле председательнең «Беломор» дип соравын ишетмәде икән? Сәбәбе шул: Баланлыга хатынсыз килгән бу яңа председатель белән ул аның үзен күргәнче үк кызыксына башлаган, аны үз янында озаграк тотарга тели иде. Кем белгән ирдән аерылып кайткан яшь хатынның күңелендә ниләр кайнаганны!

Ахунҗанов белмәсә белмәс, ах алла, безгә мәгълүм: безнең әллә кайчангы танышыбыз ич бу Мөршидә апа дигәннәре! Теге кичне, Баланлы авылына, аның бәрәңге бакчаларына, бакча киртәләренә, аның олылы да кечеле өйләренә кичке эңгер төшкән бер мизгелдә, бер үзе Ык буена каз эзли төшкән һәм шунда кулындагы чыбык белән сукмак буендагы әремнәрнең, алабуталарның башларын кыйгалап узган рәхимсез Нечкәбил ич бу! Исебездә, исебездә, безнең башның да сукмак буенда тәгәрәп үскән шалкан башы булмаганлыгы өчен бик тә куанган идек без ул чагында. Шулай булмыйча соң! Кем генә димә, берәүнең дә искәрмәстән генә моңдый чибәр апа алдында башсыз каласы килмәс. Тагын шул чаклысы да исебездә: ул анда, без күргән шул тын кичтә, озын сыйрагыннан су анаеы тартып алыр дип һич шикләнмичә, япа-ялгызы Ыкта су коенды һәм чабак балыктай шәп йөзә белгәнлеген күрсәтте. Шулай да, күз бәйләнгәч япа-ялгыз су керергә курыкмаса да, суда чабак балыктай йөзә белсә дә, шулай да тормышта, семья корып тора башлагач, бик алай оста йөзүчеләрдән булмаган икән: ирдән кайткан нәрсә диделәр ич ул Мөршидәне!

Ә Ахунҗанов-сабый хәтта без белгәнне дә белми, ахрысы, әнә тора да тора прилавка алдында. Кӫтә дә кӫтә «Беломор» алып биргәнне. Ә теге, хәйләкәр Мөршидә апа күрми дә күрми председатель хәтле председатель басып торганны.

Күрмиме соң, күрмәгәнме соң, әллә кайчан күргән, күңеленә беркетеп үк куйган: кайчан булса да йомышы төшми калмас кибеткә. Кирәчәгеп дә чамалаган, кергәч ничек дип сүз башлап җибәрәчәген дә уйлап куйган. Шулай да, әнә бит, күрмәмешкә салыша — шайтаный сабырлык булса кирәк бу. Сызганып эшкә керешкән, артта сөйрәлүче колхозны алга чыгарырга дип йөргән безнең ул гөнаһсыз председателебезне искәрмәстән генә үзе белән упкынга сөйрәп алып китмәсә ярый.

— Мин «Беломор» дигән идем...

Юк, кырыс итеп кабатламады Ахунҗанов бу юлы да — шундый сөйкемле, яшь, чибәр, ирдән кайткан хатын белән кырыс сөйләшергә мөмкинме соң!

— Ә... гафу итегез, ишетми дә торам,— дигән булды Мөршидә. Һәм, бу сүзләрне юри генә әйткәнлеген тизрәк белдерергә ашыккандай, бөтен бите белән җәелеп көлде. Каһәр генә төшсен, ходай уйламаган бәлаказалардан сакласын, бу Мөршидә дигәннәренең көлүе дә бик хәтәр икән. Көлгәндә, мәрҗән кебек тезелеп, ап-ак тешләре күренеп калды. Ахунҗановның башы, әлбәттә, үз урынында, ләкин Мөршидә, иблис токымы, бу беренче очрашуны болай гына калдырырга һич уйламый иде.

— Карагыз әле, иптәш прсидәтел,— дип эндәште ул чыга башлаган Ахунҗановка. Теге, туктап, әйләнеп карарга мәҗбүр булды — әйләнеп карамаган булса, тукталмаган килеш чыгып китсә, бәлки, яхшырак буласы булгандыр. Ул арада теге ирдән кайткан каһәрнең әлеге матур, ап-ак тешләре, смотрга тезеп куйган энҗе токымнары кебек, бичара председательнең нәкъ күз алдында тагын бер кат тезелеп куелган иде инде.

— Сез үткәндә-сүткәндә шулай кергәли йөрегез, Ахунҗанов абый,— диде Мөршидә, ни өчендер үзе дә алсу-кызылга манылгандай,— без гел болай ярлы булмыйбыз, безнең бай чакларыбыз да була.

Ничектер баш әйләндерә торган итеп, үзенең дә башы әйләнгәнлектән әйтте ул бу сүзләрне, әйтмичә кала алмаганлыктан әйтте.

Кирәк бит шундый чакта! Хатыны янына, Хәдичәсе янына, сөеклесе, үз сөеклесе янына кайтырга дип ашкынып йөргән минутларда. Үзе «Беломор»ын кесәсенә салып кибеттән чыгып китте, ә теге аяклы коткының яңгырап калган уенчак тавышы колак төбендә тора да тора. Кирәк бит, кирәк бит шундый чакта очрап торырга. Нәрсә булса да, кем әйтмешли, ахыры хәерле булсын!

## Тырнак астыннан кер эзләмәсеннәр икән!

Кайтты. Мәргәнтау авылы шунда — үз урынында. Өй дә. Балалар да. Хатын да. Чү, әллә хатын бик үк үз урынында түгелме?

— Ник кайттың? Өзелеп көтеп торганыбыз юк иде әле моңарчы,— беренче сүзе шул булды Хәдичәсенең. Әллә уйнап, әллә чынлап әйтте, ләкин әйтте. Балалары чиратсыз-нисез әтиләренә ябырылдылар — берсе кулына сикереп менде, икенчесе култык астында ышкыла, өченчесе — зурраг'ы — каршында катып калган, әтисеннән күзләрен алмый, үзе әтисе өйдә юк чакта булган яңалыкларны тезә: Галиәкбәр абзыйларның этләре үлде. Кичә мин ферма таена атланып йөрдем. Бүген әби ураза тота, көндез ашамый, кич кенә ашый.

Балалары арасында камалышта калган Сәлим, бер ара табып, хатынына мутларча күз кысып алды:

— Син сагынмасаң, сагынмассың, күрәсең, балалар сагынган.

Почмак сәкесендә самсырап яткан җиреннән әби дә терелеп чыкты.

— Ходавәндә, сарылдыгыз сез дә,— диде ул, оныкларын юри ачулангач булып,— сезнең әтиегез булса, ул минем улым. Миңа да килеп карарга ирек бирегез. Бераз суырыла төшкәнсең түгелме, Сәлимҗан? Сырхауламыйсыңдыр бит?

— Сырхап торырга вакыт тигәне юк, инәй. Чабарга туры килә.

— Шул чапкан арада, әнә, дөньяда семьясы барлыгы да исенә төшкән. Ун көнгә бер булса да.

— Районга йомыш төште. Шунда барышлый урап кердем,— дип аңлатып үтәргә ашыкты Сәлиме, хатынының тавышындагы, сүзләрендәге кинаяләрне төшенергә тырышып та карамастан. Күз алдында елкылдап һәм чак кына киреле-мырлырак сөйләнгәләп торган «кара балыгын» (тилереп иркәлисе килгән минутларда яки берәр җирдән үтә сагынып кайткан чакларында Сәлим үзенең Хәдичәсенә, кара тутлы булганы өчен булса кирәк, «Кара балык», «минем саздан тотып алып кайткан Кара балыгым!» дип тә ычкындыргалый иде) болай озак кыландырырга сабырлыгы җитмәде иренең. Тегесе, табын әзерләгән булып, өй белән чолан арасында керә-чыга йөргәндә, чолан ишеге артына яшерә төшеп, кысып кочаклап алды.

— Ник кайтканны сорап торалармы ирдән? Кара балык. Инәй алдында юкны-барны сөйләнеп торган буласың.

Сәлиме шул, нәкъ элекке Сәлиме — тәкатьсез, балалар күрер дип тормый, тиле, аннары тагы... чак-чак кына сагынганга да охшый түгелме соң? Шулай да Хәдичәсе башта борып җибәргән киреле машинасын тиз генә туктата алмады:

— Ник кайттың, димичә сиңа. Киттең дә баттың. «Барам да әйләнеп кайтам» дип кенә киткән кеше ич син.

— Сайладылар ич, апаем. Тәртә арасына кергәч, тартмый буламы соң.

Аннары, сүзне уен-көлкегә борып, болай да яхшы ук йомшый башлаган хатынын бөтенләй эретергә булды:

— Председатель хатыны буласым килә диген иең, ирештең морадыңа, председатель хатыны син хәзер.

Чолан ишеге артында искәрмәстән шулай кысылулап һәм иренең, председатель башы белән, шулай юхаланып, килде-китте сөйләнеп торуыннан Хәдичә, шулай ук адәм баласы, җайланмас жиреннән җайланган иде инде.

Калганын чәй эчеп туйгач, өстәл яныннан кузгалгач, чыгып китәр алдыннан, бер җай туры китереп пышылдап кына әйтте Ахунҗанов:

— Бик каттым мин, инәсе. Тән дә кычытып тора. Мунча як. Районнан кайтышлый мунча кереп, әйтеп китмәгән булсам да төн куныл, өсбашны алыштырып китәрлек булсын.

Бу гына түгел иде әйтәсе сүзләре. Анда, чит авылда, ялгыз баш яшәүнең бик үк бәйрәм түгеллеге, эшнең күплеге, арка кычыткан саен егерме километр җирдән йөгереп кайтып булмаслыгы һәм, шуларның барысын да искә алып, Хәдичәсенең ире-председателе янына күчеп бару мәсьәләсенә ничегрәк караячагы — менә шуларны кузгатып карарга иде исәбе. Әмма ныклабрак уйлагач, бу чаклысын хәзергә кузгатмыйчарак торырга булды. Мунчада яки мунчадан парланып чыккач, һәрхәлдә, аулактарак кузгату хәерлерәк булыр, дип санады.

Райүзәктә беренче йомышны банкта — ссуда мәсьәләсен кузгату иде. Ләкин монда да акчаны алай ансат кына итәккә тәяп чыгармыйлар икән. Кәгазь кыштырдатырга, төпченергә тотындылар: янәсе, колхозның хәле ничегрәк, алганы күпме дә, алачагы күпме? Әгәр бирсәләр, бирелгән ссуданы түләренә, кайчанрак түләп бетерәчәгенә гарантия бармы? Һәм башкалар, һәм башкалар. Моңа хәтле мондый «алыш-бирешләр» белән эш итәргә бер дә туры килмәгәнлектән, Ахунҗанов бу мәсьәләдә ачыктан-ачык наданлык күрсәтте. Кызу, тавыш күтәрү, колхозның киләчәгенә ышану, коры энтузиазм белән алдырмакчы булып, чәбәләнеп карады. Ләкин банк хезмәткәрләре бары тик реаль кыйммәткә таянып кына эш итәргә өйрәнгән кешеләр булып чыктылар. Аннары тагы аларның «бер көнлек хәлифәләрне» күргәннәре бар икән, «Алсу алан»га председатель булып килгәненә атна-ун көн узмаган Ахунҗановка да, шундыйларның берәрсе булуы мөмкин, диган кебегрәк итеп, шикләнеб рәк карадылар. Ссуда сорап килгән кешегә, аңарга, беләсезме, нәрсә диделәр?

— Сез, иптәш Ахунҗанов, алай зурдан кубып сөйләшкәнче, иң әүвәл безгә — банкка, идарә председателе буларак, үзегезнең сельсовет тарафыннан расланган, пичәт басылган имзагызны китерегез. Бездә сезнең имза үрнәгегез булырга тиешле. Сезнең һәм баш бухгалтер Мөстәкыймовның имзасыннан башка, без сезнең хәтта текущий счетта булган акчагызны да җибәрә алмыйбыз, шуны раз навсегда белеп торыгыз,— диделәр. Акча мәсьәләсендә мондый «каты закон» булганлыгын белү Ахунҗановны шундук салкын канлырак булырга өйрәтте: «Боларга баш төзәтү өчен өч сум сорап керә алмассың, шалишь»,— дип эчтән генә көлеп куйды ул. «Алсу алан»да беренче көннәрдә булган хәлләрне искә төшереп. Шул ук вакытта бик үк төшеп калганнардан да түгел, хезмәт көненә акчалата түләүгә күчү алдында торган колхозларның баштагы чорларда дәүләттән ссуда алу мөмкинчелеге булганлыгын белеп алган иде.

«Банкирлар» өстеннән зарлану өчен түгел, бер килгәч сугылмыйча китүне яхшысынмыйча, райкомга — Мөхәммәдьяров кабинетына барып керде. Секретарь аны ачык чырай белән каршылады, кызыксынып сорашырга тотынды. Булган хәл-әхвәлләрне сөйләп бирде Ахунҗанов, кыенлыклардан зарланырга ашыкмады, шулай ук: «Бүрек белән бәреп егам!» — дип тә шапырынмады. Эшнең ансат булмаслыгын секретарь әлек үк чамалаган, хәзер Ахунҗановның аз сүзлелегеннән ул моны бигрәк тә күреп тора иде.

держим.

— Анысын беләм, Камал Шагиевич,— Ахунҗанов, секретарьга кулын сузган хәлдә, хәйләкәрләрчә көлеп куйды,— бераз «уҗымга-мазарга» чыгылса, бюрога чакырып алып, пешерерсез. Анысын алдан ук көтеп торам.

Яшь председательнең болай оптимист күренүе, бәла-казаны алдан ук «планлаштырып» торуы секретарьның да телен чишеп җибәрде.

— Алайса, Сәлим Садриевич,— диде ул, ишеккә борылган Ахунҗановның иңбашыннан тотып,— без белеп торганны син дә белеп тор. Шатлыклы хәбәр безгә килеп җитте: сез анда Фәрдиев белән, басулар карап кайтышлый, чак кына «уҗымга чыгып» алгансыз икән.

— Неужели әләкләп тә җиткерделәр? — дип гаҗәпләнеп сорап куйды Ахунҗанов. Ул, ышанырга да, ышанмаска да белмәгәндәй, аптырабрак калган иде,— әйе, булды шундый хәл: көнозын басуда йөреп ачыккач, Фәрдиевләр капка төбендә ат туктатып, кереп чәй эчтек.

— Безгә җиткерелгән «информбюро»да чәй генә түгел, «мәй» дә диелгән.

Инде хәзер секретарь хәйләкәргә әйләнде, көлемсерәп, Ахунҗановның күзләренә карап — чынын белергә теләп, төбәлеп карый иде. Бу караш алдында яшеренеп калырга теләмәде Ахунҗанов, яшеренеп кала алмады.

— Я, берәр йөз грамм «мәй» дә булсын, ди. Шуннан нәрсә? — дип, кинәт кабынып китте ул. Һәм бер кызып киткәч, райком секретаре алдында басып торганлыгын оныта язып диярлек, күңелендә булганын бушатасы итте,— колхоз председателе итегез, дип мин сорамадым, Камал Шагиевич, үзегез җибәрдегез. Инде шулай булгач, мин сездән бер нәрсәне үтенеп сорыйм: зинһар өчен, эшләргә мөмкинлек бирегез, юк-бар өчен тырнак астыннан кер эзләп этләмәсеннәр.

Ахунҗановның чиста ак йөзенә тимгел-тимгел кызыл таплар бәреп чыкты — ул тырнак очларына хәтле ихлас күңелле, тырнак очларына хәтле үзе, һич ясалмасыз үзе иде бу минутта.

— Тырнак астыннан кер эзләргә урын калдырма, дип кисәтүем. Дус итеп әйтүем, Сәлим Садриевич,— дип, дусларча, аның аркасыннан кагып куйды секретарь.

## Ике җирдә икең—дүрт

Шулай гынамы икән? Ике җирдә икенең кайчагында биш булып чыгуы яки өч кенә булып калуы да мөмкин түгелме икән? Әнә бит Ахунҗанов белән аның хатыны Хәдичә арасындагы мөнәсәбәттә ике җирдә ике өч кенә була язып калды түгелме соң? Райүзәктән кайтышлый мунча керде Ахунҗанов, өстенә чиста күлмәк-ыштан киде, тәне җиңеләеп калды, ә җанына кирәк тынгыны тапмады. Хатын — Баланлыга күчеп барырга һич кенә дә сикереп тормый, нинди генә дәлилләр белән дә күндереп булыр кебек күренми иде. Бер карагаңда, хатынның каршы куйган дәлилләре көчлерәк тә, ышанычлырак та чыга кебек: кышка каршы кеше өстенә дүрт бала белән барып егылыргамы? Чын-чынлап эшләп-утырып калуы билгеле булмаган килеш мондагы нигезне таркатыргамы?

Мәргәнтауда төн кунып, иртәгесен шулай да күңел тынычлыгы таба алмыйча, төрле каршылыклы уйларга күмелеп кайтып килә иде, амортизаторлары какшаган иске машина, юлдагы сай гына чокырдан да курыккандай, бөтен саны белән дерелдәп куйды. Кинәт айнып киткәндәй

булды Ахунжанов, карасана, килеп эшкә керешү белән ул да, шушы какшаган машина кебек, чокырга төшмәс борын ук калтыранырга тотынды түгелме соң?

Ярый әле, алда, юл буендагы ташта берәү ял итеп утыра иде, барып житәр-житмәс борын ук танып алды: бу — «Алсу алан» кешесе, теге беренче кичне танышкан карт, ферма каравылчысы Хәтмулла булып чыкты.

— Утыр, Хәтмулла абзый. Әйдә, бергә-бергә юл кыска булыр,— дип, аның турына житү белән машинасын туктатты Ахунжанов. Хәтмулла карт үзе кебек тузган иске «берданка» күтәреп чыккан булган, беренче караштан ук яңа председательне таный алмаса да, машиналы булгач, һичшиксез, берәр «урындагы кешедер» дип уйлап, үзеннән дә битәр эшкә ярамас шул мылтыгы өчен уңайсызлангандай, каушабрак калды. Элек машина басмасы алдында аягын күтәрә алмыйча таптанып торды: «Атлаган булыр ием болай гына да. Аяк пычрак ич минем»,— дип көшкеләнгән булды, шул көшкелекнең бәласе, кер-ә башлагач, әлеге озын көпшәле мылтыгы аркасында, ишеккә аркылы килеп терәлде.

— Мондый кораллы кешене күздә тотмаганнар, ишекне бик тар ясаганнар, Хәтмулла абзый,— дип шаярткан булды Ахунжанов. Утырып, кузгалып китү белән, шундук сорашырга да тотынды.

— Терлек-туар кырда чагында бер әйләнеп кайтыйм, дип чыккан булган ием шунда,— дип, авыз эченнән бутка пешерде Хәтмулла карт. Ул хәзер инде үзенең һич уйламаганда яңа председательгә тап булганлыгын белеп, бераз шүрли калган, житмәсә тагы, шундый озын, шундый ишеккә сыймас мылтык күтәреп йөреп тә, коры кул белән кайтуы аның ирлек горурлыгына тигән, әгәр председатель сүз кушмаса, теш арасыннан бер кәлимә сүз дә чыгарырга жыенмый иде. Әмма Ахунжанов шулай да сүзне куша торды:

— Төнен каравылда, көндез менә мондый эштә... Кайчан гына ял итәсең соң син, Хәтмулла абзый?

— Эше корсын моның, үзе корсын. Бала-чага сүзенә ышанып, чыккан булганыем шунда. Төлке-мазар күренгәли диләр ич быел, әгәр чын булса...

— Куянга гына да түгел, төлкегә ук ният, алайса.

— Ният ие төлкедә, калдык менә көлкегә,— Хәтмулла картның шулай көйләп, рифмалап жибәрә торган гадәте элек-электән бар, шуның өчен аңа «тел бистәсе» дигән кушамат та тагылган иде. Шул гадәтеннән ул бу очракта да котыла алмады, ә үзе «нәчәнник» алдында болай теленә салынуыннан бер дә риза түгел иде. Шуңлыктан булса кирәк, бераздан кырыс кына итеп өстәп куясы итте:— Ник аптырадың, апаем, заманасында без төлкесен дә, бүресен дә атып алган кеше. Хәзер генә саңга сукмый башладылар Хәтмулла картны.

Картның күңелендә үпкәсе барлыгы тел төбеннән үк сизелеп тора иде, Ахунжанов житдирәк тонга күчте:

— Саңга сукмыйча нишләттеләр соң, Хәтмулла абзый, ачыграк итеп сөйләш сүзеңне.

— Ачык була-була ачка кала яздым инде, апаем,— диде ул, чишелергә бик үк теләр-теләмәс кенә,— югыйсә, мин каравылчы булып иске абзарларны саклап утыра торган әдәм түгел ием. Хәер, абзарлары да болай коелган хәлгә калмаган булырые, эшли белеп эшләгән кеше булса...

Кыскасы, картның заманасында яхшы ук тынгысыз жан булганлыгы, колхозны алга жибәрү юлында тәкъдимнәр кертәләп тә, ул тәкъдимнәрен игътибарсыз калдыра килүләре нәтижәсендә, инде аның «чебен дулап тәрәзә ватмас!» дигән карашка килеп, эчендә ризасызлык саклаганы хәлдә, мыштым гына читтә утырып калган бер кеше икәнлеге беленде. Күрәсең, аның отчет-сайлау жыелышына чакырылмый калуы да

элекке җитәкчеләрнең күпне белүче бу картны [illegible] кешеләргә күрсәтмәскә тырышуларыннан булган булса кирәк...

Ничек кенә димик, юлда туры килеп, утыртып алып кайту ярады, Ахунҗанов Хәтмулла карт белән, аның аркылы фермадагы кайбер эшләр белән дә якыннанрак таныша төште. Көндезге танышлык белән генә чикләнмичә, кичен, кеше аягы басылгач, ферма якларыннан бер урап та киләсе итте ул. Йокы барыбер килми, җан урында түгел, шул ук вакытта кешеләрнең урыннарында булып-булмауларын да үз күзләре белән күрәсе килә иде. Бигрәк тә көндез мылтык күтәреп, тоттырмаган төлкене куып йөргән Хәтмулла картның төнлә каравылда ничек торуы кызыксындыра иде аны.

Хәлбуки, Хәтмулла карт үз урынында һәм көндезгегә караганда да уяурак булып чыкты.

— Тукта, кем йөри анда? Атам, шартлатам,— дип, шаулап килеп чыкты ул каралты-кура арасыннан. Болай вакытсыз йөрүченең председатель икәнлеген белгәч, янә аптырабрак калды,— караңгының күзе юк, мазасы бар — сүзе юк, бу син икәнсең, апаем. Алла сакласын, үз прсидәтелеңне үзең атып үтерерсең.

— Атмый ич ул синең мылтыгың, Хәтмулла абзый. Көндез үз телең белән шулай дидең.

— Көндез нәмә сөйләмәс әдәм баласы, постта түгел чагында. Постта торганда килеп кара син Хәтмулла абзаң янына.

Чыннан да, көндезге зарлануының эзе дә юк, кыю сөйләшә иде карт бу төнге сәгатьләрдә. Шундый ук кыюлык белән ул председатель хәтле председательдән:

— Кая, көйрәтергә бармы синең, иптәш прсидәтел, йокы качырып, бер төтенләп алыйк, булмаса,— дип, папирос сорарга да җөрьәт итте. Кабыздылар. Өй буендагы бүрәнә өстенә утырып, ашыкмыйча гына тарта башладылар. Картның үзеннән-үзе җорлыгы ачылып китте:

— Дөресен генә әйткәндә, апаем, тәмәке эзләп чыккан чакка туры килдең. Хәтмулла абзаң болай чакта, нашатырь кыстыргандай, төнлә чыгып, каралты-кура әйләнәсендә чабып йөрмәс. Ник дисәң, кемгә кирәк синең төн йокысы качырып йөрүең. Барыбер күргән-кызыксынган кеше юк.

Картның болай, һич ясалырга тырышмыйча, ачыктан-ачык сөйләве Ахунҗановка ошады, үзе ясалуны белмәгәнгә, ул нәкъ әнә шундый ясалмасыз кешеләрне ярата, андыйлар белән тизрәк уртак тел таба ала иде. Бу очракта да карт җаена яткан атлы күренергә тырышып сөйләнде:

— Моңарчы алай булган, моннан соң алай булмас. Впрочем, Хәтмулла абзый, бүгенгә җил каравыллап йөргәне дә житкән. Ишетәсеңме, әнә ничек сызгыра.

Чынлап та, кайдадыр түбә кыегында, куплэгэн ярык-тишекләрнең әле берсеннән, әле икенчесеннән көзгә әче җил сызгырганы ишетелә иде. Карт, җил тавышына колак салып, бер мәл тынып торды. Аннары кинәт, һич көтелмәгән кырыслык белән кабынып, әлеп алып китте:

— Без көлә дип син көлмә, апаем,— ул папиросын тартып бетермәгән килеш атып бәрде, Ахунҗановның сүзләре аны нык кына кузгаткан иде,— без бу ярлылыкны күреп инде каешланган кешеләр. Көлсәк тә без тыштан гына көләбез, ә эчебез жылый. Җыларлык та, колхоз чаклы колхозны кай чиккә китереп житкердек, хет күтәреп торгыз. Ә сине, апаем, көләр өчен җибәрмәгәннәрдер. Безнең исерек башлар екты, син шуны күтәреп торгыз хәзер. Эшлә шуны егет булсаң.

— Ялгыз гына көчәнеп билеңне кузгатуың бар. Бергәләп... бергәләп күтәрик, Хәтмулла абзый.

Ләкин Хәтмулла карт аның нәрсә дигәнен анык кына ишетмәде, бер теле ачылганда ул эчен бушатып калырга ашыга иде.

— Монда, апаем, менә бу җил уйнап торган абзарларда сыер савучы кызларның куллары бирчәеп ката. Кайчанга хәтле ул шулай барыр икән? Элекке хуҗалардан сорап рәт чыкмады, сине яңа хуҗа итеп соравым.

Әлбәттә, бу сорауга Ахунҗанов шул минутта ук җавап бирә алмады, җавап бирергә маташып караса да, тел шартлату, җаһилләнү генә килеп чыгар, картны барыбер ышандыра алмаган булыр иде. Ләкин бу сорау, төнге сәгатьләрдә, икәүдән-икәү генә калган минутларда, гади колхозчы карт куйган бу кискен сорау аның күңелендә утырып калды. Димәк, җавабын да алар табарга тиеш. Сүз белән түгел, эш белән!

Ахыр чиктә, янә шул бер үк сорау килә башка: ике җирдә икен — дүрт кенә микән? Гади арифметика телендә ул, әлбәттә, шулай: ике җирдә икең — дүрт. Ә тормышта, баш җитмәслек катлаулы бу тормышта, вакыты-вакыты белән гади колхозчы карт авызыннан да әнә шундый тетрәткеч сораулар куела торган безнең бу тормышта ике җирдә икен дүрт кенә микән?

## Берничә көннән соң, иртә белән...

Борчу өстенә борчу — фермалар турында да кайгыртырга кирәк икән ләбаса! Ихтимал, бусы кышка каршы беренче чираттагы эш булса кирәк!

Сөйләшү булды. Партоешмада сөйләштеләр, бригадирлар белән бергәләп идарә утырышында да киңәш тоттылар. Бу утырышлар, сөйләшүләр бер-бер артлы тезелеп киткәч, Ахунҗанов хәтта эченнән генә уйлап та куйды: «Бу яңа предка утырыш җене кагылган, шуннан да ары китмәстер, ахры, бу... Дуслар алай уйламаса да, шулай уйлаучылар да булыр».

Әлбәттә, утырыш та файдасыз түгел, игътибар беләнрәк тыңласаң, анда да кемнең кем икәнлеген танырга мөмкин иде.

— Мәскәүне бер көнне генә корып куймаганнардыр, бөтенесенә бер көнне ябышып булмас,— дип, кабаланмаска өндәгән атлы булып, селкенмичәрәк калу ягын каердылар кайберәүләр. Бу сөйләшүләр вакытында һадиевның үзен тотышы Ахунҗановны аеруча сагаерга мәҗбүр итте. Ахунҗанов килә-килгәннән бирле, үзен алыштырган бу яңа председательне бик өнәмичә, ачыктан-ачык та, читләтеп-читләтеп тә аның бакчасына таш аткалап маташкан һадиев әлеге очракта яңа председательнең барлык тәкъдимнәрен кайнар рәвештә яклап чыкты. Алай гына әйтү аз, туктатып булмаслык ораторга әйләнде.

— Иптәш Ахунҗанов минем авыздан тартып алып әйтте сүзне: бөтенесе безнең үзебездән килеп туа, егетләр. Байлыгы да, фәкыйрьлеге дә. Тирә-күрше колхозлар һәрьяклап үргә күтәрелеп барганда, безнең генә тау төбендә чабата тузаны кагып, мышкылдап калуыбыз...

— Чабата беткәнгә биш былтыр, юкны сөйләмә, эшкә якынрак кил: нәрсә тәкъдим итәсең? — дип бүлдерделәр аны. Бүлдергәнне яратмады һадиев, кызып, авызыннан төкерекләр чәчә-чәчә дәвам итте.

— Бик алай тыңларга теләмәүчеләр, тәнкыйтьне күтәрмәүчеләр бар икән, әнә кискән ишек, чыгып китсеннәр. Мәгәр мин, зампред буларак, әйтәсемне әйтмичә кала алмыйм. Ә әйтәсе сүзем шул: болай барып булмый, иптәшләр. Ферманы кышка каршы бу хәлендә калдыру мотлак ярамаган эш түгел. Райком безгә житәкчелеккә иптәш Ахунҗанов кебек сыналган, һәрьяктан тәҗрибә туплаган, әйтергә кирәк, эшне белеп йөртә торган иптәшне җибәргән икән...

«Колагыңны сак тот, «сыналган җитәкче». Монда сине агач атка атландырулары да мөмкин!» — дип, эченнән генә көлемсерәп, уйланып

утырды Ахунжанов. Кабаланырга, әлбәттә, ярамый. Ләкин шул ук вакытта, көннәр аяз торганда утырышлар, озын-озын речьләр белән мавыгып, вакыт уздыру да җинаять булыр иде. Шунлыктан кулы эшкә ярардай бөтен кешеләрне исәпкә алып, шул җөмләдән моңа хәтле колхоз эшен бар дип тә белмәгән зампред хатыны Раушанияне дә кычкырта-кычкырта җитен җәю эшенә җибәреп, ә күп кешене ферма абзарларын сыларга, аннан кырга тирес чыгару эшенә кушып, көзге көннәрдән берсе тагын шулай башланып китте. Әлбәттә, председатель үзе аякта, кычкырынып йөрми, ләкин эш көненең башланганлыгын искә төшереп, искәрмәстән генә әле анда, әле монда калкып килеп чыга, киңәшләр бергәләп китә иде.

Ферма каравылчысы Хәтмулла карт белән алар, теге кичне аяк терәшеп бер сөйләшеп алганныкы булса кирәк, бу юлы һич тәкәллефсез очраштылар.

— Бөтенләй шыр ялангач калдырмакчы сез безне,— дип, әллә чынлап, әллә мыскыллап сүз кушты Хәтмулла карт,— болай әле, терлекләрне әйтәм, үз тиресләрендә үзләре җылынып ята бирәләр иде.

— Ә без аларны башкачарак җылыту чарасын эзләп карарга булдык, Хәтмулла абзый.

— Сөяктән сарай салыпмы? Эт тә ич кышын, койрык астына суык йөгерә башлагач, әйтә, имеш: «Җәйгә чыксам, сөяктән сарай салырием салуын»,— дип әйтә, имеш, чын булса.

Икесе дә мыек асларыннан гына көлеп куйдылар, ләкин бу ике төрлерәк көлү булып чыкты. Хәтмулла картныкы — ышанып җитмәүдән булса, ә Ахунҗановныкы — артык нык ышанудан һәм, бәлки, иртәрәк ышанудан булды булса кирәк.

— Син көләсең, картлач, ә без менә, исән булсаң күрерсең, синең бу җил уйнап торган әрбәлекләрең урынына сарайлар салачакбыз.

— Ә нигә миңа исән булмаска? Ансат кына мине җир астына илтеп тыкмакчы кеше. Сөяктән сарайлар салырга торганда.

— Сөяктән түгел, Хәтмулла абзый, таштан.

Бик өзеп әйтте бу сүзләрне Ахунжанов, сүзгә бик ышанасы килмәгән җор телле картның берьюлы авызы томаланды, күзенә яшьләрчә очкын бәреп чыкты.

— Таштан булса икенче эш, ташның орлыгы Бохарада түгел, тирәюнебез таш белән тулган.

Хәтмулла картның бу раславы үз нәүбәтендә Ахунжановны да ныгытып җибәрде. Килә-килгәннән, бу якларны күрә-күргәннән аның күнелендә бер хыял баш калкытып тора иде. Хәзергә әле кешеләргә шаулап йөрерлек дәрәҗәгә үк җитмәгән ул хыял чит-ят авылда, кеше бусагасында хатынсыз-ырусыз торып калган бу гидай бәндәне эчтән генә җылытып, очындырып йөртә иде. Йөрде, күрде, һаман күзәтә, хыялланып йөри Ахунжанов: бу «Алсу алан» колхозында игенчелек белән зур эш кырып булмастыр — чөнки җирләре шундый көлсу туфрак. Чокыр да чакыр. Бик нык ашлаганда, тирес керткәндә, әлбәттә, җиреннән дә тамак туйдырырлык кына сыгып булыр. Әмма кала кордыра торганы, кала ук кордырмаса да, колхозны башкалар рәтенә чыгарырдае — терлекчелек тармагы булырга тиеш. Моның өчен мәйдан күренеп тора монда. Тирәякта киң көтүлекләр, җәелеп яткан болыннар, бәрәкәтле Ык буе, бәләкәй булса да урманнар... Сүз дә юк, үтәли җил уйнап торган хәзерге ферма каралтылары белән түгел, икенчеләрне, моңа хәтле төшләренә дә кермәгәнне корып... Болай хыяллану өчен Ахунжановның күңелендә нинди дә шытымнар да юк түгел иде. Әйткәнебезчә, килгән беренче көннәрдә, басулар карап йөргәндә үк баш калкытты ул шытымнар. Авылдан ерак түгел, Ыкның тау як яры өстендә, исеме дә каһәрләнеп Шайтан тавы дип аталган, сөрелми-файдаланылмый ята торган сырт урын бар. Аннан кайчандыр таш чыгарганнар. Чокыганнар да кергәннәр

бер мәешне. Тирәнгәрәк киткәч, җир асты пәрие чыгар дип шүрләгәннәрме, көч җитәрлек булмаганмы, туктатканнар, ташлаганнар. Хәлбуки, аның тирә-юнендә дә, хәтта өске катта ук, котырып үскән чүп үләннәре, билчәннәр, алабута һәм шайтан таяклары арасында беләү-беләү ак ташлар кояшта кызып яталар иде. Башкаларның күзе төшмәгән, төшсә дә, шуып узып киткән бу Шайтан тавы сыртына аеруча игътибар белән күз ташлады Ахунҗанов. Күз ташлады һәм әнә шуннан бирле аңарда яшертен бер хыял кабынды: анда әле бик күп, бик зур таш байлыгы качып ята булырга тиеш. Кул сузымы гына җир үзе. Актарасы да аласы. Аласы да китереп саласы.

Дөресен әйткәндә, бу иртәнге кояшлы сәгатьләрдә Хәтмулла картка «сөяктән түгел, таштан!» дип үтә кистереп биргән җавабында аның әнә шул хыялы бәреп чыкты да инде.

Шуннан соң берничә көн буена ул тынгысыз председатель ничектер күзгә чалынмыйчарак торды. Моннан иң нык рәхәтләнүче кеше Мыек Миргасыйм булды. Рәхәт, тыкырдатып торучы юк, мыек чылатканны-чылатмаганны сизүче дә юк. Ә председательне авылына — хатыны янына кайтып китте, дип юраучылар да булды, арада «хатынын еш искә төшерә башлады, порохы бетте бугай яшь әтәчнең» дип, мыскыллап теш агартучылар да булмады түгел. Ләкин эшнең соңгы көннәрдә һәрьяклап терелеп баруы өчен куанган һәм монда яңа председательнең «кулын» күргән чын колхозчылар бу «югалу»ны борчылып сизеп тордылар.

Хәлбуки, берниндн югалу да, хатыны янына кайтып китү дә булмаган, безнең ул «яшь әтәчебез», киртә өстенә басып кычкырырга ашыкмыйча, әкрен генә эш белән йөргән, имеш. Беренче көнне ул машинага лом, тимер көрәк салып, кеше-карага шаулап тормастан, Шайтан тавына китте. Тауның әле теге, әле бу төшенә көрәк төртеп карады — таш бар, таш аста яткан җиреннән тонык кына тавыш бирә иде. Өстәге юка катларны кузгаткач, астагылары тимер көрәкне генә «тыңламый» башладылар, аларына лом кирәк булды. Тагын да астагыракларының лом белән дә бик алай кузгаласылары килми, бульдозер сорыйлар иде шикелле.

Сызганып тотынган Ахунҗанов ялан уртасында башын кашып калды... Таш бар, хыял бар, әмма хыялны тормышка ашырырлык, мең еллар буена йокыга талган ташларны кузгатырлык көчле техника «Алсу алан»ның үзендә юк иде. Шуннан соң Ахунҗанов, шулай ук бер кешегә дә әйтеп тормастан, күрше Чапаев исемендәге колхозга чапты. Тегеләр башта зәкять өмет итеп килгән сала ярлысы белән сөйләшкән элекке кала бае булыбрак сөйләштеләр. Әмма кыйммәтле төзү материалы — таш җаный «бай абзый»ларның да күзләрен яндыра, ә таш Шайтан тавында, ә Шайтан тавы Ахунҗанов колхозында иде. Шунлыктан, Ахунҗанов агай да сала ярлысы булып түгел, үз малының хуҗасы булып сөйләште. Идарә йортында сөйләшү белән генә калмыйча, ике председатель өйгә кайтып, өченчегә алларына «ярты»ны да куеп, чын хуҗаларча сөйләштеләр. Дөрес, эш базардагыча кул чабуга кадәр үк барып җитмәде, әмма килешү ташламасыз булды: таш һәм эш куллары Ахунҗановтан, бульдозер һәм таш белән «сөйләшә алырдай» өч ир — «Чапаев»тан. Бүлешү ягыннан да соңыннан таш бәрешеп сугышырга урын калдырмадылар, өзеп сөйләштеләр: өч кубометр — «Алсу алан»га, бер кубометр — «Чапаев»ка. Шулай итеп шул, хәзергә әле чыкмаган, тау эчендә йоклап яткан ташны ике председатель үзара бүлешеп тә куйдылар.

— Хәзер инде бәләкәй чут — бу зур эшкә колхозчыларның фатихасын алу гына калды,— диде Ахунҗанов, мәгънәле көлемсерәп. Әмма шул «бәләкәй чут» бу эшкә ризалык бирмәсә, ике белдекле председательнең әллә ни кыра алмаячагын ул бик яхшы белеп тора иде.

Җыелышлар, утырышлар күпкәрәк киткәнлектән, Ахунҗанов күршеләр белән уртаклашып таш чыгаруга керешү мәсьәләсен әллә идарәнең, партактив белән берлектә, киңәйтелгән утырышында гына караргамы, дип тә уйлаган иде. Ләкин партоешма секретаре Тәлгать Хәкимов алай гына уздыруны килештермәде.

— Җире дә, ташы да колхозның төп милке. Тем более күршеләр белән алыш-бирешкә дә керәсе булгач, колхозчыларның ризалыгын алмыйча ярамас, демократияне бозу килеп чыкмасын,— дип каршы төште.

Әлбәттә, килешергә туры килде. Яңгырлы, яхшы ук караңгы октябрь кичләренең берсендә, эштән соң, колхозчыларның гомуми җыелышы билгеләнде. Көн тәртибен бик үк ачык әйтеп бетермичә, «Колхозда яңа төзелеш мәсьәләләре» дип кенә билгеләгәннәр иде. Моны төрле кеше төрлечә аңлады. Бериште гел кыр эшендә йөргән колхозчылар: «Миңа кагылмый, аягына резинкә-кәвеш киеп, кулына балта тотып, идарә тирәсендә остарып йөрүчеләр эше. Җыелсыннар да сөйләшсеннәр»,— дигән кебегрәк фикер йөртеп, йокыга тартып торган бу яңгырлы кичне чыгып йөрмәскә булдылар. Өйләре, каралты-куралары туза төшкән икенче берәүләр, «Алсу алан»га килүе белән акча өләшә башлаган бу юмарт председатель «Әллә җиңел кулдан безнең ишеләргә колхоз чутыннан өй салдырып бирергә җыенамы? Авыз ачып калмыйк тагын!» дип уйлап, вакытыннан элек үк идарә йорты белән клуб тирәсендә чуалырга тотындылар. Ахунҗанов, хәл ителәсе әлеге мәсьәлә белән барыннан да элек ферма кешеләре кызыксынырлар, дип уйлаган иде. Ләкин кичке савымнарның озакка сузылуы аркасында, аларның да байтагы килмәде. Килгәннәре дә кышын-җәен бирчәеп сыер имчәге янында утыручы кызлар түгел, күбесенчә аларның әти-әниләре һәм, шулай булarak, фермада эшләүнең кыенлыгын кеше авызыннан гына ишетеп белүчеләр иде. Икенче эш, әйтик, Хәтмулла карт. Алдан берничә мәртәбә очрашып сөйләшү картта бу яңа председательгә карата җылы өмет кузгаткан иде, җитмәсә, җыелыш алдыннан көндез Ахунҗанов аны кабинетына чакыртып, колагына гына салып та куйды:

— Теге кичне минем алда ферма кызларын яклап бик каты речь тоткан идегез, Хәтмулла абзый. Бүген җыелышта сүз нәкъ ферма турында барачак, җәмәгать алдында ярып салыгыз әйтәсе сүзләрегез булса,— диде.

Шушы кисәтүне искә төшерепме, үзенә кинәт болай игътибар итә башлауларыннан очыныпмы, Хәтмулла карт инде әллә кайчаннан шул тирәдә чуала, идарә йортына бер керә, бер чыга, сүзе сыярдай кордашрак кешене күрсә, аңардан: «Югартын килгән берәр начәнник тә булачакмы? Әллә үзара эч бушату гынамы? — дип сораша, аннары шул уңайдан,— кара әле, бармы синең яныңда? Эшкә керешкәнче берәрне көйрәтеп алыйк. Минем үземнеке кибеттә онытылып калган»,— дип, уены-чынын бергә кушып, папирос сорап ала, шуны бер кырыйга чүгәләп, тәмләп кенә тарткан җиреннән «җәмәгать алдында ярып салачак» сүзләрен иреннәре арасында кыймылдата башлый иде.

«Югартын килгән» кешеләр юк, әмма күрше «Чапаев» колхозыннан ике вәкил президиумга ук менеп кунаклаган иде. Эшкә керешү, һәрхәлдә, Хәтмулла карт көткәнчә тәкәллефле булмады. Хәтта ул беркатлы карт телене салынып «аткан» папиросын ахырынача тартып бетерергә дә өлгерә алмый калды, сәхнә ягыннан бик зәһәр кыңгырау тавышы яңгырады. Сәхнәгә куелган кызыл япмалы өстәл артына Ахунҗанов үзе, партоешма секретаре Хәкимов, ферма мөдире Шакирҗанов,

янә әлеге шул «Чапаев» колхозыннан килгән ике кеше менеп утырган иде инде. Хәтмулла картны аптыратканы бигрәк тә шул булды: беренчнди кул чабусыз-нисез җыелышны ачып җибәрделәр.

— Без барыбыз да эш кешеләре,— диде Ахунҗанов, сүзне кырку гына башлап,— эштән генә кайттык, иртән тагын эшкә барасыбыз бар. Шуны искә алып...

— ...Бауның озын, сүзнең кыска булганы яхшы,— дип, аны куәтләп куйды урыннан берәү.

Ләкин, ничаклы гына кырыс тотынмасыннар, сөйләшә башлагач сүз чыкты. Мәсьәлә бик җитди иде, аны бердән хуплап, күтәреп алучылар булганы кебек, сүздә хуплап та, асылда төрле яктан төрлечә мөгез чыгарып, мәсьәләне катлауландырырга, кешеләрнең күңелләренә шик корты үрләтергә тырышучылар да булды. Шундыйларның берсе нәкъ менә Һадиев булып чыкты:

— Мин иптәш Ахунҗановның тәвәккәллегенә, инициативасына сокланып бетә алмыйм,— дип, гадәттәгечә, председатель алдында тәлинкә тотыбрак кереште ул,— карагыз әле, ничәмә-ничә еллар шушы колхозда чиләнеп, безнең башка да килмәгән. Бактың исә, хәзинә бит бу, аяк астында яткан хәзинә. Мәгәр ашыкмыйча гына бер уйлап карыйк, җәмәгать. Кабаланмыйча уйлап карасак, уйландыра торган яклар бар бу эштә. Беренчедән, ул таш дигәнебез бик үк аяк астында түгел, җир астында, җиде кат җир астында. Уйлап карасаң, җир астында да сикереп чыгарга гына торамы икән әле ул? Анда, ул Шайтан тавы дигән урында, безгә хәтле дә казынып караучылар булды, мәгәр әллә ни кыйрата алмадылар. Бүген генә ул безгә дигән бәрәкәтен өеп куйдымы икән?.. Икенчедән... Дөрес, мин законын белмим ул хәтле, может тегеләй дә, болай да сузып була торгандыр. Чи тире кебек бит ул закон.

— Син, Бакый энем, законга тел тидерми генә сөйләш, яме,— дип, түземсезләнеп, Һадиевны бүлдерергә ашыкты Хәтмулла карт. Ул алгы рәтләрнең берсендә утыра, җитмәсә тагын, бик тә сөйлисе, сүзгә катнашасы килеп утыра иде,— закон ул үзебезнеке, совет законы. Бөтен урт тешләрем коелып беткән ие минем, пример әйтсәк, закон миңа бер тиенсез теш куйдырып бирде.

— Сүз теш турында түгел, таш турында бара, бутама, Хәтмулла абзый.

— Әйе шул, таш турында и, пример әйтсәк, җир астындагы таш турында бара,— дип кодрәтләнеп, ялгап алып китте Һадиев,— сүздән әйтик, җир астында аны безнең өчен әрдәнәләп өеп куйганнар, ди. Ул чагында да бит әле җирне казып алырга кирәк. Ә җир, ачык кына итеп әйтә калсак, кемнеке? Казнаныкы.

— Ә казна кемнеке? — дип кычкырды яшьрәкләрдән берәү. Бәлки, шул яшь тавыш булганныкыдыр, шактый гөрләп чыкты бу. Халык арасыннан бер мәл, яфракларны кыштырдатып узган коры җил кебек, гөҗләү кыштырдап узды.

Бу әле башланып кына китеше иде. Ахунҗанов җыелышны ничек кенә тиз тотарга тырышмасын, уңай якка да, икеләнеп тә, кирегә сукалап сөйләүчеләр дә байтак булды. Берәүләр күршеләр белән кушылып эш итүне ошатып җиткермәделәр, күршеләрнең боларга караганда баерак булуы аларны сагаерга мәҗбүр итә иде.

— Чапаевныкыларда аларда борын бик күтәренке, тәкәбберлек зур, үзегезнең кулыгыздан килмәде, без чыгарып бирдек ташыгызны, димәсләрме?

— Алмаган ат, тумаган тай. Әле ташның чыгасы бар.

— Чистый. Чыгуын чыкса, борын анысы минем үземдә дә аллага шөкер.

— Борын дисең син, урын диген.

— Мена-мена. Мин дә шуны әйтәм: кая куярбыз икән ул ташны? Әле агач белән җүнләп эш итә алмыйбыз. Абзарларыбызның түбә тишек, өсте ачык.

Ничек тә Һадиев ягын каерып сөйләшүчеләр баса башлагач, Хәтмулла карт түзмәде, дәррәү сикереп торды һәм, ярканат кебек, чикмән итәкләрен җилфердәтеп, сәхнә ягына таба атлады. Аның сүзен дә, үзен дә гел бер мәзәк итеп кабул итәргә өйрәнгән яшь-җилкенчәк янә шаулап алды.

— Китте... Китте Хәтмулла абзагыз таш дворец салырга.

— Сүз сорап кирәк, Хәтмулла абзый.

— Сүзне мин кешедән сорап алмыйм, сүз минем үзем белән йөри,— диде Хәтмулла карт, залга берьюлы йөзе белән әйләнеп. Тагын шунысына да игътибар иттеләр: карт бу минутта мәзәк сөйләргә җыйналмый, ул һич көтелмәгәнчә җитди иде һәм шулай җитди хәлдә, хәтта бераз ачуланган да кебек итеп, ташып китте.— Мин сезгә театр түгел, авыз җырып утырмагыз. Беләсегез килсә тагын шуны да белегез: Хәтмулла абзагыз шушы колхозның нигез ташларыннан берсен салган кеше, так што аның һәр әйткән сүзеннән кәмит корып утырырга ничу! Инде килеп бүген көн тәртибендә, әйтик, Шайтан тавыннан таш чыгару и ул таштан колхоз терлекләре өчен двор кору мәсьәләсе тора икән, мәгәр шуны белеп китегез, Хәтмулла абзагыз бу көн тәртибен и аны бүгенге көн тәртибенә китереп куйган иптәш Ахунҗановны ике куллап яклый. Бик дөрес и бик вакытлы кузгатылган эш бу! Нилектән бу чаклы өздереп әйтәмме? Потому што Хәтмулла абзагыз двор янынннан үтеп-сүтеп кенә йөрүче түгел, Хәтмулла абзагыз көне-төне, кышын-язын шунда — двор арасында чиләнүче. Хәтмулла абзагыз салкында, җилдә сыер савучы кызларның бичәеп каткан кулларын иртән дә, кич тә күреп тора. И ул куллар гел шулай катсын-өшесен дисез икән, Хәтмулла абзагызның бу әйткән сүзләрен кәмиткә чыгарыгыз, көн тәртибенә бөтенләй кертмәгез ул сүзләрне. Инде килеп, ул куллар катмасыннар-өшемәсеннәр, терлекләребез итле һәм сөтле булсын дибез икән, ташы да, Хәтмулла каравылчының сүзе дә, и килеп, бүген иптәш Ахунҗанов китереп куйган көн тәртибе дә нәкъ үз урынында. И сузып торырга ничу! Иртәгә үк, аллага тапшырып, эшкә башларга. Минем әйтәсе килгән сүзем менә шул.

Борылып урынына килешли ул шулай да үзенең гадәттәге җорлыгыннан башка булдыра алмады:

— Сорап-сузып торсаң, алырсың монда сүзне. Унъеллыкны бетереп чыккан белдекле малайлардан артмый хәзер сүз.

Күрше колхоздан килгән вәкилләр дә, гәрчә алар «Унъеллыкны бетереп чыккан белдекле малайлар» булмасалар да, әйтәсе сүзләрен әйттеләр. Кыскасы, икеләнүчеләргә, ышанып җитмичәрәк торучыларга караганда, фатиха бирүчеләр күбрәк булып чыкты — алабуталар, шайтан таяклары күләгәсендә йоклап яткан Шайтан тавына селкенә башларга вакыт җитте бугай, ахры.

## Аяк астыннан янә бер мәшәкать

Беркөнне шулай иртәгесен Андрей дәдәй, табышмакка охшатып, үзеннән-үзе кеткелдәп көлеп куйды. Ахунҗанов, чәйгә хәтле бер кат бригадаларга йөреп кайтып, бик тәмләп иртәнге чәйне эчеп утыра иде. Әлбәттә, Андрей дәдәйнең көлүенә игътибар итмичә кала алмады ул.

— Ни булса да бар синдә, Андрей дәдәй. Әллә бүген тавык суябызмы?

Аларда фатир торган шушы кыска вакыт эчендә Ахунҗанов бу киң күңелле картның юктан гына да очынып китә торган вак-төяк җорлыкларын, шулардан берсе, мәсәлән, тавык-чебеш суйган көннәрдә бик тә җилъякланып, фатирчы егеткә алдан ук:

— Бүген тавык ите пешәчәк, факыр, колагыңа киертеп куй,— дип, нәрсәнедер тегенең исенә төшерергә тырышып, ым кагып куюы кебек гадәтләрен дә белеп бетергән иде. Ләкин картның бүгенге очынуы сыйланасы килгәннән түгел икән.

— Дуся әбиеңнең серкәсе котырган чак бүген, ник дисәң, кичә мин аны театр уйнарга җибәрмәдем.— Бераз авыз чите белән көлемсерәп утырганнан соң өстәп куйды: — Клуб атаманы килгән ие кичәгенәк. Алабугадан театр эшенә өйрәнеп кайттым дип тормаган, бүреген култык астына кыстырып, «пужалсты»лап килгән: янәсе, алар театр куярга җыеналар икән дә, шунда шул әртилләренә бер тешсез карчык җитми икән. Ямадым авызын шулай да, Алабугада укып кайткан кеше дип тормадым. Беренчелектән, мин әйттем, Дуся тәтәегезне тешсез карчыкка санап йөрүегез белән бер наданлык күрсәткән булсагыз, икенчелектән, мин әйттем, Дуся тәтәегез үземә бәк кирәк, мин аннан башка ни тудым, ни сюдым дидем. Әйтер ие, сүз калмады клуб атаманына, чырлы сүзне алдан мин әйтеп өлгердем.

Картның уйный-көлә җиткергән бу хәбәре шулай да Ахунҗановны уйландыра калды. Моңа чаклы башка да килмәгән: карасана, иске булса да клуб дип атала торган урыны бар бит «Алсу алан»ның. Булды заманнар, Мәргәнтауда чагында Сәлим-сәламәт клуб эшендә актив катнаша, концертларда җырлап-биеп, һөнәр күрсәтә, спектакльләрдә зур-зур рольләрне башкара торган иде. Авылдашлары яратып карыйлар, мактыйлар иде үзен. Алардан да битәр, бу ыгы-зыгылы эшне үзе ярата иде Ахунҗанов. Мәсәлән, «Галиябану» пьесасында Хәлил ролен бик тә яратып, чын ихластан гашыйк булып уйнаганнан соң ул, шул чорларда ике кызыннан соң туган бердәнбер һәм бик тә кадерле ир баласына, хатыны Хәдичәнең, берәр яңачарак исем табасы иде, дип әйтүенә дә карамастан, тотты да Хәлил исеме куштырды. Хәер, ул чагында бригадир гына иде шул ул һәм аннары үзенең туган авылында иде, ни эшләсә — шул килешә торган чак иде.

«Ә соң монда? Председатель кешегә спектакльдә уйнау килешми, дип кем хатыны әйтте? Уйнамаса да, һәрхәлдә, кызыксыну эчне төртеп тишмәс бит!»

Һәм ул, идарәгә барып чыгу белән, беренче эше итеп клуб мөдире Бәдриевне чакыртып китертте.

— Йөргән булабыз сөйләнеп, барып чыгармы, юкмы,— дип башлады клуб мөдире, шапырынырга ашыкмыйча,— кешеләребез җитми, ора алмаган олы күсәк күтәрдек бугай үзебез дә.

Сөйләшә торгач аларның чынлап та күп кешеле, катлаулы, бай декорация сорый торган зур нәрсәгә — Таҗи Гыйззәтнең «Бишбүләк» драмасына ябышырга торганлыклары билгеле булды.

— Ә сез тотыгыз да «Галиябану»ны куегыз. Кешесе дә күп түгел, сәхнәсен дә үз байлыгыбыздан оештырырга булыр.— Бер дәртләнеп киткәч, озак уйлап тормастан, хәтта ул һич көтелмәгән тәкъдимне дә ычкындырып ташлады.— Каршы килмәсәгез, Хәлил ролен шартлатып үзем уйнап бирермен. Авылда чакта күп мәртәбәләр уйналган, сүзләренә хәтле хәтердә. Әйдә, председатель башы белән тамаша корып йөри, дип көлсәләр көләрләр.

Яшьлек тилелеге яңадан әйләнеп кайткан бу минутта җиңел генә телдән ычкынган шул бер сүз җитә калды, председатель дип тормадылар, аны араларына бөтереп алдылар, кыскасы, аяк астыннан тагын

мәшәкать килеп чыкты: председателебез искәрмәстән генә артист та булып китте. Дөрес, ул репетицияләрнең барысына да катнаша алмый, әмма катнашкан чаклысында эшкә җитди карый, кайчандыр уйналган булганлыктан, Хәлил роле аңа җиңел бирелер кебек күренә иде.

Ләкин, шул ук вакытта, эшне катлауландырыр кебек яклар да күренеп тора: Галиябану роле әлеге теге кибеттә эшләүче Мөршидәгә тапшырылган, ә ул шулай ук бик очынып йөри, рольгә ябышып ята, әллә нидә бер, башкаларга сиздермичә генә, әмма Ахунҗанов абыйсына бик тә сиздерергә тырышып, керфек астыннан томырылып-томырылып аңа карап та алгалый иде. «Кара әле, Ахунҗанов абый! Син дә кеше, мин дә кеше. Синең дә җаның бар, минем дә җаным бар. Нигә син миңа пьесадагы Галиябану итеп кенә карарга тиеш тә, нигә тормыштагы, Баланлы авылындагы ялгыз-баш тилмерүче Мөршидә итеп тә карамаска тиеш, ди?» — шулай дигән кебек тә була иде аның ул карашлары. Ахунҗанов мондый астыртын-хәтәр карашларга игътибар итмәскә тырыша — мөмкинме соң, тиле, юкка-барга игътибар итәргә. Председатель башың белән, коммунист башың белән һәм, аннан килеп, дүрт бала атасы башың белән... Шулай да күңеленең кайсыдыр яшертен бер почмагында уставка сыймый торган кытыклану баш калкытып куйгалый. Кытыклану һәм сискәндерә торган уйлану: «Чибәр бит бу гөнаһ шомлыгы! Я, шулай дигәннән ни була, Сәлим-сәләмәт, чибәр бит, ләгънәт төшкере. Үрмәкүч авы. Аяклы котвы. Ирдән кайткан вәсвәсә. Ә шулай да килешергә тиешсең, председатель. Рольне бик тә килештереп чыгара ул котвы. Ә репетицияләргә ничек очынып килә».

Ничек кенә чәбәләнмәсен, ләкин бер башлагач «уен»нан чыгу мөмкин түгел, спектакльне куйганчы шул тирәдә чуалырга кирәк иде. Ә Мөршидә-вәсвәсә, спектакльгә әзерләнү форсатыннан файдаланып, күзгә күренми торган ефәк җепләр белән уралганнан-урала бара. Әлбәттә, күңелендәге барлык яшертен серләрен берьюлы селкергә ашыкмый, күбесен уен-көлке, шуклык-шаянлык аша үреп бармакчы... Репетицияләргә киенеп-ясанып килә. Рольне ятлап өлгергән, ишектән кереп өстен чишенгәндә үк, яртылаш Галиябануга әйләнеп, «Сәгате ай, ае елдай, шул кадәрле сагындым» дигән җырны сузарга тотына иде. Ахунҗанов ул килгәнче килеп җиткән булса, Мөршидә-Галиябану әлеге җыр кисәген катырак суза, һәрхәлдә, «Хәлил»гә ишетелерлек итеп әйтә. Әгәр Ахунҗанов килеп җитмәгән булса, бик алай тырышып сузмый, шаярткан булып, ә чынлыкта исә уенын-чынын бергә кушып:

— Минем Хәлилем килеп җитмәгәнмени әле? Болай булса, үзенә үпкәләсен, тәрәзәмнән тартып ала алмамдыр мин аны,— дип, шаяртып куйган була иде.

Хәтта бер көнне, көтеп-көтеп тә Ахунҗанов килеп җитмәгәч, режиссерлык итүче укытучы репетицияне башлап җибәрергә булган иде, Мөршидә исә, бу юлы шаяртып торуны һич тә кирәк тапмыйча:

— Ничек инде ул?.. Хәлилдән башкамы? — дип, үзе дә сизмәстән, кычкырып җибәрде һәм, үз сүзләреннән үзе үк уңайсызланып, колак йомшакларына хәтле кызарып калды. Киң күңелле булыйк, дуслар, шундый яшь, шундый чибәр, шулай өлгергән-пешкән килеш ялгыз утырып калган бу «ятимә»нең күңеленә вакыт-вакыт иләс-миләсрәк уйлар килеп, искәрмәстән генә шулай кычкырып җибәргәли икән, аны каты хөкем итмик. Барыбыз да кеше, барыбызның да йомшак якларыбыз бар.

Ә Мөршидә-исәр баш «Минем Хәлилем!» дип шаяртып эндәшүләре, пьесадан отып алган җырлары, репетицияләргә вакытыннан элек һәм бик тә киенеп-ясанып килүләре, очынып йөрүләре белән генә әлегә хәтле безнең каты бәгырьле председателебезнең башын үзенә таба чак кына да бора алмаган иде, көннәрнең берендә йомыш тыңлап торуы, бугазга нужа килеп терәлгән минутта хәлгә керә белүе белән

хәтта энә шундый буйбирмәс кешене дә бора язды. Ә бу болай булды: Ахунҗановка беркөнне әлеге теге рессорлары какшаган, чокыр күргән саен алдан ук калтырана башлый торган машинасы өчен өр-яңа рессор тәкъдим иттеләр. Моны, әлбәттә, бухгалтерия һәм банк аша законлаштырып алырга кирәк иде. Ике сәбәп аркасында председатель моны шау-шусыз гына, икенче төрле әйткәндә, «итәк астыннан» гына эшләргә мәҗбүр булды. Беренчедән, тәкъдим итүче кеше шул минутта ук дигәндәй акчалата сорады, икенчедән, «Алсу алан»ның кассасы гомумән коргаксыган чак иде. Килеп тәрәлде бит шундый чакта әлеге шул бик тә кирәкле рессор. Аны-моны һич уйлап тормастан, тотты да кибеткә — Мөршидә хозурына йөгереп килде Ахунҗанов.

— Синдә — кибетче кешедә булмыйча булмас, коткар абыеңны, биреп тор колхозга фәлән сум акча,— дип, мәсьәләне кабыргасы белән куйды.

— Колхозга дигәч тә уйлап караган булырием, үзеңә дип сорасаң, берсүзсез, Ахунҗанов абый,— диде тегесе, бурыч сораучы алдында ни сәбәптәндер үзе алсу-кызылга манылып һәм әллә ни волокита корып тормастан, кассада булган акчасыннан сораганны санады да биреп җибәрде.

Нәкъ менә шушы юмартлыгы белән безнең председателебезнең тез астына сукты да инде, рәхмәт төшкересе. Бер үк вакытта аптырап һәм уңайсызланып калды Ахунҗанов. Алла сакласын, итәгеңне-җиңеңне җыебрак йөрмәсәң, нәкъ әнә шундый яхшы яклары белән аулап куюлары бар монда! Тизрәк... ничек тә тизрәк үзеннекеләрне үз янына — Баланлыга күчерү чарасын күр, Сәлим җаным! Ихлас күңелдән әйтәбез бу сүзне.

Бәлки, шулай яшертен-серле өметләрне кушып үргәнгәдер, спектакль шәп килеп чыкты. Халык күп иде, клубка сыймаганнары, ишекне ачып, ишек төбеннән үрелә-үрелә карадылар. Һәм шунда Ахунҗанов-артистның башына келт итеп тагын бер фетнәле уй килеп төште: «Зуррак клуб салдырырга да кирәк ләбаса әле». Мөршидәне моңарчы гел кибеттә, «баш төзәтә» кергән узгынчы ирләр арасында, тегеләрнең кыеклап әйткән тозсыз сүзләренә аты-юлы белән ун җавап кайтара торган һәм гомумән бирәү алдында да әҗәтле булып калмаучы бу чая, иранай хатынны шундый сөйкемле, мөлаем, ихлас гашыйк кыз ролендә күреп, бигрәк тә аның моңлы, аһәңле җырларын ишетеп, авылдашлары башта аны танымый тордылар. Таныгач, авыз эчләреннән пышылдап:

— Үзгәрсә дә үзгәрә алыр икән кеше, чын артист булып Казанга гына китәсе бар,— дип куйды беришесе. Икенчеләре, җорлыкларын кая куярга белмәгәнлектәнме, әллә инде көтәчәккә «баш төзәттерми» торган бу каты бәгырьле «кибетче-артист»ны берьюлы үстереп җибәрергә ашыкмаганлыктанмы, шулай ук авыз эчләреннән генә пышылдап, каршы төшеп маташтылар:

— Казан дисең син, Казан ерак бит ул, бер китсә, аннары кайтып күренмәс тә Мөршидә апаң. Лучше давай, путевканы Минзәләгә яз: Минзәлә театрына гына китсен.

Чынлап та, нык үзгәргән, мөлаемланган, гадәтенә хилаф буларак, басынкыланган иде спектакльдәге Мөршидәбез. Ләкин бу үзгәрешнең ни сәбәптән туганлыгын берсе дә сизмәде. Шул җөмләдән Ахунҗанов та, берни дә сизмәгәнгә сәлышып, әйтә куйды соңыннан:

— Сез бик күтәрдегез бүгенге спектакльне, Мөршидә. Күз тимәсен берүк.

— Тиясе ике күз тигән инде миңа,— диде Мөршидә, сүзгә кесәгә кереп тормыйча. Ләкин моның җавап түгеллеген ул шундук абайлады, күңеле кузгалган минутлар, уеннан алган тәэсире дә суынмаган

иде, зур эчке дулкынлану белән, авыз эченнән генә пышылдап һәм гаять җитди итеп, өстәп куйды аннары:

— Янымда сез булганга күрәдер, Ахунҗанов абый. Сез Хәлил була белмәсәгез, мин дә Галиябану була алмаган булыр идем.

Соңыннан игътибар итте Ахунҗанов бу сүзләргә: бусы инде пьесадан түгел, бусын ул Вәсвәсә чын-ихластан әйтте, әйтмичә кала алмаганлыктан әйтте бугай. «Юк, юк... сузма артык, Сәлим иптәш,— дип үзе белән үзе өзеп сөйләшеп куйды председатель,— тап уртак тел, китер үз ояңны. Китер!»

## Тагын кайтты, тагын сүз башлады

Чыгасы тирес тә чыкты, кыр эшләре дә түгәрәкләнде, Шайтан тавыннан эре-эре ташлар да актарыла башлады, спектакль дә ярыйсы үтте, ә шулай да... шулай да Ахунҗановның күңеле урынына утырып җитми. Нәрсәдер юк һәм бу юклык көннән-көн үзен ныграк сиздерә бара иде. Бактың исә, һич тә баш җитмәслек нәрсә түгел: янында гаиләсе юк, балалар чыр-чуы юк, кайтып кергәч «әти!» дип итәккә ташланучы, аяк арасыннан үтеп йөрүче чәчбиләр юк, күңел әледән-әле шуларны юксына икән! Югыйсә, ике көннең берендә телефон шалтыратып, хәлләрен белешеп тора, ләкин нәрсә ул телефон? Ул сиңа, бер канат астына җыелып, чүкердәшеп яшәүне алыштырамыни?

Җитмәсә тагы, монда Мөршидә атлы теге гөнаһ шомлыгы очраштыргалап тора. Бигрәк тә беркөнге спектакльдә ул Галияне, Ахунҗанов Хәлилне уйнаганнан соң үтә әрсезләнеп китте. Узганда-барганда очраса, ачык йөзе белән балкып әллә кайдан исәнләшә, Сәлим дигән исемне гүяки бөтенләй онытты, Хәлил! Хәлил абый! дип кенә эндәшә, үзенең иреннәре арасында һәрвакыт шук елмаю булыр, гүяки әйтә шул ук елмаюы аша: «Нишләп болай күзгә-башка чалынмыйсың син, Хәлил абый җаным, бер тирәдә торып?»

Кыскасы, алла үзе сакласын, хагы да, нахагы да уйламаганда килеп чыгуы бар. Әлбәттә, Ахунҗановка билбауны кысып, итәкнеҗиңне җыеп, сүзгә урын калдырудан сакланып йөрергә туры килә.

Бер нәрсә ачык: сүзгә-шиккә урын калдырмас өчен гаиләне китерергә, ояны бергә тупларга кирәк. Бу яктан иманы камил Ахунҗановның. Ләкин бүген, иртәгә генә моны ничек башкармак кирәк. Андрей дәдәйләр аны гаиләсе белән кертергә риза түгелләр. Килеп, рәтләп эш күрсәтмәс борын үзенә аерым дворец салдыру турында хыяллану оят булыр иде. Дөрес, тирә-юньдә андый председательләр дә күренгәли, колхозны ныгытудан элек үзләрен, үз ояларын ныгыталар. Ахунҗановның андыйларны күргәне дә, ишеткәне дә бар, ләкин үзе алай эшләргә теләми һәм хәзергә җае да күренеп тормый иде. Ә ояны бер урынга тупларга, балаларны канат астына алырга, һичшиксез, кирәк. Аптырагач, бер көнне ул бу турыда партком секретаре Хәкимовка сүз ачты. (Гомумән, үзеннән бернечә яшькә генә олы Хәкимовтан ул бер серен дә яшерми иде.)

Тәлгать Хәкимов җаваплы эштәге һәм сакалы биленә җитмәгән кеше өчен аерым торуның хәтәр якларын, Ахунҗановның үзенә караганда да, яхшырак белә икән. Ахунҗановның «бергә оешасы иде!» дигән идеясен бер искәрмәсез күтәреп алды. Бергәләп «кайда кунакларга?» дигән мәсьәләне кайгырта башладылар.

— Таптым, барып та чыга, бәреп тә ега,— дип, балаларча кычкырып җибәрде Тәлгать, бераз баш кашып торганнан соң. Чынлап та,

хәзинә тапкан малай кебек, авызы жырылган иде аның.— Әйт әле берүк, ник кирәк мина партком дигән булып, бер үземә бер өй биләп утырырга. Житмәсә әле, куш өй. Вывескасы шәп, янәсе, приемный. Фактически алып карасаң, бер сейф та берничә подшивка. Шуларга теркәлеп Хәкимов агаен үзе утыра түшен киереп. Утырырга чират житсә, әлбәттә. Барысын да и шунда бер очтан Тәлгатен дә төйибез дә бер машинага, правление йортының бер почмагына китереп куябыз. Сыярбыз бит икәү бер түбә астына? Ә хәзергә партком йортын бик әйбәтләп синең семьяңа квартир итеп җайлыйбыз. Идеяме бу? Каршы килеп кара бу идеягә.

Алты почмаклы, янында берничә торык каралты-курасы да булган партком йортын Ахунжанов, әлбәттә, белә, ул йортта берничә тапкыр җыелышта, бюро утырышларында да булганы бар. Керәшен очы белән татар ягын бүлеп торган тыкрыкка түре белән салынган бу алты почмаклы йорт карар күзгә матур, төзек, хәтта байларча диярлек. Ләкин бу тыштан караганда гына шулай, даими яшәүче күз-колак булмаганлыктан, йортның нигез яклары, тәрәзә рамнары муртайган, ныклап бер карамыйча, кышка каршы аңа бала-чага белән керү мөмкин түгел иде. Шул ук вакытта, капиталь ремонт кузгатырлык жимерек жире дә юк һәм алай олыдан кубып торырга вакыт та сыйдырмаячак иде. Булганыңа мең шөкер итеп, шундук эшкә тотындылар. Парткомның бар күк хуҗалыгын, кәгазь мөлкәтен һәм ямый торган шкафын машинага төяп, идарә йортының бер бүлмәсенә китерделәр, бушап калган тыкрык буй йортның тишек-тошыкларын ямарга ике балта остасы кушылды. Бер уңайдан Ахунжанов йорт артындагы ике торык амбарга да күз салып куйды. Бусы да артык түгел, ганләсен күчерә калса, алар белән берлектә, әлбәттә, вак-төяк терлек-туар да күчәчәк. Шуларны ябу өчен менә дигән жылы почмак әзер дигән сүз. Ләкин якынрак барып карагач, амбар дигәнебез хуҗалы булып чыкты, аның ишегенә эт башы хәтле йозак эленгән иде. Сораша торгач тагын шул ачыкланды: амбарны шул тирә авылларга хезмәт күрсәтүче киномеханик биләп алган, анда аның бензин мичкәсе, яраксыз ленталары, тимер-томырлары саклана, имеш. Бер кузгалганда бу мәсьәләне дә хәл итәргә уйлап, Ахунжанов киномеханикны идарәгә чакыртты. Кино челтәрендә эшләүче буларак, үзен бары тик райүзәккә генә буйсынучы, мондагылар белән алыш-биреше шул чаклы гына дип исәпләп йөрүче яшь кенә чибәр егет Әхсәнов үзен шулай ук «урындагы кеше»гә санап йөри, үзе яшь булса да һавалы кеше, идарә йортының бусагасыннан башны бик югары тотып атлап керде.

— Ник чакырттыгыз? Минем ни кирәгем бар сезгә? — диде ул, сәлам биреп торуны да кирәк тапмыйча. Вакытлы-вакытсыз борчып йөрткәннәре өчен үрталеп, өйнең почмагына карап кына сөйләшүенә караганда, аның бу соравын: «Сезнең миңа ни кирәгегез бар? Мин турыдан-туры районга буйсына торган кеше!» дип аңларга да мөмкин иде. Ахунжанов сөйләшүнең шома узмаячагын шундук чамалап алды, ләкин юк мыегын кабартырга ашыкмады:

— Утырыгыз, танышыйк, мин шушы «Алсу алан» колхозының председателе булам.— дип, чак кына ирония кыстырып, сүз башлады. Әхсәнов баскан урынында таптанып кала бирде, утырмады. Болай йомшак сөйләшү белән генә эш барып чыгардай күренмәгәч, Ахунжанов рәсми тонга күчеп һәм шактый кырыс рәвештә дәвам итте:

— Анда, тыкрык буендагы йортның, элекке партком йортының, амбарын бикләп алгансыз икән, аны ачарга туры килер, иптәш Әхсәнов.

Тик шуннан соң гына муенын борды Әхсәнов, Ахунжановка турырак карап куярга мәҗбүр булды.

— Анда минем материальный склад,— диде [redacted] бер-ике сүз белән араны өзәргә теләгәндәй.

Ләкин Ахунҗанов, әйткәнен эшләмичә торып, араны өзә торган кеше түгел, җае чыкканда моны бу «яшь әтәч»кә дә белдереп калу зыян итмәс, дигән карашка килде.

— Бензин мичкәнне кую өчен икенче урын табарбыз, ә амбар миңа кирәк булачак,— диде Ахунҗанов, тавышын яхшы ук күтәрә төшеп. Бу — аның монда килеп эшли башлавыннан бирле беренче мәртәбә шулай «кабыргасы белән куеп» сөйләшүе иде. Хәлбуки, кешесенә күрә болай сөйләшү дә ярый икән, Әхсәнов шуннан соң йомшый төшеп, ләкин, складын икенче урынга күчерергә бик үк риза түгеллеген сырты белән үк сиздерергә тырышкандай, сүзсез генә чыгып китте.

Ул көнне үк түгел, аның иртәгесендә дә түгел, әлеге теге ике балта остасы өйнең карыйсы җирләрен карап, тәрәзәләрен, нигезләрен ныгытып бетергәч, үзе керәчәк бу «сипләнгән дворецтан» бик тә канәгать калып һәм, инде Хәдичә үзсүзлене күчәргә көндерә алачагына һич шик тотмыйча, яңадан Мәргәнтауга кайтып китте Ахунҗанов. Ләкин эш ул уйлаганча ансат кына килеп чыкмады.

Болай үзе бөтенесе — инәй карчык та, балалар да, тавык-чебешләр дә урыннарында иделәр, тик Хәдичәне генә, әйтерсең, алыштырып куйганнар: ул телен йоткандай сүзсез, эндәшкәндә дә гадәттәгечә күзләре белән эретеп түгел, ничектер читкә яки аска карабрак эндәшә, анда да турыдан-туры иренең үзенә сүз катудан бигрәк, балаларның я берсенә, я икенчесенә эндәшкән атлы булып, рикошет аркылы кыек атып, туры тидерергә маташа иде. Теге вакытта, кичне көтмичә, чолан ишеге артына тартып алып, бер «пәп» итү йомшартып җибәргән иде, бу юлы да шундыйрак бер «финт» ясамакчы булып карады Ахунҗанов, ләкин файдасы тимәде. Якын килә башлау белән:

— Кыланган булмасана, монда әллә... Баланлы хөррияте дип беләсеңме? Почмак саен кулыңа ирек биреп йөрергә,— дип, тыпырчынып, читкә тайпылды Хәдичә. Тикмә түгел, ахры, монда кояш кире яктан чыккан, әллә, бет ачуын туннан алып, бөтенләй чыгарга ук оныткан-мы? Шулай да зур сүзне бу ыгы-зыгы арасында, балалар колагы төбендә башларга ашыкмады Ахунҗанов, кичкә калдырырга булды. Әйтсә дә, олыдан кубып түгел, балалар белән сөйләшкән атлы булып:

— Сезнең анда дус малайлар мондагыдан күбрәк булачак, шуны белегез, Наилне кайчан алып киләсен, дип артымнан кычкырып калдылар. Барабызмы соң? — кебек сүзләр белән, нәрсәгә дип кайтуының очын-чачагын шулай да гел сиздерә торды.

Хәдичә исә мондый сүзләргә колак та салмаган кебек үз эше белән йөри бирә иде. Болай «балалар белән сөйләшү» генә йогынты ясамагач, Сәлим-аптыраган үрдәк хатыны белән турыдан-туры сөйләшергә булып:

— Кара әле, хатын-җаный, өс-баш та каралды, тән дә кычыта, кайткан-кайткан, мунча кереп китәсе иде бит,— дип сүз кушып карады. Бусы балаларга әйтелгән сүз түгел, Хәдичә моны әйтмичә үк чамаларга тиеш иде, югыйсә. Ләкин ул бу сүзгә дә ләм-мим җавап кайтармады, ишетмәгәнгә салышып, үз эше белән йөри бирде. Ә шулай да, тормыш күргән кеше бит, кунакның ул сүзләре инәй карчыкның колагына кереп калган булган икән, ир белән хатын арасына кысылмаска тырышып, озак кына чыдап утырып та, килененең мунча ягарга ашыкмаганлыгын күргәч, карчыкның түземлеге җитмәде:

— Килен, Сәлимҗан мунча дигән ие шикелле. Утынын күтәреп илтеп ташлаучы булса, ягуын үзем дә карап ягар ием, анлык кына дәрманым бар,— дип кысылып куйды. Ләкин көе киткән киленне бу «кысылу» да йомшарта алмады.

— Сор[redacted]диләр.

Сүзне артык куертучы булмады, күзе булган кешегә күренеп тора: монда, чынлап та, кемнендер нәрсәседер җимерелгән иде булса кирәк шул.

Шулай да вакыт ир белән хатын арасын бераз төзәткән иде, ахры, иртәгесен Хәдичә-килен таңнан торып мунчасын яккан — Әхтәм күршеләрнең миче җимерелгән булса, Миңзариф күршеләрнеке җимерелмәгән икән! Гомумән, Хәдичә-килен иртәгесен яхшы ук ачык чырайлы күренә, мичкә дә ягып җибәргән, табалар да кузгаткан — ахры, кунакка нәрсә булса да пешерергә исәбе бар. Балалар үзара талаша башласа да, «Тавышланмагыз, әтиегез йоклый!» — дип кенә тора. Ир белән хатын арасындагы хәлләрне белмәссең: төн үзе белән ияртеп хатынның «җеннәрен» алып киткәнме, әллә Ахунҗанов-председатель үзе шулай юк-бар җеннәрне куркытканмы?

Ләкин Хәдичә-килен шулай да әйтәсе сүзләрен әйтеп бетермәгән булган икән — кияү коймагына бераз ашыгра төшкәнбез. Чак кына мәзәгрәк килеп чыга: иң зур сүзен ул, аулак урын дип булса кирәк, мунчада әйтергә калдырган, имеш.

— Өйдә, балалар алдында, әнекәй карчык сеңдереп утырганда тешемне кысып әйтмичә чыдадым, монда алар юк, күземә карап әйт: менә бу нәрсә? Ничек аңлатасың моны?

Хәдичә алачыкта эленеп калган жакет кесәсеннән дүрт почмаклап төрелгән хат алып кереп, Сәлимнең өстенә ыргытты.

— Чү, апаем, суга төшерә яздың бит документны. Күзгә сабын кергән чак, житмәсә,— дип сөйләнгәләп, эшне уен-көлкегә юрап бетерергә тырышты Сәлим. Шулай да хатны кулына алмыйча булдыра алмады. Ә анда язылганнарны уен-көлке белән генә күмеп калдырырлык түгел: имзасы күрсәтелмәгән, кем кулы икәнлеге билгеле булмаган ул хатта Сәлим өстенә юып кына бетерә алмаслык бер кочак пычрак ташланган иде: янәсе, Сәлим Ахунҗанов Баланлыга килү белән хатынын, балаларын онытып, кайтса да күз буяр өчен генә кайтып-килеп йөри. Янәсе, ише кушын тапты, монда, имеш, ирдән кайткан бер сөйрәлчекнең итәгенә ничек тагылырга белмичә чаба. Мөршидә атлы ул кибет күсесе турында безнең авылда:

Мөршидәгә сүз әйтмәгез, сүз күтәрми Мөршидә,
Килгән берсе анда кунак, әрәм китми берсе дә.—

дип җыр да чыгарып бетерделәр, ник ул хатынсыз килгән председательне генә читтә калдырсын. Әчендә жаны булган ир хатыны, ник ул фәрештә затыннан булмый, бу әйткәннәрдән ни дә булса аңлар һәм ул азгын ирен тезгенләп алыр, дип ышанабыз.

Хатта әнә шундый сүзләр язылган иде, укыгач, акланырга тырышудан бигрәк, ачуы чыкты Ахунҗановның: бар бит әле дөньяда кеше арасын бозарга йөрүче кабахәт адәмнәр! Дөньяда бардыр да бардыр инде ул, күптер, кара әле, хәтта Баланлыда да бар икән андый бәдбәхетләр. Димәк, итәкне-җиңне җыеп йөрергә кирәк! Аннары тагы хатыны Хәдичәгә дә бераз кәефе кырылды: акыллы хатын, ничә ел бергә торалар, дүрт баланары бар, бер-берсенең акылын-фигылен белдек, дип йөриләр иде. Юк икән, белеп үк бетермәгәннәр икән. Кара әле, кичәдән бирле шул «пүчтәк» өчен тартәга тибеп йөргән булуын!

Ләкин, ничек кенә игътибарсыз калдырырга тырышмасыннар, арадан салкын җил исеп узды, иренең Баланлыга күчәргә диган тәкъдименә хәзер ачык кына бер җавап та бирмәде Хәдичә. «Юк әле, чапмыйчарак торсын. Хәдичә апаң кирәк икән, бер дә кайтырсың, ике дә кайтырсың. Көнчелектән бик алай сыгылып төште дип уйлама» дип, кирелек сукалады ул күңеленнән. Дөресен генә әйткәндә, икесен дә аптырашта калдырган читен күрешү булды бу.

Ире китте, хатыны калды. Тагын калды...

Җавабы табылмаган бәйләнчек сораулары, икеләнүләре, шөбһәләре, юкны-барны күз алдына китерүләре, әйтелмәгән үпкәләре, кеше сүзе кергәннән бирле аеруча котырып кузгалган сөю-көнләшү хисләре һәм йокысыз төннәре белән торып калды. Көндез ул хәтле кыен да түгел, балалар ыгы-зыгысы белән, эш белән ничектер үтә, бигрәк тә кичен, йокларга яткач, өйдә ут сүнгәч, балалар шау-шуы басылгач башлана эчке борчылуы. Ничектер бөтенесе берьюлы — бергә үткәргән бәхетле еллар, шатлыклар һәм булып узган борчулар, Сәлимә укырга киткәч аны сагынып торулары, хат язышулары, сагынулары һәм кавышу сөенечләре ничектер бөтенесе-бөтенесе искә төшә... Азмыни бергә үтелгән гомер, азмыни шатлыклы якты көннәр булган, аннары тагын гомер булгач гел генә якты көннәрдән генә дә тормагандыр? Шул ук вакытта, күңелдәге шикне гел яңартып торучы әлеге каһәр төшкән хат кисәге дә анда саклана, аны борчый, аны төрлечә уйланырга мәҗбүр итә иде...

Кыскасы, Хәдичә өчен берсе дә, бер вакытта да болай авыр, болай билгесез, болай йөдәткеч булганы юк иде. Бер яктан, аны өзлексез эчке шик кимерә: «Утсыз төтен булмый. Юк сүз кеше теленә кермәс!» дип, күңеленнән үзенә-үзе тәкърарлый һәм шунда ук кемдер — әлегә аның өчен билгесез, ләкин кем булса да бик тә рәхимсез, ерткыч, кеше тормышын бозарга йөрүче, шул ук вакытта Хәдичәгә караганда, әлбәттә, чибәррәк, чаярак булган шул икенче берәү — Хәдичәнең кулыннан көпә-көндез аның Сәлимен тартып алырга җыенадыр төсле. Икенче яктан, бичара хатын үзенең тискәрелеген җиңә алмаудан өзгәләнә: кайтты лабаса аның Сәлиме, әйтте ләбаса! «Берьюлы барысы да коеп куйган булмас, читенлекләр булыр, әмма минем өчен иң читене: сездән башка яшәү. Борын төртергә урын әзерләдем, өскә кар-яңгыр явып торасы түгел, җыеныгыз, төйим дә алып китәм!» диде. Шуннан да ачык, шуннан да эчкерсез итеп тагын ничек әйтергә мөмкин? Алай-болай шикле эше булса, семьясын күчерергә шулай атлыгып торыр идемени соң? Ә менә Хәдичә-тиле ачык җавап бирмәде, риза дип тә, риза түгел, дип тә әйтмәде, эчке шөбһәләрен җиңә алмады, калды. Бактың исә, ялкынсыз утта янар өчен калган икән.

Шундый каршылыклы уйлар, уяулы-йокылы саташулар белән бимазаланып чыккан тынгысыз бер төннең иртәгесен ул, үзенә союзниклар табарга тырышкандай, иң элек каенанасы Мәгъмүрә карчыкка сүз катты:

— Сәлим синең белән дә сөйләшкәндер, әнекәй, сөйләшмичә булмас,— дип, карчыкны үз ягынарак аударырга тырышкандай, җайлап кына башлады сүзне,— үзе ныклап эшләп китмәгән, эшләп китә алырмы, юкмы, янәсе, без кышка каршы, чеган кебек, белмәгән-күрмәгән җиргә төялеп китәргә тиеш. Тәпигә киткән-китмәгән бер кочак бала белән. Мин риза булмагач, үпкәләп китте. Үзең уйлап кара, әнекәй җаным, синең белән мин чиләнергә тиеш булачакбыз бит күчә калсак. Ир кешегә аңа нәрсә? Керсә — бар, чыкса — юк.

— Сәлимҗангa да үпкәләп булмый, килен,— дип, бусы килененә караганда да йомшаграк, хәйләкәррәк рәвештә башлап китте,— эше шунда булгач, тормышын да шунда корасы килә торгандыр. Карага катып, гел генә кеше бусагасында йөри алмас шул. Инде килеп, мин карчыкка эш теләлә калса, Сәлимҗанның үзенә дә әйттем, сиңа да әйтүем шушы булсын, килен: картаймыш көнемдә яшьләр тәгәрмәченә күсәк булып тагылып йөрисем килми. Миңа карамагыз, үз җаегызны

үзегез [illegible] намазлыгым, [illegible] нигезем калса, чәйгә сөтен савып алырлык бер кәҗә калдырсагыз, шул бик житкән. Әллә ни ерак ара түгел Баланлы, кайта-килә йөрерсез. Бөтенләй ялгыз калдырмыйк, дип әйтсәгез, мәптегендә укуы да бар, бәлки, яңа шәпкә иптәшкә Наилне калдырып торырсыз.

Кара гына әле бу тешсез әбине. Тотты да хәл итеп куйды бит — һәм һич тә катлауландырып тормыйча. Хәлбуки, Хәдичә аңарга, ирнең үзен монда кайтарту юлында союзник булмасмы, дигән караштан чыгыбрак мөрәҗәгать иткән иде. Иренә ачык кына җавап бирмичә үпкәләтеп җибәрүе өчен ул әле һаман борчыла һәм, әгәр әни карчык та киленә җырын җырлабрак торса, Хәдичәгә ничектер җиңелрәк булыр кебек тоела иде. Ул чагында вөҗданны тынычландыра төшәргә мөмкин: янәсе, мин генә түгел, Сәлим җаным, дәррәү алай күчеп китүне әнә әнекәй дә өнәп бетерми.

Бер үк вакытта бу — әнкәй карчыкның кылын тартып карау да иде. Күрәсез, ул бу мәсьәләне, килене Хәдичәгә караганда да, айныграк һәм тормышчарак хәл итеп куйды: эше кайда кешенең — тормышы шунда. Димәк, күчә калсалар, әнкәй карчык ягыннан бернинди дә каршылык булмаячак!

Бер котыптан икенче котыпка: әле балалар бар, алар моңа ничек карарлар икән? Киңәш итеп түгел, шаяртып сөйләшкәндәй итеп башлады әниләре, иң элек олырагы Наилдән башлады:

— Менә без әтиең эшли торган Баланлыга күчеп китсәк, кара аны, Наил, гел уенга акаеп, дәресеңне онытып бетермә, мин укытучы Ханифә апаңа әйтеп калдырам, кирәк тапса, колагыңны борыр, кычкырасы булма.

— Китәбезмени? Кайчан китәбез? — дип, аңлар-аңламас канатланып куйды анысы.

Ходавәндә! Бу тәтелдегенә чаклы әтисе союзнигы булып, «китәбез!» дип чатылдап тора. Ә бит әнисенең малайны юри генә сынап каравы иде.

— Китсәк тә, бүген-иртәгә генә түгел, арбага сикереп менәргә торма.

— Арба белән түгел, машина белән апкитә безне әти, әллә белми дип беләсеңме?

Әтиләре, белдекле баш, кайда мина куеп китәргә икәнен белгән, малайларны жилкендереп өлгергән икән. Моннан Хәдичә үзе өчен янә бер тынычландыргыч нәтиҗә ясады: димәк, «күчерәм» дигән сүзне аның белән генә сөйләшмәгән, балалар белән дә сөйләшкән, әнкәй карчыкның да күңеленә салган, күз буяр өчен генә әйткән сүзе булса, аларны да жилкендермәс иде. Әйе, әйе, әлеге теге эш, имзасыз хатта язылган җирәнгеч сүзләр хак сүз булсалар, Сәлим юләр түгел, аларны үзе янына күчерергә бик алай ашкынып тормас иде, юк, тормас иде. Буш сүзләр ул, дошман гайбәтедер.

Балаларның кечерәкләре белән дә сөйләшеп торуны кирәк дип тапмады Хәдичә. Әбекәй карчыктан бүтәннәре бөтенесе әтиләре янына китеп, «прсидәтел балалары» булырга атлыгып торалар иде. Дөресен әйткәндә, Хәдичә үзе дә «прсидәтел хатыны» булудан бик куркып тормый, дөрес, колхоз эшендә эшләгән кеше, әле дә эшли алырлык, колхоз эше кайда да бер, кирәк булса, «Алсу алан»да да эшләр — болары турында ике дә уйламый. Тик менә теге сабын күбегенә буялып чыккан хат кына аның башын бутап ташлаган. Шул хат аркасында бит, сөйләшергә дип кайткан Сәлименә «барабыз!» дип ачык җавап бирмичә, аны үпкәләтеп җибәрде.

Эшнең әлегә хәл ителеп беткәне юк. Наилнең мәктәбенә барып, укытучысы белән сөйләшеп карарга булды: һич югы, ул союзник бул-

укуына зарар килер, дип чәчрәп чыкмасмы?

Әгәр малайның укытучы апасы бу эшне бик өнәп бетермәсә яки әбисе белән генә калган укучысының өлгерешенә ышанычы какшабрак торса, бу хәл Хәдичәнең иренә ачык җавап бирмичә җибәрүен азмы-күпме аклау өчен бер сәбәп булыр иде: янәсе, син шулай дип әйтәсең әйтүен дә, Сәлим җаным, беренче ел мәктәп бусагасын атлап кергән улыбызны сәлперәйгән әбисенә калдырып китеп, укудан ничек барышын күзәтеп тормасак, шәп булып чыкмас бит!

Ләкин Наилнең укытучысы, мәсьәләне игътибар белән тыңлап, бераз уйланып торганнан соң, икеләнергә урын калдырмаслык итеп, үзеп әйтте:

— Наил минем иң яхшы укучыларымнан берсе, мин аның житәкләмичә дә бара алачагына ышанам, классымның ышанычы булган укучымны ансат кына биреп җибәрү минем үзем өчен дә авыр,— диде. Аннары, Хәдичәнең эчендә кайнаган каршылыклы уйларын белгән кебек, көлемсерәп беравык карап торды да өстәде: — Ә сез, Хәдичә ханым, хафаланмагыз, ирегез чакыра икән — җыеныгыз да китегез, энәсе кайда — җебе шунда.

Җыеныгыз да китегез, имеш. Әйтергә генә ансат. Берничә көн элек яки, һич югы, кичә, әтиләре киткәнче ишеткән булса иде ул бу киңәшне... Энә белән җеп турындагы бу ансат киңәшне.

Җыенырга, төенчекләрне төйни башларга кирәк икәнлегенә хәзер инде ул үзе дә ышанды. Хәер, ул аның шулай булачак икәнлегенә, шулай тиешлегенә элек тә, хәтта ире Сәлим кайтып сүз башлаганчы ук ышанган иде. Шик юк, берең мәшрикъта, берең мәгърибтә торып семьяны төзек хәлдә саклап булмаячак. Әлбәттә, энә кайда — җебе шунда.

Ләкин Хәдичә энә артыннан сузылып йөри торган җеп кенә түгел, ул — кеше. Кеше буларак, аның үзенең эчке каршылыклары баш күтәрә, ул торып-торып уйланып кала иде. Беренчедән, кичә тәмле теле белән чакырып торган иренә ачык кына җавап бирмәде, сырт йонын кабарткан булды, ә бүген, имеш, аның артыннан, «Барам! Барам! Капкаңны ач!» — дип, кычкыра-кычкыра чыгып йөгер. Килештерми Хәдичә моны, ничектер, балаларчарак чыккан кебек тоя иде.

Икенчедән — аны тагын да ныграк уйландырып калдырганы: тукта әле, көнчелеге кузгалганнан шулай кылана башлады түгелме соң ул? Шушы уй, килеп-килеп, аның күңелен өтеп ала, ләкин Хәдичә моны кабул итәргә теләми, моны кабул итү дигән сүз — имзасын ачык куярга батырлыгы җитмәгән куркак бер бәндәнең сүзенә карап, ничәмә-ничә ел бергә торган иреңә, балаларыңның әтисенә карата шик тоту булыр иде. Юк, шикләнми, шикләнергә дә теләми Хәдичә. Аның Сәлиме ул, бары тик аныкы гына, шикләр — барысы да кибәк, менә җил чыгар да очыртып алып китәр.

Ләкин шунда ук, «Нишләп ачык авыз булып торам соң әле мин? Кичә үзенә үк ияреп китәсем калган икән! Дөньянықын белмәссең!» — дигән уй да килеп, аны тагын эчтән әкрен генә кимерә башлый иде. Чынлап та, кем белеп бетергән кеше табигатенең эчке «карурманнарын». Яратуы, ихлас күңеллелеге белән бергә үк, бәлки, акылы белән кире кагарга тырышуына да карамастан, көнчелеге дә кузгалып-кузгалып куядыр — кешене соң моның өчен гаеп итеп буламыни!

Җыенырга, китәргә кирәк — бу чаклысын Хәдичә инде үзенә үзе хәл итеп куйды. Ләкин ничек һәм кайчан? Сәлименең тагын бер кайтып, баш орып, ялынуын көтәргәме? Әллә, кеше сүзләренә, эчтә кузгалган шикләргә, ялган горурлыкка — барысына да, барысына да төкерергә дә, иртәгә үк җыенып юлга чыгаргамы?

Тукта, бәйрәмгә үзе кайтыр, кайтмый булмас, дип көтте Хәдичә. Ләкин Ахунҗанов, телефон шалтыратып, хәлләрен белү, тәбрикләү белән чикләнде. Хатыны бик төпченә башлагач шулай да әйтмичә булдыра алмады: бәйрәм уңае белән колхозның сузылып калган «койрыкларын» җыештыргалау өчен удар вахтага бастык, «кешеләрне күтәреп тә, үзем хатыным янында ятып калсам килешмәс, шунда бергә булырга кирәк» диде өзеп. Аның болай өзеп сөйләшүе дә, кайтмый калуы да хатынның төрлечәрәк уйлауларын тагын да куерта калдырды. Болай да соң дәрәҗәдә өзгәләнеп, төрлесен уйлап йөргән Хәдичә өчен бусы моның «курыкканга куш» булып чыкты. Сәлименә, әлбәттә, ул ышана, эшкә бер бирелеп китсә дөньясын оныта торган кеше, бүген генә күрмәгән, шулай да... Менә монда Мәргәнтауда оныта һәм онытыла алмый торган Хәдичәсе утырып калды лабаса. Җитмәсә тагын, ул алмага кайтканда киреләнеп калуы өчен дә үзен битәрләп туймый. Шул ук вакытта, ничаклы үзен тыныч тотам дисә дә, вакытвакыт күңеленә әллә ниткән уйлар да килә, хәерсез... Бирелеп китүнең нинди генә төрләре булмас, иргә ышанма, Иделгә таянма, дигәннәр борынгылар. Аннары тагын күңелнең тынычлыгын алган әлеге теге имзасыз хат та әле һаман аның кесәсендә таушалып йөри иде.

«Бәй, ник соң әле болай, кирәк-кирәкмәсне уйлап, үземне бетерәм. Тотарга да искәрмәстән генә барып төшәргә үзенә. Баланлы авылы качкан җирдәмени!» дигән карарга килде ул, ниһаять. Һәм бердән җиңеләеп, тынычланып калгандай булды. Чынлап та, берни дә уйлап тормаска, тотарга да барырга. Мондагыларга да күп шауламыйча, андагыларны да куркытмыйча, барырга да эшнең торышы белән танышырга, барып төшәчәк урынны үз күзләрең белән күрергә...

Әлбәттә, горурлыгы да кузгалып куйгалый иде: «Ирен күзәтә килгән, димәсләрме? Өйдәгеләргә нәрсә дип аңлатырга?» «Тукта, барып, әтиегезнең кыланышын күреп кайтыйм әле», дип булмый ич инде. Әтиләрен бүген генә күргән балалар түгел, берсе үкчәсенә икенчесе басып үсеп килүче ул чыр-чуларны муенына атландырып йөртүдән башка нинди кыланышы бар соң аның?

Уйлана торгач, хәер, кызыклы гына бер сылтау да уйлап тапты. Үзе өчен түгел, балаларны юмалау һәм әледән-әле, «Сөт-катык ярата ие, бармы икән анда сепарат аерманан сөттән без оета торган тәмле катык? Аптырап тормыймы икән Сәлимем-балам?» дип авыз эченнән сөйләнгәләп куя торган каенанасын ышандыру өчен. Хәер, үзе өчен дә ярый — һәрхәлдә, сыный килгән дип әйтергә урын калдырмаячак. Кичтән китәсе, иртән — кеше аякка басканчы барып җитәсе. Шулай уйлады да:

— Әтиегез чынлап та сөткә-катыкка аптырап тормыймы икән анда? Әтиегезгә сыерны илтеп килергә булдым әле мин,— дип хәбәр салды ул бер көнне. Сыер артыннан сөт-катыксыз тора алмаган балаларның да әкренләп тезеләчәген уйлап эченнән генә елмаеп та куйды үзе. Бу сүзне Мәгъмүрә карчык та хуплады: тормыш күргән карчык моның хәзергә балаларны юату өчен уйлап чыгарылган бер сүз генә икәнлеген, килененең, сыерны илтә барудан да бигрәк, ире янына үзен илтә баруы икәнлекне, сыер артыннан ук килененең үзенең дә, балаларның да, кыр казлары кебек, шул якка таба тезелеп китәчәкләрен, эчке моңсулану аша булса да, әлбәттә, төшенә иде ул.

— Шулай шул, килен, үз өе түгел, сыерсыз ул анда нишләсен,— дигән булды, килененең ниятен куәтләп. Беравыктан, бу юлы инде гаять җитди итеп өстәде: — Бер уңайдан тормышын,— сезгә йорт әзерләдем дигән ие, шул йортны да күреп кайтырсың. Хатын-кыз күзе ир

күрмәгәнне күрә, кышка каршы ...
масын.

Ә хәйләне-серне белмәс балалар нишләргә белмәгәндәй сикерекләргә тотындылар.

— Инәй, мине дә алып бар эти авылына,— дип тыпырдады уртанчысы.

— Сыер өстенә атландырыпмы? — дип көлде олысы, әнисе өчен җавап биреп. Болай барып чыкмаслыкны төшенеп алгач, уртанчысы һәм аңарга ияреп кечерәкләре:

— Алайса, этинең үзен монда апкайт,— дип бәйләнә башладылар.

— Бәй, котырмагызчы юк сүзләрегез белән,— дип, карт әби балаларның бөтенесен берьюлы кырт кисте,— этиегез анда уйнап йөридер ие, ди. Сезне ничек итәгенә төяп апкитәргә белми йөргәндә, сез этиегезнең үзен мунчаклап монда кайтармакчы, акылыгыз алтын икән.

Бу — «улларым, сезгә әйтәм, киленем, син тыңла!» дигән сүзе дә иде Мәгъмүрә карчыкның. Хәдичә килен моны, бер үк вакытта, моңарчы аерым торганнары өчен каенанасының шелтәсе итеп тә, шул аерымлыкны бетерү юлында, хәтта сыер житәкләп булса да, сәфәр чыгу алдыннан биргән фатихасы дип тә кабул итте.

Шулай да көне-сәгате белән генә чыгып китә алмады Хәдичә. Бәйрәм алдыннан һәм бәйрәм көннәрендә әле кар, әле карлы яңгыр явып, аяк астын нык кына изрәткән иде, юлны тундырганны яки, тагы да шәбрәге, аяк астына йомшак кырпак төшкәнне көтте. Шул ук вакытта эченнән, «Тукта, искәрмәгәндә генә үзе кайтып төшмәсме?» — дип тә көтә иде. Ләкин бу соңгысы ул көткәнчә килеп чыкмады, ахрысы, тегендә, чынлап та, уңга-сулга карамыйча «койрыклар»ны җыялар иде булса кирәк.

Аяк астын тундыруны, кырпак төшүне көтеп торганда, ноябрь урталарында, һич күренмәгән хәл, кинәт аязып, җылытып җибәрде. Аяк асты сурыкты, юллар ипләнде, кичләрен коры салкын төшә, төннәре чалт аяз, житмәсә, ай урталары торганлыктан, юлдан энә табарлык якты иде.

Әнә шундый ай яктысы төшкән, коры һавалы кичләрнең берсендә, кеше-кара күзе басылгач, төнгә каршы, безнең Хәдичә киленебез сыерны алып Баланлыга сәфәр чыкты. Сөйләнәсе сүз өйдә чакта ук сөйләнеп беткән, берсенә дә капка төбенә чыгып, кеше күзенә күренеп йөрү рөхсәт ителмәде. Кече капка тын гына ачылды, тик сыер-ялкау гына төнгә каршы үзен болай бимазалап йөртүләренә аптырагандай, атлар-атламас тартылгалап карады. Әмма Хәдичәнең кулы нык (сыерны гына түгел, ни чәя Сәлимне дә тота белә торган кул!), биле буылган, аягында нәрсә булса — шуңа әзер торучы кирза итекләр (тракторда эшләгән чагыннан калган!), житмәсә тагын, бер кулында ихтимал булган бәлаләрне сугып егарлык сыек чыбык иде. Эшнең уен түгел икәнлеген һәм, бигрәк тә, хужа хатынның кулындагы сыек чыбыкны сизеп, хайван да, бер юлга чыккач, тартылу-киреләнүнең файдасыз икәнлеген төшенеп булса кирәк, тәүфыйклы сыерларча җай гына атлап бара башлады. Айлы төн, игеннәрдән бушаган такыр кыр юлы әллә кайдан әллә кайларгача ялтырап ята, һава салкынча, коры һәм саф, сыер житәкләп бару өчен генә яралган төн диярсең. Кайтасы кеше кайтып, китәсе китеп беткән, кеше-мазар очрап, кызыксынып сорашучы булмады, кыскасы, хәзергә бернинди тайпылыш та юк, барысы да алдан корган план буенча бара, бигрәк тә сыерның, инде бу вакытсыз сәфәр белән тәмам килешеп, тезеп-тезеп кенә атлап баруы Хәдичәнең күңеленә үтә хуш килә иде. Шунлыктан булса кирәк, кинәт сыеры белән әңгәмә башлап җибәргәнлеген үзе дә сизми калды.

— Баруын барабыз инде, аныкаем,— дип, яратып һәм хайванны назлап сүз башлады ул,— тик болай тилереп йөргәнебез өчен абые-

югыйсә.

Сыер мондый катлаулы хәлләрне колагына түгел, мөгезенә дә элми, бер җай алган килеш тагылып килә дә килә, ичмасам, койрык очын гына бер селкеп карасынчы. Хәер, сыерга аңа нәрсә, саламнылечәнне җәлләмәсәләр, салкыннан-җилдән ышыкланырдай бирәр торык абзарлары булса, сыерның җәннәте шул инде. Бераз тын баргач, бу тынлыктан туеп, тагын сөйләшергә тотына Хәдичә.

— Юк,аныкай, син уйлый күрмә тагын,— дип башлый ул, барган ходка авыз эченнән генә мыгырданып,— янәсе, синең Хәдичә апаң, нинди дә булса сөйрәлчектән көнләшә башлады да шунлыктан менә син хайванны вакытсыз тинтерәтеп йөртә, дип. Шулай булмаган кайда, ди. Минем Сәлимемне минем кулымнан тартып алырга кемнең дә булса кодрәтеннән килер микән? Дөньяга тумаган әле андый адәм баласы, беләсең килсә, бел.

Төн тын. Йолдызлар чекерәешеп яналар. Шактый гына еракта, уң кул якта — кайдадыр Бөгелмә юлында булса кирәк — фаралары белән әллә кайдан тирә-юньне яктыртып автомашиналар узгалап китә, сыер да, аны җитәкләп килүче Хәдичә дә җанлана төшәләр, Хәдичә кайчандыр үзенең дә тракторда эшләгән чакларын искә төшерә. Төнге сменада эшләгәндә ул да менә трактор фарасы белән дөньяны шулай балкытып йөри иде... Хәер, ул чагында шул Сәлиме аның үз янында иде, күңелгә бернинди дә шик-шөбһәләр килми торган чак иде.

Әлбәттә, көлке бу телсез сыер белән сөйләшеп бару.

Болай төнгә каршы сыер өстерәп юлга чыгуы да көлке. Моның шулай икәнлеген белә Хәдичә. Шуны белә торып, үзенә үзе ачуы чыкканнан, үзен-үзе үчекләгәндәй юри сөйләшә. Ачу чыкмыйча соң! Болай кузгалыр нияте барлыгын белгән булса яки шул хакта иренә нинди дә бер ишарә ясаган булса соң, болай азаплап йөртер идеме аны Сәлиме! Машина белән зырылдап килеп җитәр иде, зырылдатып алып китәр иде. Әйтте бит, еландай телен чыгарып ялынды: «Минем ялгызыма гына читен анда, кеше яны — кеше яны ул, әйтердәй сүзеңне дә әйтми каласың кай чагында. Әйдә, бергә оешыйк», диде. Телен тешләде Хәдичәсе. Барам дип тә, бармыйм дип тә әйтмәде, кирелеге кузгалды. Күңелендә әлеге теге каһәр төшкән хат кара төен булып утыра иде. Хәер, ул кара төеннең әле хәзер дә югалганы юк. Гел шул төен котырта, гел шул төен болай тилертеп йөртә дә инде. Янәсе, искәрмәстән генә барып төшә дә бу, үз күзләре белән күреп, нәрсә чын, нәрсә ялган — шуны аныклап кайта һәм, шуннан чыгып, күк капусы берьюлы ачыла да китә. Әлбәттә, кызыксынып сорашучылар, көнчелеге куып китергән дип әйтүчеләр булыр. Хәтта торып-торып, үзенә-үзе дә шулай әйткәләп куя ул: «Тиле бәрән син, Хәдичә җаным, көнчелегеңнән шулай тилереп йөрүең бу, гөнаһысыз менә бу мәхлук хайванны тинтерәтеп. Оят түгелме? Дүрт балаң була торып. Ничә ел бергә гомер иткәннән соң! Сәлимеңнең акылын-фигылен, синең өчен үлеп торуын белмәсәң икән!» һәм шундук тагын, үзен ничек тә акларга тырышып, үзе белән үзе һәм аннары, җавап кайтара белмәсә дә, янәшәдә җай гына атлап килүче сыеры белән сөйләшергә тотына:

— Барсак соң, әллә ят кешегә барабызмы? Үз абыебыз янына барабыз, әйе бит, аныкай? Әллә аның чәйне куе сөт салып эчәсе килми торгандыр дисеңме? Өс-башы да катып беткәндер, без булмагач, шулай бит? Тыңлыйсыңмы соң син, әкәмәт? Барасын башыңны салып. Әллә инде арый да башладың? Менә барып җитик, ял итәрбез. Мин дә арыдым, җаным, болай төн пәрие булып йөрер иемме соң, шул тинтерәткеч абыебыз булмаса...

Соңга таба бәтенесе туйдырды. Үзен-үзе битәрләү дә, күзгә күренмәгән Сәлиме белән әрепләшү һәм, бер үк вакытта, аны тизрәк күрәсе

килү дә, сыер белән сөйләшү дә туйдырды. Ничек кенә әйтсә дә сыер аягы — сыер аягы, ул синең күңелендә ташыган уйларыңны беләмени! Атлый бирә бер гамьсез. Күренеп тора: ахры, төн узганчы барып житеп булмастыр. Житмәсә, төн урталары авышкач, һич көтмәгәндә төньяктан үзәкне өзә торган каты жил исә башлады, моңарчы сыерны өстерәп барган Хәдичәбез инде сыер жылысына үзе ышыкланырга мәжбүр...

Юк, башта корган планы барып чыкмады, юлда очраган кечкенә бер авылда туктарга булдылар. Йоклаган йортларның берсен уятып, фатир кертүләрен сорау алдыннан тагын бер киртәгә кермәгән уйдырма уйлап чыгарырга туры килде Хәдичәгә:

— Көзлектән китеп югалган сыерымны табып алып кайтышым, зинһар, баш куеп ятарлык бирәр почмагыгызны жәлләмәгез,— дип сорады ул, бу очракта инде бик тә тәмле теллегә әйләнеп. Шулай булмыйча соң! — «Югалган яки югалырга торган иремне эзләп барышым!» дисә, ышанмаулары мөмкин. Үзегез беләсез, әгәр чынлап торып югалса, андый ирне төн йокламыйча эзләп кенә табып буламы соң!

## Килде... Әллә бөтенләйгә? Әллә кунакка гына?

Бик үк шауламасалар да, шул бер-ике ай эчендә Ахунжанов турында озын телләр кайбер гайбәт сүзләре таратырга өлгергәннәр иде инде. Янәсе, хатыны белән аларның борчагы пешми икән. Янәсе, бу анын семьясыннан кыякларга йөрүе, имеш. «Кыяклар, ник кыякламасын, кызларның базары чабата базары белән бер булып калгач!» Бигрәк тә керәшен очы белән татар очын бүлеп торган тыкрыктагы партком йортын бушатып, каратасы жирләрен каратып куйганнан соң да йортның әле һаман буш торуы төрле сүзләргә, юрауларга сәбәп иде. Ахунжанов мондый гайбәт сүзләрен ишеткәләсә дә, игътибар итмәскә тырыша, хәер, гайбәт жыярга анын вакыты да юк, таш чыгарту, яртылаш ишелгән терлек абзарларын вакытлыча гына булса да ямату-сипләү, жыелып бетмәгән салам-кибәкне жыйдыру һәм башка, һәм башка тавык та чүпләп бетермәслек эшләр белән башы каткан иде. Һәм эш белән шулай мәйханә килеп йөргәндә — ичмасам, кич-кырын, эңгер капкан вакытта да түгел, иртәнге кояш яктысында — искәрмәстән генә, сыер житәкләп, хатыны килеп төшмәсенме! Әлбәттә, бераз аптырабрак калды. Аптырамыйча соң! Киләм дип тынын чыгарган булса, болай тинтерәтеп йөрткән булыр идеме соң! Берьюлы ике машина ук жибәрмәсә дә, бер машина баскыч төбендә, әлбәттә, көтеп торган булыр иде. Ай, бу хатын дигән кешенең катлаулылыгы!

Хәер, Хәдичә бик алай очынырга юл калдырмады. Бәлки, әлеге шул катлаулылык, берьюлы сер бирмәскә тырышу кулын-аягын богаулагандыр.

— Көтеп торгансыңдыр, дип килүем түгел,— диде ул, уенын-чынын бергә кушып. Әмма үзенең бөтен килеше, жәелгән көләч йөзе, туры карамаска тырышып та, карамый булдыра алмый торган наян күзләре кычкырып тора: мәтәштерүе генә бу,— курыкма, иртәгә үк китәм. Әнкәй йөдәткәнгә генә килдем. Сәлимжаным сөт-катыкка аптырап тора торгандыр, алып бар булгач, алып бар сыерны, дип колак итемне ашады.

— Бәй, кемне ышандырам дип сөйләп торган була? Күрегез әле минем бу теленә салынган хатынны,— дип, өй хужасы Андрей дәдәй белән аның карчыгын үзенә ярдәмгә чакыргандай, көр тавыш белән ирләрчә бер гөрләп куйды Ахунжанов. Ә үзе, картлар күздән югалып торган бер форсатны чамалап, хатынын кул очына күтәреп алды:

— Ә мин менә шуны әйтәм: үзең сагынып килгәнсең. Борчак хәтле генә булса да әүлиялыгың да бар икән: минем сагынганны да белгәнсең.

Берсен-берсе сагынышып торган ир белән хатынга шушы аңлашу җитмәгәнмени! Янә бер якын итеп, йөрәкне ачып күрсәтергә теләгәндәй, томырылышып карашып алдылар һәм шуның белән сатулашу да, мәтәштерү дә, шик тә бетте — алар бергә, элек тә бергә иделәр, хәзер дә бергә, гел шулай бергә булачаклар!

Ләкин тынычландырырга чак кына ашыкканбыз икән! Юл тузаннарын каккалап, күңелдә булган шик-шөбһәләрне бер якка атып, кунак сыерны вакытлыча Андрей дәдәйләр абзарына урнаштырып, тәмам тынычланып, өйдәшләр һәм өй хуҗалары тату бер семьядай, гөрләшеп чәй табыны янына утырганнар гына иде, ишектән ялт итеп кибетче Мөршидә килеп керде.

Кешенең ашаган-эчкән вакытына туры килүе өчен чак кына уңайсызланган кебек кыланды башта, ләкин шундук үзенең шушы авыл кешесе икәнлеген, кот очарлык сәбәпнең һич юклыгын килгән кунакка сиздерергә теләгәндәй:

— Шушыларның гел ашаган-эчкән чакларына туры киләм, мактап та йөрмим инде, югыйсә,— дип бер шаулап куйды.

Ишетмәгән-белмәгән кебек күренергә тырышса да, Ахунҗановның хатыны килгәнлеген ул ишеткән, нинди дә булса усал ният белән генә дә түгел, аны хатын-кызга хас кызыксыну, «хатыны ниндирәк адәм икән безнең председательнең, үзенә торырдай кеше микән?» дип беләсе килү, юк йомышны бар итеп, бу бусаганы атларга мәҗбүр иткән иде. Инде бер атлап кергәч югалып калу аның характерында түгел, җитмәсә тагын бер күз ташлау белән Хәдичәнең төшеп калганнардан түгел икәнлеген күреп алу аны дәррәү җилкендереп җибәрде.

— Кунак киләсе бар, дип әйтмәгән идең шикелле, Ахунҗанов абый.— Ап-ак тешләре белән юри бер мактанып алырга теләгәндәй, авызын ерып көлде һәм, күзләрен хәтәр уйнатып, Ахунҗановка — әйе, бу юлы гел аның үзенә генә — томырылып бер карап алды. Аннары бөтергечтәй бөтерелеп ишеккә борылды, ләкин чыгып китәргә ашыкмады, күрәсең, әле аның әйтәсе сүзе әйтелеп бетмәгән, ә кем белә, бәлки әлегә башланып та китмәгән булгандыр.

— Синдә ие йомышым, Дуся түтәй,— диде ул, аннары коры гына хуҗа карчыкка эндәшеп,— болай үзегездә дә кунак булгач, әйтсәм дә әллә ничек инде. Иртәгә мунчагызга яктырмассызмы, дип килүем иде.

Ахунҗановның сүзгә бер дә катнашмыйча әдәпле шәкерт булып утыруы бу чая хатынны яхшы ук оскытып җибәрде. «Хәлил белән Галиябану булып уйнаганыбызны онытканмы, кара, башын салып кына утыруын, хатынынннан шүрли, күрәсең!» — дигән мыскыллы уй йөгереп үтте аның күңеленнән һәм чыгышлый, нәрсә булса — шул, дигәндәй, тавышын юри уйната биреп:

— Кибет ягына бер дә сугылмыйсың соңгы вакытта, Ахунҗанов абый. Бер дә йомышың төшми, ахры,— дип болгатып чыгып китте. Сүзләре дә, күзләре дә, искәрмәстән генә килеп керүе дә, килделе-киттеле сөйләнеп, курт кына чыгып китүе дә — бөтенесе, бөтенесе әйтеп тора: председательгә чынлап та тыныч карый алмаган булса кирәк бу Мөршидә дигәннәре. Һәм аның, киенеп-ясанып килгән бу яшь, чибәр, күзләре ут уйнап торган хатынның әлеге «визиты», никадәр генә игътибар итмәгәндәй күренергә тырышмасын, чынлыкта Хәдичәне, әлбәттә, тыныч калдырмады.

— Шушы икән алайса кайбер адәм балаларының башларын әйләндерүче,— дип төрттереп әйтеп куйды ул, бер аулак араны туры китереп.

диде Ахунжанов, хатынының сүзләрен ничек тә уен-көлкегә борырга тырышып,— колхозчыларым өчен жавап бирә-бирә дә жан чыккан.

Шулай уйный-көлә бер «сөзешеп» алу белән узар, инде бүтән яңармас, дип уйлаган иде Ахунжанов. Һәм Хәдичәнең үзенен дә бу темага икенче әйләнеп кайту нияте юк иде кебек. Алар дөнья хәлләре, өйдә калганнар, бала-чагалар турында сөйләшеп, озак кына кич утырдылар. Сөйләшә торгач Сәлим, үзе һөҗүмгә күчеп, Хәдичәнең кеше көлдереп сыер житәкләп йөрүен телгә алды. Бу юлы да инде әнкәй карчыкка сылтап калдыру әллә ничек, сөйгән иренә дөресен әйтмичә мөмкин түгел иде.

— Белгән юк, минме сыерны житәкләп килдем, сыермы мине житәкләде,— диде Хәдичә, иренең шелтәле сүзен ничек тә күмеп калдырырга тырышып,— киләсем килде дә килдем, ә сыер дүрт аяклы хайван ул. Сыймастай булсак, без аның белән, шулай ук житәкләшеп, килгән юлыбыздан кире китәргә дә күп алмабыз.

Ахунжанов хатынының тел төбен шундук сизеп алды: бу темага сүзне артык куертырга ярамый иде. Бигрәк тә теге аяклы коткы юкнырбарны сайрап чыкканнан соң Хәдичә күзгә күренеп үзгәрде, жаеннан гына тормасаң, менә-менә чәлпәрәмә килеп ватылырдыр кебек күренә иде. Әле ярый, тәжрибәле карчык Дуся әби эшне икенче яккарак борып жибәрде.

— Юл килеп арыгандыр кеше,— дип арага керде ул, бер яктан икенче якка мендәрләр ташый башлап,— күп сүз китапка ару. Кайсыберләрен жәрепгә калдырып торсагыз да жарар.

Аннары, аларның үз уллары кебек кеше бит, каршы килеп торырга ярамаганлыкны алдан ук кисәтергә тырышкандай, өзеп кенә Ахунжановка эндәште:

— Мин сезгә урынны зал як караватка түшим, улым. Ишеген жабып жатарсыз, юкса, без иртә кузгалабыз, сыерын савасы, терлек-туарын карыйсы, дигәндәй.

— Сыер анысы безнеке дә бар,— дигән булды Ахунжанов. Әмма бу кунакчыл әбине жавапсыз калдырмас өчен генә әйтелгән сүз, Хәдичәсен аулаккарак алып яту Ахунжановның үз планында да бик тә туры килә иде.

— Тәрәз пәрдәләребез калын, алай-болай тыш салкыны үтә калса, пәрдәләрне төшереп жатарсыз,— дип өстәүне дә кирәк тапты әби. Аның кунак алдында ничек тә куштанлык күрсәтәсе килә иде, шуның янына тагын, белмәссең, тәрәзә пәрдәләренең калын булуы белән кунак хатын алдында чак кына мактанып аласы да килгәндер.

Әллә кайчан барып яткандыр дип торсак, хәйләкәр карт Андрей дәдәй дә аларның сүзләренә колак сала йөргән икән.

— Юкка кайгырма, карчык, яшьләр арасына салкын үтмәс. Синнән генә ул жылы качты соңгы бакытларда. Ташлап чыккан мунча пиче кебек.

— И авызы сөйли лыгырдыкның... Чак кына аракы керер хәл жук.

Кыскасы, кичтән Андрей дәдәйләр өе әнә шулай уен-көлке, табигый жылылык, аш-су исе, берсенә берсе яхшылык, татулык теләү хисләре белән тулган иде, тәрәзә салкынын сизәргә өлгерә алмадылар, ут сүнүгә йоклап киттеләр. Һәрхәлдә, хужалар үзләре яткан алгы якта шулай булды. Чөнки көнозын аяк өстендә селкенеп йөреп, аннары кунак алдында ничек тә куштанлык күрсәтергә тырышып, Дуся әбиебез торыксыз калып арыган, ә карты Андрей дәдәй, әлеге шул аз булса да «кибет суы» кергәннектән, мендәргә баш төртмәс борын ук йокыга киткән иде.

Ә анда, зал ягында, ишекләрен ябып, калын пәрдәләрне төшереп ятсалар да, төн бик алай тыныч үтмәде шикелле. Төннең бер вакытында — Дуся әби беренче йокысыннан уянып, күргән төшләрен күңеленнән юрап ята иде ул вакытта — зал ягыннан әкрен генә елаган тавыш ишетелгән кебек булды. Бераз аптырабрак калды карчык. Язгыннан курыкса да, эчке кызыксынуын баса алмыйча, мендәреннән башын калкыта биреп, тыңларга тотынды.

Елау озак дәвам итмәде, аны пышылдау — ир кеше пышылдавы алыштырды. Сүзләре, әлбәттә, бөтен тулылыгы белән ишетелми, әмма ишетелгән чаклысы тегеләйрәк — ягъни, карчык юравынча әйтсәк, ир белән хатын аерым торган арада күңелгә урнашып өлгергән шикләрне таратышып азапланалар иде шикелле. Өзек-төтек ишетелгән сүзләрдән, кайберләрен карчык фантазиясе үзеннән ясап, чамача, менә мондыйрак «Сорау-җавап кичәсе» булды алар арасында.

— Бетердеңме җылап? Мин синнән мондый номер көтмәгән идем, апаем.— Монысын Сәлимә әйтте.

— Җыласа соң... Әллә миңа җыларга да ярамыймы? — Бусын Хәдичә «апаем» шулай сузып куйды. Тавышына, сүзләренә карагандa, ул хәзер инде ник болай сәбәпсез җебеп төшүенә үзе дә үкенә башлаган иде.

— Үзең әйткән идең теге чакта, председатель хатыны буласым килә, дигән идең... Ышан синең сүзеңә.

— Минем сүземә ышанырга була... Мена синекенә ничек ышанырбыз икән?

— Анысы синең эш инде, хатын... килче, кысып чыгарыймчы шул урынсыз шикләреңне...

— Кыланмасана...

— Кылану түгел бу, апаем, сагыну галәмәте... Сагындым и все.

— Теге мунча сорый килгән «апаем» да сагыну галәмәтедер инде?

— Тагын шул балык башы: болай тилерә торган булсаң, решение чыккан: сыерыңны җитәклисең дә иртәгә үк Мәргәнтауга кайтып китәсең.

Нәкъ менә шунысын шул бер дә ишетергә теләми иде Хәдичә. Кинәт тынып калды ул һәм Дуся әби, ир белән хатын арасындагы серне тагын һәм тагын ишетергә тырышып, колакларын бик торгызып ятса да, артык ишетә алмады.

Ә иртәгесен... безнең Хәдичә килен — ак-җәймә көн, җитмәсә тагын Дуся әбиебез, кунак хакын хаклап, мунча да ягып куйган иде. Ләкин, дөресен әйтергә кирәк, шундый-шундый тиле сүзләрдән, юкка бәйләнүләрдән соң да кинәт кенә: «Инде китмим! Бөтенләйгә шушында... синең янында калам!» — дип, берьюлы иреңең аягына егылып төшүне горурлыгы күтәрми иде.

Хәер, күп баш ватарга туры килмәде, анысының да юлы табылды. Яңа хуҗаларның үзенә тизрәк күчеп килүләрен көтеп, шыңгырдап торган әлеге тыкрык буй йортны — аллы-артлы ике бүлмәле, аерым кухняле, шифер түбәле болындай зур йортны күргәч, Хәдичә килен сары май булып эреде дә төште.

— Күчер безне, әтисе, балалар инде әллә кайчаннан «Әти янына барабыз!» дип тасыраешып торалар,— диде, ап-ачык әйткәнен үзе дә сизеп өлгермәстән. Хәйләкәр соң хатын да: әйтәсе сүзен дә үз исеменнән түгел, балалары исеменнән әйтә. Чынын гына әйткәндә, күңел тиранлегендә барысы бергә буталган. Өйне дә ошатты, анпары — кеше-кара ишетә күрмәсен, үзенә генә икърар итүе — теге, кеше теләнә менгән, кича Андрей дәдәйләргә мунча сорый килгән кара кашлы, кара күзле, хәтәр чая сайрый торган чибәр толдан да шүрли — юк, аерым тотканчы, үз янында, үз тәзгенендә тоту хәерле ирне!

Җир шарының түгәрәк булуы аның өстендәге барлык илләрнең һәм барлык язмышларның да түгәрәк булуы дигән сүз түгел әле. Ай-һай ла, бик тә күп әле түгәрәкләнмәгән, күз яше һәм хәсрәт белән сугарылган язмышлар. Тыштан түгәрәкләнгәндәй күренеп тә, эчтән кай почмагыдыр китек булганнары да бар. Ахунҗанов, мәсәлән, тыштан эш белән мавыгып, ирешелгәннәре белән куанып, кул җитмәгәннәре өчен пошынып, кыскасы, район җитәкчеләре алдында үзенә зур өметләр уяткан «номенклатурный работник» булып йөрсә дә, семьясыннан аерылып «Алсу алан»да эшли башлаганнан бирле үзендә нииндидер бик үк ачык та булмаган эчке китеклек сизә. Мәргәнтауга соңгы кайтуында Хәдичәсенең юк сүз белән бәйләнүләреннән соң, бу китеклек бер мәл тагын да тирәнәя төшкән иде.

Хәдичәсе хәзер балалары белән аның янына күчеп килде, менә инде алар тыкрык буй өйдә, бер түбә астында, бергә оешып, чүкердәшеп яши башладылар — түгәрәкләнде дә куйды Ахунҗановның тормышы. Карасана, күп тә кирәк түгел икән бит кешегә!

Шулай диебрәк тынычланып йөри башлаган иде председатель, кинәт шулай түгеллеге күренә башлады.

— Бәй, мин шулай бала багып, председатель хатыны булып калырмын микәнни, элекке комсомолка? — дип сүз башлады Хәдичә. Ахунҗанов иртән эшкә ашыккан булып, бу сүзне ишетмәмешкә салышып уздырмакчы иде дә, Хәдичә ишеттерерлек итебрәк икенче тапкыр да кабатлады.

— Үз Мәргәнтавыбызда вакытлыча булса да ярады, анда үз кешеләр иде, балалар да бәләкәйрәк булдылар. Әйтсәләр дә бугазга терәлми иде, ә менә монда әйтмәсәләр дә күңелне тырный. Сүзем шушы булсын: утырт мине тракторга! Туңга сөрүем соңга калды дип тә өзгәләнәсең.

— Сөйләмә юкны, буеңда була торып. Аннан башка да аяксыздан төпсез дүрт балаң була торып.

— Бала бүтән кешеләрдә дә бар. Әйтсәм әйтим, апаем, синең эшең җир сөрдерү, хайван үстерү генә түгел, балалар, балалы хатыннар турында да кайгырту. Ник ясле ачу, балалар бакчасы турында кайгыртмыйсың?

Җир генә йотсын, кара әле, ул эш тә бар икән бит әле! Кайда ул тиз генә түгәрәкләнү, китек-чатаклар аяк асты тулы.

Шулай да, семьясын, бала-чагасын, тавык-чебешен күчереп китерүе колхозчыларда председательгә карата ышанычны тагын да ныгыта төште — болай булгач, кул сынап карау өчен китерелгән «чираттагы бер хәлифә» генә булмады инде бу. Моның белән уйнап эш итәргә ярамас! Үз башы беләнме яки кешедән ишетепме, ничек кенә булмасын, әнә шундый нәтиҗәгә килде колхозчы. Ә бу, үз нәүбәтендә, аңарда хезмәт активлыгын, оешканлыкны, дисциплинаны күтәрә төште. Китте чираттагы эшләр тезелеп: орлык чистарталар, Хәдичә, әлбәттә, быелга тракторга ук утырырга өлгерә алмады, механизаторлар туңга сөрүне бетереп кайттылар, машиналарны ремонтлау башланды, таш чыгаралар, таш ташыйлар, кар төшкәнче дип ферма тирәсенә салам-печәнне китерәләр, булган азык-төлек байлыгыннан чыгып, бу яңа председатель идарәдәге исәп-хисап кешеләренә артык мәшәкать ясап, рацион төзәргә кушты, ферма абзарларына фонарьлар куелды, тишек-ярыкләрдан җил уйнаса уйный, яктысы булгач рәхәт, каравылчы Хәтмулла карт: «Кинәндем, күземә бер сарык ике булып күренә башлады, яңа прсидәтел шаукымы бу, әллә байый башлавыбыз шушыннанмы?» — дип, ферма кызлары тирәсендә теләнә салынып йөргән була.

Әмма кайдадыр шунда, әкренләп булса да яңалык килгәнен күреп, шуна канатланып йөрүче шул гади кешеләр арасында, бу «яңа прсидәтел»не әле һаман өнәп бетермәүчеләр дә бар, аларның да куллары уйнамый түгел иде. Шундыйларның коткысы кереп булса кирәк, мәсәлән, киномеханик Әхсәнов әлегә хәтле Ахунжановның боерыгын колагына да элмичә йөри бирә; әйберләрен кучерергә икенче бер буш келәтне күрсәтеп бирүгә дә карамастан, «Барып йөрү ерак» дип, Ахунжанов кучкән тыкрык буй өенең амбарыннан әйберләрен алмый да алмый иде. Шуның аркасында Хәдичәнең әлеге теге төнгә каршы Мәргәнтау иленнән Баланлы иленә беренче буларак күчеш ясаган батыр сыеры һәм бүтән кош-кортлары һаман Андрей дәдәйләр абзарында гомер кичерәләр, бу, әлбәттә, өстәмә сүз тудыра, шул сәбәпле кайчагында ир белән хатын арасында сыер җиленәнә ябышып яшәү турында тәмсез сүзләргә дә урын килеп чыга иде. Кирәк бит, шул юк кына нәрсә безнең моңа хәтле туры гына атлап йөргән председателебезне сөртенергә мәҗбүр итте.

Ә бу болай булды:

Әйтеп-әйтеп тә, сүзне колагына алмый йөргән киномеханикны бер көнне идарә йортына чакыртты Ахунжанов. Әйтеп, сүзен әрәм итеп тормады бу юлы. Әхсәновның ишектә күренүе булды, тегенең биргән сәламен дә алмыйча, үзе белән ияртеп алып китте. Күренеп тора: дәү абзыйның кыллары тартынкы иде бу юлы.

Барып җиттеләр әлеге амбар капкасы төбенә. Юл буе сүзсез килгән Ахунжанов монда да сүзне бик кыска тотты.

— Ач,— диде ул, шул бер сүз белән эшне өзәргә булгандай. Әхсәнов каршы килеп тормады, ачты. Ләкин эчкә керергә бик үк ашыкмый иде.

— Ал йозагыңны ишектән,— дип боерды Ахунжанов, өстәп. Әхсәнов бу юлы инде сүзсез генә бирелергә исәп итми иде. Бераз аптыраган кыяфәттә калса калды, ләкин үз кирелеген итмичә булдыра алмады:

— Йозак кемгә дә мишәйт итми, торсын,— дип мыгырданды ул, авыз эченнән бутка пешереп. Кырын-ярын торып ташланган бу кыска-кыска сүзләр аларның икесенең дә сырт йоннары кабара барганлыгын күрсәтә иде. Ниһаять, Ахунжанов бу кире беткән кешегә үзенең председатель икәнлеген күрсәтергә булды:

— Тормасын, минем бикләп тотардай алтыннарым юк,— диде ул, йозакны берьюлы тартып алып. Йозакны Әхсәновка биреп тә тормады, ишек төбенә, карга ыргытып бәрде, ишекне төбенә чаклы каерып ачып җибәрде.

— Аласыңмы бу чүп-чарларыңны...— диде аннары, амбар эченә күз ташлап,— әллә чыгарып атканны карап торырга булдыңмы?

Әхсәнов кымшанып та карамады, ул үзен, күрәсең, кагылмаслык хаклы саный иде.

— Атып кара... җавабын үзең бирерсең,— диде анысы, юри ачу китергеч тынычлык белән. Һәм шушы тынычлыгы белән ул Ахунжановның «Алсу алан»га килеп эшли башлаганнан бирле җыела килгән — эшкә чыкмый калуны гадәти хәл дип санап өйрәнгән колхозчылар өчен дә, итәгенә ут каба калса да пошына белмәс урынбасары өчен дә, узганда-барганда гел, «Безнең сөтсезбикәләрне кайчан ташпулатка кертәсең, прсидәтел?» дип теленә салынып кала торган Хәтмулла карт өчен дә, хатыны Хәдичәнең шул хәтле ерак җирдән — Мәргәнтаудан арлык җәяүләп, сыер җитәкләп килүе өчен дә, бигрәк тә шул үзе җитәкләп килгән сыер өчен, урынлы да, урынсыз да, ире Сәлимгә үпкә белдереп, үзен сыер койрыгына бәйләп калдыруда гаепләве өчен моңарчы әйтелмичә, эчендә җыела килгән ачуын берьюлы һәм тыелгысыз көч белән кузгатып ташлагандай итте.

— Җавап бирүдән курыкмыйбыз без, җавап биреп өйрәнгән кешеләр,— диде ул, Әхсәновка түгел, үзе белән үзе сөйләшеп, һәм шул кызган шәпкә амбар түрендәге мичкәне тышка таба тәгәрәтә дә башлады. Мичкә буш, шыңгырдап тора һәм, болай шәп шыңгырдавына караганда, амбарның эченнән амбарның тышына чыгуга әллә ни каршылыгы да юк иде шикелле. Ә менә хуҗасы Әхсәнов моңа алай тыныч карап кала алмады.

— Не смей минем әйберләргә кагылырга,— дип, ярсып, Ахунҗановның өстенә ташланды. Эш болайга киткәч, элеккеге тракторчы, элеккеге шофер, бүгенгесе көндә дә, узганда-барганда, кеше әллә ни уйлар дип тормыйча, мәктәп ишек алдындагы йөз килограммлы штангны күтәрә-ташлый беләк мускулларын чыныктыра йөргән Ахунҗанов Сәлим дә, әлбәттә, «ләхәүлә!» укып тормады, дәррәү киерелеп, тегене иңбашыннан алып атмакчы иде... теге Әтәч Фәхри ул арада, чигенеп, амбар ишеге чатына барып бәрелмәсенме!.. Тавыш купты һәм, белмәссең, моның зур җәнҗалга барып тоташуы да ихтимал иде. Әмма җене кузгалган Ахунҗанов аны-моны уйлап тора алмады, киномеханикның әйберләрен үз куллары белән берәм-берәм тышка ата бирде.

— Иртәгә үк барып әләклә, соңга кала күрмә, ишетсен колагың,— дип, үчекләү сүзләре белән ачуын басты ул. Һәм соңыннан Әхсәновның үзен, җай гына култыклап, әйберләре янына чыгарып бастырды.

Тавышка Хәдичә дә ишек төбенә чыгып баскан, сүзгә кысылырга базмыйча, бер читтән аптырабрак карап тора иде. Әхсәнов, бензин мичкәсенә утырып, тынып калган, чигәсеннән саркыган канны сөртергә һич ашыкмастан, шушы хәлемдә күрсеннәр дигән кебек, чүмәләдәй утыра бирә иде.

Ул арада Ахунҗанов, ике кеше утыртып, йөк машинасы алып килде. Киномеханикның әйберләрен төяделәр, Әхсәнов үзе амбар капкасына сөялеп, кыл да кыймылдатмыйча, басып тора бирде. Төяп бетергәннән соң, Ахунҗанов, кушып та түгел, ялынып та түгел, әйтте аңарга:

— Сиңа кайда урын бирелгәнне беләсең, алып барып бушат,— диде. Әхсәнов, бер карышусыз һәм шул ук вакытта председатель белән килешергә дә ашыкмыйча, сүзсез-нисез генә кузовка сикерде.

Машина ишек алдыннан чыгып киткәч, Хәдичә карты янына якынлаша төште. Булып узган бу җәнҗалдан, дөресрәге, аның соңы ни белән бетәчәген уйлап, ул борчылып калган иде, моның нәрсә белән бетү ихтималын ничек тә белергә-ачыкларга тырышып, төпченергә тотынды:

— Ниндирәк кеше соң бу? Зурга җибәрмәсә ярый ла.

— Зурга җибәреп нишләр? Аның тиресе әтәч тиресе булганы өчен мин гаеплемени?

— Шулай да... уйлабрак кирәк иде, Сәлим.

— Барысын да ничек уйлап бетерәсең,— диде кабынып, ачуы әле һаман басылып җитмәгән Сәлим,— хатыныңны эшкә урнаштыру турында уйла, ул өстерәп алып килгән сыерга җылы урын әзерләү, ферма терлекләрен ач калдырмау турында кайгырт, эчеп, эшкә чыкмый калган кешеләрне чакыртып өшкер, ә син беләсеңме, миндә дә шул бүтән кешеләргә бирелгән баш кына бит.

Дөресен әйтергә кирәк, бу минутта ул хәтта сөекле Хәдичәсенә дә яхшы ук турсайган иде. Шуның кәсафәтенә бирелеп, тагын да ныграк төрттерә торган итеп өстәп куйды аннары:

— Синең кадерле сыерың аркасында килеп чыкты барысы да.

Хәдичә бу очракта сүзне артык сузмауны хәерлерәк санады. Ахунҗанов, өйгә кереп тормыйча, идарәгә китте, булып узган күңелсез вакыйгага ул әллә ни әһәмият бирмәгән кебек күренә, дөресрәге, шулай күренергә тырыша иде.

Ләкин бу тыштан гына шулай, чынлыкта исә Ахунҗанов ул көнне көнозын кайта-кайта шул турыда уйланып, борчылып йөрде. Соңыннан сүзе булыр, югарыга барып җитәр, авторитетыма сугар, дип куркудан түгел — аның өчен ул әллә ни көйми иде — әнә бит юктан гына кызып китте, димәк, болай дигән сүз килеп чыга: кешеләр белән син әле, хөрмәтле иптәш Ахунҗанов, тиешенчә эш итә белмисең икән, дигән сүз килеп чыга.

Үч иткән кебек, кичен алар өенә каршы яктан салкын җил бәреп исә башлады, өйнең бар күк җылысы кичтән үк очып-таралып бетте, йокы аралаш өсләрен ачып ташлый торган балаларга әледән-әле күз ташларга, урыннан кубып, өсләренә япкалап торырга кирәк иде. Бу мәшәкатьне бер шыңшусыз үз өстенә алган Хәдичәсе турында уйланып ятты Ахунҗанов һәм, көндез хатынына карата ясаган тупаслыгы өчен дә, өйне тиешенчә карамаган килеш семьясын күчергәне өчен дә, әлеге хатыны кузгаткан ясле, балалар бакчасы турында хәзергә әйтерлек эш кырмаган килеш, үз сыерына җылы абзар булдыру өчен шул хәтле кызуы өчен дә һәм, ниһаять, җилнең кинәт кенә аларга каршы булуы өчен дә үзен хатыны алдында гаепле санап, гафу үтенгән сыман әйтеп куйды:

— Бөтенесенә каян күз җитсен, Хәдичә. Каралуы шуның төслерәк булган бу өйнең дә. Әллә бәләкәен үз янибызга алып ятабызмы?

Кечкенә Хәлилне үз араларына алып салдылар. Моннан гына, әлбәттә, өйдәге җил басылмады, ләкин күңел сизелерлек тынычланды. Балаларыннан да бигрәк, үзләре җылынып калган кебек булдылар.

— Кичтән бераз җылы төшереп, ягып аласың калган,— диде Сәлим,— бу юлы инде чак кына булса да гаепне хатыны өстенә аударырга тырышып.

Хатыны, үз нәүбәтендә, Сәлиме турында кайгыртып яткан булган, имеш.

— Кайсыгыз әлек башлады соң сезнең? — дип, истә-оста юкта сорап куйды Хәдичә, көндез булып узган җәнҗалны яңадан искә төшереп, шома гына узмас, кире беткән әдәмгә охшый.

— Бәй, әле син гел шул турыда баш ватасыңмыни? — Сәлим якын итеп, хатынына кулын салмакчы булды, ләкин ике арада тигез генә сулап йоклап яткан Хәлиле бик алай сузылып үрелергә ирек бирми иде.— Юк белән баш ватканчы, инәсе, лутчы син өйне ничек җылыту турында уйла. Бу күсәкне гел генә ике арабызда яткыра алмабыз ич.

Җил кичтән ничек кенә каршы исеп тормасын, иртәгесен яңа көн тумыйча калмады һәм ул яңа туган көн үзе белән яңа мәшәкатьләр, көтелмәгән хәлләр алып килде. Шул көтелмәгән хәлләрдән берсе: икенче көнне, көн урталарында идарә йортына киномеханик Әхсәнов, чакыртып алганны көтмичә, үзе килеп керде. Сүзен нидән башларга белмичә, ишек төбендә чак кына таптанып торды, аннары шул тирәдәге сыңык аяклы урындыкка килеп утырды, чөйкәлеп егыла башлагач, «Ник тоталар монда бу инвалидны?» дип авыз эченнән генә мыгырданып алды да иплебрәк тагын шул ук «инвалид»ка килеп утырды һәм председательнең бушый төшкәнен сүзсез генә көтә башлады. Ә председательгә — әле теге йомыш, әле бу йомыш белән, ә кайберләре исә, эш кырган кеше икәнлекләрен күрсәтеп, юк йомышны бар итеп — керә торалар, керә торалар, кергән берсе аягындагы карны эретә тора, барны-юкны белмичә, аңардан әле теге нәрсәне, әле бусын сорый торалар иде.

Кеше аягы басылып торган бер араны туры китереп, ниһаять, бүреген култык астына кыстырган Әхсәнов та өстәл каршынарак килде.

— Иптәш Ахунҗанов,— дип башлады ул, председательгә бик үк туры карарга кыеп җиткермичә,— мин әлеге... шул кичәге эш буенча.

Сүзгә урын юк, үзең беләсең. Атта да, тәртәдә дә гаеп бар, иптәш Ахунҗанов, ә ныклабрак уйлап карасаң, гаепнең авыр башы миндә. Әйтә торып, кисәтә торып, суза килүче кеше — ул мин. Кыскасы, зурга җибәрмик без ул эшне, кайда булган — шунда калсын. Килештекме шулай?

Өстәл аркылы гына да сузарга мөмкин иде кулны, ләкин Ахунҗанов урыныннан торасы, өстәлнең бу ягына чыгасы итте. Тик шуннан соң гына кулын бирде, Әхсәновның күзләренә карады:

— Бүләсе малыбыз юк, син шушы «Алсу алан»га эшлисең, мин шул «Алсу алан»га бил бөгәм, килешмичә, кая барыйк икән? — дип куйды, уенын-чынын бергә кушып. Ләкин Ахунҗанов бу фактта ничектер зурракны да күрә иде: әнә бит килгән, үз аяклары белән килгән, килешү эзләп килгән. Күрәсең, алдагы уртак эшләрнең, ике арада кабынып киткән очраклы үпкә-сапкаларга караганда, зуррак һәм әһәмиятлерәк икәнлеген чамалаган. Шушы түгелме соң колхозның бер җиңеше, апаем!

## Яз килде, карлыгачлар килде...

Көн язга таба авышты. Буранлы салкын кыш Ахунҗановны башта бик куркыткан иде, инде менә кышны да әкренләп ерып чыгып баралар. Булган салам, печән запасын көздән ферма тирәсенә ташытып, чамача үлчәмен алып, көнлек азыкны рационлап бирү ярады, башка еллардагыча, көздән силос-печәнне ничек эләксә шулай таптатып, әрәм-шәрәм итүләргә, кыш авышу белән кояшта калтырап торуларга юл куелмады. Җитмәгән кадәресен шулай ук алдан кайгыртып, район оешмаларының бусагаларын таптап, кайбер урыннарда юмалап, теленә салынып, кайда өстәл төеп кычкырышып, комбикорм кайтартуга иреште. Мондый сөйләшү вакытларында Ахунҗанов төрле методлар кулланды: берсендә сыгылма телләнеп, дипломатия сата, файдасы тиярдәй кешенең салпы ягына салам кыстыра, икенчесендә, әйтик, район авыл хуҗалыгы производствосы бүлеге Гыйлаҗ Хәмдиев алдында: «Сез үзегез илтеп тыктыгыз башымны, терәлгән вакытта булышырбыз дидегез, мин бүгенгесе көндә терәлүнең аргы ягында. Давай, ирләр булыйк, әйткән сүзебездә торыйк, ләмкәгә тыкмагыз минем газиз башымны, булышыгыз!» — дип, кабыргасы белән китереп куйды мәсьәләне һәм... тегенең әллә ни вәгъдә итми торган, ләкин мәгънәле карашына юлыкты.

— Ул хәтле үк вәгъдә итмәгәнмендер, белмим тагы хәтердән төшеп калган булсаң,— диде, көлеп.

— Төшеп калмаган булырга тиеш, Хәмдиевич,— диде бусы да Хәмдиев җаенарак ятып,— бик истә калырдай чакта, узган елның яңгырлы сентябрендә, покоста яныл яткан борчак басуы кырыннан мине «Алсу алан»га председатель итеп кодаларга алып барганда яудырдыгыз сез ул вәгъдәләрне. Тәки шул минем «Алсу алан»ныкы булып чыкты ул борчак. Без аны, конечно, булдыра алган чаклы җыйдык, кар астында калдырмадык. Но менә кар астыннан чыгып килгәндә көймә комга терәлде. Биргән сүзегездә торыгыз, зинһар, күтәрәмгә калдырмыйк сыерларны.

Тегесе дә хәйләкәр, барын-югын сайрап тормады, телефон колагына ябышты, кем беләндер нык кына әйткәләшеп алдылар. Һәм Ахунҗановка күп сөйләшеп, серне чишеп йөрмәскә кушып, кечкенә бер язу тоттырды. Ике көннән «Алсу алан» колхозына ишелерлек итеп төялгән өч йөк солы саламы, печән кайтты. Ничек итсәләр дә иттеләр,

һәрхәлдә, малларны күтәрәмгә калдырмадылар. Каравылчы Хәтмулла карт хәтта терлек караучы ферма кызлары арасында:

«Бу үзе ахун булмаса да, җаны ахун, ахры, моның. Бер дә тапмаганы юк, тәвәккәлләп, бер әйтеп карыйм әле, миңа рәтлерәк бер карчык та табып бирә алмас микән? Җиңгәгезнең җае китте, төнгә каршы йокы баса, кытыклаганны тоймый башлады, ходай рәхмәте»,— дип теленә салынгалап та алгалый иде.

Эш арасында берме, икеме тапкыр спектакль дә куеп алдылар. Ләкин бу спектакльләрнең берсендә дә кибетче Мөршидә катнашмады. Әйтсәләр, әле ревизия киләсе бар, театр уйныйсы көннәрем алда дип, әле теге чакта Галиябану булып уйнаганым өчен дә хурланып бетә алмыйм, сезнең дүрт балалы Ахунҗановыгызны төнлә, йокы калдырып, тәрәз төбемдә сагалап утырасым юк. Ичмасам, киләчәктә бирәр төрле хикмәте чыгардай адәм булса икән! дип, шаяртып булып, эчендәгесен шарран яра әйтеп бирә иде. Әмма бу «тартагә тибүләр» бөтенләй юктан гына да түгел, Ахунҗановның семьясы килү, аларның бергә оешып тора башлаулары Мөршидәнең еракка төбәлгән планнарын берьюлы җимереп ташлаган, хәзер инде аның кибетенә бурычка акча сорап барырга шалишь, хәер, колхоз соңга таба янчык төбе селкерлек хәлгә дә калмый, шулай булгач «спектакльләр» уйнарга туры да килми иде.

Шулай да бер авыл бит — юллары сирәк булса да очраштыргалап тора. Урамнан башны бик текә тотып, кышкы салкыннан һәм канының үтә кайнар булуыннан кызышып, авылның тол ирләрен «каккан көлтәгә» исәпләп, егет-җилкәннәрен борын аслары кипмәгән малайларга санап, берсенә дә сәлам бирмичә һәм берсеннән дә биргән сәламне алмыйча, тыз-тыз атлап баручы бу тәкәббер чибәрнең юлына шулай да, алла туры китереп, әлеге шул, болай да яшертен каһәрләргә дучар булган «Ахунҗанов абыйсы» очрый гына күрмәсен. Очрадымы, Мөршидәнең бөтен тәкәбберлеге берьюлы коелып төшә, йөзе тагын да алсулана һәм ул, туктамас җиреннән туктап, үзе башлап сүз куша:

— Карагыз әле, Ахунҗанов абый,— ди ул, гозерен әйтмәс борын ук алдан кызара-уңайсызлана төшеп,— райсоюзга йомышым төшеп тора бу араларда. Районга барасыгыз юкмы? Мин дә барыр ием бер читегезгә генә кысылып.

— Юк,— ди Ахунҗанов, бер сүз белән өзәргә теләгәндәй. Һәм шундук үзенең дә, кибетче хатынның да рәсми кешеләр — эш кешеләре икәнлеген искә төшереп, җитди генә өстәп куя: — Әгәр ат кирәк дисәң, кайчан барасыңны идарәгә кереп әйтерсең, нәрәт бирербез.

Һәм шул кыска гына, ачык кына сүзе белән Мөршидә-хыялыйның бөтен өметләрен таптагандай, китә дә бара.

Тагын нәрсәләр булды соң әле ул кышта?

Бураннар булды, суыклар булды, райком бюросына чакырып, «өркетүләр» булды, шифер түбәле тыкрык буй өйдә таракан катырырлык төннәр булды, гаҗәп түгел, шуннан чыгып Хәдичәнең ара-тирә үпкәләүләре дә булгалый торды. Сүзгә сәбәбе дә бар иде, хәер: «Эшең күп булгандыр шул, әтисе, без күрмәдек-белмәдек, эштән бүтәне дә булгандыр, тик миңә, әйтсәм әйтим инде, балаларыңны китергәнче өеңне каратып куярга гына вакытың булмаган. Иртән ягам, кич ягам, төннең икенче яртысында хет кулыңа бияләй киеп йокла».

Бер карaганда, ярап та куя болай кимерүләр. Ничектер тормышка охшап китә. Хатының булып та, иртә-кич колак итеңне кимермәсә, ул аннары тормышмыни!

Әлбәттә, өйне бик нык лап каратырга кирәк булыр — җәйгә чыккач эшләнергә тиешле эшләрнең берсе шул. Ахунҗанов моны күңел дәфтәренә беркетеп куйды. Ләкин Ахунҗановны да, хатыны Хәдичәне дә сүзсез генә уйландыра торган бер мәсьәлә көн тәртибендә тора: Хәди-

чәнең бишенчегә буенда бар. Ул инде Мәргәнтауда чакта ук бар иде, үзен сиздерә башлаган иде, монда килеп «Алсу алан»ның житәр-житмәс әпәен ашый башлагач, туганым-җиңги күзгә күренеп күперep китте. Менә моны инде, абзыкаем, җәйгә, өй ремонтлагач, дип арткарак күчереп торырга һич мөмкин түгел. Суыкмы өең, җылымы — аның белән исәпләшеп тормастан, дөньяга киләчәк җан киләчәк!

Җитмәсә тагын, бәләкәй Хәлил, хәзергә иң төпчеге — иң кадерлесе буларак, әти белән әни арасында йокларга инде тәмам ияләшеп өлгергән иде. Аны әкренләп биздерү, ике араны туачак бишенчесенә — тагын да кадерлерәгенә — әзерләү өчен әти белән әни кешегә Хәлилмалай алдында өстәмә аңлату-төшендерү эшләре алып барырга кирәк иде.

— Улым,— диде әтисе бер көнне, тора-торышка малайны иркәләп,— сиңа безнең арада йоклау рәхәтме?

— Ләхәт,— диде тегесе, бу сорау астында мәкерле ният ятканлыгын һич төшенмәстән. Ә әти кешегә, бигрәк тә председатель булган әти кешегә, җеп очын артык эчкәре яшереп, бутап сөйләү, әлбәттә, килешми. Шулай булгач, председатеть-әти малайга суынырга ирек бирмәде:

— Ләхәтен-ләхәттер дә бит, улчыгым,— диде ул, малай логатенәрәк күчеп,— әнә бит әниең әйтә: судан нәни бәбәй алып кайтам, ди. Ике арада шул нәни бәбине йоклатырга кирәк булыр.

— Үзем ятам, үзем ятам,— дип тыпырчынды малай. Әлбәттә, көне-сәгате белән генә бәләкәй Хәлилгә бу катлаулы философияне аңлатып биреп булмады. Өйне тышкы яктан да, түбән өйгә төшеп, эчтән нигезен дә ныгытып карадылар, аңа карап кына өй әллә ни җылынмады. Яз бусага төбенә үк килеп җиткән булса да, кыш әлегә бирешми, күрсәтәсе зәһәрен күрсәтә тора иде. Шул арада безнең Хәдичә килен, бернн белән дә исәпләшеп тормастан, бишенче баласын, «Алсу алан»га килгәч беренчесен, «судан» алып кайтырга да өлгерде. Кыз бала, белеп торыгыз, бусы инде «Алсу алан» кызы, сүзгә урын юк, Хәлил абыйсына, теләсә, теләмәсә дә, ике араны калдырырга туры килер.

Шулай итеп, «Алсу алан»га элек кыз, кыз артыннан озак та көттермичә яз килде. Кызга Тәскирә дип исем бирделәр, бәхетле кыз булырга охшый, салкын өйдә озак туңарга туры килмәде, яз үзе белән җылы көннәр, шаулы гөрләвекләр, дәртле ташулар, кара-кучкыл сыерчыклар алып килде. Ык елгасы, ярларыннан чыгып, болыннарга җәелде, елга буе тирәкләре су эчендә калды, шул ук су уртасында анда-санда утрау булып калкып калган түбә урыннарда өннәрен югалткан куяннар чапаланалар, ә кем белеп бетергән, ашыгып һәм дулап килгән бу ташкынлы яз тәэсирендә чапаланучы җан ияләре, бәлки, ул куяннар гына да булмагандыр. Ыкның болай җәелеп ташуын, сыерчыкларның болай кара-кучкыл булып килүләрен яхшыга — елның уңышлы килүенә юраучы тәҗрибәле картлар Баланлыда да, әлбәттә, юк түгел иде. Аларның бу юрауларына рәхәтләнеп колак салганы хәлдә, Ахунҗанов шулай да ул юрауларга гына ышанып ята алмады. Бу әле аның «Алсу алан»дагы беренче язы, чын дәреслектә аның төп эше дә шушы яздан башлана. Шайтан тавындагы ташларны кузгатуын, «хезмәт көненә акчалата түли башлыйбыз» дип кесәгә керәчәк акча исәбенә колхозчыларны җилкендерүен, Хәтмулла картның сыерларына ташпулат вәгъдә итүен һәм кайбер эленке-салынкырак йөрүче кешеләр белән якага-яка килүен искә алмаганда, моңа хәтле әле ул, күбесенчә, узган хуҗалык елының сузылып калган «койрыкларын» җыю белән генә үткәрде. Инде менә үз елын башлый, куктән сорап торганчы җирдәгене әйләндерәсе булыр, хәер, иманы нык яңа председательнең, һәрхәлдә, үз «койрыкларын» башкаларга җыярга калдырмас.

Язгы кыр эшләре зур оешканлык һәм аннан да зуррак өметләр белән башланып киткән иде, югыйсә. Шулай да күчәр башлары бәреләсе урыннар бар икән. Шулардан берсе — бухгалтер Мөстәкыймов белән булды. Колхозчыларга акчалата түләүгә күчкәч исәп-хисап эшләренең катлауланууыннан һәм, аннан да бигрәк, касса төбең такыр килеш төрле якка акча белән селтәнүдән аптырабрак калган бухгалтер, колхоз хисабыннан стипендия түләү шарты белән өч кешене Бөгелмәгә — төзүчеләр курсына җибәрергә дигәч, тәмам чыгырыннан чыкты.

— Чәчү өстендә, панимаешь, бер кешене өчкә ярырлык көннәрдә,— дип тотынды ул, барыннан да элек колхозның кыр эшләре турында кайгырткан атлы күренергә тырышып. Чын дәреслектә, бухгалтерны колхозның касса ягы борчый. Моңа хәтле булган председательләр вакытында җыйган ачы тәҗрибәсе дә житәрлек, тәңренең бирмеш бер көнендә бөтенләй буш кесә белән комда утырып калудан шикләнә иде. Ахунҗанов аның борчылуын аңлый, ләкин шулай да тәвәккәлләү ягында тора иде.

— Бүредән курыксаң, урманга барма, син бу мәкаль белән килешәсеңдер ич, Әзһәр абзый? — дип сабыр гына тотынды ул һәм, колхозның якын киләчәктәге эшләрен күз алдына китереп булса кирәк, соңга таба ялкынлана төшеп исбатларга кереште.— Бүген белән генә эш бетми; дөресе, абзыкаем-җаным, бүген әле безнең зур эшебез башланырга гына тора. Әнә никадәр көч салып, таш чыгардык. Әрдәнәләргә өеп куеп, бер читтән сокланып карап торырга дип чыгардыкмыни без аны? Язгы кыр эшләрен генә иңнән төшерик, сразы терлек абзарларына тотыначакбыз. Специалистлар кирәк булачакмы бу эш өчен? Кирәк булачак. Синең янчык авызын кысып тотуың әйбәт, Әзһәр абзый, анысына сүзем юк, мәгәр... мондый чакта әйтелә торган тагын бик шәп бер мәкале бар татарның барлыкка да, хәзергә калып торсын инде. Кыскасы, булган чаклысына янчык авызыңны чишә тор, житеп бетмәстәй булса кайбер башка ишекләрне кагарга туры киләчәк, дөнья бу, причем социализм дөньясы. Бу урында ул әлеге иске танышы кибетче Мөршидә аягына барып егыларга исәп тота — ах алла, колхоздан ат сорап торганда ярый, бушлай сорамый, әҗәткә сорый.

Моңа чаклы бик аз сүзле, кырыс председатель бу сөйләшүендә татарның әллә кайчангы мәкальләрен кыстырып сөйләшкәч һәм бер-ме-икеме газет сүзе дә кушып җибәргәч, безнең саран бухгалтерыбыз булган чаклысы белән янчык авызын чишмичә булдыра алмады.

Шул рәвешчә, бу сөйләшүне дә эш файдасына җайлап, кичлек эзләгәндәй кырларга чабып, анда да бензин яндыру белән генә калмыйча, кайсына җылы сүз белән җан өреп, кайсына кирелә... машинасын ходка җибәрергә булышып, арып-талып, идарәгә кайтып егылган гына иде, ишек төбендә аны танып бетермәгән бер колхозчы көтеп тора, имеш. Моңарчы йөзгә йөз туры килмәгән бу кешенең исемен белеп житкерми иде әле Ахунҗанов, шуның өчен эченнән генә уңайсызланып һәм бик тә иплә күренергә тырышып:

— Нихәл соң, абзый, ни йомыш белән йөрү иде? — дип, үзе сүз башлады. Бер мәл ниндән тотынырга белмичә аптырабрак торды абзый, иреннәре мелт-мелт кыймылдый, ә үзенең сүзе чыкмый иде. Ниһаять, бар күк зиһенен туплап һәм үзе монда булмаган бер кешегә бик тә хәтере калганлыгын ачыктан-ачык сиздерергә тырышып, башлап китте:

— Йомыш дип әйтерлек әллә ни зур йомыш та түгелдер, кем, иптәш прсидәтел. Бәлкем, уттай эш өстендә юк белән йөрисең, дип әрләп тә чыгарырсың. Илла-мәгәр әйтмичә булдыра алмыйм, түздем-түздем, инде артык түзәрлек әмәлем калмады: ник сүгенеп сөйләшә ул Әшрәпов Миргасыйм? Җүнләп әйтәсе урында, авызына кергәнне

эт жыймый. Бүген килеп, дөньядагы белән минем иллелән узган карчыгымны сүгеп киткән. Теге бичараны таш төяргә — Шайтан тавына җибәрмәкче, ә карчыкның бүсере кузгалганлыкка кулында брач язуы бар. Әйтик, брач язуы булмасын да, ди. Әйтегез әле, зинһар, кем, иптәш прсидәтел: көпә-көндез кешене, әйтик, нәмәхрәм хатын-кызны, дөньядагы белән тотып сүгәргә дигән закон бармы икән? Үзем, аллага шөкер, елның елында милимунны тутырып барам, шушы «Алсу алан» колхозына беренче булып аяк баскан кеше — бармы икән шундый битиран колхозчыга кычкырырга ярый дигән закон? Бригадир булдым дигәч тә, теге ни...

Чынлап та, бик нык ачуы чыккан иде булса кирәк, абзый кеше әнә шулай тезде-тезде дә кинәт тукталып калды һәм, башлагандагы кебек, иреннәре сүзсез генә мелт-мелт кыймылдап тора башлады. Ахунҗанов шундук счетовод кызларның берсен чакыртып, бу ачулы абзыйның сүзләре ни дәрәҗәдә дөрес булганлыгын тикшерде. Шулай икән, юкка шапырынмаган: абзыйның узган хуҗалык елында бер үзенең йөз житмеш хезмәт көне җыелган, карчыгыныкы да үз турына ярарлык иде. Яңадан теге борын төбендә генә кыска мыек үстергән һавалы егет күз алдына килеп басты председательнең.

Бу колхозчыны ничек кирәк алай тынычландырып җибәргәннән соң, Ахунҗанов шундук бригадир Миргасыйм Әшрәповны чакырып сөйләшмәкче иде дә, сөйләшү белән генә рәт чыгарып булырына ышанмыйча, мәсьәләне идарә утырышына куярга, ныклап кыздырырга һәм урынына берәр иплерәк кеше карый торырга булды. Онытмас өчен өстәл календарена билге дә ясап куйды. Бригадир Әшрәповның кешеләр белән тупас мөгамәләсе, әшли белмәве турында моннан элек тә сигналлар булгалаган иде, күрәсең, ничектер колак яныннан узган. Моңарчы идарә тирәсендә чуалып йөрмәгән бер колхозчының килеп эч зарын бушатуы председательне бу турыда ныклабрак уйланырга мәҗбүр итте. Һәм бу эпизод Ахунҗановны тагын да житдирәк, моңарчы ничектер башка килмәгән бер ачышка китерде: кара әле, колхозчы үзенең кешелек абруен саклый белә бит хәзер, урынлы-урынсыз үзенә кычкырганны гафу итә алмый! «Алсу алан»га килгәч алган күп кенә сабаклары янына, менә тагын бер сабак. Ә менә Әшрәпов урынына кемне табарга булыр? — бик күп мәшәкатьләр өстенә тагын бер өстәмә мәшәкать дигән сүз.

Әнә шундый эреле-ваклы мәшәкатьләрне җиңеп, өстән дә, астан да сабак ала-ала, шулай да алар язгы чәчүне үз вакытында һәм тел тидермәслек итеп ерып чыктылар.

## Ә бу юлы аны ектылар

Борынгыдан калган йола: сабан чәчүләрен бетергәч, тузан коеп, бер җилләп алырга — бәйрәм итәргә кирәк иде. Баланлы авылы кешеләре дә бу мәсьәләдә бүтән авыллардан калышмадылар, кайбер яклары белән хәтта чак-чак кына арттырып та җибәрделәр түгелме икән әле! Кунак чакырулар, бал әчетүләр, бер кузгалганда бөтенесен берьюлы өстән төшерергә тырышып, малай өйләндереп, кыз биреп, туй итеп калырга әзерлек күрүләр, яки бернинди әзерлексез, бергә кино караган җирдән, кино билеты бәясенә әнине киленле, үзен кәләшле итеп калдырырга тырышулар гармун кычкырту, телевизор белән мактану, кызмача баштан мотоциклга утырып, урамда тавык тапгатып чабулар, кибет алды мәзәкләре, бернинди музыкасыз, бары тик эчкә үрләп өлгергән «шайтан суы» коткысына бирелеп, җиргә бүрек бәрә-бәрә биюләр, тагын башка күп төрле шашынулар — о, уңышлы башка-

рылган язгы [illegible] соң җиңеләеп калган авыл кешесениләр генә кыланмый да, моның өчен аңарга үпкәләргә мөмкинме соң!

Шулай да авылда өч кеше бу сабан туена бөтенләй үзләренчә әзерләнделәр, шаулавын күп шауламадылар, ә баскан җирләрендә эзләре калды.

Бу өчнең берсе, әлбәттә, колхоз председателе Сәлим Ахунҗанов иде. Хәер, очынырлык җире дә бар иде шул бер караганда. Язгы чәчүне, бик үк беренчеләрдән булмаса да, үз вакытында ерып чыкты. Җитмәсә тагын, Баланлыга килгәч туган кызы Тәскирәсе бар, бигрәк тә шунысы ярап куйды: бала тугач, Хәдичәсе тоташы белән шуңа сыланды, башка дәгъвалары ничектер икенче плангарак күчте. Колхоз председателе буларак, һәм, шуның өстенә тагын, бу авылда үзен чамача яңа кеше санап, Ахунҗанов, әлбәттә, сикермәде, үзен тыйнак тотты, кунакка чакыручы кешеләрдән төрле сылтаулар белән тайпылып калу ягын карады, без тегеләй эшләдек, без болай эшләдек, дип мактанып, район газетасында мәкалә бастырырга да ашыкмады. Кибеткә кереп чыгасы килгән минутлары булгаласа да, бердән, кибетче Мөршидәнең кыек атып туры тидерергә тырышып әйтә торган чая сүзләрен ишетергә теләмәде. Икенчедән, кибет алдында мәзәк сатып торган кайбер сәрхүш авылдашларын бүлдерүдән куркып, ул тирәне әйләнебрәк узу ягын карады. Аның каравы, мәктәп тирәсеннән берничек тә әйләнеп уза алмый, киресенчә, соңгы вакытларда, бигрәк тә сабан туе көннәре якынлашу алдыннан, иртән — бригадаларга узышлый да, кичен кеше-кара аягы басылгач та мәктәп ишек алдына кагыла китә, мәктәп ишек алдында аунап яткан әлеге йөз килограммлы штанганы күтәреп ала да ыргыта, күтәреп ала да ыргыта. Менә бу чаклысында ул гаеп итәрләр дип тә тормый, тыйнаклык саклауны да артык саный — чөнки күңелендә тыелгысыз бер тилелек саклана: сабан туе мәйданында көрәшкә чыгарга дәрте кузгалып тора иде. Дөресен әйткәндә, Сәлимнең күптәнге өянәге бу. Ул Мәргәнтауда чагында да көрәшкәли иде, районда шоферлар курсында укыган чагында район сабан туена туры килеп, хәтта бер батыр да калган иде. Шул вакытта бүләк итеп бирелгән кер югыч аппараттан аның Хәдичәсе әле бүген дә булса файдалана. Дөрес, ул вакытта колхоз председателе түгел, гади бер механизатор гына иде ул. Мәргәнтауда исә үз кетәге, шунда торып канат каккан әтәч. Анда аңарга ничек канат какса да яраган.

Хәзер бит колхоз председателе, аның бөтен хәрәкәтен сынап торалар булыр, әтәч булып кычкыручылар аңардан башка да табылыр. Көрәшкә яшьрәкләр дә бетмәгән, биш бала атасы була торып ул кысылып йөрмәсә дә...

Аннары тагын, үзе шундый өянәкле кеше булгач, якланып китеп, сабан туе бүләгенә бик тә күз төшәрдәй зат әйбер тапкан иде ул. Район универмагыннан бик шәп стена келәме сатып алып кайтып, идарә исеменнән сабан туе комиссиясенә шул бүләкне тапшырган иде. Җитмәсә тагын — кеше күңеленә ни килмәс — шул келәмне кулга төшерергә йөри, бармагы үзенә кәкре кешенең, дип уйлаулары да мөмкин.

Күңеленнән шуларны үткәреп, көрәшкә бөтенләй чыкмаска, вакарь саклап кырыйдан гына карап торырга булды. Шулай карар кылды, шулай эшләсә дөрес чыгачагына акыл белән үзен тәмам ышандырды. Ләкин акыл бер нәрсә, яшьтән кузгалган өянәк икенче. Бигрәк тә элек кайчандыр берничә мәртәбә көрәшеп, бу дәртле ярышның корты кергән кеше өчен.

Шулай уйлады Сәлим, ләкин шулай эшли алмады. Мәйданда көрәш башлану белән бөтенесен, шул исәптән үзенең колхоз председа-

теле икәнлеген дә, биш бала атасы булганлыгын да онытты, тыелгысыз көч белән мәйдан уртасына сикереп чыгып, көрәшкә кушылып китте.

Штанга күтәргәләп маташулары да тиккә генә булмаган икән, электән көрәшкәләп йөрүләре дә үзенекен итте, бер киткәч китте безнең председатель, берне екты, икенчене әйләндереп салды. Аннары аңарга каршы Соликамск ягыннан кайткан бер әзмәвер килеп чыкты, урман эшендә эшләгән кеше, диделәр, үзе дә ачык җирдә — кояш күзе астында үскән яшь имән кебек таза иде. Моны күреп, кайберәүләр шундук председательләре турында кайгырта башладылар: «Ай-һай ла! Җайсыз килеп чыкмагае председателебезнең эше, беләкләре берсе бер самовар юанлыгы, безне председательсез калдырмагае бу нахал кунак!» дигән пошаман узды. Китте як-яктан сүз ташлау, кисәтү:

— Кара әле, кем, Сәлим туган, әллә, болай гына бәхилләшеп, күтәртеп кенә куясыңмы бу егеттән. Җилкә бик киң, пранә мич капкачы хәтле.

— Биш баласы бар, хатыны яшь, панимаешь... Алдын-артын уйламый кеше.

— Менә син уйлыйсың да бит... көч ягы сыек.

— Әйдә, аллага тапшыр, прсидәтел. Керәшен алласы ни, татар алласы ни, икесе дә почетта түгел хәзер.

Ахунҗанов игътибар иттеме бу сүзләргә, юкмы, ул турыда башка китерергә дә өлгерә алмадылар, менә ул бурсыктай бөтерелеп Соликамск әзмәвереннең култык астына кереп чумды, башы шунда, кайдадыр, аста, бер мәлгә югалып калды, шуннан — астан торып теге «Яшь имәнне» берме, икеме тапкыр зырылдатып селкетеп куйды, теге моны нәрсәгә юрарга да өлгерә алмый калды булса кирәк, көчтән дә бигрәк хәйлә белән Ахунҗанов кунакны астан казып чыгарды һәм баш аркылы чөеп атты. Бөтенесе — дусы да, дус түгеле дә — мәйдан яңгыратып гөжләп куйдылар, тагын уены-чыны яварга тотынды.

Ахунҗанов биш минутсыз сабан туе батыры, идарә исеменнән билгеләнгән зат келәм менә-менә хөрмәтле председательнең өстенә бөркәлергә тиеш... дип көткәндә, мәкер белән корсагы тулган ич бу дөньяның, чыкты шуннан «Алсу алан»ның үзеннән бер яшь әтәч, тракторист диделәр үзен, Ахунҗановның белгән-яраткан егете, Таш елганыкы, әлек дусларча елмаешып көрештеләр. Бу көрешүне төрлегә юраучылар булгандыр, янәсе, әгъвали түгелме председатель Таш елга егетен? Ләкин алай булмаган икән шул. Белгән кеше дип тә тормады Таш елга, биш баласы бар дип тә исе китмәде, ниһаять, «Председателем бит ул минем, соңыннан йомышым төшүе бар!» — дип тә курыкмады, Ахунҗановның үзе кебек, култык астына чумып, югалып та маташмады, алды биленнән кысып, чөеп күкрәк өстенә менгезде, бер мәл мәйданга күрсәтеп селкеп йөртте һәм... Сау бул, председатель Ахунҗанов! Сау бул, ике йөз сумлык келәм, мәйдан «ух!» итеп гөжләде, ә председатель, бөтен мәктәп штангасын күтәреп җыйган мускуллары һәм батыр калырга чамалаган исәпләре белән, бер якка чәчрәп барып төште.

...Шунысы кызык: бу егылуыннан соң Ахунҗановның көрәш өянәге басылса басылгандыр, әмма «Алсу алан» кешеләренә булган ышанычы һәм мәхәббәте басылмады гына түгел, ә бәлки тагын да көчәя төште: «Борынынны бик чөймә, Мәргәнтау тумасы. Монда синнән мәргәнрәк егетләр үсә икән!» дип, үзенә-үзе сабак биреп куйды ул.

Сабан туена хәзерлек көннәрендә, бәйрәм үзе шаулаган бу көннәрдә, үзенә бер шашыну белән, җанына урын тапмыйча атылып йөрүчеләрнең берсе кибетче Мөршидә булды. Сәүдәсе туктап торганнан түгел, юк, ул көннәрдә сәүдәсе шәп барды аның, кешеләр кибет юлына тузан төшермәделәр, дөресен әйткәндә, Мөршидәгә көндезләрен күңелсезләнергә вакыт та тимәде. Изүләрен бәйрәм җаена җилбәгәй

җибәргән яшь-җилкенчәк кибеткә керә торды, өендә салынган «нигезне» кибеттәге алты кырлы стакан белән нygыта торды. Һәм үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, кәефе күтәренке ир-ат мондый чибәр кибетче хатын кулыннан алып эчкәч, теленә хуҗа була аламы соң: я кирәгеннән артык мактап, я булмаса киртәгә кермәгән берәр уен-көлке әйтеп, теге бичараның бәгыренә тоз салып чыга. Ә төбендә боларның бер нәрсә ята: Мөршидә «ирдән кайткан нәрсә», янәсе, күчәр башы белән бәрелеп киткәнгә генә укасы коелмас, коелса тагын елап барып сыеныр кешесе бармы? Телдән әйтеп үк бетермәсәләр дә, бу шук шаяру сүзләрен Мөршидә шулай аңлый һәм, әлбәттә, кешегә чыгармыйча, эченнән генә моңа бик-бик кимсенә иде. Сөйләп тә торасы юк, аның да, әлбәттә, иргә чыгасы килә, яшьлек тилелеге белән эшләп ташлаган хатасын хәзер инде бөтен ачылыгы белән төшенгән: ир хатыны булып, иреңне иркәләп, үзең аның тарафыннан иркәләнеп торуга җитми икән. Ике арада кайчак тырт-пырт әйткәләшеп алулар булса булыр — була бирсен, ул шулай ике арада була да бетә, иртәгесен тагын син аңарга, ул сиңа кирәк, аның каравы, ир белән торганда синең янында яклаучың бар, узып барган һәрбер эте-бете синең битеңә тәрәп юкны-барны әйтә алмый.

Шундый борчылып уйланулар, кимсенү һәм яшертен сагышлар аркылы үтеп килмәкче иде Мөршидә «Ахунҗанов абыйсы»ның ишыгына, ә менә ул ишыкта туктап хәл җыярга мөмкин булмады, чөнки аның ишыгында икенче кеше — аның үз кешесе бар икән. Шулай да икәүдән-икәү генә калып, бер сөйләшәсе иде, чынлап та, чынлап та өзелмәслек җепләр белән берекканнәрме алар? «Чәчләр бәйләнгән, балалар булган, инде кая барасың?» дип кенә яшәүләре түгелме? Шулай уйлап, тагын бер очрашу өчен озак кына җайлы форсат сагалап йөрде Мөршидә.

Ә хатын-кыз, бигрәк тә Мөршидә кебек чая хатын-кыз, эшлим дисә, күңеленә килгәнне эшләми каламы соң! Әлеге шушы сабан туйлары белән баш әйләнгән көннәрнең берсе иде, идарә йортында Ахунҗановның ялгыз үзе генә утырганын тәрәзә аша күреп, Мөршидә, алдын-артын уйлап тормастан, аның янына барып керде. Керде, ләкин ишек төбеннән узмады. Балалар кебек бераз тотлыкты, шул ук вакытта балалар кебек логикасыз иде.

— Син курыкма, Ахунҗанов абый, мин хәзер чыгам... Мин болай гына,— дип башлады ул, кереп баскан җиреннән адым да кымшанмыйча,— колхоз белән безнең алыш-биреш түләнгән.

— Безнең бухгалтер да шулай уйлый,— дип шаяртыбрак җавап кайтарды Ахунҗанов. Бәлки, аңарга бу минутта болай шаяртырга кирәк тә булмагандыр, Мөршидә кинәт битен учлары белән каплап елап җибәрде.

— Син шаяртасың, Ахунҗанов абый,— диде ул, бераздан ничектер үз хәленә кайтып,— ә мин менә сүзем булганга кердем.

— Язма рәвештәме, телдән генәме? — дип, әле һаман да шаярта биреп сорау куйды Ахунҗанов. Куркуын курыкмаса да, кинәт килеп кергән бу сәер хатын председательне бераз аптыратыбрак калдырган иде. Ләкин инде бер дерелдәп алган Мөршидә бик катгый һәм бик җитди иде бу минутта. Һәм сүзне озакка сузуны кирәк дип тә тапмады.

— Сүзем шул, Ахунҗанов абый...— Мөршидә тагын тотлыгып калды, тәрәзәгә күз төшерде, ахрысы. «Кеше күрмиме минем монда ялгызым гына басып торганны?» дип уйлады булса кирәк күңеленнән. Һәм, шуннлыктан аеруча кабаланып, булган логикасын да чуалтып, кинәт һәм беркадәр дорфарак рәвештә ярып салды,— әйтегез әле, Ахунҗанов абый, только ни... яшермичә генә әйтегез: Хәдичә апа гел

шушында безнең «Алсу алан»-да торырга ... ... ... ... ... ... ... ...
Әллә китәчәкме?

Ахунжанов сорауның болай кинәт һәм кабыргасы белән куелуын-нан, Мөршидәнең тавышында һәм күзләрендә чагылган ялварудан ук сизеп алды — юк, уйнап килмәгән, уйнап сөйләшми иде бу тынычлыгын югалткан хатын. Һәм, әлбәттә, җавапны да житди итеп әйтергә кирәк иде.

— Ә кая китсен ул, минем законный хатыным була торып? Мин кайда — ул шунда.

Башка берни дә кирәк түгел иде Мөршидәгә, бөтенесен шушы берничә сүздән аңлап өлгерде ул: әйе, бу шул — Мөршидә кемнән булса да көтә торган яклау сүзе инде, ләкин ул сүзләр бөтенләй башка кеше адресына — Хәдичәсенә карата әйтелде. Димәк... син үзеңә ышыклану урынын башка тирәдән эзлә инде, хөрмәтле кимсенгән жан!

...Шуннан өч-дүрт көннәр узгач, сабан туе шау-шуы басыла төшкәч, телдән-телгә күчеп һәм жор телле кешеләр тарафыннан бераз куертылып өлгергәннән соң гына Ахунжановка бер хәбәр килеп житте: кибетче Мөршидә, кибетен ашыгыч рәвештә сельпога тапшырып, Соликамск ягыннан сабан туена кайткан элеге егеткә ияреп китеп барган. Чын булса әгәр, әйткән, ди, киткән чагында: «Бар иде Баланлыда күз атып йөргән бер кешем, бактың исә ул да: «Кем колы торырсың? Хатын колы торырмын», булып чыкты, инде хәзер Баланлы авылыгызда үземне түгел, эземне дә таба алмассыз!» — дигән, ди.

Әйткәндерме-юктырмы, ул чаклысы ачык түгел, ачыгы шул булды: атнамы-ун көнме узгач, «Алсу алан» колхозы идарәсенә, колхоз председателе Ахунжановка адресланган, ләкин кайдан икәнлеге күрсәтелмәгән, кыска гына бер хат килеп төште:

«Ахунжанов абый! Озак саташырга сәбәп калдырмыйча, ачыктан-ачык әйтеп бирүең өчен рәхмәт. Үзеңнең Хәдичәң белән яшә, мәңге бәхетле булыгыз. Ә мин үз бәхетемне әлегә һаман эзлим, һаман таба алмыйм.

*Соңгы сәлам белән: Мөршидә дип белсәгез, укып, хәер-дога кылсагыз икән».*

Тагын да соңыннанрак, башта телгә алынган «өч кеше»нең өченчесе, соңгысы, калкып килеп чыкты. Бер көнне кич, истә-оста юк чагында, Ахунжановның квартирына аның урынбасары Һадиев килеп керде. Бәйрәмнәр инде узган булса да, Һадиевның бәйрәме әлегә узып бетмәгән, ул әлҗе-мөлҗерәк иде. Бәлки, болай батыраеп өйгә чаклы ук килеп керүе дә шул әлҗе-мөлҗелеге аркасында булгандыр. Шулай да үзен-үзе белештермәслек түгел, аягында нык басып тора, исерекләргә хас булганча, керүе белән сүздән бау ишәргә тотынмады. Бер-ике генә адым атлады да туктады, түбәнгә карап кына сүз башлады.

— Бу сабан туе шаукымы узсын да, син, председатель, мине бүтән бер эшкә куш, яме. Житте, председатель булып та карадым, заместитель дә булдым, эш кенә кыра алмадым. Кәнсә эше — минем эш түгел, ничу кара әпәйдән ак әпәйгә сузылып азапланырга. И тагын шул хәтлесен дә әйтим, күңелем йомшак чакка туры килдең, әйтмичә кала алмыйм, душа мой, синең тәгәрмәчкә таяк тыгарга маташучыларның берсе — ул мин дурак идем. Ә туктатып булмады синең тәгәрмәчне и канса-канис, ник кирәк аны туктатырга? Только сүз шул: котлар син мине папка күтәреп йөртүдән.

Ахунжановның башына кинәт кенә тәвәккәл бер уй килде: «Ә ничек булыр моны Мыек урынына бригадир итеп куйсак? Ничек тә жирне ярата торган кеше бу».

— Ә соң син кешеләр белән эшли белерсеңме, Бакый абзый?

— Әйттең сүз: кешеләр минем алда биеп торачаклар.

— Биетү соралмый, эшләтә белеп эшләтү сорала.

— Болай салгалап йөрүләр булмасмы?

— Булмас! — диде Һадиев кистереп һәм болай кистереп әйтүенә төзәтмә кертергә ашыккандай, өстәп куйды: адәм әүлия түгел, чамасы туры килгән чакта анда күз күрер.

— Акчасы бар чакта дисәң дөресрәк булыр, Бакый абзый.

Ахунжановка Һадиевнең рыяланып тормавы ошады.

— Бар, бүгенгә кайтып ят, иртәгә керерсең, уйлашырбыз. Анысы правление эше.

— Мин үзем дә правление члены,— диде Һадиев, кукрая төшеп, һәм күндәм рәвештә кабатлады:

— И шуның белән кәнсәләрдә болганып йөрүләргә капут. Сөйләштекме шулай, Ахунжанов?

Бу әле, әлбәттә, сөйләшү түгел, бу — бәйрәме тукталып житмәгән урынбасарның, ихтимал, аяк өсте күргән төше генәдер. Шулай да моңарчы гел кара коелып йөргән Һадиевнең уйламаганда болай өйгә кереп, болай кинәттән чишелеп ташлавы һәм, аннан да бигрәк, үзенең чын эшкә сусаганлыгын ачыктан-ачык әйтеп бирүе — уйландыра торган факт иде. Һәр яктан истәлекле булды бу сабан туе. Ә алда — андый сабан туйлары тагын күпмедер әле!



## Эпилог

Булып узган шул хәл-әхвәлләрдән соң биш ел узгач, без менә әлеге шул «Алсу алан» колхозында. Авыллар үз урыннарында. Урманнар, елгалар, чокыр-чакырлар да үз урыннарында. Ык та үз урынында: яшел тугайлар, әрәмәлекләр, биек булып үскән карт тирәкләр ышыгында тын гына агып ятмакта. Хәер, быел ул вакыт-вакыт дулап та күрсәткән, янәсе, сез миңа бик үк ышанып бетмәгез, кешеләр! Минем искәрмәстән генә дулап куя торган гадәтем дә бар. Кайдадыр, елганың югарыгы өлешендә, кинәт орып яуган көчле яңгырлар булып узган булса кирәк. Ык дигәнең җәй уртасында ярларыннан чыгып ташыган, югарыдан мунчалар, сөт бидоннары, сарыклар агып килгән. Басмаларны, күперләрне агызып алып киткән. Аның каравы, миллионнарга төшереп, Мөслим янында Ык аркылы салынып ята торган тимер-бетон күпер белән мактанырга өйрәнеп килаләр монда.

Теге вакытта Шайтан тавыннан чокып чыгарыла башлаган ташлар хәзер инде терлек фермалары, каралтылар, ашлык амбарлары, мастерскойлар булып басканнар. Дөрес, Хәтмулла абзый көткән «таш пулатлар» ук булып житмәгәннәр алар, ләкин авыл читендә озын-озын сузылган һәм озак елларга исәп тотып, нык итеп эшләнгән, башлары шифер, черепица белән ябылган таш каралтыларны күреп, мин бик куанып йөрдем. Шулай ук Хәтмулла агай язмышы да кызыксындыра иде мине. Гел кырлар, гектарлар турында гына булмасын, дип мин председатель өендә табын янында утырганда аның исемен дә кузгатасы иттем.

Хәтмулла абзый дигәнебез, бөтен нәрсәдән кызык табып, юктан гына да уйнап-көлеп гомер иткән ул карт, кеше сүзенә балалар кебек ышанучан һәм вакыты белән кешеләрдә дә ышаныч нуры кабыза белүче һәм, шул яхшы сыйфатлары өстенә, агай-энедән «аткан» тәмәкесен веручә тәмле итеп тарта белүче, карчыгы тыеп тормаганда чак кына мутлыгы, чак кына борчак сибүе белән дан казанган ул гөнаһлы адәм баласы, сибәсе борчагын сибеп бетергән дә инде дөнья куйган.

Аның каравы, зәңгәр күк чатыры астындагы бу ямьле җирләргә колхоздагы зур эшләрне дәвам иттерү өчен икенче кешеләр килгәннәр һәм, аларның алда әле тагын да күбрәк киләсен күздә тотып булса

кирәк, колхоз председателе, безнең әлеге шул күптәнге танышыбыз Сәлим Ахунҗанов, сүз чыкканда, уенын-чынын бергә кушып әйтте безгә:

— Сыерлар, бозаулар өчен житкерәсен житкердек, инде үзебез өчен, туачак балалар өчен бала тудыру йорты да салып җибәрсәк,— диде, хәйләкәр көлемсерәп.

Колхозының киләчәгенә зур ышаныч белән яшәүче Ахунҗанов, шулай да бу мәсьәләдә безне бераз мәтәштерергә уйлады булса кирәк. Шуннан әйтәм бу сүзне: шушы «Алсу алан»га килгәч туган һәм бу якты дөньядагы беренче көннәрен-атналарын таракан катырырлык салкын өйдә уздырган Тәскирәдән башка «үрчемнәре» күренми иде аларның.

Бу якка ым ясый башлагач, Ахунҗанов ике уйларга урын калдырмаслык итеп өзеп әйтте:

— Биш бала, ике кешегә бу бик житкән, план үтәлеше ике йөз процентган артык. Башкалар шулай, без тырышканча, тырышып карасыннар иде әле,— диде.

Җитмәсә тагын, «Алсу алан»га килгәч туган бу бишенчесе, Тәскирә кызчык, гаҗәп тере күренә, әтисе-әнисе суыкка чыныктырып үстергәнгә шулай ул дип, юкка гына әйтмидер, ахры.

«Суык өй» дип узганны искә төшереп әйтүләре, хәзер ул тыкрык буй өй яңадан каралган, сипләтелгән, эченнән-тышыннан такта белән төрелгән, «хәзер безгә суык борынын төртә алмый!» дип, сүз арасында мактанып куйды хуҗа. Хатыны Хәдичә ханым, теге вакыттан бирле бераз үзгәргән, хәрәкәтләре салмаклана, үзе юаная төшкән, ләкин төс салмаган, элекке кебек үк сөйкемле, кунакчыл хозяйка, форсаттан файдаланып, шулай да ире бакчасына җиңел генә бер таш атмыйча кала алмады:

— Ярлы кеше яманыр да куаныр, ди... Шулай булмый хәле юк инде, председатель башы белән үзенә аерым яңа өй салдырып кирә алмагач.

Икесенеке дә дөрес, әмма иң дөресе: ир белән хатын арасына кысылмау! Әллә җәй уртасы булганныкы, әллә хуҗаларның якты чырайларыннан — миңа председатель өенең түр башында, сый-хөрмәт белән тулган табын янында гаҗәп дәрәҗәдә җылы һәм ипле иде.

Аш-суга оста хозяйка ул арада бик матур чынаякларда, ак подноска тезеп, кап-кайнар чәй дә ясап китерде. Чәй бирелү — сайрашып утыруның чиге дигән сүз инде ул. Моны мин эчемнән генә уйлап куйдым, ләкин шул ук вакытта болай затлы итеп ишекне искә төшерә белгән хозяйкага нинди дә булса бер мактау сүзе әйтмичә дә мөмкин түгел иде.

— Әллә сездә бөтен нәрсә эфсен көче белән эшләнәме, Хәдичә ханым? Шундый тиз арада, шундый авыз пешерә торган кайнар чәй өлгертеп китерүегездән әйтәм.

— Белмим шул... Безгә газның шундый эфсенлесен җибәрә торган булсалар инде,— диде Хәдичә, шуклыкка каршы шуклык белән. Әмма Ахунҗановның үзенең бу мәсьәләне шуклык белән генә күмеп калдырасы килми иде.

— Җибәрмиләр, үзебез машина җибәреп алдырабыз газны,— дип сүзгә кушылды ул, чак кына мактану тоны белән,— бездә хәзер өй саен диярлек газ.

Газ, электр, телевизор, кызларында тез асты чокырларын күрсәтә торган кыска итәкле күлмәк, егетләренең авызында бастырык юанлыгы папирос — тәмам түгәрәкләнгән монда тормыш, шәһәрен бер якта торсын. Шулай да «кибәнне очлап» куярга ашыккан булганмын икән, түгәрәкләнмәгән икән әле дөнья.

бик чекерәешеп торуына караганда, нәрсәдер сизелгән дә кебек иде, «август аенда мондый салкынча төннәр буладыр инде ул» белән минем «барометр» туктаган иде инде. Иртәгесен — бик аяз салкын иртә иде ул, җылы өйдән чыккач мин тоташ чирканып куйдым — яңа «ГАЗ»ына утырып Ахунҗанов безнең капка төбенә килеп туктады.

— Әйдә, күрсәтәм мин сезгә «түгәрәкләнгән» дөньяны,— диде ул, кырыс кына. Артык бер сүз дә өстәмичә, юлда да ни турында да сүз башламыйча, туп-туры кырга — кукуруз басуына алып китте.

Кичә без бу басулардан бер узган идек, каерылып үңгән яшел кукуруз плантациясенә карап сокланган идек. Көлсу туфрак дип кайчандыр кимсетелеп телгә алынган җир — үзенә азык биргәч, игелеген кешедән яшерми икән — кара-кучкыллы кукуруз урманына әйләнгән иде. Кеше әйтеп кеше ышанмас, бер төн, чекерәешкән йолдызлары белән килгән бер афәтле төн бу «яшел урманны» үзенең каты кыравы белән кара яндырып ташлаган иде. Без машина керткесез куе булып үскән, ләкин чәкәнләнергә өлгерер-өлгермәстә башлары, өске яфраклары көеп калган кукуруз плантацияләре янында, башларыбызны иеп, мәет өстендәге кебек, сүзсез басып тордык.

Һәм Ахунҗанов һаман шулай кара көйгән хәлдә, миңа күтәрелеп тә карамастан, машинасына борылды.

— Менә күрдегезме, безнең эшнең җан җәфасы белән барганлыгын,— диде ул, кузгалып бераз киткәннән соң.— элек терлекләр өчен торак дип тир түктек. Инде торакларыбыз бар, азык проблемасын яңадан карарга кирәк булып чыкты. Бу яртылаш көйгән силос массасыннан без көткәннең утыз проценты да чыгачак түгел.

Аның тавышында кичә «өй саен газ кертү» белән мактану өненең әсәре дә калмаган иде бүген. Һәм, гомумән, ул көнне председатель гел ачулы төс белән, кашларын җыерып, бераү белән дә рәтләп сөйләшә алмыйча, кара көеп йөрде. Ә кем белгән, бәлки әчендән генә теге сабан туе көннәрендә, көрәш мәйданында егылганнан соң ясаган нәтиҗәне үк ясагандыр. Таш амбарлар, таш кладовойлар, терлек абзарлары салды колхоз, электр китерде, газ китерде колхоз, кешеләр әнә шифер, калай түбәле өр-яңа өйләр, радиолалары, телевизорлары, иләннәренә келәмнәр җәелгән өйләр ясап керделәр, болары белән мактанырга була. Ә менә табигать кирелекләре белән көрәштә әле кайвакытларда егылгалап та куйгалыйбыз. Димәк, тынычланырга урын юк, исереп калырга урын юк, мускулларны бушатмаска, көчне йомшартмаска, мәйдан гел алда, көрәш гел дәвам итә дигән сүз.

*Казан, 1969—1970.*

**Марс Шабаев**

# ҖИКӘН КАМЫШ

ИКЕНЧЕ ДӘФТӘРДӘН

## Йөгереп-уйнап...

Йөгереп-уйнап йөгерек дулкын килә,
Йөгерек дулкын ярга тартыла.
Килә...
        бәрелә...
                үлә...
Күбекләре сүнә...
Яңалары йөгерә артыннан.
Йөгереп-уйнап... йөгерек...
Шулай бертуктаусыз,
Берөзлексез дулкын... дулкыннар.
Йөгереп-уйнап йөгерек...
Берөзлексез
Кабатлансам әгәр, кем тыңлар?
Йөгереп-уйнап...
Җитте!
Баш әйләнә...
Дулкыннарга башны куялмыйм.
Ә нигә соң, нигә йөгерек-уйнак
Дулкыннардан һаман туялмыйм.
Бу үзгәлек табигатьтән килә,
Кеше шундый инде тумыштан:
Килә...
      сөя...
          көя...
              егыла...
                    үлә...
Юк, туялмый барыбер тормыштан!
Йөгереп-уйнап...

●

Кинәт кенә...
Әллә нәрсә шунда:
Шаулап торган яшел җикәннәр
Корый...
      көя...
          яна...
              Тик көл кала...
Күтәрелә янә...
Кай арада үсеп җиткәннәр?

Ялтыр-йолтыр килеп күтәрелә
Төсен җуйган кояш нурында,—
Камышмыни? —
Корыч штык болар!
Ничек җырлыйм алар турында?
Саташаммы әллә?
Карыйм күлгә.
Әллә нәрсә шунда:
Якты күл
Кара болыт булып күтәрелде,
Җирдән күккә таба акты ул.
Чү!
Күл төбе янә тулып килә...
Тулып килә мөлдер-мөлдерәп...
Күз яшьләре белән!
Ярылмыйча,
Шуны җырласынмы бу йөрәк?!
Ник саташам?
Асты-өскә килсен!
Күз яшьләре тулы ул күлне
Чорнап алган штык-камышларның
Сызгыруын ишетәм түгелме?
Күл түгел бу.
Бу бит — дөнья күзе!
Корыч штык — һәрбер керфеге.
Ул сагалый,
Ул чамалый Җирне...
Йөрәк шуны җырга кертерме?
Булсын!
Керсен!
Дөнья күз яшьләре
Бер иләмсез күлгә агылсын,
Бар штыклар шунда камыш булсын,
Саклап торсын күлнең кайгысын.
А, саташу!
Тагын ни-нәрсәләр?
Як-ягыма куркып каранам.
Транзистор.
Соңгы хәбәрләр.
Саташуым бары аңардан.
Нинди «изм»нарда гаепләрләр,
Ләкин мена июль кичендә,
Биш минутлык соңгы хәбәр сәбәп
Саташулы шушы хисемә.

## Чатыр таудагы уйлар

Иңгән, иңгән Чатыр, картайган...
Өсләрендә иңри кылганнар.
Чак табарсыз аны картадан —
Легендалар калса калганнар.

Бик мәһабәт булган кайчандыр,
Түбәсендә күкләр күкрәгән.
Хәзер инде Чатыр, һай, чандыр —
Еллар баскан ак таш күкрәген.

...Була кемдер — күз өстендә кан
Яши күкрәп зур эш кылгандай.
Чатыр тауга карыйм: ком да таш...
Өсләрендә иңри кылганнар.

## Кыргый песи

Күрдем аны камыш арасында.
Күзләрендә усал кыргыйлык.
Йомшак мендәр, җылы мич башыннан
Артыграк, ахры, кыр болын.

Уянгандыр бабалары каны...
Чын юлбарыс инде, юлбарыс!
Тотып ашар иде мине дә ул —
Буе гына ләкин бер карыш.

Тук тормыштан, сөт-май дөньясыннан
Туйган икән тәмам, күрсәнә!
Хуҗа колы түгел. Ул — ирекле.
Ул буйсынмас, гүргә керсә дә.

Кыю песи, булдыргансың үзең,
Я, кил монда. Сыйлыйм әле бер.
Өч шыртлака белән кем баеган,
Безгә бәхет чиертми барыбер.

Өч шыртлака үзенекен итте...
Юлбарыслар күреп төшендә,
Йоклый инде кыргый горур песи
Йомгак булып... минем түшемдә!

●

Яшел алан.
Кура җиләк.
Күпереп кайный
Кара чиләк.
Сары ялкын,
Зәңгәр төтен.
Ах, чәй исе! —
Дөнья бөтен.
Рәхәт биреп
Тәнгә, җанга,
Кайнар ширбәт
Йөгерә канга.
Кура җиләк,
Карлыганда
Җитмеш дәва,
Бардыр анда.
Юкка чыга
Арганнарың.
Эреп очa
Ялганнарың.
Дөрләтәбез
Тормыш утын.
Яшел алан...

Дөнья тып-тын...
...Ә кайдадыр
Еракларда
Зәңгәр дәрья
Бәрелә ярга.
Ак пароход
Дулкын кага.
Сызылып-сызылып
Җыр-моң ага.
Зәңгәр төтен,
Яшел алан
Әсирлектә
Шул моңнардан.
Ә моң ерак,
Ул сагышлы...
Чакырулы...
Ул тавышны
Мин ишеттем!
«...Яшел алан,
Зәңгәр төтен...»
Синме шулай
Җырлап үттең?

Сары комда кызынып яшьлек ята —
Печәнчеләр ялга туктаган.
Рәссам бул да, төсен бозмый гына,
Күчер дә ал шушы ноктадан.
Әнә бер кыз.
Сары сусән чәче
Сары комга төшеп тарала.
Кушаматы — «сары песнәк кызы»,
Тик күзләре конгырт-каралар.
Сары песнәк — Галимәттәй хәзер...
Сабит абзый аны ерактан,
Галинасын сугыш кырларыннан
Алып кайткан...
Димәк, яраткан.
Сабит абзый кызы Галиягә
Шаян телле егет ялына:
— Әнкән безгә килгән. Үзең китмә,
Булма бирәрсенә Галина...
Сары сусән төсле сары чәчен
Кайнар сары комнан күтәреп,
Сикереп тора да кыз Ыкка чума:
— Я, кайсыгыз куып житәр? — дип.
Ярсу атлар кебек елгырланып
Атылалар ярдан егетләр.
Куышалар, көлешәләр... Суда
Күтәрелеп кайный күбекләр...
Ә Галия инде аргы якта!
Сары чәче төшкән таралып.
Нәкъ татарча көлгән күзләрендә
Әткәсеннән күчкән каралык.

●

Ык суында йөзә пар акчарлак.
Юк аларда дөнья кайгысы.
Зәңгәр күкне кыеп-кыеп төшәр
Ак кайчысы белән кайсысы?

Юрамыйм да, юраган да булам
Юрамалый гына... тиктомал...
Әле зарыгу түгел, өзелү түгел,
Тойгыларны тыю... күк томан...

Ык өстендә йөзгән акчарлактай,
Пакь, саф, якты әле хисләрем.
Парын югалткачтын — ярын жуйгач,
Белмим әле, белмим нишләрен.

Зәп-зәңгәр күк. Кояш. Пар акчарлак.
Мин ваемсыз әле, кайгысыз.
Кыюлыгы житеп, бәхетемә
Кулын салыр икән кайсыгыз?

▪▪▪▪▪▪▪▪▪▪▪▪

Гарәфи Хәсәнов

# ИМӘН

ЭТЮД

*Бөгелмәс ул, сыгылмас ул, җилләр иссә...*
*Педер Хузангай*



Шундый да күрекле... Борынгы римлеләр «Кверкус» дип белми әйтмәгәннәр! Бу исә — матур дигән сүз. Матур да, нык та агач ул. Имәнгә охшаталар ирнең асылын. Ул имән кебек нык, диләр.

Аның берсен үземне белә башлаганнан бирле күрә киләм. Үзе аръякта, тугай уртасында ук, ә үзе авылның түбән очыннан да күренә. Бер Алып батыр диярсең! Үзен ник бер агач ышыкласын, үзе җил-давылларга бирешми. Җәй коры килсә дә, аңа да исе китми. Тамырлары тирәндә булгач, нәрсә ул аңа корылык!

Язын, тугайны су баскач, имән ничектер инеп, кечерәеп калгандай күренә. Әмма, су чигенгәч, бөтен матурлыгы, бөтен горурлыгы белән яңадан калкып чыга.

Колхозның сыер фермасы да шул якта. Аны җәйге ферма дип йөртәләр. Ул андагы иркенлек, киңлек... Ул сусыл үләне, ул суга якын булуы... Елга булып сөт акса да гаҗәп түгел монда.

Җәйге эсселәрдә имән ябалдашлары гаҗәеп олы, гаҗәеп киң чатырны хәтерләтә. Сөтең дә әчеми, чатыр астында үзенә дә җиләс.

Ул ничә яшьләрдә дигәндә... Анысын тәгаен генә белүче юктыр. Мин моны этидән сораган идем. Әти йөзне тутырган — ул да әйтә алмады: «Мин белә башлаганнан бирле шундый агач инде ул»,— диде. Кайчандыр әти дә бабайдан: «Имән ничә яшьтә?» — дип сораган. Ләкин мин үзеннән нәрсә ишетсәм, ул да бабайдан шул ук сүзләрне ишеткән.

Әтием хәзер дә умарталар караучы. Имән кебек нык. Имән үзе дә аңа охшаган: язын мүк төсле яшел сыргаларга бизәлә, көзен чикләвекләр өлгертә. Гел эштә, хезмәттә...

Имән өч йөзгә тикле чәчәк ата, биш йөзгә, меңгә кадәр яши, диләр. Ә бу имән ел саен чәчәк ата. Димәк, күп булса, өченче йөз белән барадыр. Шул ук вакытта яшь дип тә булмый аны. Чөнки ул хәзер буйга үсми. Фәкать юаная гына.

булса, тагын яшәгән кадәр яшисе бар дигән сүз. Менә шул чагында күрсәң иде аны!.. Минем өч улым буйга житеп килә. Алар да бу имәнгә минем кук сокланып карарлар. Аннары — оныкларым... Имән ул чагында тәмам картаер, аннары... юк булыр. Агач та мәңге яшәми. Тик ул да үзенә яшь алмаш калдырыр.

Имәннәр чикләвекләре беләк генә түгел, сабаклар жибәреп тә үрчиләр. Мин бу хәлне күптәннән күзәтә киләм. Ничек күзәтәм дигәндә — кайчандыр әлеге имән белән янәшә икенче берсе шаулап утыра иде. Ә быел аны яшен сукты. Бөтен кәүсәсен көйдереп, яндырып төште. Корыган имәнне кистеләр... Ләкин күпмедер көннәрдән соң имән төбеннән ямь-яшел үрентеләр шытып чыкты... Бу, әлбәттә, табигый хәл: кайчандыр зур печән кибәненә охшап утырган имәннең бөреләре күп санлы ботак-чатакларында гына түгел, төбендә дә булганнар. Алар имән бик нәни вакытта ук яралганнар. Имән ел саен юанайган, ел саен өскә үрләгән. Ә астагы бөреләр изрәп йоклый биргәннәр. Ботакларда һәртөрле сайрар кошлар ыгы-зыгы килсә дә, көне-төне яфраклар шауласа да, уянмаганнар алар. Чөнки дым һәм шифалы сулар, астагы бөреләрне читләтеп, югарыга, яфраклар янына омтылган. Шуңа күрә изрәп ятканнар да инде әлеге бөреләр. Ләкин үлем йокысы булмаган бу. Йокы аралаш сизелер-сизелмәс хәрәкәтләнгәннәр алар (югыйсә, кәүсә эчендә — бөтенләй томаланып калуың бар!), үзәк тамырларын жибәреп, имәннең калын кабыгына үтеп чыкканнар...

Имәнгә хәвеф килде. Имән үзе юк инде. Ләкин «нинди биек булмасын, тамыры жирдә»,— дип агач турында дөрес әйтә халык. Тамырлар буенча аккан тереклек суы әлеге бөреләрне уятты, аларга яшәү көче бирде... Һәм озакламый бөтен тирә-юньгә яшь яфраклар жыры таралды. Әнә шулай итеп имән яңадан яши башлады.

...Яшь имәннәргә карыйм да мин, карт имәнне искә төшерәм. Никадәр чикләвекләр өлгертте. Ул чикләвекләрдән никадәр яшь агачлар үсеп шаулады. Аз гына шул имәнгә охшаса икән дә, үзе турында шул имән кебек матур истәлекләр калдырса икән кеше!

# ХӘЙ ВАХИТ

# КҮК КАПУСЫ АЧЫЛСА...

КОМЕДИЯ-ВОДЕВИЛЬ, ӨЧ ПӘРДӘДӘ

Вакыйга Татарстанда, кечерәк шәһәрләрнең берсендә бара. Шәһәр читләрендә салын
торган бер квартиралы коммуналь йортларның ишек алды. Терлек асрамаганлыктан
ул яшеллеккә төренгән. Куе тирәкләр артындагы рәшәткә бөтенләй күренми дә. Түрд
тыкрыкка алып чыга торган арт капка. Уртада күршеләрнең уртак файдалана торга
өстәле, озын эскәмия. Бер читтәрәк самовар кую һәм савыт-саба юу өчен махсус әзер
ләнгән урын. Кер элү өчен баулар асылган.

Уң яктагы квартирада Газизләр семьясы яши, сул яктагысында Госман семьясы. Га
зизләр йортының безгә террасасы, алгы бүлмәнең ишеге һәм тәрәзәсе күренә. Террасад
тумбочка, тумбочка өстендә телефон. Шнуры озын булганлыктан, аны күчереп йөртерг
дә мөмкин. Йорттан алдарак, уң якта, ягъни ишек алдының түрендә, сарай булырг
тиеш. Ул безгә күренми, шул якка сузылган сукмактан гына без аның барлыгын чама
лыйбыз. Госман семьясы ике катлы йортта яши. Әмма безгә йортның икенче каты д
балконы да күренми. (Хәер, театрның мөмкинлеге бар икән, күрсәтә бирсен.) Безгә алг
бүлмәнең тәрәзәсе белән ишеге күренсә дә бик җиткән. Йорт алдында, сул якта, бакч
булырга тиештер, рәшәткә шул турыда сөйли.

### ВАКЫЙГАГА КАТНАШУЧЫЛАР:

Газиз. 22 яшьтә.
Госман Ганиевич. 50 яшьләрдә. Комбинат директоры.
Шәмсия. Госманның олы кызы.
Рәмзия. Госманның кече кызы.
Шакир. Газизнең атасы. Пенсионер.
Бибиәсма. Газизнең анасы.
Гайфи Габдрахманов. 25 яшьтә.
Ризван Арсланов. 20 яшьтә.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Пәрдә ачыла. Эчке пәрдә артында музыка[1], җыр ишетелә.

Сокланалар миңа карап дуслар,
Ямь табарсың диеп тормыштан.
Шат яшәргә сездән өйрәндем мин,
Шаянлыгым минем тумыштан.
Яннарымда якын дуслар барда
Гөрләп уза җәем, кышларым.
Зәңгәр күктә күпме йолдыз булса,
Шул кадәрле җирдә дусларым.

Моңаерга күнекмәгән күңлем,
Дөнья мине көләч яраткан,
Туганчы ук минем күгемдәге
Кайгы томаннарын тараткан.

[1] Бу әсәрдәге җырларга композитор Сара Садыйкова музыка язды.

Минем өчен сайрый кошларым.
Зәңгәр күктә күпме йолдыз булса,
Шул кадәрле җирдә дусларым.

*Эчке пәрдә телем-телем булганлыктан, башта спектакльгә катнашучылар башларын гына күрсәтеп җырлыйлар, аннан үзләре дә сәхнә алдына чыгалар. Җырны шунда гына тәмамлыйлар да күздән югалалар.*

*Эчке пәрдә ачыла. Июнь ае. Шимбә көн. Иртәнге сәгатьләр. Йорт артыннан Бибиәсма килеп чыга. Кулында комган. Сулдагы йортның тәрәзәсе ачылып китә, анда Рәмзия күренә. Җырлый.*

Рәмзия.

Йөрәгемдә ташкан хисләр
Тулыр да бер түгелер дә.
Күз алдымда йөрмәсәң дә,
Йөрерсең күңелемдә.
Яна минем йөрәгем,
Өзеләдер үзәгем,
Әйтелмичә калыр микән инде
Әйтер сүзләрем.

Әсма. Уяндыңмыни, Рәмзия? Иртәләгәнсең.
Рәмзия. Йоклаган булсам уяныр идем дә. Әти кайтмады, Әсма апа. Кичтән балыкка дип киткән иде. Озак утырмам дигән иде.
Әсма. Чиерткәненә алданып утыра микәнни?

*Сукмак буйлап, төймәләрен төймәли-төймәли, Шакир килә.*

Шакир. Кайтыр, борчылма. Балык тотарга дигәндә дөньясын оныта инде ул.

*Террасада Газиз күренә.*

Рәмзия. Хәерле иртә! *(Ишектән чыга.)* Төн буе утың сүнмәде. Әллә таң атканчы утырдың инде?
Әсма *(самовар янында)*. Аның шул инде, көн димәс, төн димәс. Яза да сыза, сыза да боза.
Рәмзия. Нинди машина уйлап чыгармакчы була икән бу кеше? Белсәң иде.
Әсма. Чыгара, пычагым. Аңа булмый да булмый дип тукып торалар, ә ул үзенекен итә тора.
Рәмзия. Тырыша, тырмаша. *(Уртәп.)* Сабырлык бирсен ходаем...
Газиз. Ике бака каймак чүлмәгенә төшкән, ди. Берсе моның чыгарга теләп бераз тыпырчынып караган да барыбер булмый дип туктаган. Ә икенчесе өметен өзмәгән, һаман тыпырчынган, һаман азапланган. Алҗып беткән. Инде тәмам хәлдән тайдым дигәндә, караса: аягы астында каты әйбер. Каймактан май төшкән.
Шакир *(күтәреп ала)*. Әһә, шуңа басып бака чүлмәктән чыкканмы?
Газиз. Чыккан. Менә шул икенче баканы ошатам мин.
Рәмзия. Син үзең аңа охшагансың. Ква-ква!
Газиз. Ба-ка-ка! *(Рәмзияне тотарга теләп куа башлый.)*
Шакир. Чыгар шул! Өметсезлеккә бирелеп, туктальп калмаган, шуңа чыккан да ул. Син үзең дә, Газиз, юлыңдагы киртәләрне җимереп чыгарсың әле, шәт иншалла!
Әсма. Чыгар, аягын сындырмаса.
Шакир. Әйткән иде диярсез! Тырышкан ташка кадак каккан, диләр. Менә директорың кайтсын әле балыктан. Мин аның белән үзем сөйләшеп карыйм.
Газиз. Сиңа гына катнашырга калган иде!
Шакир. Катнашам. Бөтен эшеңне тоткарлап килүче ул ич.

*Радиодан иртәнге физкультура музыкасы ишетелә башлый. Газиз белән Рәмзия физзарядка ясарга керешә. Шакир да яшьләрдән калышмый.*

Шакир. Пенсиягә чыккач самый раз ул. Юкса, нәрсә белән юанасың.

Шакир чүгәләгән жиреннән аягына баса алмый, аны Әсма күтәреп торгыза. Рәмзия исә физзарядка ясаудан бигрәк Газиз белән шаяруны артыграк күрә. Әле бер ягыннан, әле икенче ягыннан ул аның ботына менеп кунаклый. Газиз аны чимкәлдереп җибәрә. Шау-шу, чыр-чу. Шул чакта еракган ук Госманның тавышы ишетелә башлый.

Госман. Аттырам!..
Әсма. Чү! Үзе кайтты түгелме? Госман!..
Рәмзия. Әти!..

Арт капкадан Госман кайтып керә. Киемнәре буялып беткән, үзе туңган, дер-дер калтырый. Иңендә кармаклар.

Госман. Аттырам! Бөтен этләрне аттырып бетертәм!
Шакир. Күрше, ни булды?
Госман. Кичке тынлыкта бераз утырыйм дип балыкка барган идем. Аргы елгага. Бер дача буенда туктап кармакны салам дигән дә генә, арттан килеп «һав!» — бозау кадәр эт. Овчарка. Угры дип уйлады, ахры.
Газиз. Шуннан?
Госман. Аягым таеп суга барып төштем.
Шакир. Әйе.
Госман. Чыгармый гына бит, кафер. Таң атканчы су эчендә тотты. Аттырам!

Җыйнаулашып Госманны чишендерергә керешәләр. Рәмзия белән Газиз итекләрен салдырып, эчендәге суын түгәләр. Итек эченнән вак балыклар, ташбашлар коела. Шакир белән Әсма Госманның чалбарын салдырып, аны сыга башлыйлар. Сыга торгач, чалбарның бер балагы өзелеп үк чыга.

Әсма. Ай, харап булды.
Госман. Нишләдегез инде!..

Газиз белән Рәмзия өйләреннән икесе ике одеял алып чыгып, Госманны алдан да, арттан да одеялга төреп утырталар. Бу эшләр барысы да музыка астында бара.

Шакир. Төн буе билдән суда тордыңмы, күрше?
Госман. Билдән!.. Билдән генә булса бер хәер иде, муеннан тотты, колактан.
Әсма. Ходаем икән.
Госман. Әз генә селкенә башладыңмы, лап! — лапысы белән баш түбәсенә. Кычкыра башладыңмы — лап!
Әсма. Әстәгъфирулла.
Госман. Чыгармый да, батырмый да. Суы салкын, җилекләремә үтте. Күгәреп, бөрешеп беттем. Дер-дер калтырыйм. Ә ул үзе ята ком өстендә, койрыгын болгап. Дачасын саклый, янәсе. Йоклап та китми, ичмасам. У-у-у!.. *(Рәмзия елый ук башлый.)* Елама әле син.
Шакир. Менә сиңа кирәк булса.
Госман.Ниләр генә кылмадым, ялварып карыйм, ялынып карыйм. Юк. Нинди генә тәмле сүзләр әйтмәдем: акыллым да калмады, йомшагым да, матурым да. Юк, колагына да элми. У-у-у! Аттырам! Тиресен тунатам!
Шакир. Кая, суык тия күрмәсен тагын.
Әсма. Хәзер самоварым кайнап чыга.
Шакир. Әй, куй әле самовар! Әнә анда шешә төбендә бераз калган иде бугай. *(Өйгә кереп китә.)*
Госман. Рәмзия, бар әле, анда селедка бар.
Газиз. Селедка, селедка!

Госман. Хуҗасы күренмәде. Әллә дачада булмады, әллә булып та качып калды. Шулай да исемен сорашып белдем. Гайфи атлы икән. Судка бирмәсәмме мин аны!

Шакир шешә белән аракы алып чыга.

Шакир. Әйдәле, күрше, тот әле. *(Стаканга аракы салып бирә.)* Бетереп эч, бетереп. Менә шулай. Ул җелекләреңә үткән суыкны кысрыклап, куып чыгармыйча ярамый. Менә булдырса шушы гына булдыра инде аны. Яле, тагын тот әле, тот.

Госман. У-у-у...

Шакир. Каяле, үзем дә булышыйм.

Әсма. Син суга төшмәгән идең бугай?

Шакир. Самоварың, самоварың кайнап бетмәсен. Әйдәле, Госман, күптәннән бер гәпләшеп тә утырасы килә иде. Сөйләшәсе сүзләр дә шактый җыйналды. *(Салып бирә.)* Үзеннең күз алдында, күрше... Газиз турында әйтәм... Көн-төн утыра. Ник бер генә эше гамәлгә ашсын. Турысын гына әйтсәм, син аңа юл бирмисең, күрше. Күпме чертеж гына сызды...

Госман *(стакандагы аракысын күтәреп эчә дә кычкыра)*. Селедка!

Шакир. Селедка!

Газиз. }
Әсма. } Селедка!

Рәмзия селедка алып чыга. Шакир селедка төрелгән кәгазьгә күзе төшеп, тукталып кала.

Шакир. Бу ни? Газиз, кил әле, бу синең чертежың түгелме соң?

Газиз *(чертежга карап алгач, Госманга текәлә)*. Мин аны сезгә моннан бер ай элек, танышып чыкмассызмы, дип керткән идем.

Шакир. Ул аны карап та тормаган. Тартмасына салган да куйган. Аннан алып селедка төргән. Беткәнме гәзит?! Көн дә берәр кочак китерәләр. Укып өлгерер хәл юк. Ә ул селедкасын чертежга төреп кайткан. Кешенең айлар буенча, еллар буенча утырып эшләгән хезмәтенә!

Госман. Кара син аны, синең чертежың әләккәнмени? Ай, бу хәтер, ай, бу ыгы-зыгы. Мәшәкать белән баш катып беткән. Син ачуланма инде, Газиз, ялгышлык миндә.

Шакир. Ачуланмас идек тә, беренчесе генә булса. Синең бит, Госман Ганиевич, гел шулай. Газизне санга да санамыйсың. Кирәкле эш белән утырамы ул, кирәксезме.

Газиз. Ул минем җүнле эш чыгара алуыма ышанмый.

Шакир. Техниканы үстерү буенча күпме тәкъдим кертеп карады. Берсе дә эшкә ашмый. Суга ташлаган таш кебек төшә дә югала.

Госман. Я алла, аның тәкъдимнәренең эшкә ашарлык булмавына мин гаепләмени?!

Шакир. Син директор, аның язмышын син хәл итәсең.

Госман. Юк инде, Шакир ага, күрше хакы дип, мин җыен чиле-пешле тәкъдимнәрне кабул итеп утыра алмыйм. Бигайбә.

Шакир. Алай икән. Болай булгач, син аның соңгы эшен дә чиле-пешле диярсең инде.

Госман. Нинди эшен?

Шакир. Җыю цехына конвейер кертү буенча. Әле яңа гына тәмамлады.

Госман. Соңга калган. Безгә ул тәкъдимне керттеләр инде.

Шакир. Ничек? Кем?

Госман. Арсланов. Чертежлары белән танышып та чыктык. Ошаттык. Әйбәт дип таптык.

Ш а к и р. Газизнең алдына төшкәннәр икән, алайса, ә ул нинди Арсланов тагын? Каян килеп чыкты.

Г о с м а н. Мин аның үзен белмим. Күрмәдем. Мин югында килгән. Эшен, әнә, Газизгә калдырып киткән. Вакыты тыгыз булган, күрәсең. Чертежлар белән танышып, фикер туплый торырга үтенгән... Рәмзия, кая, китер әле телефонны. Конторага шалтыратып әйтим әле, эзләсеннәр, тапсыннар Арслановны.

Р ә м з и я, тәрәзәдән генә үрелеп, телефонны ала да, шнуры озын булганлыктан, атасына китереп тоттыра.

Ш а к и р. Ә үзең, Газиз озайткан шнур дип, чирканып тормыйсың. Файдаланасың.

Г о с м а н. Вакытында рәхмәт әйткән идем шикелле. *(Номер җыймакчы иде, исенә төшеп.)* Бүген шимбә түгелме соң? Бу ике ял көненә һич кенә дә күнегеп булмый. *(Телефонны кире бирә. Рәмзия аны үз урынына илтеп куя.)*

Ш а к и р *(һаман да тынычлана алмыйча)*. Арсланов... безнең кеше түгел икән. Ә Газиз?

Г а з и з. Куй әле, әти. Кем мин алар өчен? Исемем бармы, дәрәҗәм?!

Ш а к и р. Анадан берәү дә исем белән тумый. Алай икән, төпсез көймәгә утыртып калдырганнар икән үзеңне.

Г а з и з. Әти, ташла инде.

Ш а к и р *(аның саен котырынып)*. Ташламыйм! Синең өчен минем йөрәгем әрнемимени?! Чыннан да Арсланов дигән кеше чертеж китердеме?

Г а з и з. Китерде, китерде инде.

Ш а к и р. Җыю цехына конвейер кертү буенчамы?

Г а з и з. Әйе инде, әйе.

Ш а к и р. Ә синеке нишләп кала? *(Тагын Госман каршына килә.)* Әгәр дә син Газизне чиле-пешле чертежлар белән утыра дип уйлыйсың икән, алайса, нигә аны башта ук үзенә әйтмәдең, турыдан-туры? Күршең бит, ялын онытып утырганнарын көн дә күреп торасың?

Г о с м а н. Чудак син.

Ш а к и р. Кем судак? Минме? Син ул судак. Балыкчы.

Г о с м а н. Чудак дим. Әгәр дә берәү рак белән авырса, врачлар аңа дөресен әйтәме соң? Әйтми. Алдый, әле ялганлый. Шифалы ялган дип атала бу.

Ш а к и р. Ялган булгач, черт булса да ялган инде.

Г о с м а н. Аның өметен өзәргәме? Өзмим! Менә мин үзем балык тотарга хирес кеше. Кармак салырга дисәң, ашарга-эчәргә бирмә инде. Мине син балык өчен утыра дисеңмени? Мин ләззәте өчен утырам. Газиз дә шуңа утыра. Аерма тик шунда: мин елга буенда утырам, ә ул бүлмәсендә. Әйдә утырсын, нигә кешенең өметен өзәргә?! Шулай, Шакир ага, бу дөньяда һәркем үзенчә балык тота.

Ш а к и р. Газизне, өстәл янында кармак салып, алтын балык капканын көтеп утыра, дип көлеп йөргәнсең икән әле.

Г о с м а н *(кызып)*. Менә нәрсә, талашасың килә икән — талаш, әмма чыгырыңнан чыкмыйча.

Ш а к и р. Әйтер идем инде...

Г а з и з. Әти!

Ш а к и р. Әй!..

Г о с м а н кулындагы стаканны алып, аракысын күтәреп эчә дә өйгә кереп китә.

Г о с м а н. Азына башлады, әйтмәгән саен теге.

Үз квартирасына кереп китә. Ул ара да булмый, сөйләнә-сөйләнә, Ш а к и р кире чыга. Әйтәсе сүзе бетмәгән икән әле, йөрәге басылмаган.

Шунда гына Госманның кереп киткәнлеген аңлап ала. Госманвар йортына таба атлый, әмма, ишек буена житкәч, туктала. Террасага кире килә дә телефоннан номер жыя башлый. Менә Госман квартирасында телефон шалтырый. Госман тәрәзә буенда трубка ала.

Госман. Алло?

Шакир (*трубкага*). Нәрсәгә таянып Газизнең эшен чиле-пешле дип атыйсың әле син? Син бит аны сыңар күзең белән генә дә карап чыкмагансың.

Госман. Кара әле, бу ни эшең синең?!

Шакир. Селедка төреп куеп кына чертежда нәрсә барын белеп булмый ул.

Госман ишектән килеп чыга, кулында телефон трубкасы.

Госман (*һаман трубкага сөйли*). Ташлыйсыңмы син бу кыланышларыңны, юкмы?!

Шакир дә Госман каршына атлый, әмма трубкасын калдырмый.

Шакир (*трубкага*). Син Газизгә үсәргә юл бирмисең. Әнә, эт үзенне суга тыгып басып торганмы, шуның кебек син дә Газизне басып киләсең. Лапың белән. Баксаң-күрсәң, овчарканың кармагына эләгүең дә шуның өчендер әле. Газизне рәнжеткәнең өчендер.

Әсма (*икесенең арасына кереп*). И-и-и, ирләр безгә караганда интеллигентныйрак шул. Кара, ничек культурный гына әйтешәләр.

Госман. Кем белән авыз чайкаганыңны онытмаска киңәш бирер идем мин сиңа! (*Өенә кереп китә.*)

Шакир. Ә мин сиңа кешегә кешеләрчә карарга киңәш бирәм. Дәрәҗәсе бармы аның, юкмы, барыбер кеше ул.

Газиз. Әти, нишләвең инде бу? (*Телефон трубкасын алып урынына куя.*)

Әсма. Килешми.

Шакир. Аңа килешәме? Бер ишек алдында, бер өстәлдә ашап эчкән күршеңне шулай мәсхәрә кылу килешәме? (*Бер карарга килеп.*) Тукта әле, мин ясаган өстәл бит бу. (*Пычкы алып килә дә өстәлне кыл уртасыннан кисә башлый.*)

Әсма. Ни кыланасың инде тагын?!

Шакир. Аның белән бер өстәл янында утырырга теләмим! Бүгеннән ул минем кан дошманым. Үч, үч, үч алам!

Газиз. Әти дим!

Шакир. Тиха!

Әсма. Тәмам котырындың, билләһи.

Шакир (*кулын авырттыра*). Кил әле, мә. Тот әле, булыш!

Әсма. Шулай булмыйча.

Шакир. Тот, диләр!

Әсма (*пычкыны алып кисә башлый*). Ә-ә-әй!..

Шакир. Үч алам!

Әсма. Ходаем, нишләрсең икән. Син кем дә ул кем, хәчтерүш.

Шакир. Тиресен тунавын тунамам, әмма желегенә үтмәсәмме. Кызын ябыштырып чыгам мин аның. Яшь хатынлыкка. Урлап чыгам.

Әсма. Минем өстәнме? (*Пычкысын ташлый. Шакир үзе кисә башлый.*) Ах, оятсыз, нәфесеңне кая сузасың, жир бит. Мәләгең яраклыга күз төшермәсәң, юньсез.

Шакир. Малай белән без үзебез бүлешербез, син безнең арага тыгылма. Малайга сеңелесе, миңа авасы.

Әсма. Шәмсиясен әйтәсеңмени әле?

Шакир. Самый рәз.

Әсма. Киңүдәге нәрсәне.

Ш а к и р. Киявеннән аерылып кайтты инде.
Ә с м а. Кайчан?
Ш а к и р. Кичә.
Ә с м а. Яшь дип тә тормыйсың.
Ш а к и р. Утызда. Хатын-кызның самый котырган чагы.
Ә с м а. Әйтәм аны, физкультура уйный башладың.
Ш а к и р. Дәрт-дәрман кирәк булачак.
Ә с м а *(самовардан кружкага кайнар су агызып торган җиреннән)*. Кружкасы белән тондырырмын!
Ш а к и р. Кече кызы улыма, олы кызы үземә. Ике кияве артыннан йөгереп йөргәнен сизми дә калсын әле Госманың! *(Өстәлне урталай кисеп бетереп, ике кисәген ике якка аерып куя.)* Менә утырсын инде ярты өстәлдә.
Г а з и з *(көлә)*. Ә үзең?
Ш а к и р. Тиха!

Өеннән Р ә м з и я чыга. Ш а к и р кереп китә. Аның артыннан Ә с м а атлый. Р ә м з и я өстәлнең урталай киселгәнен күреп, янына бара. Г а з и з өстәлнең бер кисәге, Р ә м з и я икенче кисәге янында аптырап торалар.

Р ә м з и я *(кыю рәвештә)*. Газиз, мин сезнең яклы. Әти хаклы түгел, миңа хәтта аның өчен оят. Ул зур тупаслык эшләгән. Мин аны якламыйм. Мин сезнең яклы! Кирәк икән, ышанмыйсың икән, мин моны исбат итә дә алам.
Г а з и з. Ай-һай, Рәмзия, мондый хәлдә сиңа исбат итүе җиңел булмас.
Р ә м з и я. Ә мин берниндән дә курыкмыйм.
Г а з и з. Син алай уйламыйча гына ышандырма әле. Ахырдан үкенергә туры килмәсен.
Р ә м з и я. Үкенмәм. Гаделсезлек күрсәм минем йөрәгем әрни.
Г о с м а н тавышы *(өеннән кычкыра)*. Рәмзия!
Р ә м з и я. Хәзер, хәзер... *(Газизгә.)* Мин исбат итәргә әзер. Әйт кенә, нишлим?
Г а з и з. Мондый хәлдә Джульетта Ромео өчен кабергә кереп ятарга риза булган.
Р ә м з и я. Ә миңа?
Г а з и з. Сиңа да бер җиңел генә эш табылып тора үзе. Әгәр дә инде безнең яклы икәнеңне исбат итәргә телисең икән...
Р ә м з и я. Я?
Г а з и з. Күлмәкләрең тутырылган чемоданны *(Рәмзия йортыннан үз йортына күрсәтә.)* бу йорттан бу йортка күчереп куясың.
Р ә м з и я *(аңламады)*. Нәрсәгә? Әй, син шаяртасың. Ә мин чыннан әйтәм.
Г а з и з. Шаярмыйм. Мин яратам сине, Рәмзия.
Р ә м з и я *(көтмәгән иде, кызарды. Тынып калды)*. Ә? Ничек? Кайчан?
Г а з и з. Менә әле генә. Бүген иртән генә.
Г о с м а н тавышы *(тагын да катгыйрак)*. Рәмзия дим, кирәсеңме син, юкмы?!
Р ә м з и я. Хәзер, әти, хәзер. Менә чәйнекне генә чистартам да... *(Кулына чәйнек ала, чистартып маташкан булып кылана. Музыка башлана.)*
Г а з и з. Унсигез ел бергә яшәп тә, көн саен очрашып та мин сине күрмәгәнмен. Менә биш минутта күреп алдым. Рәмзия! Һаман да балага санап йөри идем, ә син менә нинди булып үсеп җиткәнсең икән. Рәмзия!..
Р ә м з и я. Газиз!.. Мин бәхетемне еракта кетә идем, әллә кайдан. Күз күрмәгән җирләрдән берәү килеп чыгар да, мәхәббәт канатына утыртып, сихри дөньяга алып очар дип. Ә минем бәхетем күршемдә генә йөргән икән. Газиз!..

Газиз.
Унсигез ел буе кургәнмен,
Унсигез ел белми йөргәнмен:
Керфекләрең синең кара икән,
Очларыннан нурлар тама икән,
Саф йөрәген балкып яна икән,
Битләреннә алга мана икән.

Рәмзия.
Бер дигәнем, өзелеп сөйгәнем,
Әллә кайдан котеп йөргәнем,
Еракларда түгел, якын икән,
Һәрбер сүзе аның ялкын икән.
Унсигез ел буе күргәнмен,
Унсигез ел белми йөргәнмен.

Бергә.
Унсигез ел буе күргәнмен,
Унсигез ел белми йөргәнмен:
Карашларын өзеп ала икән,
Йөрәкләрдә эзе кала икән.
Унсигез ел буе күргәнмен,
Унсигез ел белми йөргәнмен...

Тәрәзәдә Шәмсия күренә. Яңа гына йокысыннан уянган. Тулы гәүдәле, чал хатын. 25 яшьләрдә.

Шәмсия *(өркетеп)*. Әйт!

Рәмзия белән Газиз күздән югалалар.

Исәнме, Әсма апа!

Әсма *(күңеле бармыйча гына)*. Исәнме.

Шәмсия *(өстәлне күреп)*. Бу ни бу? Әллә монда жир тетрәдеме?

Әсма. Ирең ни хәлдә, Шәмсия, бу арада күренми?

Шәмсия. Кояш кебек.

Әсма. Матур яшисез икән, алайса. Сөбханалла.

Шәмсия. Кичтән балыкка китеп бата да, нурлы йөзен иртән генә күрәм. Ишетмәдеңмени әле? Әсма апа, аерылдым бит мин аннан. *(Әсманың кулыннан әйбере төшеп ук китә.)* Йомшак. Көн итә белми.

Әсма. Ишеткән идем дә, ышанырга базмаган идем. Дөрес икән, алайса.

Шәмсия. Әй-й-й, илле тиенгә килгән ирдән ни кәтәсең. Киногa ике билет алдым да артыгын бер ир кешегә саттым. Бу жебегән туры килде. Шуннан гына танышып киткән идем мин аның белән.

Әсма. Яшь иде бит әле.

Шәмсия. Әй, Әсма апа, андамыни хикмәт. Яшьләрнең ниндие булмый да, картның ниндие булмый. *(Кычкыра.)* Газиз!

Әсма *(узалдына)*. Тфү! Икесенең дә аягын сындырмасам шуларның!

Керел китә. Шәмсия баскычка житкәч, Газизне күреп, кире борыла.

Шәмсия. Газиз, миңа теге Арсланов турында данныйлар кирәк иде.

Газиз. Арсланов?.. Бүген ял көне, эш турында сөйләшмибез. *(Өйгә кереп китмәкче.)*

Шәмсия *(алдына төшә)*. Тукта әле, кызыл почмакка куярга карточкасы да кирәк. Бик зур гәкъдим керткән, ди, ич.

Газиз. Бик зур.

Шәмсия. Кем соң ул? Кайдан? Нинди кеше? Үзең техника бүлегендә эшлисең, үзең аның хезмәтен алып килгән, ә анкетасын тутырмагансың. Бу бит акча эше белән бәйләнгән.

Газиз. Нигә төпченеп торыйм. Мин аны белмәсәм иде.

Шәмсия. Танышыңмыни?

Газиз. Казанда бергә булдык.

Шәмсия *(кызыксынуы арта бара)*. Алайса, я әле, сөйлә әле. Нинди кеше?

Газиз. Икенче вакытта, Шәмсия.

Шәмсия *(җибәрми)*. Я инде, исеме кем

Газиз *(бераз уйлагач)*. Ризван.

Шәмсия. Ризван Арсланов. Яшь нәрсәме соң?

Газиз. Яшь тә түгел, карт та түгел, самый сөяр чак кына. Егерме биштә.

Шәмсия. Буйга ничегрәк? Төскә? Син тагын, бу үзе өчен кызыксына, дип уйлый күрмә. Бер уңайдан гына сорала торган сүз инде.

Газиз. Буйга калкурак, йөзгә ачыграк.

Шәмсия. Тагын нәрсә сорамакчы идем соң әле?

Газиз. Хатыны юк. Әллә бөтенләй өйләнмәгән, әллә инде өйләнеп аерган. Ялгызы гына яши.

Шәмсия. Чукынчык икән. Бер хатынны бәхетле итәсе бар икән әле. Бу эше өчен шактый каерыр инде ул?

Газиз. Ун меңнән артык булмас.

Шәмсия. Ә? *(Аңын җыя алмыйча тора.)* Ун мең... Үзе кайчан килер икән соң? *(Газиз кереп китмәкче иде, тагын аның юлына төшеп.)* Кайда эшли әле?

Газиз. Хәзер кайдадыр, белмим. Элек министерствода иде.

Шәмсия. А? *(Башы әйләнеп, чайкала башлый. Эскәмиягә барып ята. Газиз шүрләп кала, янына килә.)*

Газиз. Шәмсия, Шәмсия!

Шәмсия. Ха-ха-ха... Әзрәк кызган, ичмасам, тәмам тәкатьсез итәсең бит, җүнсез. *(Аягы белән Газизнең тез астына кагып җибәрә, Газиз егыла.)* Үзен күргәнче үк гашыйк булдым, ахры, карточкасын, карточкасын табып бир! *(Көлешәләр.)*

Газиз. Эти, бар әле, Ризванның карточкасын алып чык әле. Синең тартмаңда ята бугай.

Шакир. Кайсы ул?

Газиз *(Шәмсиягә ишеттермичә)*. Бар инде, берәр яшьрәк ирнекен алып чык шунда.

Шакир. Ни өчен?

Газиз. Соңыннан. Бар инде.

Шакир җилкәсен җыерып, берни дә аңламыйча кереп китә.

Шәмсия. Газиз, иң кирәклесен сорарга онытып торам икән. Адресын.

Газиз. Менә анысын үзем дә хәтерләмим.

Шәмсия. И, шулай ярыймыни инде. Тиз генә чакыртырга кирәк булса нишләрбез. Газиз, әгәр дә адресын табып, янына үзем барып чыксам, килешер микән?

Газиз. Юкка сабырсызланасың, Шәмсия. Менә-менә үзе килеп чыгарга тиеш. Бүген булмаса, иртәгә.

Шәмсия. Шулаймыни? Ходаем, ул хәзер капкадан килеп керсә. *(Өстендәге халатының төймәләрен ычкындыра да, итәкләрен җәеп өйгә юнәлгәндә, башын күтәрсә, каршына килеп чыккан Шакирны күреп, кычкырып җибәрә.)*

Шәмсия. Ай! *(Тиз генә халат итәген яба. Шакир кулыннан карточканы ала да текәлеп кала. Моны Әсма читтән күзәтеп тора.)*

Шәмсия. Чибәр ич бу. Мин моны зурайтып *(сөенеп кычкыра)*, стенага эләм!

Урдәк кебек йөзеп кенә өенә кереп китә. Әсма да күздән югала. Шаян музыка яңгырап куя.

Ш а к и р. Анлат әле, нәрсә бу? Мин аңа үземнең яшь чакта төшкән карточкамны бирдем, ә ул аны зурайтып стенага элмәкче. *(Газиз көлә.)*

Г а з и з. Барысы да Арсланов белән саташкан. Эзлиләр, хыяллана-лар, көтәләр. Әйдә, юансыннар. Тик болар бик куырып, эшне бозып таш-ламагайлары. *(Бер карарга килеп.)* Әти, мин Ризванны чакырып хат сал-ган идем, һаман да күренми. Әллә син дә язып карыйсыңмы? Яз әле. Килсен, кунак булсын.

Ш а к и р. Кайсы Ризванны?

Г а з и з. Җизнинең апасының каенесен.

Ш а к и р. Аның монда ни катнашы бар?

Г а з и з. Бер дә катнашы юк.

Ш а к и р. Шулай булгач.

Г а з и з. Фамилиясе Арсланов.

Ш а к и р *(нәрсәдер сизенеп)*. Ә... Арсланов, карточка, Ризван... Әллә болар барысы да... Тукта, тукта, синең алдыңа төшкән Арсланов әллә ул дөньяда бөтенләй юк кешеме?

Г а з и з. Шыпырт.

Ш а к и р. Димәк, Арсланов ул — син?

Г а з и з. Үзең генә бел. Май кап.

Ш а к и р. Булды. Каптым да, йоттым да... Ха-ха-ха... *(Госман йорты-на бармак янап.)* Ә-ә, Госман Ганиевич, кем утырыр әле ул төпсез көймәгә.

Г а з и з.
Иләләлә, иләлә,
Эшләр безнең көйләнә.
Болай булгач утыртабыз
Үзен төпсез көймәгә.
Ул гына бик белдекле,
Ул барсыннан остарак.
Терсәген тешләр иде дә,
Муены булыр кыскарак.

Ш а к и р.
Әттәтәтә, әттәтә,
Менә дөнья нишләтә,
Кешегә көлеп карасаң,
Кайтара ул бишләтә.
Терсәгеңне тешләтә.

Г а з и з. Хезмәтемне ошаттылар, әмма әле ул кабул ителмәгән. Андый-мондый эш Арсланов фамилиясенә килеп терәлсә, Ризванның бездә булганы яхшы. Аны әзерләп куярга кирәк.

Ш а к и р *(түбәсе күккә тигән)*. Кирәк, кирәк. Саклангәнны алла саклаган. Хәзер, хәзер... *(Йөгереп кенә йөри. Ни арада кәгазь белән карандаш табып китерә, өстәлнең үз яртысына утырып язарга әзерләнә.)* Ай-яй, шәп каптыргансың! *(Утырган җирендә сикеренеп куя.)* Молод-чина. Әгәр дә өйләнергә ниятең булса, әйдә, туеңны бер итеп үткәрәм. Дөньясын дер селкетеп. Шундый туй итәрбез, кем туе дигәндә...

Ә с м а ишектән килеп чыга. Кулында себерке.

Ә с м а. Туй? Ах, жир бит, әле ул ниятеннән кайтмагансың икән. Ясармын мин сиңа туй! Икегезне дә себерке белән айкап чыгарырмын.

Ш а к и р. Үзең ул туйда биеп йөрмәгәен әле.

Ә с м а. Биермен, синең җилкәңә менеп атланып!

Ш а к и р хат язарга керешә. Өстәле әледән-әле авышып китә. Ш а к и р аны казык белән терәтеп куя. Ә с м а Ш а к и р н ы ң җилкәсе аша үрелеп кенә, язганына күз төшермәкче була. Ш а к и р моны сизеп алып, язуын эшләпәсе белән каплап куя.

Ә с м а. Нәрсә язасың?

Ш а к и р. Кит, комачаулама.

Әсма. Гомер иткән хатыныңнан сер саклый башладыңмыни инде? (*Елый башлый.*)

Шакир. Авызыңда җәпләкәле сүзләр дә тормый. Сиңа сөйләү урамга чыгып кычкыру белән бер.

Әсма. Ачуымны чыгарасың, билләһи.

Шакир. Чыкса, төтен түгел, күзгә кермәс.

Әсма. Өйләнешкәндә, берәүгә дә күз төшермәм, дип антлар эчкән кеше.

Шакир. Һәйкәл түгел лә мин. Һәйкәл генә матур хатыннарга күз төшерми. Чөнки ул таштан ясалган. Ә үзен нәрсә дигән идең?

Әсма. Әй, Сәмигуллага үч итеп кенә чыктым ла мин сиңа кияүгә дә.

Шакир. Миңа үч итеп Сәмигуллага чыкмавың кызганыч. Гомер буе көнләшеп үттен үзәгемә. Күпме нахак сүз ишеттем. Менә, ичмасам, берсе дөрескә чыксын. Күршедә тол хатын барында. (*Көйләп.*)

Абзыкаем Фәрхетдин,
Кигән киемен бәрхетдин.
Күрше кызы кияүдән кайткан,
Бер дә безнең бәхетдин.

Әсма. Пенсиягә чыккач, маең кайный башлады. Бу хөкүмәте дә ни дип шул кадәр зур акча түли торгандыр.

Шакир (*үзе һаман өстәл белән азаплана-азаплана яза*). Эштән пенсиягә чыгып була. Көнләшүеңнән чыгып булсын иде.

Әсма. Бая Шәмсиягә нәрсә бирден?

Шакир. Я алла, ике гашыйк бер-берсенә нәрсә бирешмәс. Кая киттең? Аларга аяк басасы булма!

Әсма. Тиха! Миңа ярый. Мин сезнең ызгышка катнашмыйм. Мин битараф.

Госманнарга кереп китә. Шакир көлеп кала.

Шакир. Ха-ха-ха. Итәрсең сине битараф.

Газиз. Әллә телеграмма гына сугабызмы? Хат кайчан барып җитә.

Шакир. Әйе шул. (*Язган хатын ертып ташламакчы була, әмма ул ниятеннән кире кайта.*) Тегенең күзенә чагылмасын. (*Хатның ертыкларын самовар трубасына салырга җыена. Шул чакта Госманнардан Әсма килеп чыга. Ишекне ябуга, туктала, алъяпкыч кукрәкчәсеннән карточка алып карый. Карый да лап итеп баскычка утыра.*)

Әсма. Карточка! Карточкасын биргән. (*Ярсып Шакир янына килә.*) Яшь чакта төшкән карточкаң белән кызыктырырга уйладыңмы? Аңа гына риза булыр микән соң ул?

Шакир. Ничек ул синдә?

Әсма. Сиздермичә сумкасыннан урлап алып чыктым.

Шакир. Нигә син безнең арага керәсең?! Битараф икәнсең, битараф бул.

Әсма. Шулай, син тол хатыннар белән шаярганда, мин битараф булып торырмын менә. (*Шакир хат кисәкләрен самовар трубасына салып бетерә.*) Нигә яндырасың аны, эзе калмасын дисеңме?

Шакир. Мәхәббәт хатын сиңа укытмам инде.

Әсма тузынып Шакир өстенә килә, шул вакытта өеннән Госман чыга. Аны күреп, Әсма тыелып кала.

Әсма. Әйдә әле, өйгә керик әле.

Шакир. Кермичәрәк торсын. Колак итемне ашар иден бугай.

Шулай да, Госманны күреп алгач, хатыны артыннан кереп китә. Газиз дә алардан калмый. Тәрәзәдә Рәмзия, балконда Шәмсия күренә. Өчесе бергә күршеләре хәленнән шаркылдап көлешәләр. Ул ара да булмый, өйләреннән күршеләре үзләре килеп чыга. Боларга җавап итеп, алар да кычкырып көләләр. Госманнар ишек-тәрәзәләрен ябып кире китәләр.

Кай жирдә тудың син,
Кай илдә үстең син.
Нинди саф чишмәнең
Суларын эчтең син.
Буйларың — тал-зифа,
Карашың сер генә.
Карачы үземә
Елмаең бер генә.

Шакир. Кем ул?
Газиз. Ризван түгелме соң бу?

Әсма иске самовар трубасына охшаган подзорный труба алып чыгып, Шакирга тоттыра.

Шакир (*трубадан карый*). Кая әле.
Газиз. Әти, Ризван бу, Ризван!

Ризван керә. Җилкәсендә юл капчыгы.

Шакир. Әйдүк, Ризван. Әйдүк. Хуш киләсең.
Ризван. Исәнме, кода?
Газиз. Саумы? (*Исәнләшә, капчыгын алып куя.*)
Шакир. Өйдәгеләр сау калдылармы?
Газиз. Көттерден. Әллә инде килми микән дип торабыз.
Ризван. Хатыңны алуга юлга чыктым.
Газиз. Телеграмма сукмакчы идек әле.
Шакир. Әйе, мә менә, кабул итеп ал. (*Үзе язган кәгазьне чыгарып карый, укып ук бирә.*) «Срочно приезжай».
Ризван. Нәрсәгә шулай бик ашыгыч кирәк булып чыктым соң әле мин?
Газиз. Үзеңнән бигрәк безгә фамилияң кирәк, кода.
Ризван. Берни төшенмим.
Шакир. Әйе, фамилияң синең бик хикмәтле булып чыкты, кода.
Ризван. Ни булган минем фамилиямә?
Шакир. Арсланов! (*Госман өенә карап алып.*) Әйдәгез, рәхим итегез, иптәш Арсланов! Без бик шатбыз. Тәкъдимегез безгә бик ошады.
Ризван. Нинди тәкъдим? Чүгез әле, аңлатыгыз әле.
Шакир. Тиха! (*Госманга ишеттерергә теләп.*) Сез бүген минем иң хөрмәтле кунагым. Әйдәгез өйгә! Тартынмагыз!
Ризван (*берни дә аңламый, шулай да аңа кызык, көлә*). Ха-ха... Кара боларны.
Шакир. Әйдәгез, әйдә, өемнең түренә узыгыз, иптәш Арсланов!

Алар шулай Ризванга киргәгеннән артык зур ихтирам күрсәтеп, килгән юлларына келәмнәр җәеп, каршылау оештыралар. Менә барысы да өйгә кереп китә. Тәрәзәдә Шәмсия күренә.

Шәмсия. Арсланов? Әһә!

Югала. Шаян музыка яңгырап ала. Ишектән чемодан күтәреп Рәмзия чыга. Чемоданы авыр. Көчкә күтәреп, Газизләргә табан атлый. Газизне эзли. Ишектән Әсманың чыкканын күреп, кире чигенә, тирәкләр артына кереп яшерена. Капкадан Гайфи керә. Кулында намордник — эт борынчыгы. Артыннан борылып кычкыра.

Гайфи. Амур! Пошел Амур!.. (*Як-ягына карана, Госман йортына күз төбәп, тукталып кала. Әсма янына килә.*)
Гайфи. Исәнмесез, апа!
Әсма. Сау гынамы?
Гайфи. Госман Ганиевич дигән кеше шул йортта торамы?

Г а й ф и. Әйтә алмассызмы, апа, кәефе ничегрәк икән?

Ә с м а. Табада кыздырылган май кебек. Бер тамчы су төштеме, чыжлап китәргә генә тора.

Г а й ф и. Һаман да тынычлана алмый икән. Нишләргә инде...

Ә с м а. Йомышың бар идемени соң?

Г а й ф и. Минем Амур аны бүген төн буе судан чыгармаган.

Ә с м а. Кем дисең?

Г а й ф и. Амур. Һау-һау-һау!..

Ә с м а. Ул синең этең булганмыни? И-и, алайса, күзенә күренмәвең хәерлерәк.

Г а й ф и. Эт кызганыч. Адәм акылы бар иде үзендә, ялгышкан. Артыграгын кыланып ташлаган. Инде харап иттермәгәе дип куркам. Аттырам дип яный икән.

Ә с м а. Ачуы бик кабарып кайткан иде.

Г а й ф и. Бераз йомшартып булмасмы дип килгән идем. Эт кызганыч. Бик эт җанлы кеше мин. Ничек тә җайлыйсы иде, апа, ә. Апа дим! *(Кулын Әсманың җилкәсенә сала.)*

Ә с м а *(кочаклый дип уйлап)*. Кит җүнсез, нишләвең! *(Бер уйга килеп.)* Башта кызын җайласан гына инде. Кияүдән кайткан бернәрсәсе бар, ирләргә бик һәвәс нәмәрсә. Ишетүгә эреп китә торганнардан. *(Ишектә Шәмсия үзе күренә. Күлмәген алмаштырган.)* Әнә үзе. Җебеп торма. Кызын карата алсаң, атасы җайланыр. Этең дә исән калыр.

Г а й ф и *(өмете кабына)*. Шулай дисезме, булыр дисезме. Рәхмәт, апа, рәхмәт. Мә, Амурның йөгәнен алып кына куй әле. *(Кочаклап ала.)*

Ә с м а. Чү, кит, җүнсез. Ходаем икән...

Керел китә. Ш ә м с и я белән Г а й ф и бер-берсенә карашып торалар.

Ш ә м с и я. Исәнмесез.

Г а й ф и *(ялгыш ычкындыра)*. Һау!.. Исәнмесез.

Ш ә м с и я. Мин сезне беләм. Сез — Арсланов.

Г а й ф и. О-һо.

Ш ә м с и я. Исемегез Ризван.

Г а й ф и. Ризван? Точно.

Ш ә м с и я. Сез министерствода эшлисез.

Г а й ф и. Әйе.

Ш ә м с и я. Сез новатор. Безнең комбинатка бик зур тәкъдим керттегез. Сезгә 25 яшь.

Г а й ф и. Сез сихерче. Колдун. Чегән кызымы әллә? Куркам мин сездән.

Ш ә м с и я. Миндә сезнең карточкагыз да бар иде әле, әллә кая куйганмын.

Г а й ф и. Зыян юк, мин сезгә яңасын бирермен.

Ш ә м с и я. Кайчан килдегез? Озаккамы?

Г а й ф и. Әле генә килеп төштем. Озак тора алмам. Минем монда туганнарым яши.

Ш ә м с и я. Арсланов иптәш, мин сезне тәбрик итәм! Сезнең тәкъдимегезне ошаттылар! Бу күңелле хәбәрне сезгә беренче булып җиткерүем белән мин бәхетлемен.

Г а й ф и. Рәхмәт сезгә. Ләкин әле минем шигем бар. Барын да беләм дисез, ә иң әһәмиятлесен әйтмисез. Димәк, белеп бетермисез.

Ш ә м с и я. Рәхим итегез, сорагыз.

Г а й ф и. Нинди тәкъдим керттем икән соң мин?

Ш ә м с и я. Җыю цехына конвейер кертүне хәл иткәнсез. Чертежларын да эшләп китергәнсез.

Г а й ф и. Точно. Болай булгач ышандым: беләсез. Ә менә миндә сезнең талант юк шул, исемегезне дә белә алмыйм.

Шәмсия (кулын сузып). Шәмсия!
Гайфи (кулын кысып). Ризван Арсланов! Иптәшегез ни эшләр бетерә?
Шәмсия. Мин ирдә түгел.
Гайфи. Алай икән, ирегез әле өйләнмәгән икән.
Шәмсия. Мин беләм: сез дә өйләнмәгән.
Гайфи. Хак сүз.
Шәмсия. Туры килеп торуын кара син аның. Минем булачак иремнең дә, сезнең дә өйләнмәгән булуыгызны әйтүем.
Гайфи. Үзем дә шаккатам. Бу кадәр туры килүнең берәр хикмәте юкмы икән дим.
Шәмсия. Сез чыннан да өйләнмәгәнме?
Гайфи. Өйлән... мәгән, мәгән. Ялгышлык бер булган иде, ләкин мин аны бик тиз төзәттем. Аерылдым.
Шәмсия. Хәзер сайлыйсызмы инде?
Гайфи. Гадәтем шундый минем. Мин алася хатын бик матур да, бик акыллы да булырга тиеш.
Шәмсия. Сез нәрсә, берьюлы ике хатын алмакчы буласызмыни?

Ишектә Госман күренә.

Шәмсия. Әти, иптәш Арсланов килде.
Госман. Арсланов? (Каршына атлый.) Исәнмесез, хуш килдегез. Бик шатмын. Без көтә идек.
Гайфи (каушап кала). Исәнмесез, Госман Ганиевич.
Госман. Юл бик ватмадымы?
Гайфи. Зарланмыйм.
Госман. Тәкъдимегез безгә бик ошады.
Шәмсия. Мин сөйләдем инде.
Госман. Әлбәттә, кабул итәчәкбез. Җыю цехына конвейер кертми һич ярамый.
Гайфи. Мин дә шулай уйлыйм.
Шәмсия. Әти, юлдан килгән кешене сүз белән генә сыйламыйлар.
Госман. Әйе, әйе. Әйдәгез өйгә.
Гайфи. Борчылмасагыз иде.
Госман. Ниткән борчылу ди ул, язмаганны. Сез бүген минем иң хөрмәтле кунагым. Әйдәгез, рәхим итегез. (Шакирларга ишеттерергә тырышып.) Әйдәгез, иптәш Арсланов!

Гайфине кыстый-кыстый, этә-төртә, өйләренә алып кереп китәләр. Гайфи тартышып карый, әмма ычкына алмый. Ишектә Газиз, тәрәзәдә Шакир күренә. Бер-берсенә карашып, аптырашып торалар.

Газиз (бер фикергә килеп). Госман Ганиевич!

Өеннән Госман чыга.

Газиз. Госман Ганиевич, мин үз фикеремне сезгә белгертергә тиешмен. Иптәш Арслановның хезмәтенә житдирәк карасагыз икән. Минемчә, аның тәкъдиме... ничек дип әйтим... әлегә өлгермәгән.
Шакир. Син ни сөйлисен, нәрсә уйлап чыгарасың тагын?
Газиз. Әйе, әйе, әти, ялгышлык килеп чыкмасын. Мәсьәләгә житди карасыннар. Принципиаль рәвештә. Ахырдан үкенерлек булмасын.
Шакир. Ташла, синең анда ни эшең бар! Үзләре караганнар, үзләре ошатканнар. Син инде катнашма.
Газиз. Мин кисәтергә тиеш.
Шакир. Бар әле, әнә өйгә кер, әнием көтә.
Газиз. Ахырдан әйтмәде дип әйтмәсеннәр. Госман Ганиевич, минемчә, Арсланов хезмәтенең бик зур кимчелекләре, житешсезлекләре бар. Ул әле...

Госман. Я, як

Газиз. Ул әле чиле-пешле.

Шакир. Эх, син үзең чиле-пешле! *(Малаена кул селтәп өенә кереп китә.)*

Газиз. Госман Ганиевич, ашыгырга ярамый. Күпме расход тотылачак. Кайта-кайта танышырга, кат-кат уйларга кирәк.

Госман *(гаепләп елмая)*. Тагы, тагы?

Газиз. Менә шул: Арслановның эше мина ошамый.

Госман. Шундый эшне юкка чыгарырга ничек оялмыйсың? Техника бүлегендә эшләүче буларак, якларга тиеш идең. Ә син яманлыйсың. Көндәшен булганга. Бу, күрше, түбән җанлылык.

Газиз. Мин аны яклый алмыйм.

Госман. Күреп торам. Без аны тормышка ашырырга берәр айдан тотынырбыз дигән идек. Болай булгач, синең ишеләргә үч итеп, бер атнадан!

Өенә кереп китә. Газиз елмаеп кала. Аның күңеле күтәренке. Ул шат.

Газиз. Кирәген бирдем Арслановның. Шул кирәк аңа.

Яшеренгән җиреннән әкрен генә Рәмзия чыга.

Рәмзия. Син нәрсә, берәр батырлык эшләгән кешедәй тантана кыласың. Мин синең урыныңда булсам...

Газиз *(биленнән алып әйләндермәкче)*. Булма, кирәкми. Син үз урыныңда әйбәт. *(Рәмзия ачулы, моны күреп Газиз кисәк туктала.)* Син тыңлап тордыңмы?

Рәмзия. Ә син минем тыңлавымны теләмәгән идеңме? Син вак кеше икәнсең, кеше уңышын күрә алмаучы.

Газиз *(һаман шаярта)*. Күрә алмаучы.

Рәмзия. Көнче.

Газиз. Көнче.

Рәмзия. Үз эшең барып чыкмагач, үч аласың.

Газиз. Үч алам.

Рәмзия. Кемнән, үзеңә караганда булдыклырак кешедән?!

Газиз. Булдыклырак.

Рәмзия. Ква-ква!

Газиз. Бака-ка!

Рәмзия Газизгә нәфрәт тулы караш ташлый да, тирәкләр артыннан чемоданын алып, баскычка юнәлә. Газиз шунда гына эшнең нәрсәдә икәнен, үзенең нинди ялгышлык ычкындырганын аңлап ала.

Газиз *(нишләргә дә белмичә)*. Ах, чемодан!.. Рәмзия, бәгърем, ул якка түгел! Безнен өйгә! Бир, үзем...

Рәмзия. Юлымны бүлдермәгез.

Газиз. Син ялгышасың.

Рәмзия. Мин ялгышымны төзәтәм.

Газиз *(утлы табага баскандай)*. Ах, Рәмзия! Аңла, мин Арслановны мактап тора алмыйм бит инде.

Рәмзия. Алмыйсын шул.

Газиз. Булмый. Ярамый. Мин аны яклый алмыйм.

Рәмзия. Хезмәтен ошатмасаң да, син аны якларга тиеш. Икегез бер тема өстендә эшләгәнсез. Аныкы әйбәтрәк булып чыккан. Хәзер инде син аны батырырга телисең. Үзеңә юл ачарга.

Газиз. Юк.

Рәмзия. Мин барысын да ишетеп тордым. Син үзеңне генә ярату-чылардан икәнсең. Болай булгач, Арсланов синнән күп өстендер.

Г а з и з. Арсланов миннән түбән ул. Буш куык, күләгә, чүп ул. Исеме бар, жисеме юк.

Р ә м з и я. Оял, Газиз. Әзрәк әдәп бел. Бу түбән җанлылык.

Г а з и з. Мин түбән җанлы икән, Арсланов та түбән җанлы.

Р ә м з и я. Мин сезне тыңларга да теләмим! *(Кузгала.)*

Г а з и з. Рәмзия, әгәр дә мин Арслановны яклап чыксам, мактасам, түбән җанлы булыр идем.

Р ә м з и я артык әйтешеп торырга теләми, чемоданына үрелә. Шул чакта ук Г а з и з дә чемоданның тоткасына тотына.

Музыка башлана.

Г а з и з.

Өзгәләмә күңелемнең пәрәсен,
Телгәләмә йөрәк ярасын.
Сиңа төбәлгән бар карашым,
Китмә, ташлап китмә, җанашым.

Р ә м з и я.

Бердәнберем диеп гомер-гомергә
Багышлаган идем хисемне,
Өзелеп сөйдем мин сине,
Инде оныту җиңел дисеңме?!

Б е р г ә.

Онытылмаслык булып мәңге-мәңгегә
Юл алдың минем йөрәгемә.
Сайрамас булгач, былбылым,
Нигә дип кундың тирәгемә.

Р ә м з и я чемодан өстендә утырган Г а з и з н е этеп җибәрә дә, еларга житешеп, чемоданын өстерәп өенә атлый. Чемоданы ачылып, күлмәкләре туздып бара.

*Пәрдә.*

*Ахыры киләсе санда*

# Мөнир Мазунов

## Яшь каләмдәшкә

И бар да соң инде шигъри йортлар!
Тик минеке генә — алачык.
Ә шулай да, ачып бер кергәчтең,
Нидер сора, нидер ала чык...

*Т. К.*

И бар да соң инде зур күңелләр!
Тик син генә әле бала күк.
Ә шулай да, мыштым бу «сабыйдан»
Нидер сорыйм, нидер алам күк.
И бар да соң тирән, серле күлләр!
Синең күлең үтә күренә.
Тик шулай да, җитәм диеп керсәң,
Бик тиз җитеп булмый төбенә.
И бар да соң инде бал-җимешләр!
Тик синеке генә баланмы?
Ә шулай да, аны авыз иткән:
— Җан азыгы шуннан алам,— ди.
И бар да соң инде киң елгалар!
Синең елгаң гына әле тар.
Ә шулай да, аккан суларының
Башка судан үзгә тәме бар.
И бар да соң инде такыр юллар!
Тик синеке бераз туфраклы.
Ә шулай да, бәхет эзләп чыккач,
Теләмиләр бугай уртакны.

## Хәлимә

*Җыр*

Хәлимәнең керфекләре
Гөлләр куесы микән.
Күзләренең тирәнлеге
Серләр коесы микән.
Кушымта:
Их, Бибихәлимә,
Килсәң иде яныма.
Сөюемне беләсең бит,—
Күз салмыйсың хәлемә.

Хәлимәнең иреннәре
Бал микән, шикәр микән.
Ике бите — ике алма,
Үпсәң ни итәр икән?

Кушымта.

Хәлимәнең жырлаулары
Тургай тавышы микән.
Чишмәләр агышы микән,
Кызлар сагышы микән...

Кушымта:

Их, Бибихәлимә,
Килсәң иде яныма.
Сөюемне беләсең бит,—
Күз салмыйсың хәлемә.

## Ак күгәрченнәр

1

Еракка киткән
Кошлар юлыннан
Парлап очалар
Ак күгәрченнәр.
Ак күгәрченнәр,
Пар күгәрченнәр!
Безне сагынган
Күк күгәрченнәр
Сезнең аркылы
Хат җибәрсеннәр.

2

Ак күгәрченнәр,
Ак юлыгызда
Күк күгәрченнәр
Күп иярсеннәр.
Ак күгәрченнәр,
Пар күгәрченнәр!
Кайта алмаган
Күк күгәрченнәр
Сезнең аркылы
Хат җибәрсеннәр.

3

Җирдә яшәгән
Бар күгәрченнәр
Бергә җыелып
Бер гөрләшсеннәр.
Ак күгәрченнәр,
Күк күгәрченнәр!
Еракта торган
Якын дусларым
Сезнең аркылы
Хат җибәрсеннәр.

1970

# ЯШЬ БУЫН ИҖАТЫ[1]

*Шагыйрьләр поэзияне иң кыен жанр диләр. Драматурглар, драма язудан да авыр эш юк, дип бара. Прозаикларның бу бәхәскә алай күп катнашканнарын мин хәтерләмим. Бу хәл проза жанрының җиңеллегеннән түгел, бәлки прозаикларның башка жанр вәкилләре алдында әдәп саклауларыннан булса кирәк. Шаяртып әйткәндә, прозаиклар башкалардан тыйнаграк күренәләр. Бусы, бәлки, проза әдәби жанрларның иң олысы булуыннандыр дип уйлыйм.*

*Ә дөресе, әдәбият дип олы, чын әдәбиятны истә тотып сөйләсәк, башкаларыннан җиңелрәк яисә кыйммәтлерәк дигән жанр юк — барысының да дәрәҗәсе тиң. Шулай да, алданрак тууы ягыннан булмаса да, җитдилеге, тирәнлеге һәм салмаклыгы ягыннан прозаны башка жанрларның анасы кебек күрүемне тагын бер кат әйтеп үтәсем килә. Бусы, бәлкем, үземнең проза кешесе булуымнан туган фикердер. Ни генә дисәк тә, бер илнең, бер милләтнең йөзен күрсәтерлек әдәбият турында сөйләгәндә, ул илнең иҗтимагый тормышы, психологиясе, культура байлыгы һәм культура дәрәҗәсе башка жанрларга караганда прозада (бер чорда, бер әсәрдә) тирәнрәк тә, киңрәк тә күренүе бәхәссез.*

*Бу уйларымны мин әдәби жанрларның кайсы мөһимрәк дигән сорауга җавап бирер өчен түгел (андый сорау үзе үк дөрес булмас иде), бәлки гомумән әдәбияттагы җитдилек, мәгънәлелек, тирәнлек кебек сыйфатларны аеруча билгеләп китәр өчен әйттем.*

*Кыргыз әдәбиятының яңа, соңгы буыны вәкилләре 50 нче елларның азагында һәм 60 нчы еллар башында әдәбиятка килгәндә нәкъ менә шундый караштан чыгып эш иттеләр. Тар тирәлек белән чикләнеп калмыйча, әдәбиятка биектән карап, үз иҗатында шул югары таләпләргә җавап бирергә тырышу яшьләрнең иҗади бер үзенчәлекләре булды. Бу яхшы сыйфат күптән өмет ителеп килгән хасыять иде. Билгеле, алар әле яшь иде һәм яшьлеккә хас кимчелекләрдән дә азат түгел иделәр. Әмма бу кимчелекләр, үсү дәверенең вакытлы бер җитешсезлеге генә булганлыктан, яхшы якларның җитлегә, ныгый баруына киртә була алмадылар.*

*Актуаль теманы кыю күтәрү актуальлекне тирән һәм дөрес төшенүне таләп итә, аны югары сәнгать дәрәҗәсенә җиткереп ачып бирү зур талант һәм осталык сорый. Безнең яшьләр бу таләпләргә нигездә җавап бирә алдылар дип уйлыйм.*

*Бер әдәбияттагы бөтен бер буынның шундый сокланырлык үзенчәлеккә ия булуы, әлбәттә, юк җирдән генә килеп чыкмаган.*

*Безнең гомуми совет җәмгыятебездә, рухи тормышыбызда 50 нче елларда булган яңару, тирәнгәрәк керү тенденцияләре ул чакта үсемлек чорын кичергән яшьләргә зур тәрбияви йогынты ясап, дөньяга карашларын һәм культура дәрәҗәләрен ачыклый, үстерә төште, осталык яңа баскычка күтәрелде. Иҗатта аналитик уй йөртә белү, психологик тирәнлек, тормыш чынлыгын сәнгать чынлыгына әйләндерүдә үз-үзенә ышанганлык — язучы яшьләрнең беренче әсәрләрендәге уңай яклар шулар иде. Моны иҗтимагый тормышта туган әлеге тенденцияләрнең логик нәтиҗәсе итеп аңларга кирәк.*

*Болар әле мәсьәләнең бер генә ягын тәшкил итә. Әгәр дә соңгы буын язучы яшьләр олы буын язучыларның эзендә таптанып, алардан югары күтәрелә алмыйча, аларның*

---

[1] Бу мәкалә һәм хикәяләр Татарстан китап нәшриятында басылып чыгачак кыргыз хикәяләре җыентыгыннан алынды.

чакта алар бу хәтле сүз кузгатуга лаек булмаслар, үз вакытында күзгә дә күренми калган булырлар иде. 60 нчы еллардагы укучылар 40—50 нче еллардагы укучылар түгел иде инде. Димәк, аларның әдәби, эстетик таләпләренә җавап бирердәй әдәбиятны тормыш үзе даулап, үзе биргән. Аннары, беренчедән, кыргыз әдәбияты 60 нчы еллардан соң гына үсә башламады. Шулай булгач, яшьләр элекке буыннарның иҗат тәҗрибәсенә таяндылар, аларның казанышларын һәм кимчелекләрен өйрәнделәр. Моны искә алмыйча торып, яшьләрнең иҗади йөзен тулысынча күз алдына китерү мөмкин түгел.

Яшьләр әдәбият мәйданына күбесенчә хикәя белән килделәр. Хикәя алар өчен, прозаның оператив жанры гына булмастан, киләчәктә зур полотноларга күчәр алдыннан үзләрен сыный торган полигон хезмәтен дә үтәде. Аларның беренче хикәяләре, бик тиз телгә кереп, капма-каршы фикерләр дә тудырды. Әмма бу фикерләр, барыннан да элек, яшьләрнең, һичшиксез, сәләтле икәнлекләрен раслады.

Әдәбиятка килгәндәге уртак сыйфатлары, алда әйтелгәнчә, бер булса да, һәркайсының үзенә генә хас тавышы беренче әсәрләрендә үк инде аермачык сизелеп торды. Берәүләр һәр детальне ювелирчә нечкәләп, образны вак штрихлардан корып ясаса, икенчеләре буяуны куе салып, каләмнәрен зур-зур адымнар белән атлатты, берәүләр кешенең психологиясенә үтеп кереп, аны тирәннән ачуга омтылса, икенчеләре характерларны экспрессив алым белән төзүне күз алдында тотты. Мондый индивидуаль үзенчәлекләр яшьләрне берсе-берсеннән бөтенләй аерып куймады, ә киресенчә, бер буынның гомуми иҗади йөзен, характерын мәгънәлерәк итеп күрсәтте.

Бу яңа буынның иҗатындагы тагын бер үзенчәлек исә — масштаблылык булды. Билгеле, бу әле аларның әсәрләрендә тәмам бирелеп җиткән масштаблылык түгел, ә бәлки уйлау киңлеге, милли мәдәниятнең байлыгына, мөмкинлегенә дөнья культурасы биеклегеннән карап эш итү киңлеге иде. Элегрәк көндәлек таләпләргә яраштырып язылган кочак-кочак романнардан алҗый башлаган укучылар, вак тема, кечкенә хикәя булса да, зур фикер сеңдерергә тырышкан яңа әсәрләр укыганда, үзләрен эчпошыргыч күңелсез өйдән саф һавага чыккандай сизделәр. Яшь буын язучылар укучыларның эстетик ихтыяҗларын менә шул юнәлештә тәрбияләп, аларны үзләренә тарта башлады.

Дөрес, глобаль масштабта уйлау дигәндә, ике аягың белән нык басып торган җирдән аерылып, буш һавада асылынып калу куркынычы да бар. Әмма яшьләр мондый хәлгә төшмәделәр. Беренчедән, алар ил-җирләре, тормыштагы бүгенге җитди таләпләр белән нык бәйләнештә иде; икенчедән, студент эскәмиясеннән туп-туры әдәбиятка килеп керсәләр дә, җилкәләрендә бай тормыш багажы бар иде: сугыш чорындагы авыр еллар аларның үсмерлек аң-сиземенә, йөрәкләренә тирән кергән; сугыштан соңгы кыен еллар да акылга утыра торган, тормышка уйланып карый торган чакларына туры килгән. Ә инде язучы өчен бөтен гомере эченнән бала вакытында башыннан кичергәннәре һәм күңеленә сеңеп, исендә калганнары мәңге кипшенмәс чишмә булуын онытмаска кирәк. Менә шуңа күрә без яшьләрнең мәдәни дәрәҗәсе ятлап алынган сай, ясалма культура булмыйча, талантларына сеңгән аңлы культура икәненә ышандык һәм алардан тагын да зуррак әсәрләр көтеп калдык.

Бу көтүнең җимеше хәзер аз-азлап күренә башлады инде. Дөрес, башта ду килеп, гөрләп чыккан яшьләр соңгы өч-дүрт ел эчендә бераз сүрелеп калдылар. Моны, яшьләрнең оеткысы әйныды, дип уйлау дөрес булмас. Таудан ташланып, шарлап килгән су үзәнгә төшкәч, тирәнәеп, салмакланып аккан кебек, алар да баштагы ярсудан соң акыл туплап, иҗатларының эчтәлеген тирәнәйтү юнәлешендә эшләп ятканлай сизелгән иде. Соңгы елларда аларның кайберләре таләпчән укучыларның күңелен биләрлек әсәрләр бирде. Әмма күбесе безне һаман әле көттереп тора. Шулай да безнең алардан өмет өзгәнебез юк, чөнки аларга ышанабыз.

Бу җыентыкка кергән әсәрләрне укып чыгып, һәркайсының үзенчәлеге, уңышы һәм кимчелекләре турында уй йөртүне укучыларның үзләренә калдырыйк. Мин барыннан да элек татар укучыларын безнең кыргыз әдәбиятының кече буыны белән гомумән таныштырып, аларга булган өметебез һәм ышанычыбызны гына бүлешергә теләдем.

ЧЫҢГЫЗ АЙТМАТОВ,
Ленин премиясе лауреаты.

**Мурза Гапаров**

# ТУРГАЙ

Ничәләрдә булдым икән мин? Тугыздамы, әллә сигездәме? Юк, тугызда булсам кирәк. Шул кышны, пелт-пелт килеп утырган сукыр лампа яктысында җеп эрләгәндә, дәү әниемнеңниндидер бер сүзенә кушып: «Бу язда син тугызга чыгасың»,— дигәне хәтеремдә калган. Шуннан соң яз миңа бик тиз җиткәндәй тоелды.

Иң элек төннәрен туңып, ә мин мәктәпкә барганда аяк астында шыгыр-шыгыр итеп калучы каты кар эреде, аннары салкын көздән бирле безнең бакчада кунып йөргән каргалар очып киттеләр; таллар бөре бәйләп, өрекләр чәчәк атты; авылның этләре үткән елдан калган, кар астында ятып күгәреп беткән өрек төшләрен карс-корс кимереп, көнозын агач төпләрендә иснәнеп йөрделәр; тавыклар кояш төшкән дубалларданˡ чебен чүпләде; кайчакта алар азык эзләп ерак камыллыкларга кадәр китеп баралар иде; безнең чуар мәчебез иртәдән кичкәчә иске ындыр табагында тычкан каравыллап йөрсә, аның өйдә калган ялгыз баласы дәү әниемнең зырылдап әйләнгән орчыгы белән уйный. Күрше карт көн саен иртән китмәнен кайрый. Шул язның тагын бер билгесе буларак, нәкъ безнең өй өстеннән торналар очып киткәне хәтердә. Әле дә күз алдымда, дәү әнием чүплеккә көл түгеп ятканда, кинәт кулын маңгаена куеп, күккә карап тураеп калды. Мин дә башымны күтәрдем һәм болытлар астыннан йөзеп баручы, бичара Кондыз җиңгәмнең тоташ куе кашлары сымак урталары кыйгачланып тезелешкән зур-зур кара кошларны күрдем.

— Торналар,— диде дәү әнием уйчан гына,— нинди түбән очалар. Бу яхшылык галәмәте. Боерса, быел туклык була, пырунт та бетә...

Шулай диде дә дәү әнием өйгә кереп китте. Ә мин торналарның җирдә шуышып барган күләгәләрен күреп калдым. Бала бит, шул күләгәләр артыннан чабып киттем. Йөгерә-йөгерә куып җитәсе килә. Юлсыз-нисез чабам, арыклардан[2] сикерәм, чокырларга төшәм, каты үлән камылларына аякларымны канаттым, иске ыштан балакларымны телгәләп бетердем. Һаман чабам. Ахырда: «Әй!» дигән тавышка әйләнеп, көчкә туктадым. Колхоз рәисе икән. Үзенә чакыра. Йөгереп бардым.

— Иртәдән башлап Кондыз җиңгәң белән сукага йөрисең, ат башы тотарсың,— диде.— Укытучыларыгыз укудан бушатты. Бер сине генә түгел, әлбәттә. Малайлар-кызлар — шактый буласыз. Нәрсә ул кадәр шаккаттың? Хәлгә төшенергә вакыт инде. Кеше җитешми бит, күреп торасың!..

Әйтте дә, нигәдер миннән күзләрен яшереп, борылып китте. Ә мин авызымны ачып карап калдым.

Кондыз җиңгәм иртә таңнан килеп җиткән. Үзе дә атка атланган, бер атны җитәкләп тә алган. Нишлим, киттем аның белән...

Кондыз җиңгәм нинди зирәк җан иде, мескенкәй. Аның яшьли үлгәненә әлегәчә бәгырем көя. Унҗидедә булган икән, уйлап карасам. Алты ай гына элек туен уздырган идек. Туйдан соң нибары өч көн кияү куенында ятып калды; абыйны фронтка озаттык. Уйнап уенга туймаган, көлеп көлкесе бетмәгән... Ах, бичара җиңгәм! Һәрвакыт уйчан, моңсу

[1] Дубал — дувал, балчык яки кирпечтән ясалган койма.
[2] Арык — канау, арык.

төшеп, миңа үземнең яшьтәш кызларымча мөгамәлә кылып, уйнап, шаярып китә иде. Я булмаса, мине дә кешегә санап, минем өчен әллә ни төшенеп булмаган мәгънәле сүзләр дә әйтеп куйгалый иде.

Атлар арыгач, аларны туктатып, сукаланмаган җирдән мәк чәчәкләре яки башка гөл-үләннәре өзгәләп, үзенчә хыялга бирелеп, кайчак авыз эченнән көйли-көйли күзе күргән якка атлап китәр иде дә, аннары минем онытылып еракта-еракта калганымны искәреп, атларыбызның бик өркәк булуларын, ташлап китәргә ярамаганын белсә дә, тиз генә үз янына чакырып алыр иде. Мин килеп җиту белән: «Каенем, әйдә, атларыбызга чаклы йөгерешәбез»,— ди иде. Яки башка берәр кызык уен табып күңелемне күтәрә иде. Кайчак ат өстендә сөйләшми генә, уйчан гына, хәтта борчулы гына килә-килә дә, кинәт: «Каенем, ялыккансыздыр? Әйдә, чабышабызмы?» — дип, атын чаптырып китәр иде.

Бу юлы без атларыбызны үзебезнең өрек бакчасына утлауга куйдык. Бакча зур, куе. Өрекләрнең шау чәчәктә чагы. Күк ап-ачык, айлы. Борынга яшь үлән һәм өрек чәчкәсенең исе бәрелә. Бакча ниндидер серле булып, язгы тынычлыкта изрәп утыра.

Без көндәгечә атларыбыз янында кунар өчен урын-җир ала килгәнбез.

Җиңгәм түшәкләребезне җәйде, икебез дә чишенмичә генә сузылып яттык. Бер-беребезгә сүз катмыйча, хыялга чумдык. Шулай озак яттык. Бервакыт җиңгәм:

— Каенем? Әй, каенем,— диде.

— Ә?

— Әйдә, качыш уйныйбызмы?

Күптән уйнамаганлыктан, качышны сагынган идем. Куанып сикереп тордым. Озак уйнадык без. Икебезгә дә бик күңелле булды. Ләкин, берьюлы мин яшеренгәч, җиңгәм нигәдер эзләмәде. Көтәм юк, көтәм юк. Арыган булса кирәк дип, качкан җиремнән чыктым да, агачтан-агачка яшеренеп, бакчаның аргы башына, алдан сөйләшенеп куелган юан өрек агачы янына киттем. Якынлаша төшкәч, агачка сөялгән ниндидер ак нәрсә күрдем. Башта мин моны өрек куагының җиргә иелеп төшкән чәчәкле ботагымы дип тә уйлаган идем. Яхшылап карасам, җиңгәм икән. Ерактан урап килдем дә, «ть-фу-ү!» дип кычкырып, агачка төкереп куйдым. Аннан җиңгәмнең алдына чыгып: «Әй, җиңгәй, тоттыгызмы, я? Тоттыгызмы, я?» — дип, аны үрти башладым. Ләкин җиңгәм эндәшмәде дә, кыймылдап та карамады. Якынрак килсәм, аның ай яктырткан ап-ак йөзе буйлап яшь ага иде. Мин, ни кыларымны белми, аптырап калдым. Җиңгәм дә, шул килештән, өрекнең чәчәкле ботаклары арасыннан йөзеп барган айга карап, тилмереп тора бирде. Аның ике күзеннән — төбе караңгы куш чишмәдән — топ-тонык сулар мөлдерәп чыгып, ике елгачык сыман, түбән таба акты да акты. Бу суларда өрекнең чәчәкле ботаклары, бер өзем ак болыт, йөзеп барган ай, сөттәй ак, салкын күк чагыла кебек иде...

Бераздан җиңгәм мине әкрен генә кулымнан алды да түшәкләребез янына җитәкләп китте.

Без килеп яттык, ләкин йоклый алмадык. Һәркайсыбыз үзебезнең яшерен дөньябызга чумды. Мин, өрекнең чуар ботаклары арасыннан күккә карап, якын җирдә утлап йөргән тышаулы атларыбызның дук-дук сикергәннәрен, шырт-шырт итеп чирәм йолыкканнарын, вакыт-вакыт пошкырып куюларын, кайсыдыр бер өрек куагында сайраган былбылның яз башындагы дәртле җырын тыңлап яттым. Ике кулын баш астына салып, минем кебек үк күккә карап яткан җиңгәм исә вакыт-вакыт авыр гына көрсенеп куя иде.

Минә бакчаның бер почмагында сөтак сайрый башлады. Шуннан бераз үткәч, җиңгәм миңа:

— Нәрсә, җиңги?

— Беләсезме, каенем, сөтак бер заман пәйгамбәребезнең килене булган, имеш. Аннары, каргыш тиеп, шушы кошка әйләнгән, ди.

Мин моны дәү әниемнән ишетеп беләм. Сөтак төн буе: «Сөт, ак?! Сөт, ак?!» — дип чыга икән, ләкин сөт акмый, таң алдыннан гына аның кипшенеп беткән томшыгына күктән бер тамчы сөт тама, имеш. Бусын да ишеткәнем бар.

«Бу пәйгамбәрләре бик бай кеше булса кирәк,— дип уйладым мин шунда, җиңгәмнең янында ятып,— минемчә, киленен төшергәндә зур туй биргәндер. Уен-көлкесе белән... Ә шулай да җиңгәм белән Якуб абыемның туйларына җитә алмагандыр әле. И-и, аларның туе! Андагы уен-көлке, ай-һай! Егетләр көрәше... кыз-киленнәрнең таган атынулары... Ай нурында, кар өстендә яулык ташлау, ак чүлмәк уеннары... Килен төшкәндәге күңелле ыгы-зыгы... Килен каршылау... Чаршау артында җиңгәмнең мең дә беренче кабат йөгенүе, һәр йөгенгән саен, алкаларының айга чагылышып, кошка тагылган кыңгырау сыман, нәзек чыңылдаулары...»

— Каенем? — диде җиңгәм.— Әй, каенем! Йокламыйсызмы әле?

— Юк.

— Минемчә, быел фронт, сүзсез, туктый. Туктамаса да, барыбер Якуб кайта. Мин әйтте диярсез. Кайта. Җиңгәм әйткән иде менә диярсез. Бер җиреннән җиңел-җилпе генә яралана да, кайта да килә.

Мин эндәшмәдем. Шуннан соң йоклап та киткәнмен.

Иртәгесе көнне, гадәттәгечә, таң атканда тордык. Төнге чыктан авыраеп калган түшәкләребезне кагып-селкеп, утлап еракка киткән атларыбызны тотып, сугарып, аннан өйләребезгә барып, кичке азыгыбызны алып, эшкә киттек. Эшләгән җиребезгә килеп, күп юанмыйча, атларны сабанга җиктек. Ә дигәнче ике буй җирне сөреп тә ташладык. Менә шул сәгать, шул минутта әлеге каһәр суккан бәхетсезлек чыгып куймасынмы...

Тургай күктә күтмәгәндә пәйда булды. Нәкъ безнең баш очыбызда. Кайчан ул шунда күтәрелеп өлгергәнен мин, гадәттәгечә, тагын күрми калдым. Ул җырлап күтәрелде һәм озак-озак сайрады. Һай, ничек бирелеп тыңлый идем мин үземнең әле гөнаһсыз, югалтуның ни икәнен белмәгән чагымда — бу бәләкәй генә соры кошның иске хәмер исе аңкып торган борынгы шәрык шигырьләредәй ләззәтле җырын.

Кизәк җыеп далада йөргәндәме, гөмбәгә дип тау итәгенә баргандамы, сыер көтеп чишмә буенда яткандамы — кай җирдә генә ишетеп алмыйм мин бу тургай тавышын, көндез йолдыз эзләгәндәй, аны ерак күктән эзләргә тотына идем. Ләкин, көндез йолдызны күрү никадәр кыен булса, биектә сайраган тургайны күрү дә минем өчен шулай ук кыен була иде.

Күпме җентекләп карама, һаман шул: иртәнге язгы күк... сүнеп барган соңгы йолдыз... батырга өлгерми калган ай... айга каршы йөзгән, дөя баласына охшашлы ак болыт... Ә тургай күренми. Сайрап тора, ләкин күренми. Дөньямны онытып, тилмереп күккә карап, күпме вакыт үткәнен дә белмим, кинәт бер атыбыз тибенеп аягымның тиресен сыдырды. Үземне екты да алга китте. Шунда ук исемне җыеп, тезгеннәргә ябыштым һәм атларны туктаттым. Җиңгәм йөгереп килде. Ул минем канаган аягыма, гаепле сыман, аңар төбәлгән күзләремә эндәшми карап торды да, үзе дә минем яныма утырып, үксеп еларга тотынды.

Мин бусына төшенә алмыйча аптырап карап калдым. Ул күпмедер шулай елады. Аннан, басылып, башын күтәрде.

— Аны күрә алмыйсыз сез,— диде ул, югары якка ишарә ясап, һәм, нигәдер, елмаерга тырышып:

— Аның бар булганы — җыр. Җырын тыңласагыз, шул җиткән. Ә беләсезме, нәрсәләр турында җырлый ул?

— Юк,— дидем, кызыксынып.

зәңгәр күк, йөгерек болытлар, көндезге ай, кояш нурлары, сукаланган далалар, каберлектә йомырка өстендә утыручы икенче бер тургай турында жырлый ул.

Шул чак якында гына «папыр-пыр» иткән тавыш ишетелде. Әйләнеп карасак, атлар артыннан ниндидер бер ак кош очып чыкты. Атлар өркеп чаптырып киттеләр. Мин чак-чак артка чигенеп өлгердем. Жиңгәм, ике атның уртасында калып, ыргып торды да бар көченә аларның тезгеннәренә асылынды. Ләкин туктата алмады, атлар аны өстерәп киттеләр. Бераздан жиңгәм егылды, кулларын тезгеннәрдән чыгара алмаган, күрәсең, жирдә сөйрәлеп бара бирде. Менә атлар якындагы текә ярлы тирән чокырга барып житте. Мин ачы кычкырып жибәрдем дә кулларым белән битемне капладым. Куркуымнан онытылып китеп, бераздан күземне ачсам, жир сөреп йөргән хатыннар һәм бала-чага барысы да дәррәү чокырга таба йөгерешәләр иде.

Жиңгәм чокырның аръягына кадәр сөйрәлеп барып, шунда егылып калган икән. Атлар юк. Кешеләр жиңгәмне уратып алганнар. Мине якын жибәрмәделәр. «Сиңа ни калган монда? Бар әнә, атларыңны эзлә!» — диде берәү. Инде китеп барганда, бер хатынның: «Мие аккан»,— дигәнен генә ишетеп калдым.

Иртәгесен Кондыз жиңгәмне жирләдек. Мин башка бер хатын белән эшли башладым.

Шул елның көзендә, бичара жиңгәм әйткәндәй, уң аягы яраланып, Якуб абыем сугыштан кайтып килде. Кайтты да, өендә бер көн ял итмичә (кайда анда ял итү) уракка чыкты. Аның уракка төшкән беренче көне хәзергәчә хәтеремдә. Төш вакыты иде. Эссе. Биек бодай арасыннан үткән тар сукмак буйлап уракчыларга чишмәдән су алып кайтам. Кинәт кемнеңдер якыннан гына:

— Әй, су бирче? — дигән тавышы ишетелде. Туктап, тирә-ягыма карандым. Бодай быел бик озын булып үскәнгә, кеше башы күренерлек түгел. Баскан жиремә чынлап торып күз салсам, Кондыз жиңгәм белән соңгы тапкыр сукалаган жиребез икән. Бу жиргә әле уракчылар төшкәне юк иде. Шуңа күрә, мине кем чакырды икән дип аптырап торганда, баягы тавыш яңадан:— Әй, алып киләсеңме инде? — дип кабатлады. Мин, юлдан чыгып, куе бодай арасыннан тавыш килгән якка киттем. Якуб абыем бугай, дип уйлап куйдым. Чынлап та, ул икән. Иске галифедән, төсе уңган ертык майка, башында сугышка кадәр үзе киеп йөргән иске калпагы. Маңгае, муены, йон баскан култык аслары манма су. Күрәм, шактый гына жирне урып ташлаган.

— Үзем чакырмасам, исеңдә дә юк,— диде ул, көлемсерәп.

Чиләкне миннән ике куллап алды да, тураеп баскан килеш, су өстендә йөзеп йөргән чүп-чарны, чикерткә тәпиләрен авызы белән өреп, чиләкнең аргы читенә куа башлады. Мин, аның бу жиргә нинди уй белән килгәнен төшенеп бетә алмый, сиздерми генә тирә-якны караштырам, теге, атлар өреккән жирне эзлим. Чамалый торгач, таптым бит шулай да. Нәкъ без басып торган жир икән. Якуб абыема күз салдым. Ә ул, авызына якын китергән суны эчмичә, чиләк читеннән яшерен генә миңа карап тора икән. Мин сискәнеп киттем.

— Шул жирме? — диде Якуб абый карлыгып һәм без торган жиргә ымлап күрсәтте.

Мин каушап, озак кына аңа карап тордым да, ниһаять, акрын гына башымны кактым.

Якуб абыемның кулындагы чиләге әкренләп түбән таба төшә башлады. Күкрәгенә кадәр житкәч, ычкынып китте дә, суы түгелеп, жирдә тәгәрәп калды.

Миң, абыемның хәлсез салынып төшкән кулларын, күгәргән иреннә-

рылдым.

Якуб абыем җиргә утырды, башын тезенә салып, үксеп-үксеп еларга тотынды. Мин аның, кичә хатыны турында әйткәндә еламыйча, бүген елап ятканына таң калып, карап тордым. Ул озак елады, аннан тынды.

Шул чак безнең яндагы куе куак астыннан «пырр» итеп тургай очып чыкты. Якуб абыем миңа ялт итеп карап алды да урыныннан сикереп торды. Без куак янына бардык. Килсәк, кечкенә генә ояда кысылышып, канат катыра башлаган өч кошчык ята. Абыем, алар янына чүгәләп, кулын сузган иде, кошчыклар авызларын ачып җим көттеләр.

Кинәт шул вакытта баш очыбызда, зымыраган биеклектә тургай сайрап җибәрде. Ул һаман шул, бөтен нечкәлекләренә кадәр күңелгә сеңеп калган, ниндидер бер тылсымлы көче йөрәкне бульк-бульк иттерә торган көйләрен сыздыра башлады...

Якуб абыем акрын гына урыныннан торды, уң кулын маңгаена куеп, күктән тургайны эзләргә керешә. Ул шулай озак басып торды.

— Эх! — диде ул, ахырда авыр сулап, һәм миңа борылды,— үлгәннәр нинди бәхетсезләр бит.

Мин, бу юлы аның йөзендә борчылу урынына ниндидер дулкынлану күреп, куанып киттем.

Шуннан соң гына буш чиләгемне чыңлатып, авыр бодай башларының биткә чапкалаганнарына да игътибар итмичә, күкрәгемне кыса башлаган шатлык хисенә бирелеп, чишмәгә киттем.

Ә тургай әле һаман сайрый иде.

## Кенеш Җусупов

# ИСКЕ РӘИС



Самый райком бюросыннан күз бәйләнгәндә чыкты. Авылныкылар шау-гөр килеп, бер-беренә эндәшә-эндәшә, төрлесе төрле якка таралыша башладылар.

Самый, тирләгән чигәсен сөртеп, тәмәке кабызды. Машина шундадыр дип чамалап, урам почмагындагы чинарга таба китте һәм, бер карачкыга юлыгып, туктап калды. Кем соң син дигәндәй, сузылып карады.

— Асакеме? — диде Самый, икеләнеп кенә.

— Мин...— Карачкы ишетелер-ишетелмәс мыгырдап куйды.— Самыймы син?..

Самый, каушап, ни әйтергә белми торды.

— Китеп барабыз... Ә сез, Асаке?.. Кайтмыйсызмыни?

— Кайтыр идем дә... Машина күренми әле...

— Өйгәдер бит?

— Өйгә.

— Алайса киттек, Асаке!.. Минем машинада...

Алар тирәккә якынлашканда, машинага җан кереп, дерелди үк башлады.

— Кемел, кузгалдык, батыр, әйдә!..

Машина үз яктысы белән җирне, өй һәм бакча буйларын ялап китеп, кеше төркемнәрен ярып үтеп, арты кызарып, зуылдап, караңгыны сыдырып бара бирде. Тәрәзәләргә анда-санда очып йөргән бөҗәкләр тиеп-тиеп китәләр иде.

төгәнә,— дип өтәләнде Самый.— Асанбекне кем төшертте икән? Һәрвакыт, бер дә тартынмыйча, район башлыкларын тәртеп-чәнчеп сөйләп йөдәтә иде шул...
— Төшеп алдыгызмы, Асаке?
— Шулай итмичә булмады...
Самый моны үз күзе белән күреп утырды. Райком секретаре «Очкын» колхозы рәисе Арпачиев Асанбектан сәламәтлеге какшау сәбәпле хезмәттән бушатуны сорап гариза килгәнен игълан итте. «Төшсенме?» «Төшсен!» «Каршы юкмы?» «Юк!» Барысы бер минутта хәл ителде.
— Торган саен кыйнала барам. Эш дип йөреп, озакка сузылды бу чире дә.
— Дәваланырга кирәк...
— Шулай итмичә булмас...
Әле бала вакытында ук Самый Асанбекны рәис дип ишетеп белә иде. Институтны бетергәч, ул «Ялгыз чишмә» колхозында өч ел агроном булып эшләде, аннан үзе дә шул ук колхозда рәислеккә күтәрелде. Күрше колхоз булгач, Асанбек белән танышып, сез-без дип йөрешә башладылар.
«Машинасына ни булган,— дип уйлап алды Самый,— ничек инде бүген билгеләнгән рәис шундук машинасын тартып алып, җәяү ташлап китсен, ди?..»
Машина шәһәрдән алып чыга торган урам башына житте.
— И-и, Кемел, без бер нәрсәне оныткабыз бит, батыр. Көнозын тамак ялгаганыбыз юк. Әле кайчан кайтып житәбез. Житкәч тә төн уртасында табак-савыт шалтыраттырабызмы, я инде? Әйдә, бор машинаны, тамак ялгап алыйк!.. Сез ни дисез, Асаке?!
Асанбек дәшмәде.
— Кая барабыз?.. Рестораннан башка ачык жир юк.
— Алайса, шунда киттек...
Ресторан дигәннәре шәһәр читенә, иске МТС курасы урынына салынган. Кайчан гына килмә, халык шыгрым тулы, пиво кайтканда, чиләкләп ташыганы күп булса, утырырга урын тапмаганы аннан да күбрәк. Районга килгән колхозчылар шул ачыны ит пешәрлек вакыт кәтеп алжыгач, «Әй, туйдым ла», дип китеп баралар иде.
Кемел, ресторанга башын тыгып:
— Пиво бар икән,— диде.
Асанбек кием алып торучы яшь егеткә акаеп, өнәмичә карады. Моны Самый шәйләп калды.
— Исле май сибеп куям әкаләргә,— диде кием әлүче егет, теленә салынып,— сараплапмагыз, рәис әкаләр... Яшь кызлар исле май исенә ияреп килсеннәр дисәгез...— Ул хахылдап көлеп куйды.
— Моның уена хатын-кыздан башка берни керми...— дип мыгырданды Асанбек.— Әйтче, кайчан авылга кайтасың?
— Кайтып ни файда...— диде кием әлүче.
— Эх, жир упкыры...— Асанбек аңар арты белән борылды.
— Рәис әкәләр, исле май...
«Бу ипкә килмәс нәрсә минем рәис икәнемне кайдан ишеткән?» — дип уйлады Самый.
Ресторанда кеше күп. Аш ташучы хатыннар, кабаланып, поднос тотырып бутылкалар күтәреп, аяклары жиргә тими йөгерешәләр. Булмәне төтен баскан. Тавыш. Чыр-чу. Ишек бер туктамый ачылып-ябылып, халык өзлексез йөреп тора.
— Теге почмак бушады,— диде Кемел һәм ашыгып шул якка атлады.
— Булды алайса.
Аш китерер кеше юк; тирә-яктагыларга күз йөртеп, эндәшми утыра бирделәр.

дәй, һәркемгә сөзеп каравында булды.
— Син нәрсә, автоинспектор булмагае, дип, куркып утырасыңмы әллә? — диде Самый, көлеп.— Нәрсә ашыйбыз?
— Шул шәһәр ашына һич күнегә алмыйм, күпме ашасам да, йөрәгемә ятмый.— Кемел бил каешын төзәткәләп куйды.
— Я, Асаке, нишлибез, бераз салабызмы?
— Сез эчсәгез эчегез. Мин аны ун ел инде авызыма алганым юк.
— Кемел, син шәп егет идең бит, чакырып кил әле теге кызны.
— Әй, була ул! — Кемел мутланып торып китте.
— Шоферың уңган егет күренә.— Асанбекның баядан бирле әйткән сүзе шул булды.
— Әйбәт егет, күңелендә кер сакламый бичара.
— Шулай булсын. Теге кием элеп кукрайган хәсрәтне күрдең бит әле. Безнең авылдан. Моннан ике ел элек печән чабарга чык дидек — киреләнеп, тыңламаган иде. Сүгеп ташладым үзен, үпкәләп шәһәргә китте. Тапкан, ирешкән хезмәте шул икән. Үзенә дә әйттем, шәһәргә хат та язып карадык, ләкин мәңгә китерә алмадык. Аның өчен кеше ояла, карачы... тап-таза егет... тьфү! Миңа оят... Менә... бу яманатны кая куясың!.. Синнән начар рәис юк шундыйлар аркасында...
Ул арада Кемел яшь киленне ияртеп килеп тә җитте.
— Яхшы ашың булса, китер, кызым.
— Бездә начары булмый.
«Мәнсез,— дип уйлады Самый, бу ачулы симез киленгә чәнчеп карап,— миңа әйтсә инде бер хәер, ә бит Асанбек илледән узган кеше!»
Килен, язасын язып, китеп барды. Аның артыннан беренче булып Кемел сүз башлады:
— Шәһәр халкының иманы качкан...
— Кышлакларда да киленнәр кимен куймыйлар...
— Алар олылардан оялуны белә, ичмаса. Бу исәрләр, колхозга барып, безнең хатыннар белән беррәттән эшләп карасыннар иде, кершән-иннек турында уйлау түгел, борыннарын тартырга да вакытлары калмаячак.
— Нигә бу кадәр бәйләнәсең шәһәр халкына, Кемел, ә? Бу ачуның сәбәбе бардыр бит, без дә белик,— диде Самый.
— Артык һавалылар.— Кемел тәмәке кабызды.— Шәһәрдә минем агам бар бит әле. Гәзиттә эшлим, ди... Белмим, нишли торгандыр анда... Барып чыгам кайчак үзенә... Аны-моны алып барам... Шуңа күнелләре була. Өйләрендә тап-такыр, елан ялап киткән диярсең... Ә киенүләрен күрсәң... кылаными инде. Кайчак, эчеп алгач, телемне тыя алмый әйтеп җибәрәм. «Авылга кайтмыйсызмы?» — дим. «Иялэштек бит инде»,— диләр. Менә шәһәрнекеләр нинди.
Килен өстәл өстен тутыра башлады.
— Әйдә, капкалап алыйк.
Кемел сөйләвеннән туктады, барысы да ашларына иелделәр.
— Бусын эчеп куйдым, алайса... Колакларыгызны кызартыйм әле бер...— Самый аракыны эчеп җибәрде.
Стаканын өстәлгә куеп өлгермәде:
— Әссәламәгаләйкем,— диде берәү.
— Кил, түрә, ләкин яманлап йөрмә, яме?
— Курыкма, рәис әкә.
Исәнләшкәч, кысылыбрак, аңар урын бирделәр. Җәйләүбаев дигәннәре шул иде инде. Үзе кызмача. Кемелгә ул яхшы таныш. Көгарт белән Долон арасында моның кебек бәйләнчекне табуы кыен. Автоинспектор... Шоферлар аның исемен генә ишеткәндә дә калтырана башлыйлар, мескенкәйләр. Юан, йомры кеше. Иң элек ул гадәтенчә Кемелгә бәйләнә башлады.
— Ресторан алдына куярга сиңа кем хокук биргән, түрәм, ә? — Җәй-

ләубаев Кемелгә жикеренде дә Самыйга тиешлесен уенга борды:— Рәис машинасы булгач, узынып түргә чыгып киткән икән, ә?

— Куркытмый гына утыр әле. Иптәш бул... Башкасы пустяк аның...— Самый аңар аракы салды.

Жәйләүбаев күнозын юл сагалап, баганадай катып тора. Ары-бире үтеп йөргән машиналардан гаеп табып йөдәтә. Машинаның әле бер ягына, әле икенче ягына чыгып, берәр сылтау табып, шоферны өркетә дә, мая жыйный. Ерактан килүче шоферлар аның турында сорашканда: «Жәйләүбаевыгыз исәнме әле?» — диләр.

Шуны исенә төшереп, Самый пырх итеп көлеп куйды.

— Асанбек аксакал, эшләр шәптәнме? — Жәйләүбаевның мыскыллап көлгәне сизелеп торды.

— Яхшы, рәхмәт.— Асанбек башка сүз катмады.

— Мин барысын да ишеттем.— Жәйләүбаев Асанбекка күз кырые белән генә карап куйды.— Моннан бер ай элек ишеткән идем инде.

— Нәрсәне,— диде Самый, сүзгә төшенмичә.— Ни ишеттең син?

— Асанбек аксакалның рәислектән төшәргә йөрүен.

«Менә бит... хәерсезне»,— диде Самый эченнән. Ул уңайсызланып башын иде, капкан ашы тамагына тыгылып калды.

— Минем тәкъдиремә язылып куелган хезмәт түгел иң ул,— диде баядан бирле кашын жыерып утырган Асанбек,— бүген мин төшсәм, иртәгә син буласың, иртәгә син төшсәң, анда тагын берәү була...

— Ай-яй... гомер буе рәис булып эшләрдәй ак нният кеше идегез.

— Сиңа бу хәтле нинди яманлыгым тиде әле? — диде Асанбек.

— Былтыр язын сарык бәрәне сорадым, көзен такта сорадым. Күңелемне калдырдыгыз.

— Менә шулай болар. Колхоз милкен үзләренекедәй күрәләр...

— Нигә аны рәис чагында әйтмәдең? — диде Самый, тегенең сүзенә ачуы килеп.— Шулчак әйткән булсаңчы?

— Әйтергә җаен көтеп йөрдем дә инде... Менә миңа да чират житте... Үлмәгән кешегә чират житә икән.

— Үчеңне алгансың, алайса? — Асанбек аңар көлеп карап куйды.

— Алмый ни...

Самый эндәшми утырды, Кемел дә авызын ачмады. Жәйләүбаев, Асанбекны үртәп, зәһәрле карашы белән аны чәнчеп-чәнчеп ала иде. Ә Асанбек үз калыбында, бер нәрсә белмәгән-күрмәгән сыман, жигүле аттай башын артка салып утыра бирде.

— Тор, Кемел, чакыр кызыңны, китәбез,— диде Самый. Һәм, янындагы Жәйләүбаевны күрәсе килмичә, ресторанда шау-гөр килеп утыручыларга карангалап алды.

Самый, табын әзерләгән киленгә аш хакын түләп, беренче булып кузгалды. Жәйләүбаев аларга ияреп бусагага кадәр килде дә, тагы кемдер чакыргач, аерылып калды.

Кием элә торган жирдәге әлеге бәндә яңадан исле маен күтәреп чыкты.

— Исле май сибик әле, әкәләр!

— Яман атың чыкканчы, авылга кайт! Жир казуның болай йөрүеннән нәрсәсе ким? Ата-ана каргышыннан курыксагыз иде, ичмасам!..— диде Асанбек.

Тегесе, аның сүзен колакка да элмичә, кемнәндер тамган чәйлекне исәпләп, елмаюын белде.

Асанбек аңа карап-карап торды да киемен алып чыгып китте. Тәмәке кабызып торган Самыйга да, Кемелгә дә күтәрелеп карамыйча, машинага барып утырды. Шәһәрдән чыкканчы беркем сүз дәшмәде, машина йөрешенә чайкалышып, оеп, машинадан төшкән ут яктысына карап бара бирделәр.

«Иртәгә эшемнән чыксам, мина да берәрсе шулай итәчәк...— Мондый

уйның Самыйга беренче кат килүе иде.— Әле кичә генә Асанбек Арпачиевтан яхшы рәис юк иде. Күп ел эшләгән, планнары һәрвакыт тулып килде... Бүген менә нәрсә диләр аңа! Көнләшә икән кеше дигәнең. Югыйсә, аның бәхетен тартып алганмы ул?»

Кемелгә хәтле, телен йоткандай, эндәшми бара. Аның алдында кызыл, яшел стрелкалар дерелди, Самыйга эссе булып китте, битләре кызыша башлады, эче пошты, кәефе кырылып, кемнедер ачы итеп сүгәсе килде, ә үзе, шуны ычкындырып җибәреп оятка калмыйм, дип тешен кысып утырды.

Бормалы юл үргә күтәрелә башлады, юл буендагы ак ташлар балыктай ялтырап күренәләр. Әле бер сәгатьлек юл бар. Юлдан берән-сәрән генә машиналар үтеп тора. «Халык ята башлагандыр инде»,— дип уйлады Самый. Нигәдер аның хәзер эчәсе килеп китте. ДЭУ[1] кибетеннән алырга булыр иде әле, өенә кертеп куеп, төнге юлаучыларга сата, имеш, дигәннәре колагына чалынганы бар. Ләкин Асанбек мондый хәлдә булганда ярамас, дип тыйды ул үзен.

— Сездә бер ни дә юкмыни соң? — дип кинәт сорап куйды Асанбек.

— Нәрсәне әйтәсең, Асаке?

— Әй, әлеге аракыны ла инде...

— Оho,— диде Кемел һәм үз сүзләренә үзе уңайсызланып китте.

— Кемел, таба алырсың бит, батыр, ә?..

— Тапмый ни!..

— Егет кешенең сүзеннән үк беленә... Кемел икәнеңне күрсәт, алайса.

Кемел ДЭУның ак өе янына машинасын туктатты да чыгып йөгерде.

Машина эчен тынлык басты. Һаулап эт өрергә тотынды. Кемелнең тәрәзә какканы ишетелеп торды. Таулар өстенә ай калка башлады. Чикерткә чыңы колакка керде. Таулар ай нурына төренеп, изрәп йоклыйлар иде.

Тау арасын тагын эт өрүе яңгыратып җибәрде. Кемел, кабаланып машинага керүе булды, моторын кабыза да башлады. Теге икәве, нәрсә әйтер дигәндәй, аңа карап, елмаеп утырдылар.

— Таптым. Рәхәтләнеп бирде. Бу кибетче дә Җәйләүбаев сыңары...

Көлеп җибәрделәр һәм шуннан соң күңелле гәпләшү башланды.

Тау сыртына җиткәч, Кемел машинаны туктатты.

— Моннан да әйбәт урын юк.

— Үзең җайла инде, Кемелбай... Менә бу җиргә утырып алыйк.

Йомшак җил биткә бәрә. Тарлавыкка алып төшкән кәкре-бөкре юл ай нурында агарып ята. Аргы биттәге чыршылар төн шәүләсендә тагын да сылурак булып күренәләр.

Шешәне җиргә куеп, тирә-якка сокланып карап тордылар. Читтә караеп машиналары тора. Баш өсләрендә күк тулы йолдыз җемелди. «Шуңа бәйләнеп, дөнья матурлыгын да күрми йөрибез бит, ә?!» — дип эченнән пошынып куйды Самый.

— Әйдәгез! — Асанбек, шап итеп, учын-учка чабып куйды.

— Монысын тау арасында миңгерәп йөрүебез өчен эчик...— Ул кулындагы стаканын күтәрде дә үлән йолкып алып иснәде.

— Алтын җир бит, әй!..— дип, Самый үләнгә сузылып ятты.

Ай нурына сихерләнеп, күзләрен киртләч-киртләч тау түбәләренә текәп, тынып калдылар.

— «Юлбарыс тиресе ябынган батыр»дагы өч дусның крепостька һөҗүм ясар алдыннан утыруларына охшап китте безнең бу утырышу,— дип, Асанбек көлеп җибәрде.

— Яле, Кемел, калганмы бераз төбендә? — Самый бутылкадагыны бүлеп салды. Асанбек белән икәү күтәрделәр.

Өсләрен кагынып, машинага кереп утырдылар. Кемел үрдән машинаны салмак кына алып төште. Машина далага кереп китте.

[1] ДЭУ — Дорожно-эксплуатационное управление.

— Берәр нәрсә сөйләгезче, Асаке!..

— Ни сөйлим... Эчем пошып килә әле...

— Нәрсәгә?

— Безнең яңа рәискә...

— Үпкәмне белдерсәм, кайсы бере Асанбек аннан үч ала, дияр. Кичә генә бала иде бит әле... Үз кулымда диярлек үсте. Атасы мәрхүм менә дигән кеше иде, сугыштан кайтмады. Ә инде улының мондый холкы... Бюро беткәч тә, машинага утырып, өенә очкан. Ярый инде миңа шулай, ә халыкка шул холкын күрсәтсә, унмас... Үзе болай өлгер, булдыклы егет, ләкин ха˘ык явызны, холыксызны яратмый... Анар намуслы да, кешелекле дә булсын. Кайчак шулай ялгышып китү гадәтебез бар... Райондагыларга ошап калгән имеш...— Асанбек тәмәке кабызды.— Әгәр без картларнын шундый тупас, әшәке эшкә кулыбыз барса, болар надан, иске кешеләр дисеннәр инде! Менә яшьләрнең шундый булуларына хәйран калам мин. Барган саен акыллырак булырга тиеш түгелләрме?.. Барган саен кешегә күбрәк яхшылык итәр өчен ашкынырга тиеш түгелләрмени! Түрәлек, дәүләт, карьерага нигә бу кадәр кызыгалар. Без яшь чагыбызда, комсомолга кереп, ачлы-туклы килеш, көне-төне кырда йөрдек. Баш булыйм, карьера ясыйм дигән ник бер уебыз булсачы. Бу илгә кирәк, моны партия кушты, дисәләр, җаныбызны биреп, эшне бетергәнче чаба идек, кире сөйләп, кире эшләгәнне күргәнем булмады... Бары тик үз башыбызны, үз файдабызны гына кайгырткан булсак, шул чакта баеп, теләгәнне булдырып калмас идекмени? «Куй, алай итмә», дип тыючы аз булды. Нәфесе бозык кулаклар бар иде, аларга күрмәгәннәрен күрсәтте халык... Ә менә хәзер, шулай ашып-ташып торган иркенлектә үз жаны хакында гына уйлаганнарны күп күрәм...

— Андыйлар бар...— диде Самый, баш кагып.

— Элек без мондый идек, тегенди идек, дия башласак, кайберәүләр мактанмагыз, дип, безне яңа чорны бәяли белмәүдә гаепли башлыйлар. Нигә алай итәргә инде! Нигә начар ягыбызны гына күреп, яхшыны күрмәскә. Хәзергеләр шул хакта ныклап уйлашсалар тагын да зирәгрәк, әйбәтрәк булмаслар идемени?!.

Самый башын түбән иде. «Бер кечкенә йомрыдан ачылып китте. Эчендә тары бөртеге хәтле дә кер сакламый торган әйбәт кеше икән», дип уйлады ул Асанбек турында.

— Инде, шуны кара, сугыш вакытында ничек эшләдек: көне-төне кырда. Төнлә дә җан тынмый иде бит... Алда берәү фонарь күтәреп йөри, калганнарыбыз шуның яктысында иген урабыз, бала-чага, карт-корыга чаклы... Менә шундый көннәр булды. Әлеге язучы дигәннәрең, аны-моны күрмичә, ясалма нәрсәләр язып йөриләр!.. Чынлыкны язсалар, елатырлык китап чыкмас дип уйлыйлармы?.. Балаларыма тегенди идек, мондый идек, дисәм, һич ышанмыйлар. Башкаларны әйтмим дә инде, үз балаларым ышанмый. Аларның бар мактанганы шул — синдә белем юк, диләр. «Синдә белем юк!» Ярый, миндә белем булмасын ди!.. Миндә тормыш тәҗрибә бар түгелме? Минем кулым белән колхоз төзелде, беренче өйне салучы мин!.. Кулак дигәнне бетермәдемме?!. Басмачы дигәнне тар-мар итмәдемме?!. Боомга [1] тимер юл салып килмәдемме?!. Ә немецне?!. Без булмасак, нәрсә булыр иде?.. Ничә җирдән яраландык. Эшемнән бушанып йөрүем дә шунын шаукымы бит... Әгәр ике авыз сүз әйтеп кәгазь язсам, пенсия дигәнен бирәчәкләр... Язмадым, анысын берәр мыжыкка бирсеннәр, кирәге юк миңа... Гомеремдә берәүгә яманлык эшләмәдем, шуңа разыймын. Берәүләргә телем тигәндер, берәүләр миңа яман сүз әйткәннәрдер, аларның барысын истә тотып, үч саклап йөриммени? Җәмәгать эше — төрле чагы булгандыр!..

«Менә сиңа аз сүзле кеше,— дип, тагын гаҗәпләнеп уйлап куйды

[1] Боом тарлавыгы — Ысык күлгә чыга торган тау тарлавыгы.

Самый.— Кайчак шулай эчендә җыелганны берәүгә сөйлисең килеп китә. Андый чакта кешесе дә табылмый әле аның...»

— Без чабабыз, аһ-ваһ итәбез, ә тормыш үтә бирә, ил-халык кала бирә...

«Эт баласы,— диде Самый эченнән, әлеге «Очкын» колхозының яңа рәисенә саруы кайнап.— алып китсә ни булган инде... Ахмаклык бит... Асанбекның да болай кәефе кырылмас иде...»

— Үкенгәндә дә, хәзергеләр кебек муллыкны күрмәдек, иркенчелектә рәхәтләнеп яшь алмадык, дип үкенмим мин. Алар безнең хезмәтебезне юкка чыгармасыннар, дәвам итсеннәр иде. Җан әрнеткеч булмасыннар. Байлык, карьера, ач күзлелек — нәфескә табынмасыннар... Дөнья бу, Самыйбай, төрлесе була... Бүген бар, иртәгә юк... Кешелегеңнән, саф күңелеңнән генә язма...

Машина зур юлдан борылып, «Очкын» колхозы буйлап килде дә, көньяктагы бакчалы өй янына туктады.

— Килеп җиттек,— диде Кемел.

Самый каерылып карады, ләкин урыныннан кузгалмады. Машинадан төшеп өлгергән Асанбек кычкырыбрак:

— Әй, Самый, төш әйдә, керик! — диде.

— Җиде төн уртасы бит, Асаке, өйдәгеләрне мазалап йөрмик инде...

— Ярамый алай, төш!.. Олы кеше әйткәч... Әйдә!..

Самый төште. Асанбек, ишекне кагып, кычкырды:

— Җәмилә, ач ишекне... Ачасынмы инде, әй!..

Ишек ачылды.

— Узыгыз! — диде Асанбек, кулы белән ымлап.— әйдәгез, дуслар, әйдәгез, алга!.. Бер заман шулай дип җырлый идек бит. Әйдәгез алга. Курыкмагыз, берни юк... Җәмилә, мин бүген кызмача, байбичә!..

— Рәхәтләнгәнсең икән! — диде хатын-кыз тавышы.

— Берәр нәрсә булса, алып чык кунакларга!..

— Нәрсә алып чыгыйм тагын...— Тур өйдән симез хатын җенләнеп чыкты. Асанбекның кыяфәтен күреп кабарынып китте.— Ун ел эчми йөреп, бүген хурлыгыннан эчтеңмени, ә?!.

Асанбек ни әйтергә белми аптырап калды. Самый, җир тишегенә керердәй булып, «ни пычагыма кердек әле без монда», дип, үз-үзен сүгеп куйды. Кемел, хатыннан күзен ала алмыйча, шаккатып тора иде.

Асанбек, хатынына бер генә акаеп карады да, аш бүлмәсеннән шешә алып чыгып, кунакларның алдына китереп бастырды. Хатыны, үзалдына мыгырданып, җилләнеп борылды, ишекне шап итеп ябып чыгып китте, теге яктан аның һаман әле чәпчеп сөйләнгәне ишетелеп торды.

Бераздан Самый:

— Кайтыйк инде, Асаке, рөхсәт итегез,— диде.

— Ярый алайса, ихтыярыгыз,— дип, бераз карлыккан тавыш белән җавап кайтарды Асанбек.

«Хатыны бөтен куанычын җимереп ташлады»,— диде Самый үз-үзенә.— Бер сүз, бер генә елмаю, бер генә караш кешене күккә кадәр күтәреп җибәрә яки бәреп ега... Хатыннарыбыз да аңламагач, кем аңлар безне...»

— Алама хатын икән... Шундый әйбәт кешегә бер каһәр сукканын боера да инде,— диде Кемел, юлга чыккач.

Колхозга кайтып җиткәнче башка сөйләшмәделәр.

Урамның аргы башына җиткәч, Самый машинаны туктаттырды.

— Калганын җәяү кайтам, син китә бир! — Ул, ишекне ачып, машинадан төште. Бүген иртә белән «докторга барыр идем», дип машина сораган карт исенә төште.— Иртәгә теге картны докторга алып бар да кире алып кайтырсың...

«Кеше күңелен калдырмасам иде...» — дип уйлады Самый һәм өенә таба китте.

Кыргызчадан ҺАВА ХӨСӘЕНОВА
тәрҗемәләре

## Эдуард Мостафин

### Югалган углан монологы

Каршы алыгыз, дип хәбәр итмим.
Мин җил булып киләм ишеккә.
Төн уртасы. Әни ишек ача
Минем тавышымны ишетсә.

Самоварын куя. Урын җәя
Һәм сораша дөнья хәлләрен:
«Бик сагындым, улым.
Күп көттерден.
Озак килми торды хәбәрен».

Дивардагы рәсемемә кунган
Тузаннарны сөртеп төшерә,
Чәе бетсә, төн уртасы дими,
Шундук кереп китә күршегә.

Таң атарга, әни, күп калмады,
Йокларга да бәлки вакыттыр.
Арыгансындыр, көтү чыкканчы
Инде бераз гына ятып тор.

Ничәнче ел шулай тик җил генә
Улың булып килә ишеккә.
Җил алдалый сине, үтенәм, әни,
Колак салма, тавышын ишетмә.

Минем өчен диеп ясап куйган
Чәең инде күптән суынган.
Кара рамнан сейгән улың карый,
Улың карый сугыш кырыннан.

Язмыш белән без бәхәстә мәңге,
Язмыш белән мәңге алышта.
«Язмышыңнан өстен булыйм,
дисәң,
Чигенмәскә өйрән карыш та».
Шулай куша тормыш, безне үзе
Салларына салып агыза,
Йөрәгенә нәфрәт уты ташлый,
Я мәхәббәт нуры кабыза.
Нәфрәт йотып без сөяргә тиеш,
Күз яшьләре аша көләргә,
Тез чүкмичә дошман каршысында
Намус куша көлеп үләргә.
Пропискабыз вакытлыча җирдә,
Ә чиратта яңа токымнар.
Кеше! Язмыш белән син бәхәстә,
Үзең бар дөньяга хөкемдар.

●

Сулар ага да ага.
Агачтан оча яфрак,
Керфектән тамчы тама,
Атадан кала бала.
Сулар ага да ага.

Җилләр исә дә исә.
Агачта яфрак шаулый,
Керфеккә кояш төшә,
Тәгәрәп уллар үсә.
Җилләр исә дә исә.

●

Мин ант иттем сиңа кайтмаска, дип.
Качкан йөрәк, әйдә, еласын.
Туң ярларга бәреп дулкын тынды,
Кошлар китте ташлап оясын.

Таш өстендә соңгы чәчәк шиңде,
Яфрак очты соңгы хат булып.
Күңелемә беренче кар төште
Сүнгән йолдыз кебек атылып.

Сагындым мин яфрак яшелләгән,
Төшкә кереп кошлар кагынды,
Бик тыңлыйсым килде дулкын шавын,
Тере чәчәкләргә табындым.

Хыянәт иттем, боздым антымны.
Сагынуым күзгә тамчы булып
Керфекләргә тамып талпынды.

Килгән якка горур башны идем —
Күзгә сулар юмаган эзне.
Ялындылар җирдә яфракларым:
«И агачым, кире ал безне!»

●

Юеш канатларын кагып
Кая очып бара казлар.
Каңгылдашалар үзара:
«Офык артында, дип, язлар».

●

Скрипка елый — нәзек кыллар
Күз яшедәй ята күңелгә.
Хатирәләр сары яфрак коеп,
Салкын томаннарга төренә.

Скрипка елый — канатларын
Күтәрәлмый казлар талпына.
Нәзек кыллар әйтеп биргән моңның
Үзәкләргә үтә салкыны.

Соңгы көзе бу көз мәхәббәтнең
Һәм үксүе үксез күңелнең.
Скрипка моңы, хыялларның
Сары көзе булып түгелдең.

1970

◇◇◇◇◇◇◇◇◇

## Зөлфия

*Зөлфия бәхетле шагыйрә. Аның исеме, язмышы үзбәк халкы белән аерылгысыз. Ул үз халкы язмышын ил халкы, дөнья халкы белән бәйләп җырлый. Зөлфия күп йөри, күп күрә, күп халыкларның тормышы белән кызыксына. Һиндстанда, Югославиядә, Цейлонда, Мисырда, Японияда йөргән чакларында ул хезмәт ияләренең уртак бер хис — җирдә тынычлык, дөньяның киләчәге турында кайгырту хисе белән яшәүләрен күрә. Бөтендөнья халкы өчен изге булган бу теләкне чагылдырып шагыйрә бик күп шигырьләр язды. Аның ул шигырьләре Ватаныбыз халыклары телләренә генә түгел, чит илләрнең күбесендә тәрҗемә итеп басылды.*

*Зөлфия зур җәмәгать эшләре башкара. Ул Азия-Африка илләре язучылары ассоциациясе члены, Үзбәкстан Верховный Советы депутаты, Үзбәкстан коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты члены. Олы язмышлы язучылар һәрвакыт зур эшләр, олы хисләр турында язалар. Зөлфиянең туган ил, хезмәт һәм тынычлык турында язган шигырьләрен һәркайда яратып укыйлар. Аның йөрәктән чыккан шигырьләре йөрәккә барып керә. Туган халкы аны олылап, Үзбәкстанның халык шагыйрәсе дигән исем бирде. Һиндстан турында язылган шигырьләр циклы өчен Җәвахарлал Неру исемендәге Халыкара премия лауреаты булды.*

*Үзе дә эшче гаиләсендә туып үскән шагыйрәне хезмәт иясе хатын-кызлар язмышының дулкынландыра. Озак еллар буе ул Үзбәкстан хатын-кызлар журналы «Саодат»ның баш редакторы булып эшләп килә.*

*Зөлфия үзенең лирик шигырьләрендә хатын-кыз хисләренең барлык нечкәлекләрен — мәхәббәтнең сафлыгын, ана булу бәхетен, ялгыз калган тол хатынның сагышларын яза. Бу хисләрне шагыйрә үзе кичерә, үз йөрәгеннән үткәрә. Үзбәкстанның танылган шагыйре Хәмид Алимҗан аның тормыш иптәше була. «Ул мине уйларга, эшләргә, шигырь язарга өйрәтте»,— ди Зөлфия үзенең якын кешесе турында. Һәм соңыннан, Хәмид вакытсыз үлгәч, шул мәңгелек олы мәхәббәт шагыйрә иҗатының буеннан-буена лейтмотив булып бара.*

*Соңгы биш ел эчендә ике тапкыр Казанда булып киткәннән соң Зөлфиянең шигырьләрен «Азат хатын» журналы һәм республикабыз газеталары үз укучыларына тәкъдим иткән иде инде. Журналыбызның бу санында без аның бер бәйләм лирик шигырьләрен бирәбез.*

### Җил

Шаян җил, күрмим дә үзеңне,
Тотып та багалмыйм.
Нинди син буй-сынга, ни төсле?
Җавап та табалмыйм.

Тәнемне сыйпаган кулыңны
Кулыма алмадым.
Мөлаем елмаеп торуыңны
Җырыма салмадым.

Иркәләп син адәм баласын
Сөясең, сизәм мин.
Сурәтең тасвирлау чарасын
Эзләп ил гизәм мин:

Кем соң син? — Бер оста биюче?
Я бөре талларда?
Кошларның сайрашып көлеше?
Я үлән далада?

Әллә син салкыны суларның,
Чишмәләр агышы?
Йолдыздан түгелгән нурларның
Җирдәге балкышы?

Я ана күкрәген имүче
Хуш исле бәбиме?
Я җанда тик туып килүче
Өр-яңа бер көйме?

Әллә син болытлар киеме —
Парчадай һәйбәтме?
Я яшьлек язының килүе —
Сихерле әкиятме?

Тинтәкме син көзге көннәрдә
Яфраклар олактырган?
Я исә кагылып гөлләргә,
Чәчәкләр аттырган?

Шаян җил, кил миңа һәр таңда,
Ач миңа гөл-бакча.
Сурәтең язмаган булсам да,
Сар мине, кочакла.

## Сагыш

Бу көннәрдә язга бик зармын,
Балкысын дим, таңнан күзләрем.
Җимешсез бер агач сыман мин,
Көз шикелле сары йөзләрем.

Бу көннәрдә язга бик зармын,
Сагышлардан йөрим тинтерәп.
Ялгыз түгел, янда дусларым,—
Нәрсә эзли икән бу йөрәк?

Бу көннәрдә язга бик зармын,
Күңел җырлар тели тагын да.
Мин сер итеп саклап торганны
Каләм сөйләп тора барын да.

Бу көннәрдә язга бик зармын,
Үз языма, яшьлек языма.
Мин киселеп төшкән бер талмын,
Яз кайтмас ул минем янныма...

Аһ, мин язга шул кадәр зармын!

Ник тынып калдың болай моңаеп,
Башыңны салып мамык мендәргә?
Булыйм дисеңме бер дәрвиш-гарип?
Телимсең дауда ялгыз җиңәргә?

Кайда хисләрең ялкынлы, горур? —
Толлыкны җиңү! Язмыштан көлү!
Кайда балкыган күзләрдәге нур?
Ник өметләрдән болай аерылу?

Нигә кайгыру еллар үткәнгә,
Кемнең сакланган унсигез яше?
Зур язмышыңда узган көннәргә
Бизәкләр салган хәят нәккашы[1].

Озын юлларда кем калмый арып,
Ял ит утырып дуслар янында.
Тыңла сүзләрен син колак салып,
Уртаклаш, бүлеш ятлар зарын да.

Җырлардан тынса кемнеңдер җаны,
Көлү-елмаю сүнсә иренендә,
Син аңа кабат кайтар аларны,
Үзеңә авыр дип торма бер дә.

Имә башыңны, бу киң дөньяда
Күрер шатлыгың, кылыр эшең бар.
Кыйтгалар буйлап гизден пәядә[2].
Зиһен коесын кемнәр казырлар?!

Сине таш кебек баскан чирләрдән
Атыл җырыңа мохтаҗ халыкка.
Әй, хәким! Таштан, чәчәк, чирәмнән
Дәва тап җиргә — бөтен барлыкка!

## Йөрәгем калды сездә

Калдырып сезгә үз йөрәгемне,
Сезнекен алып киттем мин ерак.
Сагынып аны туган җиремдә,
Җырладым кайчак кушып җырымда.
Кайда ул хәзер, кайда ул йөрәк?

Кичтем кыялар, түземсез җандай,
Таулар менгәндә талды тезләрем.
Чәчелде шатлык якут-мәрҗәндәй,
Силләрдә үчте баскан эзләрем,
Сыкрап сызлана талган тезләрем.

---

[1] Нәккаш — бизәүче-рәссам.
[2] Пәядә — җәяү.

Шахтага төштем — караңгы юлга,
Бары да бар: руда, мәгъдән кирәкме!..
Минем сукмагым балкыды шунда:
Мин чыраг итеп алдым кулыма
Үземнең якты, кайнар йөрәкне.

Умырзаялар, чияләр төсе
Елмая миңа сабыйлар төсле.
Үз йөрәгемне күрдем аларда.
Көннән-көн минем йөрәк тибеше
Ешая бара, көчәя бара.

Беләм, бәхетнең чиге юк, әгәр
Йөрәктә булса ялкын вә дәртләр,
Җырчы исеме алганнан бирле,
Елгага койган сулар шикелле,
Миңа омтыла сезнең йөрәкләр.

Мин сезне тоям җылыгыз белән,
Күз нурларыгыз җаныма иңгән.
Сезнең йөрәкне җырда китердем,
Үз йөрәгемне мин эзләп килдем,
Бит аны сездә калдырган идем.

## Айлы төн

Айлы төндә гөл-бакчада
Булганың бармы синең?
Таң калып шул тантанага
Торганың бармы синең?

Ай бер калгый болытларда,
Бер тыңлый агачларны.
Бер чаба охшап атларга,
Чәчрәтеп су, ташларны.

Я көзге була ул күлдә,
Карадым ярдан шуңа:
Очраштым мин айлы төндә
Үз-үзем белән суда.

Якты йолдызлар тотам да
Учымда бергә кушам,
Барысын бергә кочам да
Туган җир буйлап очам.

Җир палас шикелле яткан,
Ай аны чигеп тора:
Яфраклардан челтәр япкан
Да борын чөеп тора.

Яңгырдан калган суларда
Чагыла нурлар төшеп.
Ай салган күлгә, буага
Нурлардан басма ишеп.

Чыклар яна ут шикелле,
Җил чәчте микән кырга?
Күләгә төшләрдә — серле,
Дөнья тик ачык нурда.

Ничек йоклый оясында,
Нинди хиссез бу кошлар?!
Йоклый шул бар дөньясы да,
Мин генә уяу, дуслар.

Йөзләремне ачтым айга
Бу гаҗәп якты төндә,
Мин тәмам кушылдым аңа,
Нур — тышым да, эчем дә.

Ник болай каплыйбыз икән
Кыскартып тормыш ямен,
Көндезге эшләребездән
Якты төн бәйрәмнәрен?

«Түрдән узыгыз»,— диләр миңа һәр дәм,
Барып күрсәм таныш, дусларга.
Урын тапсам сезнең йөрәкләрдән,
Барыбер миңа кая узсам да.

Дус йөзендә күрсәм үз йөземне —
Мин тәхеттә кебек хис итәм.
Бик бәхетле саныйм мин үземне —
Аннан артык хөрмәт бар микән?!

Хөрмәтеңә торам хәйран калып,
Халкым, түреңә менәр идем мин:
Шигърият ул — бердәнбер патшалык!
Аның тәхетен теләр идем мин.

●

Һавада, бер телем кавын күк,
Бөкерәеп тора сап-сары ай.
Кайгыдан төшкән ул бөгелеп,
Атадан ятим бер баладай.

Көн үтәр, төн үтәр... Бер заман
Ялтырап яктырыр тулган ай!..
Үсәр ул, булыр бер каһарман,
Тулган айдай балкыр шул малай...

## Минем таңым

Юмарт туфрак кырларда ята,
Игеннәргә биреп кодрәтен.
Минем таңым йөрәктә ата,
Уйдан куып төннең золмәтен [1].

Төннән таңны тартып алам мин,
Якты булсын диеп эш көнем.
Кәгазьләргә таңны салам мин,
Озын булсын өчен гомерем.

Ай калдырган якты эзләрне
Күчерәм мин шигъри юлларга:
Ялкын биреп, шук йолдызларны
Өндим кеше кебек суларга.

Фәрман бирәм: безнең таңнарны
Кара болыт каплап алмасын,
Һәр иртәбез бәхет таллары,
Яфраклары булып шауласын.

---

[1] Золмәт — бу урында караңгылык.

Минем таңым башлана төннән:
Күрәм, кичерәм иҗат сөенечен,
Тау артында башланыр көннән
Яфракларда чыклар сүнешен.

Кай өйдәдер бала елады,
Сөтле күкрәгенне бир, ана.
Биек булыр аның юллары,
Карт планета инде тар аңа.

Якын-ерак тәрәзәләрдә
Берәм-берәм утлар кабына.
Сәлам сөйләп шат иртәләргә
Галәм моңы күкрәп агыла.

Ни китерсәң дә хуп, ал таңым,
Шатлык, сагышмы ул, китер, я!
Тик китермә моңсыз җыр! Тагын
Укылмастай китап китермә.

## Кайда сәламең?

Яктырта җирне таң, нурга тулып,
Куенында аның: эш, көрәш, шатлык.
Һәрбер таң синең сәламең булып
Башлана иде,— инде югалттык...
Син юк... Кайда соң, дустым, сәламең?

— Сәлам сиңа! — дип әйткән сүзеңне
Җир таң көткәндәй, көтәм зарыгып.
Җанда, җырымда тоям үзеңне,
Бөтен барлыгым белән сагынып.
Ишетәсем килә, кайда сәламең?

Кояш нурларын миллион елларча
Безгә кызганмый балкыта-сибә.
Минем сөюем, газабым барча
Ничек тә тәэсир итмиме сиңа?
Ник эндәшмисең, кайда сәламең?

Астроном күктән эзләгән кебек
Беленер-беленмәс йолдызны көндез,
Мин эзлим хәзер синдәге элек
Кабынган уттан калганмы дип эз.
Бик телим синең кайнар сәламең.

Җилме, буранмы, кышмы я көзме...
Килмәссеңмени бер күрешергә?
«Исәнме» дигән тылсымлы сүзне
Ишетәсем килә... Инде без бергә
Булмабызмыни гомер-гомергә?
Шагыйрем, кайда синең сәламең?

Шат тавышлар белән шаулап, көлеп,
Атылып төшә өстән шарлавык.
Күңелләргә яңа җырлар биреп,
Илһамымнан миңа яр салып [1].

Шашып, кайнап төшә ул бар көчкә,
Күккә чөеп көмеш тузанын.
Ирек теләп чыккан зур көрәшкә,—
Ватарга дип таулар тозагын.

Бар суларны бозга әйләндергән
Кыштан нәкъ үч алган шикелле,
Тирә-якны үзенә баш идергән,
Ята җир, таң калган шикелле.

Укчы кояш күктән уклар ата,
Җәя итеп салават күперен,
Дулкынланып, ярсып сулар ага,
Күреп дала, кырлар күңелен.


Ә шарлавык — салкын, саф сулары
Хезмәт итсен өчен кешегә,—
Эзләп ага елга, каналларны,
Уңыш теләп иген эшенә.

Җырым минем, син дә шулай тулып
Ярларыннан ага бирсәнче,
Хезмәт белән гел аваздаш булып,
Йөрәкләргә үтеп керсәнче.

НУРИ АРСЛАНОВ тәрҗемәләре.

---

[1] Яр салып — хәбәр итеп.




**«ТАТАРСТАН АССРДА ЙӨК АВТОМОБИЛЬЛӘРЕ ҖИТЕШТЕРҮ БУЕНЧА ЗАВОДЛАР ҺӘМ АҢА КҮРШЕ РАЙОННАРДА АРАДАШ ПРЕДПРИЯТИЕЛӘР КОМПЛЕКСЫ ТӨЗЕРГӘ».**

*(КПССның XXIV съезды директиваларыннан)*

## Тәүфыйк Сәгыйтов

# ГАЛИМУЛЛА АГАНЫҢ ИСТӘЛЕКЛЕ КӨНЕ



Октябрь бәйрәме көне иде. Бөтенсоюз радиосы, Кызыл мәйдан аша үтә торган хезмәт иңнәренең демонстрациясеннән репортаж тапшырып, бөтен илебез шәһәрләре буйлап атлаучыларны да тоташтыра-тоташтыра, гүя миллионнарның дирижеры хезмәтен үти, бер теләк, бер уй, бер үк омтылыш белән яшәүче халыкларның нык адымнарын, алар күңелендәге шатлыклы хисләрне ерак-еракларга җиткерә. Башкалабыз предприятиесенең эшчесе һәм Донбасста күмер чыгаручы, Әзербайҗан нефтьчесе һәм океан киңлекләрендә балык сөзеп Владивосток портына килеп туктаган траулер егетләре, Урал металлурглары һәм Белоруссия төзүчесе, Мәскәү язучысы һәм Новосибирск галиме сөйләгән чакта, Чаллыдагы монтажчы Галимулла Хәлиуллинга да сүз бирделәр.

«Бүген Чаллы урамыннан бәйрәмчә киенгән меңнәрчә кешеләр атлый,— дип башлады ул сүзен.— Алар, автозавод төзүчеләр буларак, Октябрь демонстрациясенә беренче мәртәбә чыгалар әле. Бу рәтләрдә Себердән һәм Кавказдан, Украинадан, Урта Азиядән, үзебезнең Татарстаннан һәм Башкортстаннан килүчеләр дә күп. Биредә кырыклап милләт вәкилен күрә аласың. Телләр төрле булса да, теләкләр бер, максат уртак. Чал Кама буендагы бу гигантны бөтен ил кора. Хәзер автозавод объектларында эш кайный. Чаллы үзе дә көнләп кенә түгел, сәгатьләп үсә. Шушы тырыш куллар быел гына да 100 мең квадрат метр торак мәйданы өлгертәчәк... Биредә энтузиастларның девизы шундый: әтиләребез магнитканы төзегән, ә без автозавод корабыз. 1973 елда илебез юлларына бердәм булып беренче яңа машиналар кәрваны китәр!..»

Мәскәү. Кызыл мәйдан. Хезмәт иңнәренең хезмәттә җиңү рапортлары. Күтәренке күңел, музыка. Бөтенсоюз радиосы дикторы әйткән сүзләр... Чаллы урамы... Анда-

гы бәйрәмне, ерактарак кешеләрнең җырлавын, котлауларга бердәм «ура» белән җавап кайтаруын һәм шушы фонда үзенә таныш монтажчының сүзләрен дә ишетү, ничектер, Чаллының илебез күләмендәге зур игътибар юнәлтелгән әһәмиятле үзәккә әверелүе күңелдә горурлык хисләре тудырса, икенче яктан, инде ничәмә мәртәбәләр күрешеп, шактый якын белеш-танышлар булып киткән Галимулла аганы яңадан күз алдына китереп бастырды: шактый сирәкләнеп бара торган кара чәч, калын-калын кашлар, озын керфекләр, мөлаем гына елмайган коңгырт күзләр, ябыграк битләре шадраланып тора. Хәер, чуендай каралган йөздә сизелми дә ул. Зәмһәрир суыкта, ачы җилләрдә, җәйге челләнең иң эссе көннәрендә дә ачык һавада эшләгәнгә күрә шоколад төсенә әверелгәндер ул. Буе да уртача гына аның... Әле дә хәтеремдә: парткомда Бөтенсоюз күләмендәге «Гидромонтаж» трестының бездәге участогында эшләүче монтажчы белән таныштырабыз дигәч, күзләре ут уйнап торган, кл[а]һи таза гәүдәле, пәһлевандай кешене күрермен дип көтеп йөргән идем. Карасам, ни күрим, оялчан гына, килеш-килбәте белән дә башка төзүчеләрдән бер дә аерылып тормаган кеше булып чыкты ул Галимулла ага.

— Ни дип мине алай аерып күрсәтәләр икән, кирәк булганга гына эшлибез инде, югыйсә...

Үзе шулай җилкәсен сикерткәләп, гаҗәпләнгән була, үзе уңайсызланудан, иртән кырырга өлгерә алмаган сакал-мыегын, сыпырып алгалап, томаларга тырыша. Ә куллар, физик хезмәт белән сөялләнеп ныгыган таза куллар! Гүя андагы эзләр бу кешенең үз хезмәте белән мәңгелек һәйкәлләр салуын әйтеп тора да, ә битләрендәге, маңгаендагы төрле сызыклар булып сузылган тормыш буразналары ул үткән юлларның сикәлтәле булуын да, яшәү дәверендә шактый гына ла[е]ш шулпасын татырга туры килүен дә ачык әйтеп тора...

Шушы очрашудан без Галимулла ага белән танышып киттек. Очрашкан саен сөйләшеп утырабыз, һәрвакыт аның шушы Чаллы белән горурлануы арта баруын тоясың. Эшкә бирелүе, аңа булган мөнәсәбәтендә бу аеруча ачык чагыла.

«Гидромонтаж» коллективы төзелеш индустриясе базасында да шактый эш башкара. Тимер-бетон колонналар, металл каркаслар, технологик җиһазлар шушы батыр йөрәкле кешеләр кулы белән монтажлана. Бирегә алар башкарачак эшнең еллык күләме 100 миллион сумнан артык санала. Һәр бригадада тәҗрибәле кадрлар, төзелешләрдә күп эшләгән осталар да бар: Энгельс Дәүләтшин, Әсәт Шәймәрданов, Вениамин Захаров, Фәрит Мостафин, Владимир Денисов, Виктор Герцен, Рафаэль Мөхәммәдиевләрне аеруча мактап телгә алалар.

Аларның бөтенесе дә берсеннән-берсе чибәр, нык егетләр, әмма иң беренче сыйфат буларак күз алдына килеп басардай артык таза да түгелләр. Бәлки, бу монтажчы исеменең безнең хыялда батырлык һәм ныклык, тән белән күңел көрлеген бергә берләштергән образына бәйләнгәндер. Күреп сөйләшкәч, буйга кечкенә, хәтта беренче карашка ябыграк тоелган бу кешеләрнең хезмәттәге терелегенә, үт уйнатып торуларына хәйран каласың. Әйе, «Карама беләккә, кара йөраккә»,— ди шул халык мәкале. Галимулла ага аларның чын бәясен яхшы белә, «Коллективның алтын запасы» дип атый һәм аларны аталарча саклый, үстерә...

Колонналарны күтәрү башланды... Краннарның гүләп эшләве, тросларның шыгырдатып авыр йөк кысып алулары игътибарны үзенә җәлеп итә. Ара-тирә Галимуллэ агага карап куям, ул урталыкка баскан, башында бүреге дә юк, әллә киярга онытКан, әллә ул төшеп үк киткән, кем белсен, кулын күтәргәннән-күтәрә бирә, үзе кабатлый: «Вира, вира»... һәм кинәттән: «Майна!» Колоннаны нигезгә тигез генә итеп төшерергә кирәк... Ул, читкә китеп, турылыгын карый, кайвакыт: «Беркетегез!» — дип куя. Шунда гына, иланбаш икәне исенә төшеп, бүреген алып кия.

Шушы алышта сигез сәгать үткәнен сизми дә калганбыз. Смена ахырында Галимулла ага җиңел сулап куйды.

— Хәбәрчеләр: «Иң истәлекле көнең кайсы!» — дип сорарга яраталар. Менә күр, туган, шушы инде ул: зур объектның беренче колоннасын утырту иң истәлекле көн була монтажчыга. Чөнки, бөтен сызымнарны карап, син тәмамлангач аның ничек буласын күзаллап керешәсең бу эшкә. Иң беренче колоннаны утыртуы мөһим безгә,

тора да эшнең күләме, әһәмияте турында сөйләп ала.— Күп әле, күп. Бу төзелеш индустриясе базасы елына 240 мең квадрат метр торак йорт салырлык блоклар җитештерергә тиеш. Үзе бер кечерәк шәһәр дигән сүз бит бу! Әле автозавод цехлары өчен никадәр тимер-бетон конструкцияләр дә биредә коелачак. Әкәмәт зур була ул!.. Бүгенге көндә тимер-бетон конструкцияләр урманы булуга бер дә исең китмәсен. Алар сигез рәт булып төзеләләр, һәрберсендә 26 шар данә. Авырлыгымы! Бер колонна — үзе сигез ярым тонна...

Смена ахырындамы, төшке ашка туктагандамы, башкарган эшләрне дә ул теркәп бара. Мин башта аңысы прораблык вазифаларына керәдер, дип уйлап куйган идем. Кайтканда сорарга булдым.

— Һе,— диде ул, оялчан гына елмаеп,— колонналы утырту бик җаваплы процесс. Күзәтеп тор, ышаныч зур нәрсә, билгеле, ләкин ышан да — тикшергәли тор диләрме әле. Һәр колоннаны документлаштырып барырга кирәк: кайсын кем утырткан. Аз гына тегәлсезлек җибәрдеңме — иртәгәме, ун көннәнме, соңыннанмы — барыбер белена. Вакытында төзәтеп төгәл итеп бармый ярамый. Аннан, беләсеңме, яшьләр күп бит. Эш таләбе буенча берникадәр катырак тәртипкә дә башта ук өйрәнсеннәр... Монтажчы эше катлаулы эш ул. Аңардан, туган, физик сәләт, фикер тизлеге, кыюлык таләп ителә. Безнең һөнәр иләс-миләслекне яратмый ул...

Кич. Өч бүлмәле квартираның эче якты, җылы. Пөхтә итеп җыелган, заманча әйберләр куелган. Ялтырап торган мебельләр. Киштәләре сыгылып торган китап шкафы. Нинди генә томнар юк биредә. Өстәл өстендә газета-журналлар.

Журналлар актара-актара, Галимулла аганың тормыш иптәше Газимә апа белән сөйләшеп утырабыз.

Ул унбиш ел буе укыткан. Ун классны тәмамлауга ук сайлап алган шул һөнәрен яраткан ул, әлбәттә, ләкин монтажчы белән зур төзелешләрдә йөргәндә һөнәрен алмаштырырга туры килгән. Хәзер кислород станциясендә моторист булып эшли икән.

— Икәү генә калдык хәзер. Кызлар да кош балалары кебек таралыштылар. Олы кызыбыз Рузилә Түбән Кама шәһәрендә яши, каучук производствосында аппаратчы булып эшли, кичке техникумда укый. Ял көннәрендә кайткалый. Үзебез дә барабыз. Ә кечесе — Тәнзилә Әлмәттә физкультура техникумда укый. Кечкенәдән спортны ярата.

Озак та үтми, Галимулла абый да кайтып керде. Бу тату семьяда җылы әңгәмә шактый дәвам итте.

Аннан Галимулла ага телевизор абызды. Бигрәк вакытында эләккәнбез икән. Нил елгасындагы Асуан ГЭСын күрсәтәләр иде. Бу кадрлар Газимә апа белән Галимулла аганың күңел түрендәге хатирәләрне яңарттылар.

1960—1962 елларда Галимулла ага Воткинск ГЭСы төзелешендәге гидромонтаж идарәсендә бригадир булган. 1962 елда ул Берләшкән Гарәп республикасында Советлар Союзы ярдәме белән төзелә торган Асуан ГЭСына эшкә җибәрелә.

— Июльнең сигезләре тирәсендә Каһирәгә килеп төштек,— дип искә ала ул көннәрне Галимулла ага.— Бик җылы каршы алдылар. Икенче көнне — экскурсия. Каһирәдә ике көн тордык. Аннан соң поезд белән Асуанга алып киттеләр. Әкертенләп күнектек. Эсселек тә ул кадәр сизелми башлады. Иң беренче итеп гидроузел төзелешендәге эшләрне алып бара торган кранны монтажладык.

Билгеле, гарәп халкы дуслык сөючән. Ләкин шул ук вакытта Англия колониясе булган чагында колонизаторларның изүләрен, алар белән нинди мөгамәләдә булганнарын да оныта алмый. Колонизаторлар алар өчен ак кешеләр булып, ак киемнән йөргәннәр. Ә Россиядән килгәннәр белән алар арасында — җир белән күк арасыдай аерма.

Без бер төрле эштән дә читенсенмәдек. Кирәк чагында ачкыч, кувалды тотып та эшләдек.

Ял көннәрендә кибеткә, базарга чыксаң, шунда бергә эшләүче гарәп дуслар күреп ала да, килегез, берәр стакан чәй, кофе эчәрбез, безнең өчен хөрмәт булыр.

ләребез, ничектер, аларның хәтта аңына сыеп бетми ~~сыман иде.~~

Бергә эшләгән дуслардан Хәсән Нурси рус телен яхшы белә, дөрес үк сөйли иде. Тагын электросварщиклардан Әхмәт, Сәет, Ибраһим, Мәхмүтләр дә безне дус иттеләр. Миндә аларның фоторәсемнәре әле дә саклана. Әнә биредә алар... Мин торган йортка кунакка килгәннәр иде. Шунда төшереп алдым.

Шулай... Үземнең өстәл артына утырттым боларны. Йорт хуҗасы булгач — хөрмәт итәсең. Чәй ясап китердем, һәр беренең алдына куя торам. Шул вакыт миңа сорау бирәләр:

— Али, садыйк Али (ягъни Али дус), безгә килешми бит, без гади эшче кеше, рагиль — кара эшче. Ә син, белгеч була торып, безгә хезмәт күрсәтәсең, чәй китерәсең. Бу безнең аңга сыймый,— диләр. Мин аларга үземнең гади крестьян баласы булуымны аңлатырга тырыштым, авылда үстем, мин әйтәм, шулай булгач — аңлагыз, син рагиль икән, мин дә җир улы, крестьян баласы, дим.

Билгеле, соңгы елларда алар күпне аңладылар. Советлар иленнән килгән кешеләр барысы да шулай, чын йөрәктән ярдәм итә, кеше белән кеше барысы да тигез икәнен төшенделәр.

Кайтыр вакытлар җиткәч, безнең белән бергә эшләгән дуслар барысы да безне Асуанның тимер юл вокзалына озата килделәр. Чын дуслар белән аерылышкан кебек аерылыштык.

Анда эшләгән, алар белән яшәгән, Асуан кояшы астында көн иткән чаклар әле дә истә. Бергә эшләгән гарәп дусларның кайберләре үзләренең яралары сызлавын әйтәләр иде. Алар Англия интервенциясе вакытында Сүәеш каналында яраланганнар. Үзем дә Ватан сугышында катнашкан кеше булуым сәбәпле, алар сызлануы минем өчен дә авыр иде. Хәзер дә, Израил агрессиясе башлангач та, билгеле, ул иптәшләрнең күбесе кулына корал алып көрәш сафларына басканнардыр. Яңадан богау киярга берсе дә риза булмас. Гарәп халкы чын күңелдән азатлыкны сөя, хезмәт ярата.

— Садыйк Али, бер ун елдан соң безнең илгә килегез әле, безнең үсешне күрерсез,— дия иделәр алар.

Бу — бик аңлаешлы шатлык: элек бернәрсә булмаган ташлы җирләрдә мәһабәт плотина үсеп чыкты. Ул күпме өйләргә яктылык алып килде дә, күпме җирне сугару өчен су бирде! Ә бит плотина төзелгәнче, ел саен күпме җирне су баскан, никадәр бала-каза кичерелгән... Ә хәзер — яктылык та, дөге дә...

Хатирәле еллар бик күп. Берсеннән-берсе мәртәбәлерәк вакыйгалар шактый. Ул, Галимулла Хәлиуллин,— ватаныбызның гади улы — шушы һөнәре белән хезмәттәге һәр җиңүгә өлешен керттә, аңа хәләл көчен куйды. Табигате-фигыле белән тынгысыз, күбрәк күрергә, күбрәк белергә тырышкан Галимулла ага бер эштән дә баш тартмады. Ир илне сөйсә, ил ирне канатландыра, ди халык. Шулай булды да. Хәзер Галимулла Хәлиуллин ил күләмендәге мөһим төзелештә катнаша. Әнә шундый кешеләр бүгенге Чаллының һәр сәгатен көнгә тиң итәләр, ә көннәрнең һәр берсе гүзәл Кама ярындагы бу төзелеш тарихына берсеннән-берсе матуррак булган сәхифәләрне яза.

Галимулла ага эшкә барыр алдыннан һәр иртәне башта тирә-якны күзәтеп ала. Гасырлар буе тынлыкка мңгән бу яклар бер тәүлек эчендә күпмегә үзгәргән!! Төзелеш колачын һаман киңрәк җәя, аның һәр почмагында кызу эш кайный. Кешеләр, һава шартларының нинди булуына карамастан, табигать белән якалаша. Чал Кама ярында яңа квартал үсеп килә. Бу биналар тиздән тагын бер урамны хасил итәрләр. Уйласаң, ис китәрлек шул: Чаллы әле кайчан гына аларны кечкенә авыл өйләре белән каршы алган иде бит! Инде бүген үк яңа шәһәрне күзалларга мөмкин: көмештәй һава лайнерлары зур аэропортка борөзлексез килеп кенә торалар. Кама буендагы мәһабәт шәһәр беренче килүчеләрне үзенең гүзәллеге белән хәйран калдырыр. Тугызар, егермешәр катлы йортлар салыныр. Урамнарының киңлеге генә дә йөзәр метрдан артык булыр. Иркенлек, яшеллек.

дә саны артканнан-арта бара. Һәр көн саен килеп кенә торалар. Әлегә торак яклары да авыр икәнен белеп, бары тик ачык һавада эш урыны бар икәненә генә ышанып киләләр алар. Ләкин шунысы гаҗәеп: аларның һәрберсе дә автозаводны белә, кинди шәһәр булачагын тәфсилләп сөйләп бирә ала. Эшнең кызу, киң фронт белән барачагын да әйтәләр.

— Көн саен миллион сумлык, хәтта аннан да күбрәк,— ди берсе, телен шартлатып, баш бармагын күрсәтеп.

— Яшең дә бик күп түгел, кем булып эшләргә исәбең соң! — дип сорады Галимулла ага берсеннән.

— Яшем — унтугызда,— диде түгәрәк йөзле егет,— һөнәрем — сварщик. Институтка керергә исәп. Моңа кадәр Казанда яшәдем, тулай торакта тордым.

Күренеп тора: Галимулла ага аның өчен горурлана. Бәлки, ул хәзер үзенең яшьлеген хәтерли торгандыр...

...Унҗиде яшь... Кайсы гына егет бу чорда үзен көчле кеше итеп тоймый да, кайсы гына егет иләр гизү, әкияттәгедәй шәһәрләр кору, үзе туган авылны дөньядагы иң гүзәл бакчага әверелдерү турында хыялланмый... Әйе, 17 яшьлек Галимулла да Сөн елгасын кочаклап йөзгәндә, туган авылы Сәдек янындагы күлләрдән төнбоекләр җыйганда әнә шулай хыялый булгандыр. Ул хыяллар нишле семьяда, ятимлектә үсүне дә берникадәр җиңеләйткәндер аңа. Ә менә сугыш... Мәрхәмәтсез сугыш — меңәрләгән тормышларның уртак фаҗигасенә әверелгән, берничә буын гамьлрына берьюлы балта чапкан сугыш Галимулланың бөтен хыялларын челпәрәмә китерә.

Аның өчен югары уку йортын һава десантчылары хәзерләү мәктәбе алыштыра: яшь егетнең тормышны, аның бөтен матурлыгын тоя, тирәнтен аңлый башлаган йөрәге йодрыктай кысыла, кырыслана һәм дошманга каршы чиксез нәфрәт белән ыргыла.

Яшь командир өчен сугышчан чыныгу 1943 елда фронтларның иң җаваплы участогы — Курск дугасында башлана. Монда аның кебек яшүсмерләр белән Мәскәү, Сталинград янында баһадирларча сугышкан солдатлар да була. Беренче чыныгу, дары исе исләү әнә алар сафында башлана. Составында ул сугышкан Бишенче Гвардия һава десанты армиясе турында фронт командующие, талантлы полководец генерал Ватутин менә нәрсәләр әйткән: «Бишенче армия, чын мәгънәсендә, Суворов гаскәрләре үрнәген күрсәтте һәм ике көн эчендә, хәрби припаслар күтәргән хәлдә, рәхимсез эссе кояш астында 150 километр марш ясады». Гитлерчылар зур өмет баглаган «Цитадель» операциясен хурлыкка дучар итүдә десантчылар гаять зур роль уйный. Югары командование бу армияне иң әһәмиятле участокларга ташлый. Галимулла ага Днепр, Днестр елгаларын кичкәндә плацдарм яулап алуда, Киев, Житомир шәһәрләрен азат итүдә кан койгыч сугышларда катнашып, өч тапкыр каты яралана.

Сугыш унтугыз яшьлек егетнең тәнен җәрәхәтли алса да, күңеленең ерак түренә яшеренгән яшьлек хыялларын үтерә алмый. Киресенчә, бөтен афәтләргә үч итеп, тизергә, җир йөзен яшәртергә, туган илен гөлбакчага әверелдерергә дигән якты хыялларын тормышка ашыру теләге белән кайта ул сугыштан.

Билгеле, икенче группа инвалид өчен монтажчы хезмәте корычтай ныклык, киләчәккә зур ышаныч таләп иткәндер. Әле дә әнә шул җәрәхәтләр сызлаудан әрни-әрни тешен кысып эшләгән авыр еллар хәтеренә киләдер аның. Ул дөньяда шушы иң гуманлы, тынычлык һөнәре хезмәте белән сызланууларын да җиңгән һәм танылган төзүчегә, киләчәкнең бөек рәссамына әверелгән.

Менә шуңа күрә дә, бөтенсоюз радиосы аша аның тавышы миңа тагын да ягымлы булып тоелды, һәм ул гомер буе онытып алмаслык танышларымның берсенә әверелде... Ничектер, яңадан аны күрәсе, сөйләшеп утырасы килде...

Шул ук өй, шул ук күләч йөзле семья. Бу килүемдә дә яңалык шактый иде. Минем кебек, аны күреп сөйләшергә теләүчеләр искиткеч күп икән. Өстәл өстендә дистәләрчә телеграммалар ята. Кемнәр генә җибәрмәгән аларны. Галимулла ага үзе аңлатып бара:

— Монысы белән Туймазада эшләгән идем, ә бу иптәш белән Казагыстандагы Караганда, Гурьевка шәһәрләрендәге электростанцияләрдә монтажчы идек...

ловка, Чайковский, Зэй, Асуан, Красноярск, Чаллы...

Үткән юллар, үзең корган биналарның һәрберсе күңелдә тирән эз калдырган. Павловск ГЭСын төзү еллары Галимулла ага тормышында зур борылыш еллары булган. Ул җитәкләгән монтажчылар бригадасы төзелештә беренчеләрдән «коммунистик хезмәт коллективы» дигән мактаулы исемне яулаган. Ә үзен хөкүмәтебез «Почет билгесе» ордены белән бүләкләп, фидакарь хезмәтенә зур бәя биргән. Воткинск ГЭСы аның хәтерендә коммунистлар партиясе сафына басуы, бригадасы рекордлы срокта монтажлаган авыр йөк күтәрүче баһадир кран, ул вакытта үзе керткән рационализаторлык тәкъдименең Бөтенсоюз халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең медальгә лаек булуы кебек вакыйгалар белән якты эз калдырган. Зәй ГРЭСы исә — ул үзе туып-үскән караңгы авылларга яктылык илтте... Үзе төзегән дистәләгән энергия гигантларының һәркайсы Галимулла агага үзенчә якын, үзенчә истәлекле... Алар хезмәт һәм тырышлык үрнәге генә булып калмаганнар, ә тәрбия мәктәбе дә булып килгәннәр. Менә «Чаллы, монтажчы Хәлиуллинга» адресы белән килгән котлау хатларының берсеннән кайбер юллар:

«...Бүген илебез чәчәккә күмелгән икән, һәр көн иртән безне аяз зәңгәр күктән тынычлык кояшы назлап иркәли икән, тирә-юньдә сабыйлар яңгыравыклы тавыш белән көләләр икән, кешеләр төннәрен тыныч йоклыйлар, матур киенеп мул яшиләр икән — болар һәммәсе дә кан коеп сез яулаган азатлык җимешләре. Менә шуңа күрә сезне, Ватан-ана өчен арысландай сугышкан батыр улларны, чын күңелдән Җиңү бәйрәме белән котлыйсы, корычтай нык сәламәтлек теләп каласы килә... Һәркемнең һәрвакыт исендә: күпме шәһәрләрдә мәңгелеккә дип кабызган утлар гомерләре вакытсыз өзелгән кешеләр йөрәге җылысы булып яналар. Ә сезнең, исән калганнарның, сафка басуы һәркем өчен авырлыкны җиңү мәктәбе була алырлык бит. Әле дә хәтеремдә, Галимулла ага, буш вакытларда сөякләре ватылган сул кулың белән күнегүләр уздыра идең. Тимергә тотынып, үзеңне-үзең күтәргәндә чыраеңны сытканыңны һич онытасым юк. Ул минутларда йөзең, чыраең ничек сытылуын берничек тә әйтеп бетерерлек түгел. Син бик тиз борылып китә идең. Күзеңнән яшь тә атылып чыккандыр, без сизми идек, йөрәгең бик сыкрангандыр ул минутларда... Аннан 1952 елда медицина комиссиясе вакытында, «сизелми, авыртмый!» дип, врачларны ышандырдың бит. Әмма шуннан соң да күпме интектең бугай әле син, тик ыңгырашмадың, сиздермәдең... Ул йодрыгың хәзер дә шулай чалыш тора торгандыр әле. Син хәзер, Галимулла ага, автозавод төзисең икән. Радиодан ишеттем. Егетләреңне һәрвакыт шулай өйрәт, таләпчән бул...

Синең Анатолиең!»

...Ул чакта кан саркыган җәрәхәтләрнең эзләре тәндә һәм йөрәк түрендә гомер онытылмаслык урын алганнар. Хәер, таш кыялар телгәләнеп, ярылып бетсәләр дә, йөзләрчә ел нык торган кебек, Галимулла Хәлиуллин сыман Ватан уллары да андый җәрәхәтләргә бирешергә теләмиләр. Яуда туган батырлык һәм ныклык яңа тормыш төзү фронтында дәвам итә. Сугышчан һәм хезмәт традициясе шулай бергә үрелеп, алтын куллы төзүчеләрнең исемен йөзләрчә таш биналарга язып калдырган. Хәзер аның чираты чал Кама буенда. Ирексездән үзенең хыялый елларын исенә төшерткән яшьләр һәм алар алып килгән энтузиазм белән бай тәҗрибә бергә дә алда торган бурычны уңышлы үтәр.

◊◊◊◊◊◊◊◊◊

## Мөнир Юсупов

# СҮРИЯДӘ ОЧРАШУЛАР



Безне совет илчелегендә эшләүчеләрдән бер төркем кешә каршылады.

Ә берничә минуттан үзебезнең «Волга» машинасында шәһәр үзәгенә чаба идек инде. Ун минутлап чүлдән баргач, ямь-яшел урамга кердек. Йортларның яссы түбәләре, киң балконнар һәм террасалар күзгә ташлана. Тәрәзәләрне каплаган матур агач рәшәткәләр өй эчендәгеләрне чит күзләрдән һәм кайдерге эссе кояштан, тузаннан саклый.

Дәмәшк — бик борынгы матур шәһәр. Аның биш мең еллык тарихы бар. Күп гасырларның сәяхәтчеләре аның матурлыгына сокланганнар, күп әдипләр һәм шагыйрьләр аны мактап шигырьләр язганнар.

Касыюн тавы итәгендә, чүл арасында утырган шәһәр, безнең Ташкент шикелле үк, зур бакчалы хәтерләтә. Әйтерсең лә ком диңгезе уртасындагы яшел утрау.

Икенче көнне сәгать 12 ләрдә мин илчелекнең экономик мәсьәләләр буенча киңәшчесе Равил Солтанович Аклаев бүлмәсендә утыра идем инде. Ул Уфа нефть институтын тәмамлаган инженер-нефтяник. Хәзер вакытлыча Тэхноэкспортның кадрлар бүлеге начальнигы ярдәмчесе вазифасын үти. Равил Солтанович Сүриядә ике ел эшләү дәверендә Сүрия диалектында бик шәп сөйләшергә өйрәнгән. Ул мине бирегә эшләр белән, хезмәтемнең характеры һәм шартлары белән таныштырды. Сөйләшеп утырганда мин совет геологларының Сүрия чүлләрендә файдалы казылмалар табуын, совет нефтьчеләренең Сүрия белгечләре белән берлектә илнең төньяк-көнчыгыш районнарында нефть ятмалары эзләүләрен һ. б. турында белдем.

Бер көннән соң мин Халеб (Алеппо) шәһәренә китәргә тиеш идем. Зурлыгы ягыннан Дәмәшктән генә калышкан бу шәһәрдә Сүрия тимер юлларының генераль дирекциясе урнашкан.

Проектның баш инженеры Тер-Микаэлянцны йөртүче Абдрахман үзенең «Шевролеһендә мине гостиница янында көтеп тора иде инде.

Дәмәшк — Халеб шоссесы Сүрияне көньяктан төньякка таба кисеп үтә. Ярты юлга җитәрәк зурлыгы ягыннан өченче урында торган Хомс шәһәре бар. Ул Сүриянең иң салкын урыны. Шәһәр зур юлларның кисешкән урынында, киң генә үзән уртасында утыра. Тау тезмәләре арасыннан диңгез җиле өреп тора. Сул якта Хомс күле күренеп кала. Ул Нахр-Аси елгасын бүлеп ясалган. Европалылар аны Оронт дип йөртәләр.

Шәһәргә кергәч, машина ике катлы йорт алдына килеп туктый. Фасадына «Фундук Басман җәдидә» дип язылган. Безнеңчә Яңа Басман гостиницасы була. Биредә мине Ленгипротранс инженерлары — Мәскәү егетләре Владимир Муквич һәм Валерий Рудицкийлар каршы алды. Алар гарәп телен белә торган тәрҗемәчене күптән көтәләр икән инде.

белгечләр дә килеп җитмәгәнлектән, кайбер бүлмәләрдә кеше юк.

Икенче көнне миңа Офиска (Тартус — Хомс тимер юлын төзүче оешманы кыскача шулай диләр) барырга кирәк иде. Ул без торган гостиницага якын урнашкан «Зәһрә» кинотеатры артында гына булып, бер зур йортның икенче катын тулысы белән алган. Бирәдә Ленгипротрансның утызлап инженеры Тартус—Хомс тимер юлын проектлаштыру өстендә эшлиләр.

Хомстан Халеб шәһәренә Ливаннан килә торган тимер юл тармагы үтә. Тартус—Хомс тимер юлы да эшли башлагач, Советлар Союзыннан Тартус портына килгән йөкләрне Евфрат плотинасы төзелгән җиргә турыдан-туры илтеп булачак. Ә Евфрат плотинасы әһәмияте ягыннан Мисырның Асуан плотинасы белән тиңләшергә хаклы.

Сүрия халкы уңдырышлы җир мәйданына бик мохтаҗ. Евфрат корылмасы тәмамлануга җирле халык элек булган файдалы чәчү мәйданына өстәмә рәвештә 550 мең гектар җир алачак. Шуның өстенә 400 мең киловатт куәтле гидростанция эшли башлаячак. Ә бит аңа кадәр Сүриядәге бөтен электростанцияләрнең егәрлеген бергә кушсаң да нибары 250 мең киловатт кына булган.

Плотина төзү эше күптән үк планлаштырылган була. Элекке хөкүмәт башлыклары ФРГдан кредит сорап мөрәҗәгать итәләр, хәтта килешүгә дә ирешәләр. Ләкин Көнбатыш Германия әһелләренең яшерен максаты бик тиз фаш ителә. Үзләре салачак капитал бәрабәренә теләгәнчә һәм теләгән вакытта алар Сүрия нефтен Германиягә озатып тору шартын куялар.

Сүрия хөкүмәте моны кабул итә алмый, әлбәттә.

1966 елның апрелендә Сүрия җитәкчеләре Мәскәүгә килгәч, Ефрат плотинасын кору өчен ярдәм сорап, Совет хөкүмәтенә мөрәҗәгать итәләр һәм бу сөйләшү Ефрат плотинасының төзелүен реаль нигезгә куя.

Минем төп вазифам тәрҗемәче булып Совет һәм Сүрия белгечләрен тимер юл төзүдә булган дөньякүләм казанышлар белән таныштырып бару иде. Шуңа күрә миңа гарәпчә һәм русча китап-журналларны бик күп укырга, өйрәнергә туры килә. Җитмәсә, техника өлкәсендә дә азмы-күпме фикер йөртергә тиешмен. Ташкент университетының Көнчыгыш телләр факультетына кергәнче Сызрань техник училищесын тәмамлавымның шактый ярдәме тиде.

Бездән килгән белгечләр арасында төрле һөнәр ияләре бар: күпер төзү, җир корылмалары буенча инженерлар, геологлар һәм элемтәчеләр. Безнең барыбыз белән дә тәҗрибәле өлкән белгеч Леонид Григорьевич Комолов җитәкчелек итә. Урта буйлы, киң җилкәле бу иптәш эштә искиткеч таләпчән, бик күп яклары белән безнең һәркайсыбызга үрнәк булырлык.

Белгечләрнең тормыш-көнкүреш, культуралы ял мәсьәләләрен хәл итү безгә — тәрҗемәчеләргә тапшырылды. Шуңа күрә без Комолов белән көн дә очрашып тора идек. Минем төп эш урыным төзелеш администрациясе бүлмәсендә: гарәп чиновниклары белән янәшәдә. Хәтта төзелеш директоры урынбасары һәм баш казначей Әбү-Мусаның да урыны минем каршыда гына. Офис директоры Аднан Ильяска без, тәрҗемәчеләр, бик сирәк яки бөтенләй кермибез, чөнки ул теоретик һәм техник мәсьәләләрне генә карый, ә калган эшләрне Әбү-Муса хәл итә. Аның тулы исеме — Әбд-ер-Рәхим Камалетдин. Ләкин безнең белгечләрдән берәү дә аның чын исемен белми. Барысы да Әбү-Муса (ягъни Мусаның әтисе) дип йөртәләр. Чөнки аның алты баласы булып, арада иң яратканы Муса исемле икән. Шуңа күрә дә ул үзен яраткан улы Мусаның әтисе дип атый. Аның кул астында эшләүчеләрнең составы бик чуар. Минем белән янәшә утыручы Госман Шакир — Әбү-Мусаның урынбасары, милләте белән — черкес, мөселман динен тота. Курьеры Мәҗит Харис — христиан. Урта мәктәпне узган ел гына тәмамлаган һәм быел Мәскәүдәге Патрис Лумумба исемендәге Халыклар дуслыгы университетына укырга барырга хыяллана. Чәй һәм кофе таратучы Рәшит Юныс — көрд.

Гарәпләр үзара да, безгә дә ифрат яхшы, җылы мөнәсәбәт күрсәтеп яшиләр. Алар очрашкан саен исәнләшәләр һәм аерылган саен саубуллашалар. Эш кабинетыннан берәр сәгатькә чыгасың икән, кергәндә яңадан исәнләшергә тиешсең. Традиция шундый.

Госман Шакир сөйләвенчә, элегрәк эшчеләр чиновниклардан куркып яшәгәннәр.

әзер исә акча [illegible] генә түгел, эш вакытында, эш урыннарында да эш-
ченәр кызып-кызып үз фикерләрен яклый алалар.

Техникага кагылышлы мәсьәләләрне хәл итәргә яки шәһәр коммуникациясе турында берәр белешмә кирәк булса, без баш инженер белән турыдан-туры тимер юллар төзелеше директоры Аднан Ильяс янына керәбез. Ул әле яшь, күптән түгел генә Алеппо университетын тәмамлаган һәм хәзер гражданлык төзелеше буенча күренекле белгеч. Ләкин аның төп хыялы — Советлар Союзына барып, тимер юл төзелеше инженеры булу.

Бераз алга узып әйтергә мәҗбүрмен. Сүриядән кайтышлый мин аны Мәскәүдә очраттым. Ул анда тимер юл транспорты инженерлары институтында укый иде. Кунак каршы — кара-каршы дигәндәй, мин аны «Үзбәкстан» ресторанына чакырдым, чөнки анда ашларны гарәпләрнекенә охшатыбрак хәзерлиләр. Аднан миңа Мәскәү, аның кунакчыл халкы һәм үзенең укуы буенча фәнни житәкчесе турында исе китеп сөйләде. Үз иленә кайткач, ул Алеппо университетында укыту эше белән шөгыльләнәчәк.

Сүрия шәһәрләрендә итек чистартучыларның исәбе-хисабы юк. Кая гына барма, арттан калмыйлар. Гадәттә алар авыр эшкә ярамый торган яшүсмерләр. Күрәсең, алар өчен ризык табуның бердәнбер ысулыдыр бу.

Урамнарда көннәр буе шау-шу тынмый. Мәктәп формасы кигән балаларны күргәч, күңелләрдә шатлык, горурлык хисе арта. Әле күптән түгел генә бу нәниләр белем алуга хокуксыз иде. Ә бүген исә халык мәгарифе өлкәсендә шактый уңышларга ирешелгән. Гомумән башлангыч белем алу турында хәтта закон кабул ителгән: 7 яшьтән 16 яшькә кадәр балаларның мәктәпкә йөрүләре мәҗбүри.

Биредә эш көндезге өчтә бетә. Ләкин кибетләрдә сату-алу тукталмый. Ресторан, ашханә, фотоательеларның ишекләрендә йозак күрмисең. Тәүлек буе эшләү — аларда гадәти күренеш. Чөнки аларның товары үтми, җитмәсә, кыйммәтчелек. Шуңысы кызык, сату-алу үзе мавыгулы вакыйга. Товар бәяләре көн саен үзгәреп торуы мөмкин. Берничә ел биредә эшләгән безнең белгечләр мине кисәтеп өлгергәннәр иде инде: беренче сораган бәягә һич тә әйбер алырга ярамый. Чөнки бәя бик югары булып, шуңа күнсәң, сине акча ясаучы яки карак дип уйлаулары ихтимал. Сатып алучы башта сатучы сораганның яртысын гына бирә. Сүз ара сүз чыкканда сатучылар япон кинокамералары белән бергәттән безнең «Зенит» фотоаппаратларының да үтемле булуын мактап сөйлиләр.

Гарәп культурасы, әдәбияты, сәнгате белән кызыксынасың икән, китап кибетләренә кагылмый уза алмыйсың. Җиргә батып кергән кечкенә, тар китап кибетләрендә бүгенге язучыларның әсәрләре белән янәшә борынгы гарәп авторларының да китапларын очратырга мөмкин.

Аерым киштәләргә бик пөхтәләп В. И. Ленин әсәрләре тезелгән. Түбәнрәк рәтләрдә рус классикларының әсәрләре. Биредә китаплар бездәгегә караганда ун тапкыр кыйммәтрәк, тиражлары да күп түгел.

Газета-журналлар өчен урамнарда аерым киосклар бар. Аларда Сүриядә чыга торган «Әл-Баас» һәм «Әс-Саура» кебек официаль газеталардан тыш Мисырның «Әл-Әхрәм», «Әл-Әхбәр» газеталары һәм күп кенә Ливан журналлары була. Советлар Союзы турындагы материалларга газеталарда урын көннән-көн күбрәк бирелә. Безнең илчелектә «Вилад-ас-Суфият» («Совет дәүләте») дигән гарәпчә журнал чыгарыла.

Җомга — мөселманнарның ял көне. Дәүләт учреждениеләренең берсе дә эшләми. Мондый көннәрне без Урта диңгез буена экскурсия оештырырга тырышабыз.

Сүриянең төньяк-көнбатыш ярлары 200 километрларга сузыла. Безгә иң якын урыны 90 чакрымлап. «Ландровер»ларга («Газ-69» маркалы машиналарга тартым) утырып сәгать ярымлык юлга кузгалабыз. Тартус шәһәренә 5 километрлар кала машина сулга борыла.

Вак йөгерек дулкыннар уйнашып ярларга менәләр. Һава искиткеч саф, ял өчен рәхәт. Ярга басып диңгезне, аның зәңгәрсу киңлекләрен күзәтәсең. Ләкин, кая гына барма, нинди генә матурлык, рәхәтлек тойгылары татыма, туган ил, Казан, шаулы Идел ярлары искә төшә. Дусны гына түгел, Ватанны сөю хисен дә еракта ныграк тоясың икән. Бигрәк тә ялгыз калган минутларда сагындыра.

бер китапларда язылганча, Сүриядә аларның саны өч йөз меңгә җитә. Алар башлыча терлекчелек белән көн күрәләр, сөт, май, тире, йон хәзерләү белән шөгыльләнәләр. Киемнәре бик сәләмә. Балалары ялан аяк, ялан өс йөриләр. Тору урыннары — палатка яки камыштан үрелеп эшләнгән алачык. Ел буена күченеп йөргәнгәме — торак урыннарында бернинди дә җиһаз юк.

Бәдәвиләр кабилә-кабилә булып яшиләр. Кабиләләрне исә берничә гаиләдән торган ыруглар тәшкил итә. Ыруг — бер бабадан килгән нәселнең җыелмасы. Һәр ыругның сайлап куела торган аксакалы бар. Аксакал итеп иң өлкән, тәҗрибәле кеше сайлана, чөнки терлекләрнең туклыгы һәм ыруг-кабиләнең язмышы аның осталыгына бәйләнгән. Аксакалларның саны бер кабиләдә берничә булуы мөмкин. Арадан берсен шәех яки кабилә башлыгы итеп сайлыйлар. Кабилә башлыгы, көндәлек эшләрне бергәләп хәл итү өчен, үзенә киңәшчеләр сайлый.

Барыбызны да гаҗәпләндергәне шул булды: фәкыйрь яшәүләренә карамастан, бәдәвиләр искиткеч кунакчыл һәм гадел халык. Әгәр юлаучы-фәлән кереп туктала икән, алар аны ашатып-эчертәләр дә ятып ял итәргә урын тәкъдим итәләр. Ләкин кем ул, кая бара? Андый сорауларны бирмиләр. Һәр кабиләнең үз шагыйре бар. Шәех катлаулы мәсьәләләрне хәл иткәндә гадәттә шагыйрь сүзеннән башка бер карар да кабул итми. Шагыйрь, ирләрнең батырлыгын, хатын-кызларның гүзәллеген җырлаудан тыш, политик мәсьәләләргә дә катнаша.

Бәдәвиләрнең искиткеч гадел, пакь күңелле булуларын әйткән идем инде. Аларда кеше әйберенә тию гадәте юк, шуңа күрә ишекләре дә бикләнми. Бервакыт гарәпләр миңа шундый хәл сөйләделәр: бәдәвиләр чүлдә адашкан кәҗәләр төркемен күрәләр, ләкин кемнеке, кайсы кабиләнеке икәнен белмиләр. Шулай да, хуҗасын эзләп табып, кәҗәләрне кайтарып бирәләр.

Бәдәвиләрнең яшен чамалау кыен. Бер бәдәвине мин илле яшьләрдәдер бу дип уйлаган идем. Ләкин аның үземнән ике генә яшькә өлкән икәнен белгәч, исләрем китте. Аның ике хатыны һәм ун баласы бар икән, шуның өстенә өченче хатын алырга җыена иде. Якын араларда тагын бу тирәләргә киләчәгебезне әйткәч, аның кояшта янып җыерчыкланган йөзе балкып китте. Ул безне туена чакырды. Туй чыгымнары якынча 3—4 мең лир тәшкил итә. Калымга акча яисә терлек китерәләр.

Бәдәвиләрдә кызлар ирекле. Алар, шәһәр кызларыннан үзгә буларак, егетнең тәкъдимен кире кагарга да хокуклылар икән.

Бүген Офиска Сүрия тимер юллары генераль директоры Габдел-Кәрим Шәми әфәнде килде. Австриядән кайтарылган яңа автомотрисаларны сынауда катнашачак. Габдел-Кәрим Шәми яшь әле, ләкин үз эшен яхшы белә, белгечләр арасында да зур авторитет казанган. Автомотрисалар Ливан башкаласы Бейрут белән Алеппо шәһәре арасында йөриячәкләр. Шушы мәсьәләләргә кагылышлы рәвештә бүген үк ике чик буендагы Аккари станциясендә Ливан һәм Сүрия вәкилләре арасында сөйләшү булачак. Бу сөйләшүләргә, кунак буларак, безнең баш инженер да чакырылды. Мин бераз дулкынланам, чөнки мондый җаваплы сөйләшүләрдә беренче тапкыр катнашуым. Һәр ике якның фикерен төгәл һәм дөрес итеп җиткерү миңа тапшырылды.

Хомс станциясендә, Шәми әфәнденең әмере белән, Аккарига баручы автомотрисага утырабыз. Автомотриса — ике тимер вагоннан торган поезд. Эче киң, пәхтә, якты. Урындыклар иркен һәм йомшак. Шәми әфәндене озатучы чиновниклар белән машинист кабинасына узабыз. Алда без барасы юлның рельслары сузылган. Бу юл, совет белгечләре катнашы белән, яңабаштан корылачак. Шуңа бәйләнешле берничә мәсьәләне безнең баш инженер тиз генә хәл итеп алды.

Бер сәгатьтән без инде Аккарида идек.

Сүриялеләр Ливан вәкилләрен көткән арада без, кабинадан чыгып, диңгез ярын әйләнәбез. Көчле җил исүдән һава салкынча иде.

Станция яшеллеккә күмелгән. Якынына ук килеп җитмичә, биек, куе агачлар арасыннан йортлар күренми. Леонид Григорьевич, безнең баш инженер, бу агачларны кисәргә туры киләчәген әйтә, чөнки станция машинистка еракτан ук күренергә тиеш.

нарга утырышабыз. Леонид Григорьевич Хомстан алып килгән совет газеталарын караштыргалый һәм ара-тирә минем комментарийларны да игътибарсыз калдырмый.

Көндезге сәгать икеләр тирәсе, тәнәфес ясыйбыз. Гарсон кечкенә махсус корзинкаларда һәркайсыбызга сандвичлар өләшә. Каз ите, помидор, суган, яшел борычтан эшләнгән искиткеч тәмле ашамлык ул. Аны ашаганнан соң шундый ук корзинкаларда виноград тәлгәшләре, апельсин, мандарин һәм холодильникта тотып суытылган берәр шешә лимонад китерәләр. Шәми әфәнде, якынрак килеп, кәефебез белән кызыксына, сыйның чамалы булуы өчен гафу үтенә.

Югары белемне ул Франциядә алган. Тапкырлык һәм үз-үзен тоту манераларын да бәлки Парижда алып кайткандыр.

Төшке аштан соң сөйләшүләр яңадан башлана. Күп кенә бәхәсле мәсьәләләрне һәр ике якка да файдалы итеп хәл иткәч, тиз генә кул куеп рәсмиләштерәләр.

Урамда яңгыр чиләкләп коя иде. Шуңа күрә сириялеләр кунакларны үз территорияләренә кадәр без утырып килгән автомотрисада озата барырга булдылар.

Кичен без «Зөһрә» кинотеатрына барабыз. Анда ватандашларыбыз — «Березка» ансамбле гастрольләре. Күптәннән инде үзебезнең кино һәм концертларны караган юк.

Безнең артистларның Дәмәшктә зур уңыш казанганлыгын Сүрия үзәк газеталарын укып белгән идем. Хомс шәһәрендә чыга торган «Уруба» газетасы да «Березка» коллективының осталыгын сокланып мактады. Сүз уңаенда әйтергә кирәк, борынгы культура үзәге булган Сүриядә профессиональ театр юк. Дөрес, безнең Офистан ерак түгел «Әл-мәркәз ассакафия» (Культура үзәге) дигән берничә квартал бар. Анда кайчакларда үзешчән театр коллективлары чыгыш ясыйлар.

Моннан берничә ел элек совет балетмейстеры Георгий Потрай җитәкчелегендә Сүриядә беренче дәүләт хореографик ансамбле «Амея» төзелә. Ул халык җырларын һәм биюләрен башкаручыларны, музыкантларны һәм сәләтле студентларны берләштерә. Кыска гына вакыт эчендә ансамбль, күрше гарәп илләренә гастрольләр ясап, уңыш казана. Сүрия композиторы Мотый Мысри бу ансамбль өчен махсус программа төзегән.

Ял көннәренең берсендә миңа бу талантлы коллективның чыгышын карарга туры килде. Бигрәк тә истә калганы — «Чәчәк сатучы кыз» биюе иде. Сәхнәдә зифа буйлы кыз, өстендә кара күлмәк. Кулларында чәчәкләр белән тулы кәрзиннәр. Мөләем елмаеп, ул аларны узган-барганнарга тәкъдим итә. Ләкин берәү дә сатып алмый, кызның йөзенә кайгы, моң, хәсрәт чыга. Кинәт ул, бөтен залны таң калдырып, елмаеп куя һәм чәчәкләрне залда утыручыларга өләшә дә, көчле кул чабулар астында, сәхнәдән югала.

Сүрияләләр кинофильмнар карарга яраталар. Хомста унлап кинотеатр булып, барысы да үзәккә урнашкан. «Хомс», «Зөһрә», «Аш-Шәрыкъ» кинотеатрларына гадәттә иркенрәк яшәүчеләр йөри, чөнки анарда билетлар шактый кыйммәт. Бездәгедән үзгә буларак, балконнардагы урыннар кыйммәтрәк тора. Партерга исә солдатлар һәм тәмәке тартып, көнбагыш ашап утырырга яратучылар билет алалар.

Кинотеатрларда көнгә өч кенә сеанс була. Сүриянең үз киностудиясе юк. Соңгы вакытларда Мисыр кинолары аеруча зур уңыш белән бара. Шундыйларның берсе ике серияле «Сәлах-эд-дин» иде. Фильм тамашачыларны Сәлах-эд-дин солтан хакимлек иткән (1169—1193) чорларга, ягъни гарәпләрнең төре йөртүчеләр белән көрәшкән елларына илтә. Сәлах-эд-дин искиткеч нык ихтыярлы, оста җанлы полководец итеп сурәтләнә. Аның властена Мисырдан кала Триполь, Сүрия һәм Месопотамия дәүләтләре берләшә (1187 ел) һәм Иерусалим шәһәре тулысынча мөселманнар кулына күчә. Сәлах-эд-диннең батырлыгы һәм тыйнаклыгы хәтта төре йөртүчеләрнең башлыгын да сокландыра. Сөйләүләренә караганда, Сәлах-эд-дин үлгәч, аның кесәсеннән бары тик берничә генә тиен акча табалар. Төре йөртүчеләрнең иң фәкыйрь дигәне дә аңардан күп тапкырлар баерак йөри торган була.

Кызганычка каршы, андый картиналар бик сирәк. Кинотеатрларның күпчелеге, доход алу максаты белән, башлыча Америка һәм көнбатыш Европа фильмнарын күрсәтәләр. Аларның нигезендә исә — кешеләр арасында шәхси, интим мөнәсәбәтләр генә, ә социаль-иҗтимагый проблемалар бөтенләй юк.

рәп тамашачылары яратып карыйлар.

Хәтерләвемчә, 1967 елның җәендә — мин ул чакта Халебта идем,— прогрессив җәмәгатьчелек таләбе белән кинотеатрларның хуҗалары Америка һәм Англия фильмнарына бойкот белдерделәр. Ләкин түземлекләре атнадан артыкка бармады. Керем азайгач, яңадан күрсәтә башладылар.

* * *

Безнең группа Хомс станциясеннән Аккарига кадәр участокны тикшерергә тиеш. Минем бурыч — якын тирәдәге авыл халыклары ярдәме белән инженер-элемтәче Николай Павлович Крыловны җирле шартлар белән таныштырудан гыйбарәт иде.

Көн аяз, күңел күтәренке. Берәр гарәпне туктатып сөйләшкән саен үзеңә ниндидер яңалык ачасың шикелле.

Шунысы гаҗәп, гарәп крестьяннары ата-бабалары яшәгән җирләрдән еракка китмиләр. Йортларын да бер тирәгәрәк салырга тырышалар. Шуңа күрә алар яшәгән урын калкулыкны (гарәпчә тель) хәтерләтә. Тель-Калах, Тель-Авив, Тель-Амарна кебек күп кенә шәһәр һәм авылларның исеме шуның белән аңлатылалар.

Табигатьнең юмарт булуы җиләк-җимеш һәм авыл хуҗалыгы культураларыннан елга берничә тапкыр уңыш алырга мөмкинлек бирә. Су булган урыннарда җир саргылт һәм уңдырышлы. Арык буйларына килеп чыксаң, өлгергән җимешләре асылынып торган ачык яшькелт хөрмә, апельсин агачлары күзнең явын ала. Ләкин дым җитмәү аркасында күп кенә өлкәләрдә җирне икешәр ел чәчми торалар. Шуның өстенә кайбер урыннарны тулысынча чуерташ баскан. Андый мәйданнарны эшкәртү ифрат кыйммәткә төшә. Җитмәсә, юллар да начар, кирәкле төшкә бару өчен шоферлары да атлыгып тормый.

Без, машинадан чыгып, ике калкулык арасына урнашкан авылга җәяү генә барырга булдык.

Николай Павлович Крылов калкулыкка менүгә туктап калды һәм якында гына күренгән борынгы крепость хәрабәләрен фотога төшерә башлады. Мин аның коллекцияләр альбомының тагын да баюын уйлап алдым.

Юл буенда бер фәллах җир эшкәртеп ята иде. Мин аның янына килдем. Ярым бөгелгән, сакал баскан яңакларыннан тир ага. Мин, кулымдагы картаны ачып салдым да, якын-тирәдәге авылларны сораштыра башладым. Гарәпчә әдәби телдә сөйләшүем язу-сызу танымаган бу фәллахка сәер тоелды, ахры. Ул беразга сөйләшә алмый тотлыгып калды. Сорауларыма акрынлап җаваплар ала башлагач төшендем тагын: ул мине алла тарафыннан җибәрелгән яңа пәйгамбәр дип аңлап, үзен әлеге пәйгамбәрне беренче күрүче дип уйлаган икән.

Биредә кул белән чәчеп, кул белән уралар, җилле көн булса, шунда ук сугып һәм җилгәреп тә алалар. Кыскасы, авыл хуҗалыгы культураларын җитештерүдә моннан йөз ел элек нинди ысуллар кулланылган булса, хәзер дә шулай ук эш итәләр.

Әлеге гарәпнең исеме — Мөхәммәт. Җыерчыклы йөзенә карап, аңа 50 яшьләр бирерсең. Ә үзе 36 да гына. Ул безне өенә кунакка чакырды. Мондый чакта аның теләгән кире кагып булмый һәм алай кирәк тә түгел иде. Чөнки ул безне чын күңеленнән чакырды.

Аның йорты таш белән әйләндереп алынган. Өе тәбәнәк, озын, стеналары, ярым хәрабә хәлендә килеп, җиргә батып кергән. Ватык пыялалы тәрәзәләре ишек алдына, караңгы якка караган.

Гаиләсендә 12 кеше. Шулар нибары ике бүлмәдә яшиләр. Аның да алгы яктагысында зур-зур икмәк капчыклары. Үзе генә әмәлләп куйган өстәл-шкафларда тимер һәм чүлмәк савыт-сабалар. Өйдә күпме ир заты булса — барысы да безне кыстарга керештеләр. Алар безгә нинди дә булса ярдәм күрсәтергә әзер торалар иде. Юынырга чыгабыз, өлкән улы кулларыбызга комган белән су салып тора. Икенчесе исә арттан сөлгеләр күтәреп килгән. Хатын-кызлар исә шәригать кушканны төгәл үтә: ят ирләргә күтәрелеп карамыйлар.

Фәллахлар, бәдәвиләр кебек, кунакчыл халык. Әгәр берәр әйбер алып, аның өчен акча сузасың икән, алмыйлар. Төшке аш өчен акча тәкъдим итүебез белән без игенче Мөхәммәтне генә түгел, аның бөтен гаиләсен гаҗәпкә калдырдык.

Революциягә кадәр 12 кешелек гаилә бер аршин җирсез яшәгән. Илдә җир реформасы уздырылгач кына аларга җир бирелгән. Дөрес, әлекке җир хуҗаларының йогынтысы бетеп үк җитмәгән әле. Авыл хуҗалыгы кораллары, ясалма сугарылышлы мәйданның күбесе әлегә алар кулында. Кирәк нәрсәне сорап, еш кына аларга барырга туры килә. Авыл старосталарын (мохтар) сайлап кую кебек күренешләр законлаштырылса да, гомуми тигезлек турында сүз йөртергә иртәрәк.

Ләкин Сүрия крестьяннары күп вакыт кооперациягә мөрәҗәгать итәләр. Кооператив оешмалар аша трактор, комбайн кебек авыл хуҗалыгы машиналарын алырга тырышалар. Уңдырышсыз җирләрне эшкәртү шулар аша эшләнә.

Героик Сүрия халкының хәл итәсе проблемалары күп әле. Миңа гарәп авылларының берсендә җыелышта булырга туры килде. 20 яшьләрдәге бер егет, авыл мөгаллиме булса кирәк, баасчылар партиясенең программасы куйган бурычлар турында сөйләде. Ул Сүрия халкының уңышлары, илнең экономикасын үзгәртеп корудагы авырлыкларга тукталды.

Безнең шофер аңа биредә совет белгечләре барлыгын һәм минем гарәпчә белүемне җиткерде булса кирәк, әлеге егет яңадан торып басты һәм нәрсә дә булса әйтүемне сорады. Шунда күпләр аның сүзен хуплап кул чаба башладылар. Ярлы гарәп халкының совет иленә, совет кешеләренә зур өметләр баглаганын белгәнгә бөтенләй ят, таныш булмаган, ләкин миңа ихтирам белән караган халык алдына чыгып басарга кыюлыгым җитте. Коммунистлар партиясе, совет хөкүмәтенең азатлык өчен көрәш алып барган колониаль илләргә һәрвакыт ярдәм кулы сузарга әзер торуын, Сүрия крестьяннарының минем туган илемә зур ышаныч белән каравын һәм һич тә ялгышмавын әйттем.

Эштән кайтышлый Сүрия газеталарын ала торган гадәтем бар, чөнки һәр атнаның дүртенче көнендә үзебезнең белгечләргә политинформация үткәрергә кирәк. Тыңларга белгечләр генә түгел, хәтта аларның хатыннары да килгәли. Үзең яшәгән илдәге вакыйгаларны һәркемнең белеп торасы килә. Ә Сүриядә вакыйгалар бик җитди һәм катлаулы. 1966 елның декабрендә, Сүрия белән «Ирак — петролеум компаньон» дигән империалистик монополия арасындагы конфликт аркасында, Киркука районыннан Сүриянең Банияс һәм Ливанның Триполи портына торбалар буенча нефть кудыру туктатылды. Гаеп тулысы белән Англия, АКШ, Франция, Голландия капиталыннан торган әлеге монополия ягында иде. Чөнки компания 1965 елны Сүрия территориясе аша 43 миллион тонна ягулык кудыра. Алдан килешенгәнчә, транспортировкадан алынган табышны компания белән Сүрия дәүләте үзара урталай бүлешергә тиеш булалар. Әмма компания хуҗалары нефть кудырудан алынган табышны бухгалтерия кәгазьләрендә аз итеп күрсәтәләр һәм Сүриягә тиешле сумманы 10 ел буе бирми киләләр. Сүрия экспертизасы күрсәткәнчә, компания шушы вакыт эчендә 40 миллион фунт стерлингны яшереп калдыра.

Империалистлар шулай ук Сүрия белән Гыйрак арасындагы мөнәсәбәтләрне начарландыруны да истән чыгармыйлар.

Торбаларның эшсез торуы Гыйрак дәүләтенә елга 75 миллионга төшә. Бу исә Гыйрак өчен еллык доходның яртысы югалту дигән сүз. Шушындый авыр һәм катлаулы елларда гарәп илләре бер-берләре белән киңәшеп, ярдәмләшеп эш итәләр. Ул көннәрдә Гыйрак һәм Ливан хөкүмәте Сүриянең таләпләрен тулысы белән яклап чыктылар. «Гарәп нефте гарәпләргә!» — диделәр алар бер авыздан.

*Ахыры бар*

# МУЗЕЙНЫҢ ӘДӘБИ ФИЛИАЛЫНДА

Татарстан Дәүләт музее инде күп еллардан бирле татар әдәбияты тарихына караган материалларны туплау, өйрәнү һәм пропагандалау буенча шактый эш эшләп килә.

Казанда әдәбият музее ачу яки музей каршында әдәби филиал оештыру мәсьәләсе җәмәгатьчелек тарафыннан 25 ел элек үк кузгатыла. Күренекле татар язучысы Г. Кутуй 1944 елның 21 июнендә ТАССР Верховный Советы сессиясендә ясаган чыгышында болай дигән иде: «Мин Пушкинның каләмен, аның кульязмаларын күргәнем бар. Аларга 100 елдан артык. Алар зур мәхәббәт белән музейда саклана. Тукай моннан 30 ел элек үлде, ә мин аның каләмен, аның кульязмасын кайда күрә алам! Шуны ук Гафури, Такташ һ. б. турында да әйтергә була. Безгә әдәби музей кирәк».

Ниһаять, 1967 елда татар Дәүләт музее каршында татар әдәбияты филиалы ачылды һәм эшкә кереште. Шушы кыска гына вакыт эчендә әдәбиятыбыз тарихына караган шактый материал тупланды. Анда хәзер күп кенә язучыларның китаплары, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Ш. Камалның шәхси әйберләре, һ. Такташ китапханәсе, Кенигсберг шәһәре тирәсендәге сугышта һәлак булган шагыйрь Ф. Кәримнең пулялар белән тишкәләнгән шинеле һәм башка шундый мөһим, кадерле әйберләр бар.

Соңгы елларда, тематик план төзү һәм булачак экспозициянең тематикасын эшләү белән бергә, музейга материал туплау да бик актив алып барылды. Музей фондларында булган материалларны җентекләп өйрәнгәннән соң, экспозициягә кирәкле өстәмә материалларны җыю планы төзелде. Бу планда борынгы әдәбиятка, Ватан сугышы чоры әдәбиятына һәм бүгенге әдәбиятка караган материалларны җыйнауга төп игътибар бирелде.

Эшне үзләре сугышта катнашкан һәм хәзерге көндә дә исән, актив эшләп килүче язучылардан башладык. Бөек Ватан сугышы чоры әдәбияты бүлегенә татар язучыларының фронт блокнотларын, куен дәфтәрләре, фронт газеталары өчен язылган бәлешмәләр, хәрәкәттәге частьләргә бару өчен бирелгән таныклamалар, сугыш хәрәкәтләренең карталары, хатлар, кыр сумкалары, сугыш шартларына җайланган ручка-карандашлар, язучы белән кырыс сугыш юлларын үткән юл капчыклары һ. б. җыйнадык. Язучылар катнашында чыгарылган фронт газеталарын да читтә калдырмадык. (Үзәк Политуправлениенең карары буенча, сугыш елларында татар телендә 15 кә якын исемдә газета чыгарыла.) Бу газеталарда, информбюро хәбәрләре белән беррәттән, әдипләребезнең шигырь һәм поэмалары, хикәя һәм очерклары да басылып килгән.

Хәзерге көн әдәбияты буенча материал туплаганда музей хезмәткәрләре төп игътибарны язучыларыбызның җәмәгать эшчәнлеген һәм иҗат характерын күрсәткән әйберләрне җыюга юнәлттеләр. Мәсәлән, күп еллар буе нефтьчеләр арасында яшәп, аларның хезмәте турында романнар язган Г. Ахунов нефтьчеләр үзенә бүләк иткән каскаы, бөтен ил күләмендә үткәрелгән күп кенә әдәби очрашуларда татар әдәбияты вәкиле булып катнашкан шагыйрь Зәки Нури Казагыстан укучылары, Хакасс шагыйрьләре бүләк иткән сувенирларны, Г. Әпсәләмов Йолдыз шәһәрчеге укучылары үзенә бүләк иткән медальне, безнең үтенүебез буенча, музейга тапшырдылар.

Бүлек хезмәткәрләре 40 лап язучының өендә [кайберләрендә берничә тапкыр] булдылар. Безнең мөрәҗәгатькә җавап итеп, музейга үзләренең әсәрләренең төрле варианттагы кульязмаларын, аларның беренче һәм соңгы басмаларын, автографлар белән каләмдәш дуслары бүләк иткән китапларны, теге яки бу әсәрнең популярлыгын, язучының тормыш белән ни дәрәҗәдә бәйләнешен күрсәткән укучылар хатларын, авторларның әсәрләрендә прототип булып хезмәт иткән кешеләрнең фоторәсемнәрен һ. б. күп материалларны бүләк иткән язучыларга без чын күңелдән рәхмәт әйтәбез. Аеруча кыйммәтле материалларны без язучы Г. Бәширов, Г. Әпсәләмов, С. Хәким, Г. Минский, А. Шамов, Р. Ишморат һ. б. иптәшләрдән алдык.

Язучыларның гаиләләрендә, туганнарында бик күп кыйммәтле әйберләр саклана. Музей хезмәткәрләре аларның күбесе белән бәйләнешкә керделәр. Күренекле татар шагыйре, Бөтенсоюз укучыларына яхшы таныш, «Шүрәле» балеты, «Җәлил» операсы либреттолары авторы Әхмәт Фәйзинең бик кыйммәтле кульязмаларын, скрипкасын, күзлеген һ. б. шагыйрьнең сеңелесе Зәйнәп Фәйзиева тапшырды. Фашист тоткынлыгында Муса Җәлил белән бергә һәлак булган күренекле татар совет балалар язучысы Абдулла Алишның сеңелесе И. Сункишева исә язучының хатларын, документларын, кара савытын һ. б. әйберләрен бирде.

Әдәбиятыбыз тарихын яңа фактлар белән тулыландыру өчен, музей ТАССРның культура министрлыгы каршында татар әдәбияты классикларының архивларын сатып алу мәсьәләсен куйган иде. Бу мәсьәлә уңай тапты, нәтиҗәдә 1969—70 елларда Фатих Кәрим, Кави Нәҗми, һади Такташ, Шәриф Камал архивлары музей байлыгына әверелде. Ә ул архивларда шактый кызыклы материаллар бар. Мәсәлән, Ш. Камалның моңарчы әле беркайда да басылмаган «Шик» исемле комедиясе, һ. Такташның «Камил» исемле киносценарие һ. б.

Кайвакыт язучыларның туганнарында турыдан-туры язучыга карамаган, ләкин аның популярлыгын күрсәткән әйберләр дә очрый. Мәсәлән, Ф. Кәрим архивы [аның сугыш блокнотлары, хатлары, шагыйрь бүләкләнгән Ватан сугышы ордены] белән бергә, тагын бер бик мөһим экспонат алынды. Ташкентта уткәрелгән Азия-Африка илләре язучыларының конференциясендә, тәрҗемәче булып, Ф. Кәримнең сеңелесе Зара Муратова да катнаша. Бер тәнәфестә Назыйм Хикмәт аны Ирак шагыйре-революционер Салях Бахр Аль-Улюм белән таныштыра. Ирак шагыйре, Ф. Кәримнең сеңелесен күреп, бик нык дулкынлана һәм Ф. Кәрим шигырьләрен Ирак революционерлары төрмәләрдә укуларын, ул шигырьләр авыр төрмә газапларын җиңәргә ярдәм итүен әйтә. Татар шагыйренең героик поэзиясе каршында баш иеп, ул үзенең кулындагы йөзеген салып Зарага бирә. Бу экспонатның тарихы шундый. Без ул тарихны тагын да ачыкларга — нинди юллар белән Ф. Кәримнең шигырьләре Ирак төрмәләренә үтеп керүен һәм аларның хәзерге көннәрдәге язмышын белергә тырышачакбыз.

Музейга материал туплау эшендә әдәбиятчы-галимнәр зур ярдәм күрсәтә. Алар консультация, киңәшләр бирү, теге яки бу материалны кайдан эзләргә кирәклеген әйтү белән бергә, үзләре тапкан әйберләрне дә музейга бик теләп тапшыралар. Музей гыйльми советының актив члены, Муса Җәлилнең иҗат һәм тормыш юлын туктаусыз өйрәнүче Гази Кашшаф шагыйрьнең васыятен, Советлар Союзы Герое грамотасын һәм Ленин премиясе лауреаты дипломын тапшырды.

Музейга материал туплаганда музей хезмәткәрләре аерым коллекционерлар белән дә бәйләнешкә керделәр. Композитор Нәҗип Җиһанов безгә Муса Җәлилнең бил каешын тапшырды. Ул каешның тарихы болай: М. Җәлил фронтка китәсе кичне Н. Җиһанов аның белән, «Алтынчәч» операсының премьерасы хакында сөйләшеп, шәһәр урамында йөргән. Шул кичне аерылышканда, борынгы гадәт буенча, алар бил каешларын алмашкан булганнар.

Уральскида яшәгәндә Г. Тукайның Камил Мотыйгый белән якын таныш булуы билгеле. Менә шул кешенең улы Хәмит Төхфәтуллин Уральскидагы Мотыйгыя мәдрәсәсендә Тукайның беренче шигыре һәм публицистик мәкаләсе басылган кульязма журналны, «Яңа тормыш» исемле газета чыгару өчен төзелгән, Тукайның русча имзасы куелган договорны, шагыйрь файдаланган кара савытын тапшырды.

Мәгълүм булганча, Бөек Ватан сугышы елларында күп кенә рус язучылары республикабызның Чистай шәһәрендә эвакуациядә яшиләр. Чистайда яшәүче Авдеевлар гаиләсе нәк шул язучылар белән тыгыз элемтәдә була. Язучылар үзләре, шаярып,

Авдеевлар йортын «язучылар союзы клубының филиалы» дип йөрилэр. Ул йортның хуҗасы Валерий Дмитриевич Авдеев хәзер Ровно шәһәрендә яши. Ул Киев университеты филиалының профессоры. Валерий Дмитриевич музейга рус язучыларыннан Л. Леонов, М. Исаковский, Н. Асеев, Б. Пастернак, К. Треневларның Чистайда яшәгән вакытларында автографлары белән үзенә бүләк иткән китапларын һәм Чистайда төшкән фоторәсемнәрен бүләк итте.

Музейда язучыларның портретларына, скульптураларына һәм биографик картиналарына да зур урын бирелеп, алар әдәби экспозициянең аерылмас кисәген тәшкил итәләр.

Музейның «Язучылар Җәлил турында» дигән бүлегенә тупланган материалларны без төрле милләт әдипләренә хатлар язып, соратып алдык. Беренче булып безнең хатка казакъ язучысы Җубан Мулдагалиев җавап бирде. Ул үзенең казакъ, рус, татар, үзбәк, таҗик телләрендә чыгарылган «Җыр үлми» исемле поэмасын җибәрде. Китапларының берсендә аның «Бу поэма — данлы Җәлилнең үлемсез поэзиясе һәм батырлыгы алдында тез чүгүем билгесе» дип язылган. Аның артыннан Ю. Корольков, Н. Тихонов, С. Щипачев, С. Смирнов, К. Симонов, П. Бровка, Э. Межелайтис, Б. Кербабаев, М. Турсун-задә, Г. Леонидзе, Р. Рза һ. б. бик күпләр М. Җәлил турындагы фикерләрен язып җибәрделәр.

Менә шундый байтак кына файдалы эшләр эшләнсә дә, музейга материал туплау эше һәр яктан да яхшы бара дип булмый әле. Мәсәлән, материал җыю буенча фәнни экспедицияләр, язучылар булган, яшәгән һәм эшләгән урыннарга — Ибраһимов һәм Гафури яшәгән Уфа, М. Җәлил һәм Ш. Камал яшәгән Оренбург, Тукай яшәгән Уральск шәһәрләренә командировкалар оештырылмый.

Татар әдәбияты тарихына караган материаллар төрле җирләргә чәчелгәннәр. Аларны бер җиргә, бер кулга җыю мәсьәләсен бик кискен куярга кирәк. Югыйсә, вакыт үтү белән алар юкка чыга бара. Мәсәлән, без бик озак эзләп Ш. Мәрҗани китапханәсенең эзенә төштек һәм аны музейга алуны тизләтүгә бөтен көчебезне куйдык. Ләкин соңыннан ул китапларның, начар урында саклануы нәтиҗәсендә, бөтенләй эштән чыгулары билгеле булды...

**С. ПИСАРЕВА,**
музейның әдәби бүлек мөдире.
**Д. БАҺАУТДИНОВА,**
музейның өлкән фәнни хезмәткәре.

# КОМИССАР КАНЫ

«20 август, 1918 ел, Мәскәү. Үзәк мөселман комиссариатыннан

Астрахань хәрби мөселман комиссариатына.

Тирән кайгыгызны чын күңелдән уртаклашабыз. Ип. Туйбактинны ерткычларча үтерүче контрреволюционерлардан һәм башка намуслы революционерлар тормышына кул сузучылардан каты рәвештә канлы үч алыныр. Революцион демократия акгвардиячеләр фетнәсенең тамырын кисеп ташлар...

Комиссариатның председателе урынбасары:

*Г. Ибраһимов*».

## Астраханьда вәхшилек



Ерак Астрахань киеренке көннәр кичерә. Монда кеше хакын ашап симергән капкорсаклар, эш башыннан сөрелгән аксөякләр — буржуазия һәм аның ялчылары, революциягә каршы һәртөрле кара көчләр, үзләренең яшеренгән караңгы почмакларында колакларын торгызып, чак тыннарын алып, түземсезлек белән Советлар хөкүмәтенең зәгыйфьләнүен көтәләр. Эшче-крестьян дәүләтенең чак кына көчсезләнүен сизүгә әлеге кара козгыннар, яшеренгән урыннарыннан тиз генә ябырылып чыгалар да революция ясаган халык өстенә ташланалар: аның йөрәген чукырга керешәләр.

1918 елның җәе.

Көндезге сәгать уннар тирәсендә шәһәргә хәвефле хәбәр тарала: «Фронтка җибәреләсе солдатлар арасында низаг чыккан...» Моны ишетү белән, буржуазия агентлары һәм аның ялчыларының, контрреволюционерларның һәммәсе [illegible] крепостька таба йөгерәләр: зарыгып көткәннәре килде, янәсе, форсаттан файдаланып калырга, айлар буе җыйналган үч-ачуны алып калырга кирәк. Алар шунда ук Советка каршы пычрак агитация, кабахәт яла ягу эшен башлап җибәрәләр. Билгеле, политик мәсьәләләрдә тәҗрибәләре һәм белемнәре булмаган солдатлар арасында бу хәбәргә ышанучылар да табыла. Шуңардан файдаланып, буржуазия бөтен контрреволюционерларга корал тарата башлый. Тәмам коралланып беткәч, карагруһлар эшкә тотыналар: шәһәрдәге барлык совет оешмаларын җимерә-туздыра, талап, очраган



кызылармеецләрны һәм комиссарларны кыйнап яки үтереп йөри башлыйлар. Погромчылар походының башында Астраханьның мәшһүр буржуйлары, кара байлары һәм аларның гимназист уллары бара. Кемнәрне кыйнарга, кемнәрне асарга яки атарга, нәрсәләрне, нинди оешмаларны таларга, ватарга, җимерергә — башлап шулар күрсәтеп йөри, хулиганнарга шулар командирлык итә.

Һәркемнең үз дошманы бар. Һәркем үч алырга ашыга. Татар буржуазиясе һәм аларның ялчылары, башлап, Астраханьдагы Мөселман комиссариаты бинасына ташланалар. Янәсе, дөньядагы бар явызлык шул йорттан башлана: комиссариат кешеләре аларны гәҗитсез калдырган, шулар аларга күтәрә алмаслык зур налоглар салган, аларның «милли мөселман дружинасы» дип исемләнгән оешмаларын да шул ук комиссариат егетләре коралсызландырган. Һәммәсе өчен үч, үч алырга!.. Комиссариат кешеләренең, бигрәк тә аның комиссары, революционер Туйбактинның канын коярга!..

Комиссариат егетләре күзләрен кан баскан бандитлар төркемен пулеметлар һәм мылтыклар белән каршы алалар. Теләгәндә, әлбәттә, комиссар Туйбактин аларның һәммәсен «әһ» дигәнче аттырып та бетерә алган булыр иде (бәлки, шулай кирәк булгандыр да). Ләкин ул аттырмый. Гуманист-революционерның кан коярга кулы бармый.

— Иптәшләр! Зинһар, атмагыз! Безнең өскә килә торган татарлар үзләренең наданлыклары аркасында безгә һөҗүм итмәкче булалар. Без аларга яхшы итеп аңлаткач, шаять, безгә зарарсыз рәвештә кайтып китәрләр. Атмагыз, иптәшләр, кешеләрнең канын түкмәгез! — ди ул иптәшләренә.

Аның бу сүзләреннән соң, иптәшләре корулы пулеметларын һәм мылтыкларын читкә алып куялар. Комиссар Туйбактин исә котырынган халык төркеме алдына корапсыз-нисез чыга да сүз башлый:

— Мөселманнар! Сез ни өчен бу кадәр вәхшиләрчә кыланасыз! Миңа сүз бирегез. Һәммәсен дә аңлатырмын.

Ләкин аңа сөйләргә бирмиләр. Аның сүзләре алданган кешеләргә нинди тәэсир ясаячагын буржуазия ялчылары яхшы белә. Кызарган күзле юан корсакларның берсе, төкерекләрен чәчә-чәчә:

— И кафер! И мәлгунь! Әләктеңме!!! Син безнең мәчетләребезне яндырырга, балаларыбызны чукындырырга йөри идең,— дип акырынырга тотына.

— Ни карап торасыз...

— Башын бетерегез мәлгуньнең!!

Күзләрен кан баскан фанатиклар Туйбактин өстенә ташланып, ни туры килсә шуның белән аны кыйнарга тотыналар... Татар буржуазиясе үзе өчен иң куркыныч саналган кешеләрнең берсен әнә шулай һәлак итә.

...Дөрес, ерткычлар озак котырына алмыйлар. Астрахань эшчеләре, матрослар һәм солдатлар аларга шул ук көнне авызлык кидерәләр. Шәһәрдә яңадан Совет власте урнаша. Тик комиссар Туйбактин гына ул якты сәгатьләрне күрә алмый кала...

## Дошманлык күптән килә

Касыйм Туйбактин кара көчләрнең күптәнге дошманы иде...

Елтыр кара күзле, шомырт кара чәчле шаян малайга бик иртә — 12 яшь тулартулмас борын ук — туган авылы Каргалы (Татарстанның хәзерге Әлки районы) белән

китерә. Әмма һәрнәрсә белән кызыксынучан, үткен табигатьле малайны биредәге тәртипләр, анда укытыла торган фәннәрнең сыйфат дәрәҗәсе канәгатьләндерә алмый. Берничә елдан соң ул Казанның мәшһүр мәдрәсәләреннән саналган «Мөхәммәдия»гә күчә.

Ул да түгел, мең тугыз йөз бишенче елгы беренче рус революциясе килеп җитә. Аның куәтле дулкыннары татарның мәктәп-мәдрәсәләре эченә дә үтеп керә.

Касыйм укыган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә революция елларында еш кына зур-зур җыелышлар, әдәби кичәләр уздырыла. Туйбактин бу җыелышларны, кичәләрне оештыручыларның берсе була. Ул анда шәкертләрнең хокукларын яклап, дин әһелләрен, патша самодержавиесен фаш итеп чыгышлар ясый, үзе иҗат иткән әсәрләрен укый. Халкыбызның күренекле артисты Касыйм ага Шамил, мәсәлән, аның муллалардан, полиция әһелләреннән көлеп язылган «Кызыл этәч» исемле әсәрен тыңлаучыларның яратып каршы алулары турында сөйли.

Революция дулкыннары тәэсирендә татар яшьләре күңелендә уянган теләк-омтылышларны инде мәдрәсә стеналары гына сыйдыра алмый башлый. Тиздән «Мөхәммәдия»нең 82 шәкерте бу мәдрәсәне ташлап чыга. Алар арасында Каргалы егете — буй җиткән Касыйм Туйбактин да була.

«Мөхәммәдия»дән китеп күпмедер вакыт узганнан соң, 1908 елның сентябрь башларында, Касыйм Астраханьга китә. Биредә аңа мөгаллимлек урыны бирәләр. Үзенең төп эшеннән тыш, ул биредәге татарлар арасында культура-агарту эшләре дә алып бара. Астраханьның кара байлары, иске фикерле сәүдәгәрләре үзләренең кан дошманнары Туйбактин белән беренче тапкыр шәһәрнең вагазь мәҗлесләрендә очрашалар. Ачык йөзле, тәмле сүзле оратор егет баштан ук ошамый аларга. Яше буенча хәрби хезмәткә алынырга тиеш булмаса да, могтәбәр байларның «тырышлыгы» бушка китми: 1911 елның октябрь башында Касыймны хәрби хезмәткә чакыралар. Менә-менә хезмәт срогын тутырам дип өметләнеп йөргән көннәрдә генә беренче бөтендөнья сугышы башланып китә. Салкын окопларда тагын берничә ел гомере уза.

Сәламәтлеге начарлану сәбәпле, 1916 елның язында Туйбактин армиядән демобилизацияләнеп Казанга кайта һәм «Мәгариф» матбагасына эшкә урнаша.

...1917 елның февраленнән соң, Касыйм Туйбактин зур энтузиазм белән җәмәгать эшенә керешә. Замандашлары аның үзенә тапшырылган исәпсез-хисапсыз эшләрне ихлас күңелдән, чын ашкыну белән үтәп баруы турында сөйлиләр. Бер карасаң, ул — Казан шәһәр думасында, икенче караганда — җәмгыяте хәйриядә, өченчесендә — «Яшьләр союзы»нда яки мөселман эшчеләре союзында була.

Әнә шулай ары чабып, бире чабып ялкынлы речьләр сөйләп йөргән бер вакытта 1917 елның июль вакыйгалары килеп җитә. Буржуазия белән большевиклар арасындагы көрәш үтә рәхимсез һәм килешмәүчән төс ала. Большевикларга һәм алар яклы кешеләргә каршы көрәштә буржуазия бөтен чаралардан файдалана башлый: аларны хурлый, халык каршында абруйларын төшерү өчен, төрле ялган хәбәрләр тарата. Мәскәүдә чыга торган «Ил» газетасының 14 июль санында Туйбактин турында да пычрак хәбәр басыла. Имеш, ул провокатор! Имеш, шул эшләре өчен ул әллә никадәр акча алган, фәлән дә фәсмәтән, ягъни.

Туйбактин шунда ук Астраханьга юнәлә. Эшне тикшерү өчен төзелгән махсус комиссия Туйбактинның гаепсез булуын раслый.

Бераз алга китеп булса да, шул кадәресен әйтик: буржуаз газеталарның гайбәтенә бер эләккәч, тиз генә котылып булмый икән. Инде бу эш онытылып бетте дигәндә, 1918 елның апрель аенда татар буржуазиясенең Казанда чыгып килгән «Алтай» исемле газетасы да өлеге пычрак хәбәрне кабат күтәрә. Хикмәте бик гади: буржуазия ялчыларына Туйбактинның контрреволюцион «Болак арты республикасы»н таратуны һәм Совет хөкүмәтенең беренче милли автономияле республика төзү турындагы проектын котлап җибәргән телеграммалары ошамаган. Алар шуның өчен үч алмакчы булып азапланалар икән.

Татар совет газеталары «Алтай»ның бу ялганын бердәм рәвештә фаш итеп чыгалар. Астрахань мөселман комиссариаты органы «Тартыш» газетасында күренекле большевик Сәттар Еникиев, Үзәк мөселман комиссариаты органы «Чулпан»да Шәһит

лалар. Пипаять, Туйбактинның үтенече буенча Хәрби трибуналы эшне яңадан тикшерә һәм аның гаепсез булуын тагын бер кат исбат итә.

...1917 елның җәендә Астраханьга киткән Туйбактин яңадан Казанга кайта алмый, шунда торып кала. Озакламый кешелек дөньясында яңа эпоха ачкан Октябрь революциясе җиңеп чыга. Үзәктә һәм урыннарда Совет властен ныгыту өчен көрәш башлана. Туйбактин муеннан партия-совет эшенә чума.

Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәте, илнең Көнчыгыш халыклары арасында Совет властен ныгыту максаты белән, Үзәк мөселман комиссариаты оештыра. Урыннарда аның җирле бүлекләре булдырыла. 1918 елның 8 июлендә Үзәк мөселман комиссариатыннан Астраханьга Мулланур Вахитов кул куйган бик мөһим бер документ килә. Эчтәлеге түбәндәгечә: «Халык Комиссарлары Советы Председателе иптәш Ленин тәкъдиме белән шушы елның 17 июненнән Үзәк мөселман комиссариаты Астрахань мөселман комиссариатының функцияләрен һәм аның бүлекләрен раслый.

Шуның белән бергә иптәш Ленин карарларының копиясе җибәрелә».

Составында хезмәт, матбугат, җир бүлү, финанс-хуҗалык бүлекләре булган Астрахань мөселман комиссариаты хезмәт ияләре арасында зур һәм купкырлы эш башкара. Монда аның председателе Касыйм Туйбактинның роле искиткеч зур.

Председатель булып эшләү дәверендә ул берничә мәртәбә Мәскәүдә, Үзәк мөселман комиссариатында була. Астрахань губернасының культура ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен, ул Мәскәүдән миллион ярым сум акча алуга ирешә. Бу акчага Астрахань шәһәрендә һәм аның өязләрендә кыска сроклы милли мәктәпләр ачыла. Наданлыкны бетерү өчен 50 урында кичке курслар, 25 районда халык китапханәсе оештырыла. Илнең көнчыгыш халыклары арасында мәгариф эшенең кыен хәлдә булуын яхшы аңлаган Туйбактин бу өлкәгә аеруча зур игътибар бирә. Аның инициативасы белән Астрахань мөселман комиссариаты укытучылар өчен махсус курслар оештыра. Бу курсларда социаль фәннәр укытуга һәм аларның дөрес юнәлештә булуына зур әһәмият бирелә.

Астрахань мөселман комиссариаты «Тартыш», «Кызыл сөңге» һәм соңрак рус телендә «Голос трудового мусульманства» исемле газеталар чыгара. Бу газеталарда басылган материаллар халыклар дуслыгы, пролетар интернационализм идеяләре белән сугарылган.

Газеталарга Туйбактин үзе дә актив языша. «Тартыш»ның һәр санында диярлек Комиссариат председателенең мәкаләләрен күрергә була. Үз мәкаләләрендә ул халык массаларына революциянең асыл максатларын һәм Совет дәүләтенең якындагы бурычларын аңлата, татар буржуазиясенең, аның сатлык ялчыларының чын йөзен тирән нәфрәт белән фаш итә.

...«Алар, без милләтебезне сөябез, кем дә кем милләтен сөймәсә, рус малайларына кул бирсә, ул милләт баласы түгел (дип), әллә нинди матур бизәкле кабыклар эчендә агуларын эшчеләргә йоттырырга тели башладылар. Шул сүзләре берлә «Сез милләтне сөймисез» дип безнең йөзебезгә карап сөйләргә батырчылык кыла башладылар. Кораллары яхшы, телләре дә бик матур, сүзләре дә бик килешле.

Ләкин онытмагыз, алар ул матур сүзләре белән нәрсә үткәрмәкче булалар!.. Аларның бөтен максатлары — милләт флагы астында үзләрен, малларын, алтыннарын саклау гына...» («Тартыш» газетасы, 1918 ел, 4 март.)

Туйбактин ачы телле мәкаләләр язу белән генә чикләнми, бик күп җыелышларда, митингларда кайнар речьләр дә сөйли, кичәге «хуҗалар»ның, бүгенге халык дошманнарының мәкерле планнарын ачып сала. Татар байлары шуңа да аны күрәлмыйлар, аннан куркалар. Мондый явыз дошманнан бары үтереп кенә котылырга мөмкин, янәсе. Бу мәкерле планнарын гамәлгә ашыру өчен алар җай чыкканны гына көтеп торалар.

# Комиссар каны җирдә ятмас

«Кеше каны җиргә сеңмәс»,— ди халык. Әгәр ул кан кешеләрнең бәхете, халык азатлыгы өчен көрәшеп йөргән каһарманныкы да булса, бигрәк тә сеңми инде. Касыйм Туйбактинның вәхшиләрчә үтерелү хәбәре сыйнфый дошманнардан үч алырга чакырган көчле набат булып яңгырый:

*Күтәрелегез, егетләр, калкыгыз аякка, алыгыз коралларыгызны, тиз булыгыз, тиз!!*

*Сезне Касыймның каны чакыра, сезне Шуралар хакимияте чакыра, сезне революция корбаннарының җаны, каны чакыра!..*

*Контрреволюция тамырларын туздыруны сездән сорый, ярлы халык дошманы буржуазия, спекулянтларны, провокаторларны, сатлык җаннарны, буржуазия агентларын, лакейларын, буржуазия сакчысы акгвардеецларны — хулиганнар бандасын кырып-себереп ташлауны сездән көтә, Кызыл Шуралар җөмһүриятен хәшәрәт үрмәкүч ояларыннан тазартырга сезне чакыра!*

*Ишетәсезме аларның тавышларын?!*

*Әнә, әнә үчкә чакыра...»*

Касыйм Туйбактинны күмү Совет властен якларга ант итүче, революция дошманнарыннан үч алырга ант итүче эшчеләрнең зур демонстрациясенә әйләнә.

«15 август вакыйгасы безнең өчен бер имтихан һәм киләчәккә бер сабак булды,— диләр алар.— Инде моннан соң тагы да без корып куйган пулеметларыбызны һәм кулыбыздагы мылтыкларыбызны өстебезгә килә торган вәхшиләрне атып бетермичә читкә куймабыз!..

Инде, татар карагруһлары, сезгә ни булачак,— бик дикъкать белән тыңлагыз.

Сезгәме, сезгә шул булачак: сезнең әлегә кадәр торып килгән тугыз-ун бүлемле йортларыгыз безнең иптәшләр кергән каберләрдән мең мәртәбә тар булачак, әллә ничәшәр пот мамыктан ясаган мендәрләрегез таштан да каты булачак, ниһаять, сезгә бөтен байлыкларыгыздан колак кагып фатиха укырга туры киләчәк».

Һәм эшчеләр үз сүзләрендә нык тордылар. Әйе, комиссар каны җиргә сеңми шул!

Астрахань хезмәт ияләре Касыйм Туйбактинның Советлар өчен көрәштә зур өлеш кертүенә югары бәя бирделәр һәм аның данлы исемен мәңгеләштерделәр. Астрахань эшчеләреннән һәм кызылармеецларыннан торган полкка Туйбактин исеме бирелде. 1918 елда Астраханьда Касыйм Туйбактинга багышланган махсус җыентык чыгарылды. Егерменче елларда киң Идел суын дулкынландырып Туйбактин исемендәге пароход йөзеп йөрде. Комиссар Туйбактин исеме мәктәпләргә, колхозларга һәм урамнарга бирелде. Шул ук елларда драматург Габдулла Уральский «Туйбактин» исемле пьеса язды. Әсәр беренче мәртәбә 1920 елда Астраханьның «Вулкан» театрында куелды. Туйбактин ролен ул вакытларда яңа үсеп килгән яшь, талантлы артист Камал III башкарды. Әйе, Камал III Туйбактин ролен башкарырга лаек артист иде. Чөнки, беренчедән, артистның үзе сөйләвенчә, үзенең тышкы кыяфәте белән ул Туйбактинга охшашрак булса, икенчедән, Астрахань мөселман комиссариатында берничә ай буе аңа Касыйм Туйбактин җитәкчелеге астында эшләргә туры килә.

Озын чәчле, кечкенә кара мыеклы, башына салам эшләпә кигән, френч өстеннән җиңсез кыска камзол салган, барысына да таныш комиссар Туйбактин-Камал III җитез адымнар белән сәхнәгә килеп керүгә, залдагылар дәррәү аякка басып озак кул чабалар. Бу карагруһлар тарафыннан үтерелгән каһарманга һәм аны сәхнәдә яңадан җанландырган артистка хөрмәт алкышлары була[1].

Туган Идел буенда Совет властен урнаштыруга шактый зур өлеш керткән комиссар Касыйм Туйбактинның тормыш юлы һәм эшчәнлеге тагын да тирәнрәк өйрәнелергә тиеш. Чөнки аның якты образы бүген дә яшь буынны коммунистик рухта тәрбияләүдә үрнәк булып тора.

Риф ХӘЙРЕТДИНОВ,
тарих фәннәре кандидаты.
Габдрахман КӘРИМОВ.

---

[1] Фатих Шәрәфиев. Сәхнә остасы. «Совет әдәбияты» журналы, 1961 ел, 2 сан, 121 бит.

# КӨЧЛЕ ИХТЫЯР ҖЫРЧЫСЫ[1]

Әдип Маликов татар поэзиясенә 1945 елда үзенең «Атаудагы хисләр» дигән җитди поэтик әсәре белән килә. Әлеге поэманы ул солдат булып хезмәт иткәндә, үзе туып-үскән Агыйдел буйларыннан еракта, кояш чыккан якта—Сахалинда яза. Армия сафларына алынганчы Уфада, шулай ук Свердловск, Пермь шәһәрләрендә татар телләрендә чыккан газеталарда кечкенә-кечкенә шигырьләр язып бастырган Әдип Маликов «Атаудагы хисләр» поэмасын аеруча зур көч куеп, бөтен тырышлыгын багышлап эшли һәм, шагыйрьнең үз сүзләре белән әйткәндә, өлкән язучылар фикерен белер өчен, курка-курка гына Казанга, журнал редакциясенә җибәрә. Бәхеткә каршы, күп көтәргә туры килми, ил читендәге землянкаларның берсенә Сахалин солдатын тирән дулкынландырган хат килеп төшә. Өлкән язучылар Казанда яшь шагыйрьнең поэмасын игътибар белән укыганнар, яратканнар.

Әнә шулай, уйламаган бер көндә зур сөенеч хәбәр итеп, изге юл теләп килгән әлеге хат, ә аннан соң ул поэманың журналда басылып чыгуы Әдип Маликовны чиксез канатландыра, иҗади эшен тагын да җитдирәк дәвам иттерүгә рухландыра.

Әдип Казанга кайта. Башта ул Татарстан радиокомитетында редактор булып эшли, аннары «Татарстан яшьләре» газетасы редакциясенә күчә һәм үзенең иҗатын дәвам иттерә. Әдәби белемен, осталыгын күтәрү өчен, Мәскәүнең М. Горький исемендәге әдәбият институтында укый.

Шагыйрь, күп тә үтми, яңа салына башлаган Әлмәт шәһәренә китеп, нефтьчеләр тормышын өйрәнә. Буровойларда, тәзелешләрдә була. «кара алтын» чыккан якларның берсеннән-берсе әйбәт кешеләре: бораулау осталарының, эшчеләрнең, операторларның, төзүчеләрнең хезмәтләре белән рухланып, батырлыкларына сокланып җырлар, шигырьләр, ул якларның елъязмалары булырдай поэмалар иҗат итә.

Менә Әдип Маликовның Әлмәт якларындагы бик күп дусларыннан берсе — Сафуат Вәлиуллин. Ул — Бөек Ватан сугышы ветераны, авыр сугыш юлларын Идел буйларыннан башлап үтә, Европа илләрен азат итешә. Сугышның соңгы көннәрендә кулы каты яралана, аны Прага шәһәрендәге госпитальгә салалар. Аның кулы торган саен начарлана бара, корый башлый. Врачлар, бәлки, ки сәргә дә туры килер диләр. Бервакыт чех кызлары Сафуатка гармун алып киләләр. Ул акрын-акрын гына шушы гармун телләрен тибрәтергә керешә. Кызлар гармуны шифалы була, күрәсең, бертуктаусыз тибрәтә, уйный торгач, кулына җан кергәндәй була, бармаклары хәрәкәт итә башлый һәм туган иленә шактый ук сәламәт кул белән кайта. Егет укый, эшкә керешә һәм үзенең кулына җан кертүдә булышкан чех кызлары яшәгән илгә дуслык юлы салуда, әлеге юлдан «кара алтын» озатуда катнаша.

> Кичә Идел, Дон сулары —
> Дуслык юлы ерак-ерак...
> Ятып калган батырларның
> Каберләрен үтә урап.
> Син дә уздың шул юллардан,
> Тукталышлар ясый-ясый...
> Ротаң белән
> калаларга
> Бәреп кердең ярсый-ярсый.

Әйе, фашист илбасарны тар-мар иткән җирләрдә солдатлар хәзер өсләрендә беркайчанда кояш батмый торган бөек дуслык юллары салдылар.

Күп тапкырлар очрашу, скважинадан скважинага йөреп сөйләшү, дуслашу нәтиҗәсендә, Маликов Бөек Ватан сугышы батыры, бүгенге тыныч хезмәт алдынгысы Сафуат Вәлиуллин белән рухланып «Дуслык юлы» дигән баллада яза һәм әсәрен аңар багышлый.

Әдип Маликовның нефтьчеләр тормышын өйрәнеп яза башлаган чоры турында, аның «Гайшә апа» белән «Фәрданә» дигән поэмалары турында шагыйрь Сибгат Хәкимнең шушындый язмалары бар: «Шагыйрь Ә. Маликов берничә еллар инде Әлмәттә яши, күп йөри, кешеләр белән күп очраша. Шушы якның табигатен, кешеләрен яраттыра торган детальләрен дә аның шигырь һәм поэмаларында күп очратасың. Гел бер тирәдә әйләнгән, гел бер темаларга ябышып яткан татар поэзиясенә бораулаучылар, операторлар килеп керде, поэзия бераз киңәеп китте. Кочегар булып хезмәт итүче Гайшә апа өйләрне җылыта, меңләгән кешеләрнең күңелләрен җылыта. Автор шул гади бер хатынның тор-

[1] Татарстан китап нәшрияты Әдип Маликовның «Шигырьләр һәм поэмалар» китабын чыгарды. Ул М. Садриның «Хезмәт һәм көрәш поэзиясе» исемле кереш сүзе белән ачыла. Журналыбызның бу санында, китапка рецензия урынына, шул керешне урнаштырабыз.

детальләрен осте күрә, кечкенә поэмада аның мөлаем образы ачыла. Ә. Маликовның «Фәрданә» исемле икенче поэмасы миндә тагын да яхшырак фикер калдырды. Монысында нефть эзләүче разведчик Сәйранның мәхәббәте ниндидер романтика белән әртелгән. Аның эше шундый: ул бертуктаусыз күченә, яңа нефть байлыкларын ача. Ә Фәрданә, оператор, бер урында эшли. Ләкин алар мәхәббәтенең сафлыгына, аларның яңадан очрашуына укучы бернинди дә шик тотмый. Бу тирәнең табигате, мастерга иялэшкән поши да поэманың төп сюжетына хезмәт итә. Яхшы әсәр икәнен белүе алай кыен түгел: укып бетергәч тә вакыйгага барган урыннарда үзеңнең буласың килә башлый, андагы кешеләрнең эшләрен яратасың, үзләрен күңел юксынып куя, сагынасың».

Йөрәк кылларын тибрәтә алырдай поэтик әсәрләр, укучыны дулкынландыра торган, аңар яшәү көче бирә алырлык һәм үткәндәге тормышны искә төшереп бүгенгегә тирән мәхәббәт һәм киләчәккә ышаныч белән карарга рухландыручы әсәрләр тудыру өчен шагыйрьгә, язучыга, беренче чиратта, тормыш эчендә, хезмәт кешеләре арасында кайнарга кирәк. Әдип Маликов әнә шул сыйфатларга турылыклы булып яши, иҗат итә. Аның шигъри материаллары — объектив чынбарлык, конкрет кешеләр, яңа заманның яңа батырлары, аларның якты хисләре, бөек омтылышлары. Кыскасы, яңа дөнья төзүче совет кешеләре.

Шушы уңай белән, шагыйрьнең югарыда билгеләп үтелгән поэмаларына һәм балладасына естап, тагын бер әсәренә — «Салкын Алан» поэмасына тукталыйк. Салкын Алан — авыл исеме. Бик күп батырлар, менә дигән хезмәт кешеләре үскән бу авылда, батырларның да батыры, коммунист укытучы бар икән! Бу авылда гына түгел, ә тирә-як авылларга да исеме билгеле булган һәм һәркем олылап «Нури абый» дип йөрткән бу укытучы — Бөек Ватан сугышы ветераны. Бик каты сугышлар барган чакта дошман утыннан авылдашы Газиз үлгән, ә Нуриның ике аягы өзелгән. Әнә шундый язмышка дучар булган коммунист укытучы төшенкелеккә бирелми, үзенең ихтыяр көчен җигеп, туган якларына, авылына әйләнеп кайта:

Әрни-әрни дусты өчен,
Ерак юллар урый-урый,
Носилкадан носилкага
Күчә-күчә кайтты Нури.

Колхоз авылының алдынгы кешесе, коммунист укытучы буларак, ул тыныч хезмәт постына баса: мәктәпне юлга салып, балаларны укытырга керешә, сугыштан соңгы авыр елларда колхозны күтәрешә, үзенең бөтен тормышын халыкка хезмәт итүгә багышлый. Шуңар күрә авыл халкы аның үзен дә ихтирам итә. Ә балалар, яшьләр аның кебек батыр булырга, аннан үрнәк алып яшәргә тырышалар. Әдип Маликовның «Салкын Алан»ы — сәнгатьчә эшләнгән, сокланып укырлык, өлъязма булырлык поэма. Әлмәт шәһәренең беренче нигез

нып язылган «Ташчы», шулай ук «Таңбатыр», «Чигүле яулык» дигән поэмалары да — шагыйрьнең хезмәт кешесе тормышын белеп, яратып, эпик планда иҗат иткән әсәрләре.

Әдип Маликовның «Беренче оркестр» дигән шигыре бар. Әлмәт шәһәренең матур бер кала булып күтәрелүен чагылдырган бу шигырьне дулкынланып укыйсың. Шәһәр әле салына гына, ә яшь төзүчеләр вакытлы бараклардa быргыларда, кларнет, флейталарда уйнарга өйрәнәләр, искиткеч тулы бер тормыш белән яшиләр:

Сарайлар салынып беткәнен
Берәү дә сагынып тормады.
Тактадан ясалган баракта
Үзешчән оркестр уйнады.
Көндезен Шакирҗан таш төзә,
Биналар биеккә үрелә,
Ә кичен юнәлә клубка
Җиз торба асып ул иңенә.

Шәһәр салынуны бәйрәм иткәндә, төзүче хуҗалар үзләре оештырган оркестр белән киң урамнарны гөрләтеп алга узалар:

Атлыйлар төзүче хуҗалар,
Агыла музыка тоташтан,
Әйтерсең барасы юллары
Туган ил түренә тоташкан...

Шулай итеп, бараклардa туган «Беренче оркестр» аша без төзелеш пафосын, яңаны төзеп үзләре дә үсә, чыныга баручы, көчле ихтыярлы, киң күңелле яшьләребезне күрәбез.

Шагыйрь нефтьчеләр шәһәре Әлмәтне, үзенең күз алдында күтәрелгән, аны төзешкән Әлмәтне ярата. Солдат чагында беренче поэмасын язган Сахалинга барамы, Әлмәт якларыннан яңа җирләргә нефть эзләргә җибәрелгән осталарны күрер өчен ерак кара урманнарны үтеп, Лена елгасы буйларында йөримe — кайларда гына булмасын, аны газиз күреп, сагынып кайта. Чөнки ул бу шәһәрдәге һәр йортны, һәр нефтьчене, һәр кешене белә һәм үзенең язмышын алар язмышына бәйләп яшәргә өйрәнгән.

Урманнан шәһәргә
Күченгән юкәләр,
Иркәли аларны
Кояшлы иртәләр...
Күченгән урманнан
Кәкүкләр, былбыллар...
Шуңамы Әлмәтне
Бай диләр җыр-моңга.

Бу юлларны язган безнең шагыйрь дә якташларының күркәм сыйфатларын җырга салуда аз көч куймады.

Шагыйрь Әдип Маликов поэзия солдатлары сафына беркадәр уңайсызланып, оялып һәм гаҗәеп бер тыйнаклык белән килеп керде. Тәҗрибәле шагыйрьләр, әнә шул яшь солдатның шигъри йөрәген аңлап, киләчәгенә ышанып ярдәм кулы суздылар. Аның әсәрләре язучылар һәм шагыйрьләрнең, поэзия сөючеләрнең шул ышанычын аклавын раслыйлар.

МӨХӘММӘТ САДРИ

## Нәби Дәүли

# БИЗӘК ӨЧЕН ТҮГЕЛ, КИРӘК ӨЧЕН

*1970 елгы поэзиябез турында уйланулар*

Тормышта һәрнәрсәне төрле яктан карарга мөмкин булган кебек үк, позицияне дә күп яктан күзәтергә мөмкин. Әмма мин бу юлы шигырьнең бер генә кырын күзәтергә җыенам. Бу, мәсьәләгә конкрет юнәлеш биреп, фикерне шул тема тирәсенә тупларга тырышу теләгеннән килеп чыккан бер омтылыш.

Мин поэзиянең идея эчтәлеге дип аталган кыры турында сөйләргә телим. Чөнки бу шигырьнең аны жирга беркетеп торган төп нигезе! Шигырьнең барлык башка элементлары шул нигезгә корыла. Кыскарак итеп әйткәндә, теләсә нинди әсәрдә дә идея сүзләрне, җөмләләрне, образларны берсене берсен ябыштырып ныгыта, бер бөтен итә торган цемент ул. Шуңардан башка әсәрнең җаны да, каны да булмый.

Без — коммунистлар партиясе идеясен яклаучылар, шул идеянең чәчәк атуы өчен көрәшчеләр, кирәк чакта сугышчылар, кирәк чакта шул бөек идея өчен корбан булырга әзер торучылар.

Хезмәт — коммунизм төзүчеләрнең пароле менә шул. Бу парольне безгә партия үзе бирде. Партия сәнгать хезмәтчеләрен үзенең ялкынлы, турылыклы булышчылары дип атады.

Шагыйрьләр — коммунизм төзүчеләр сафында алдан баручы барабанчылар. Билгеле булганча, барабаннан башка марш уйнап булмый. Барабан тавышына сафлар бердәм аяк басалар. Барабан бәргәндә сафта баручыларга җиңел була. Ләкин моның өчен барабанчыга марш ритмын бик яхшы сизә белергә кирәк. Шагыйрь дә нәкъ шулай, ул үз заманының ритмын бик сизгер ишетә, үз йөрәге аша кичерә белергә, үз заманының рухы белән яшәргә тиеш.

Коммунизм өчен тимер, күмер, икмәк, машина кирәк булган кебек үк, кеше рухына азык булырлык, кешене алга, көрәшкә, җиңүгә өндәүче шигырь дә кирәк. Кешене үзен кеше итеп танытa торган, шул бөек исемгә лаеклы булып яшәтә торган, бизәк өчен түгел, ә кирәк өчен кирәк булган шигырь кирәк. Шуңа күрә мин бүгенге мәкаләмне шигырь бизәк өчен түгел, кирәк өчен кирәк дип атадым. Әйе, мәсьәлә көн тәртибенә менә шул рәвешчә куела. Бизәк өчен түгел, кирәк өчен язарга! Бу — шагыйрь өчен кулына каләм алган минутта ук инде ачыкланган мәсьәлә булырга тиеш. Шагыйрьнең осталыгы нәкъ менә шуннан башлана да.

Әмма бездә барлык шагыйрьләр дә шигырьне кирәк өчен кирәккә язалармы? Әллә бизәк өчен, бары тик сүз уйнатыр өчен генә, мин дә шагыйрь булыйм әле, дияр өчен генәме? Без, минемчә, әлегә кадәр поэзиябез турында декларация сөйләү белән канәгатьләнеп килдек. Дәресрәге, кирәксә кирәкмәсә дә мактандык, бер-берebезгә мәдхияләр укыдык. Җитте, диясе килә. Уңны, сулны белми чабып барган Пегасны тезгененнән тотып алып, бер генә сәгатькә булса да туктатып торырга, шагыйрьне иярennән тартып төшереп, кил әле бире, егет, кая чабасың? — дип, нигә

узмыйсыңмы? — дип, аны укучы алдына бастырып сорау аласы килә.

Узган 1970 ел бөек остазыбыз Владимир Ильич Ленинның туган көненә, инде йөз ел безнең белән бергә яшәгән иң кешелекле кеше хөрмәтенә багышланган иде. Совет кешеләре халыклар юлбашчысына үзләренең мәхәббәтләрен хезмәт фронтында яңа җиңүләр белән расладылар. Татарстан игенчеләре дә ил табынына 80 миллион потлы каравай куйдылар. Безнең данлыклы нефтьчеләребез елына йөз миллион тонна кара алтын чыгардылар! Кем генә, кайда гына хезмәт итсә дә, ул үзенең йөрәк тибешен, уйларын, хисләрен Владимир Ильич Ленинга багышлады. Бу ялкынлы рух мәңге шулай булачак. Без кешелек дөньясының иң бөек улына иң бөек һәйкәл салдык. Ул һәйкәлгә һәркем үзе күтәрә алган таш китереп куйды.

1970 ел поэзиясе турында сөйләгәндә иң элек Татарстан китап нәшриятында чыгарылган Лениниана китапларын искә алып үтәргә тиешбез. Алар биш том. Өчесе — поэзия китаплары. Безнең Ленин һәйкәленә куйган ташларыбыз менә шулар. Болар — безнең заманның киләчәккә бүләге. Хәзер күп меңләгән укучылар Владимир Ильич Ленин турында татар шагыйрьләре генә түгел, Советлар Союзында яшәүче башка бик күп милләт шагыйрьләренең әсәрләре белән дә таныша алалар. Шулай ук чит ил әдипләренең дә Ленинга багышланган әсәрләрен үз ана телләрендә укырлар.

Дөрес, бу әсәрләрнең барысы да бер дәрәҗәдә яхшы дип булмый. Әмма шунысы ачык, шагыйрьләр Ленинга карата үзләренең какшамас ышанычларын, эчкерсез мәхәббәтләрен җырлыйлар. Бу шигырьләр кирәк өчен язылганнар. Шагыйрьләр бу теманың нинди җитди икәнлеген аңлап эш итәләр. Шигырьләрдә гадилек, тыйнаклык, шул ук вакытта тирән эчтәлек укучының фикерен җәлеп итә. Һәрбер шагыйрь бөек юлбашчы образын тере итеп күз алдына китерергә тырыша. Бу — безнең уңышлы ягыбыз.

Мин биредә С. Хәкимнең, Г. Афзалның, Ш. Маннурның, Х. Туфанның һәм башка шагыйрьләрнең Ленин темасына иҗат иткән әсәрләре турында инде күп кабатланган мактау сүзләрен яңадан кабатларга җыенмыйм. Әмма түбәндә әйтеләчәк кайбер фикерләр ул иптәшләрнең шигырьләренә дә беркадәр кагылачак дип белдереп куярга тиешмен. Нинди фикерләр соң алар?

төсләлек, кабатланулар әледән-әле үзләрен сиздереп торалар. Күп кенә әсәрләр Ленинның биографиясен яңадан сөйләп чыгу яки шул биографиядән өзекләр китерү белән чикләнә. Әсәрдә биографик материалларның чагылышы, һичшиксез, булырга тиеш. Биография ул — әсәрнең тукымасы. Әсәр шул нигезгә корыла. Шул тукымага шагыйрь, келәм тукыган шикелле, үз фикерләрен, үз чәчәкләрен үреп бара. Әмма бу биографияне сөйләп чыгу дигән сүз түгел. Бу әр-яңа сәнгать әсәре язу дигән сүз.

Сибгат Хәкимнең «Кокушкино крестьяннарының Ленинга хаты» дигән шигыре дә Ленин биографиясенә бәйле бер момент. Анда Кокушкино авылы крестьяннары Лениннан ат сорыйлар. Әмма шагыйрь бу авыл аша бөтен Россиягә карый. Ленин бер авыл игенчеләре өчен генә түгел, бөтен ил өчен кайгыртучы итеп сурәтләнә. Әсәрнең көче әнә шунда.

Бездә биографик белешмәләрдән, өзекләрдән чын әсәр, чын шигырь булып туган башка үрнәкләр дә бар. Г. Афзалның «Ленин солдатлары» дигән шигыре шундый. Биредә бөек юлбашчы Ленин аның көрәштәшләре аша сурәтләнә. Шагыйрь Кызыл мәйданда Мавзолейга карап болай уйлана:

Җир шарына үз вакытын әйтеп,
Ил сәгате суга шушында,
Сәгать суга
Тыныч тыңлап яткан
Батырларның башы очында...

Бу урында башын ташка куеп,
Ленин солдатлары ял итә,
Көрәш өчен яңа буын туып,
Ал байракны үбеп ант итә...

Күргәнебезчә, автор Ленин образын ялгызлыкта түгел, ә революция солдатлары сафының алдына бастырып, алсу байрак итеп куя. Ә менә шул ук авторның «Печәнче» шигыре коры биография сөйләү генә булып чыккан. Автор монда үзеннән бернәрсә дә өсти алмаган. Чалгы алган да кайчандыр Ленин дошманнардан качып яшәгән шалашлы болынны бик җиңел генә чабып чыккан. Ә бит бу тема авторны бик зур нәрсәләр турында уйландырырга тиеш иде шикелле. Бу чор — Ленинның тормышы кыл өстенә куелган, иң авыр, иң куркынычлы чак. Дошманнар революция юлбашчысын дөньяны тентеп эзлиләр. Алар сатлык ялчыларга Ленин башы өчен мең алтын түләргә риза, тик революция йөрәгенә пычак кадарга кул күтәрә алган бандит кына табылсын...

масы поэзиядә генә түгел, теләсә нинди жанрда халыкара тема булып кала. Бу — халыкара политика да, халыкара дипломатия дә. Безнең шагыйрьләр шул зур темага бик аз язалар әле.

Мина калса, шагыйрь бер күзе белән үз ватанына, үз туган җиренә караса, икенче күзе белән ул чикләр аръягындагы тормышны да күреп торырга тиеш. Ә чикләрнең аръягында дөнья кайный. Революция вулканы бәреп чыгарга көч җыя. Без үз халкыбызның рухын шул революция кызулыгында тотарга тиешбез. Такташ әйткәнчә, алда әле көрәш бетмәгән. Заманында Габдулла Тукай, Һади Такташ та, Муса Җәлил һәм Фатих Кәримнәр дә бу темага киң колачлы гүзәл әсәрләр язалар. Хәзер безнең олы шагыйрьләребез Хәсән Туфан, Әхмәт Исхак чикләр аръягындагы дөнья — «тегe як» тормышы белән кызыксыналар, аларның империалистлар мәкерлеген фаш иткән шигырьләре әледән-әле күренеп тора. Ә тагын кем? Күрәсез, исемлек зур түгел.

Поэзиядә географик чикләр юк, анда идея чикләре генә бар. Шуңа күрә татар телендә язылган шигырьләрне дә, теләсә нинди темага булсын, дөнья күләмендә, теләсә нинди халык телендә яңгыраулы итеп күрәсе, ишетәсе килә. Чөнки бит без, Расул Гамзатов сүзләре белән әйтсәк, үз иҗатыбыз белән бөтен ил каршында, барлык халыклар каршында җавап тотабыз.

1970 елда безнең Ленинианага, инде әйткәнемчә, күп кенә яңа әсәрләр өстәлде. Аларның барысына да тукталып чыгарга бернинди мөмкинлек юк. Җыеп әйткәндә, татар шагыйрьләре Ленин образын киң планда иҗат итүне киләчәктә дә күз алдында тотарлар. Әмма барыбыз өчен дә уртак бурыч шул: Ленинны партия белән бергә, халык белән тыгыз бәйләнештә, хәрәкәттә, хезмәттә күрсәтергә кирәк.

1970 елда үз шигырьләре белән «Казан утлары» журналында гына да илледән артык автор катнашты. Язучылар исемлегендә булган барлык шагыйрьләр дә диярлек журнал битләрендә урын алганнар. Хәтта арабыздан вакытсыз киткән Ә. Давыдовның, Г. Хуҗиның, З. Мансурның да әлегә кадәр билгесез булган әсәрләре дөнья күрделәр. Шуның өстенә Татарстан китап нәшрияты егермеләп шигырь китабы чыгарды. Тагын да шуның өстенә башка газета-журналларда басылып чыккан, радиодан һәм телевидение экраннарында ишетелгән шигырьләрне дә искә алсак — аллачак. Без «тауда алтын күпме икән?» дигән сорау куябыз һәм шатланып та, борчылып та уйлана башлыйбыз.

Сүзне бөркетләрдән башлыйк. Чөнки безнең бит әле «беренче карлыгачларыбыз» да бар. Үткән елда җитмеш яшькә җитеп тә картаймаган олы шагыйребез Х. Туфан аерата актив эшләде: «Казан утлары»ның ике санында аның бер поэмасы, кырыклап шигыре басылды. Туфанны мактап минем азан әйтүем кирәк түгел. Аны миннән күп мәртәбә олы кешеләр бик хаклы мактадылар. Ул үзенең поэзиядә зур хезмәте өчен орден белән бүләкләнгән шагыйрь. Аның «Кара арслан», «Кем көчлерәк», «Ни?», «Әй!» дигән шигырьләре алда әйтеп үтелгән халыкара темага язылган. Ул шиырьләрне укыган саен үзеңә яңадан-яңа фикерләр табасың. Укыган саен нинди шәп шигырьләр була икән, дип шатланып куясың. Һәм нәкъ шундый матур уйлардан соң «Лирика һәм физика», «Яп әле, яп» дигән шигырьләрне күреп кинәт тынып каласың. Бу шигырьләр нигә язылды икән, дип уйланасың. Бу — Такташ традициясен дәвам итүме? Әгәр шулай икән, Такташ бит үзенә үзе дошманнар уйлап чыгармады. Ул әле бар дошманнар турында, аның һәм Туфан заманында әле социаль көч булып торган, тагын да ачыграк итеп әйтсәк, әдәби яктан типик герой дип аталган кире образлар турында язды, аларга каршы аяусыз көрәш алып барды. Моңа мисал итеп, «Син дошманым минем» дигән шигырен генә искә төшерү дә җитә. Безнең заманда исемсез дошманнар ясау — ул бит чәчелмәгән буш бакчага үз эшләпәңне кидереп карачкы куйю белән бер дәрәҗәдәге эш. Аннан да көлкерәге — шул карачкыга чын мылтыктан ату.

Физик яктан
Чандыр Т кайлардан
Күп кат көчле яңа Ишмиләр.
Көпә-көндез алар, көпә-көндез,
Күрәсезме, әнә нишлиләр...—

ди Туфан «Лирика һәм физика» дигән шигырендә. Мин сорыйм: кем соң алар «яңа Ишмиләр»?

Детонатор тыгып куеп алар,
Әвәли дә нахак «шартларны»,
Сәгатьләргә карый-карый гына
Кетеп тора безнең шартлауны.

Әнә кемнәр икән. Мин, мәсәлән, кеше буларак, үземнең баш куйган мендәрем астында мондый шартлау булыр дип борчылмыйм. Шулай ук башкалар да андый

кам. Безнең җәмгыятьтә андый «физиклар» юк. Әгәр Туфан моны үзенә карата булган берәр очрак белән бәйле икән, димәк, ул «диверсант» Ишмине үзе уйлап тапкан.

«Кер чайкыйлар кызлар» дигән шигырендә мин Туфанның хулиганнар, гитаралы битлослар турында ачы нәфрәт белән әйтелгән хисләрен бик яхшы аңлаган идем. Ә болары минә тәмам аптырашта калдырдылар. «Физиклар» дип, «бежаклар» дип аталган бу «геройларны» күз алдына һич китерә булмады.

Бездә актив яза торган шагыйрьләр күп түгел. Шәүкәт Галиев исә нәкъ менә шул ягы, күп иҗат итүе белән аерылып тора. Аның шигырьләре чыкмый калган атналар сирәк була. Күп язудан битәр бу шагыйрь бераз ашыга да кебек. Моңа карап кына аның шигырьләре начар була дип әйтергә җыенмыйм. Әмма кайберләре бик үк яхшы да булмый.

Ул сүз белән, чыннан да, виртуозларча җиңел эш итә. Теләсә нинди сүздән ул рифма ясый ала. Аңа, мәсәлән, «элмәк» белән «күлмәк» дигән рифмаларга шигырь язып бир әле дисәң, валлаһи, ул аны шул ук сәгатьтә язып куячак. Мин моны шаярып әйтмим, чөнки бу осталыкның нигезе бар. Шагыйрь иң элек балалар өчен язды һәм шәп язды. Белгәнегезчә, балалар өчен язылган шигырьләрдә рифма һәм аның да, Галиев сүзе белән әйтсәк, «шалт» итеп торган булуы мәҗбүри. Балалар өчен язылган шигырь баланың телен шомарту бурычын да үтәргә тиеш. Биредә рифма нәкъ әнә шул бурычны башкара да инде. Бу хәл, күрәсең, шагыйрьнең үзенең дә телен баеткан, тәҗрибә биргән.

Шәүкәт Галиевнең зурлар өчен язылган шигырьләреннән миңа иң ошаганы «Музейда булган хәл» дигәне булды. Гаҗәп оста, яшь аралаш көлү белән язылган шигырь ул. Ә менә «Карт карга», «Карыйм да мин, сеңелем, гаҗәпләнәм» һәм тагын кайберләре «кирәк өченме»? дигән эталонга туры килмиләр. Бу — ашыгу нәтиҗәсе. Сәнгатьтә ашыгу исә авторны кәсепчелеккә алып килә. Бу урында мин Сибгат Хәкимнән үрнәк алырга чакырыр идем. Ул күп яза, ләкин ашыкмый. Ә нигә ашыкмый, аның сере бар. Хикмәт — кирәк өчен язуда. Ул инде теманы тапкан, аның кирәклегенә ышанган, аны халык үе белән тикшереп караган. Аңа ашыгасы юк. Ул темага нәкъ аның кебек үк итеп башка беркем дә язмаячак. Шуны белгән хәлдә, ул әсәрне быел яза да, елда чыккан «Торыгыз, Мусаләр!» исемле китабында елына 2—3 кенә шигырь туры килә. Ләкин алар барысы да кирәк өчен язылган әсәрләр.

Күп язучылардан бездә тагын Нури Арслановны да күрсәтергә мөмкин. Әмма «Шагыйрьгә» һәм «Мин газазил булып күтәрелдем» шигырьләрендә кайнарлык җитми кебек. Ә менә «Мамай курганы», «Атлантида» исемле шигырьләре бик шәпләр. Бу әсәрләрдә кан да, җан да бар.

Шулай ук безнең Зәки Нури да күп яза. Ул күп җирләр гизә. Барган җиреннән буш кул белән кайтмый. Узган елда, мәсәлән, ерак Себердән, Польша якларыннан Ленин турында яңа шигырьләр алып кайтты. «Йөрәккә якын җирләрдә» исемле ул этюдларда Ленинны күз алдына тере итеп китереп бастырган менә мондый юллар да бар:

Урләрдән үргә менгән ул,
Бар көчен аямыйча.
Кулында таяк булса да
Таякка таянмыйча.

Күренә моннан Россия,
Күгендә кара болыт.
Патшалар намусы төсле
Караңгы кара булып.

Күренә узасы юллар,
Юлларның киртәләре,
Барып җитәсе көннәрнең
Коешлы иртәләре.

Ләкин Зәки Нуриның да ашыгу гадәте бар. Шуның нәтиҗәсендә кайбер шигырьләрендә төгәлсезлек, стиль таркаулыгы сизелә. Соңгы вакытларда ул дүртьюллыклар яза башлады. Узган ел чыккан «Озын сүзнең кыскасы» исемле җыентыгында дүртьюллык шигырьләрдән торган аерым бүлек тә бар. Алар — сатирик монологлар һәм диалоглар. Менә шуннан берничәсе:

ДАН «ИЯСЕ»

— Мәчә шунда миңа һәйкәл куеп,
Төрле якка сукмак сузарлар.
Кешеләр килер! Алар бер-берсеннән:
«Бу кем?» — диеп сорап узарлар.

САЗ БУЕННАН УЗГАНДА

— Кара әле, сазда нәрсә шулай
Аунар икән копә-көндезен?
— Иясе дә менеке бит болар:
Берсе ирем, берсе дуңгызым!

Безнең көнкүрештә булган кимчелекләрне шулай суктырырга чыбыркы да кулда булсын. Боларны да мин, әлбәттә, кирәк өчен язылганнар дип саныйм.

андырды. Ул «Казан утлары»нда бер шигырь бастырды. Шигырь матур язылган, чөнки материалы халык тормышыннан алынган. Үзенең күршесендә яшәгән бер сугыш инвалидының сызлануы аша шагыйрь сугыштан әле һаман да ирләрен көткән хатыннарның, сөйгән ярларын инде кабат күрә алмыйча картайган кызларның сагышларын уйлап сызланган. Шигырь аша ул сагыш безнең йөрәкләргә дә күчә, безнең дә сагышыбызга әйләнә. Шагыйрьнең күршесе безнең дә күршебез булып кала.

Яшь шагыйрь Ренат Харисовның, яңа форма эзләп, каш куям дип күз чыгарган чаклары да булгалады. Бигрәк тә Мулланур Вахитов турында язылган шигырьләре минем чәчләремне үрә торгызган иде. Ә менә узган елда бу шагыйрь бер адым алга атлады диярго була. Ул күренекле шагыйребез, сугышта батырларча һәлак булган, илдән ерак җирләрдә ятып калган Фатих Кәрим турында бер цикл шигырьләр иҗат итте.

Муса үлде...
Син.
Галимҗан...
Үлде Шамил Усманов,
Беләм, беләм,
Үлеп була
Үлемнән өстен калып,—

ди шагыйрь, һәм тагын:

Өченче ядрә,
Фатих йөрәгендә
Чарпаланып миллион ярчыкка,
Барып тия һәр сабыйга, яшькә,
Һәр агайга, картка, карчыкка...—

дип өсти.

Р. Харисовның бу цикл шигырьләре үз күлмәкләрен киеп туганнар. Элегрәк елларда бер төркем яшьләр поэзиядә «новаторлык» белән шактый озак газапландылар. Аларның баскычлап та, «аткырылып-тоткырлап» та, «ак шигырь», «зәңгәр шигырь» итеп язган тәҗрибәләре еш күренгәләде. Поэзиядә яңа форма әчарга маташу иде бу. Әмма шигырьләрнең күбесе я озын ыштанлы, я кыска күлмәкле булалар иде. Гаҗәп түгел, мондый шигырьләрнең я кендекләре күренә, я башка урыннары ялтырый торган иде. Шуңа күрә Р. Харисовның югарыда күрсәтелгән шигырьләренә карата мин «үз күлмәкләрендә» дигән сүзләрне кулландым.

Минемчә, шигырьдә форма — ул барыннан да элек тәртип, дисциплина. Шигырь дисциплинаны барлыкка китерүче факторлар. Болардан башка шигырь тумый. Кызганычка каршы, бездә «дисциплинасыз» шигырьләр дә бар әле. Мисалларын шул ук Р. Фәйзуллин, Р. Гатауллин, Р. Әхмәтҗанов, Р. Харисов һәм бүтән кайберәүләрнең иҗатында күрергә мөмкин. Мондый шигырьләр солдатлары стройда йөри белмәгән ротага охшый. Анда да бит кайбер солдатлар сул аякка, кайберләре уң аякка атлый, кайберләре артка калып, я колоннадан читкә чыгып баралар. Бездәге «ирекле» шигырь дип аталган нәрсә әнә шул тәртипсез ротаны хәтерләтә дә инде. Исемдә, бер яшь тәнкыйтьче бу шигырьләрне «поэзияне кешенең көндәлек тормышындагы гади сөйләү теленә якынлаштыру» дип яклаган иде. Ә ни өчен поэзиядә нәкъ шундый форма уңышлы дип каралырга тиеш? Бездә аның өчен проза бар. Рифмалар таба алмыйсың, иҗекләрне, басымнарны дөрес куя белмисең икән — проза яз. Әмма онытма: прозада да ритмның, аһәңнең, музыкальлекнең булуы мәҗбүри закон.

Дөрес, шигырьне шигырь иткән нәрсә рифмалар, ритм, үлчәү яки иҗек саннары гына түгел. Моның өчен купшы сүзләр дә кирәкми. «Поэзия сурәтләр, образлар белән генә сөйләшә»,— ди Белинский. Бу — поэзиянең законы. Әмма соңгы елларда бу канун белән исәпләшмәү фактлары да шактый күренде. Рифмалы прозага тартым «шигырьләр» безнең поэзия тавында катлам-катлам булып яталар. Шуңа күрә ул таудан алтын эзләүләре һаман кыенлаша бара. Бу барыбызга карата да әйтелгән сүз. Бу — безнең поэзиябезнең төп кимчелекләреннән берсе һәм иң-иң олысы.

Шуңа өстәп тагын бер фикер әйтеп үтәсе килә. Бездә, прокатка алынган музыка коралы кебек, бер шигырьдән бер шигырьгә, бер автордан бер авторга күчеп йөри торган образлар, рифмалар тәмам туйдырдылар инде. Юлында — кулында, турында — урында, күзендә — сүзендә, бабалар — балалар, алалар — калалар кебек кыршылып беткән рифмалар кемнең шигырендә юк? Каен турында без нечкә билле ак каен диюдән, Идел турында киң Идел, тирән Идел, анабыз Идел диюдән, чишмә турында чылтырап ага, җырлап ага, көмеш сулы диюдән дә ераграк узганыбыз юк. Ә кеше портретын без ничек сызабыз? Безнең герой, гадәттә, зәңгәр күзле — алтын чәчле, шомырт күзле — кара чәчле була. Әйтерсең бер үк баш, геройларның берсеннән

лыбызда меңтөрле буяулары белән балкып торган тел исемлә палитра булганда мондый хәлгә күпме түзеп торырбыз икән? Безнең шагыйрьләребездә Татарстанның менә дигән портреты дип мактап әйтерлек рәсеме дә юк бит әле. Искиткеч матур җирләрдә гомер итәбез, туган җиребезне, халкыбызны яратабыз. Ә шигырьләребездә шуның ямьле табигате, матур һәм батыр кешеләре гомергә онытылмаслык итеп әле җитәрлек сурәтләнми. Ә менә Рәсүл Гамзатов, бер үзе диярлек, Кавказ кадәр Кавказны, аның кар башлы таулары белән, шаулы шарлавыклары белән, кызлары, егетләре белән, үз җилкәсенә күтәреп алды да халыкара мәйданга китереп куйды.

Нәкъ менә шул сүзләрдән соң бүгенге көн темасы турында сөйләшү үзеннән-үзе сорала да инде. Бүгенге көн темасы — ул син яшәгән заман. Син үзең күргән табигать, син үзең очраткан кешеләр, ниһаять — синең туган иленнең язмышы, шатлыгы, кайгысы. Узганны без яхшы язабыз, киләчәккә дә күз салабыз. Ә үзебез яшәгән заманны җырлау эшен күбрәк киләчәк буын шагыйрьләренә калдырабыз шикелле тоела.

Рус поэзиясенең классиклары һәм хәзерге танылган шагыйрьләре — оста пейзажистлар, оста портрет ясаучылар. Сүз дә юк, без русның һәркем өчен зур мәктәп булган алдынгы поэзиясен, аның гүзәл үрнәкләрен укыйбыз, өйрәнәбез. Әмма бу өйрәнү беркадәр киңәш сүзенә мохтаҗ дисәм ялгышмам, бәлки. Эш болай тора: кайчакта кайбер татар шагыйрьләренең кайбер шигырьләрендә кайчандыр инде рус матбугатында укыган фикерләрне, хәтта кайбер сурәтләрне дә очратасың. Дөрес, төрле милләт шагыйрьләренең уртак фикерләре белән шигырьдә очрашулар бик мөмкин. Чөнки без, Советлар Союзында яшәүче барлык милләтләр дә, бер уртак уй белән, бер уртак теләк белән яшибез. Әмма бу очрашу һәркемнең үз халкы телендә, үз халкы җирлегендә, үз халкы гореф-гадәтләре нормасында булырга тиеш. Тема кабатланса да, ул һәр милләт шагыйренең үзенчәлекле үз темасы булып калсын. Әмма рус поэзиясе белән бик якыннан таныш булган хәлдә, без татар укучыларына татарча иҗат итәргә тиешбез. Аны тәрҗемә иткәндә ул рус телендә дә, башка телләрдә дә ер-яңа әсәр булып яңгырасын. Монда без, минемчә, сюжетлы шигырьләр белән генә алдыра алабыз.

Шунысы шатлыклы, узган елда яшьләр әсәрләрендә «новаторлык» дип дан алган формаль эзләнүләр белән мавыгу бөтенләй сизелми диярлек. Яшьләр хәзер тәртәгә кереп баралар. Алар хәзер үз арбаларына нәрсә куеп, нәрсәне тартып барырга кирәклеген аңлап эшлиләр.

Безнең союз идарәсе, әледән-әле җыелышлар, олы шагыйрьләр белән очрашулар оештырып, яшьләр иҗаты турында сөйләшүләр, әңгәмәләрне күбрәк үткәрергә тиеш.

Мондый сабак бирүләр бик кирәк. Чөнки яшьләр арасында инкубаторда яралган этәчкә охшаганнары да күренгәли әле дияр идем мин. Алар йомырка кабыгын ватып баш тырттелар исә: «— Кая, китерегез әле бире тавыкларыгызны»,— дип кычкыра башлыйлар. Бу «мин талант» дип урынсызга кәпрәеп йөргәннән килә. Ә чын талант телдә түгел, эштә күренә. Яшьләр арбага нәрсә төяп, нәрсә тартып баралар дигән сүзне, инде бик яшь булмаса да, Рәшит Гәрәй шигырьләреннән башлыйк әле. Узган елда аның шактый калын китабы чыкты. Шул китапны укыгач, мин күз алдымда бер ялгыз юлчы күрдем шикелле. Ул бара. Йөгерми дә, туктап та тормый. Юлы таптакыр. Көлми дә, еламый да. Шатланмый да, ачуланмый да. Юлында нәрсә күрсә, шуны капчыгына тутыра бирә. Кирәкме бу, кирәкмиме? Уйлап тордым — юк. Менә юлда чишмә. Рәшит аның турында да яза. Менә болын, әнә торналар оча, әнә зират. Шагыйрь барысын да яза бара, яза бара. Инде аргач, әнкәсе җибәргән мендәргә башын куеп, йоклап та ала. Аннан соң тагын юлга чыгып китә. Себергә барып җитә.

Дөресен генә әйтеп бирегез әле:
Булганыгыз бармы Себердә?
Булмасагыз, киңәш итәм сезгә
Хет бер тапкыр барып күрергә.

Шигырьләр менә шундыйрак стильдә, 10—9 иҗекле монотон белән язылганнар, барысы да бер төсле диярлек.

Рәшит Гәрәйнең матур шигырьләре дә бар. Әмма менә болай еламыйча, борчылмыйча, янмыйча яза торгач, ул яхшы шигырьләр дә күренми башлар. Рәшит Гәрәй шигырьләрендә гражданлык хисләре дә юк түгел. Әмма пафос җитми. Шигырьләрдә яндыра торган, көйдерә торган сүзләр, образлар, уйлар аз. Эрнест Хемингуэй шулай ди: «Минем иң яхшы тәнкыйтьчем — мин үзем». Рәшиткә, минемчә, шул тәнкыйтьче җитми.

Туры сүзне мин үзем дә яратмыйм. Әче нәрсә ул. И. Гази әйтмешли, тәнкыйтьне кем ярата? Әмма һәр шагыйрьгә андый тәнкыйтьчедән башка эшләргә дә, яшәргә дә мөмкин түгел.

Инде Равил Фәйзуллин белән Рәдиф Гатауллин турында. Мин аларны юкка гына янәшә куймадым. Болар, бу ике яшь кеше, безнең поэзиядә игезәк туганнар. Аларның язу стильләре дә, дөньяга карашлары да бер төрлерәк, новаторлыкта да алар бертөрле юл ярып баралар. Аларның хәтта китап исемнәре дә бер төрлерәк — таштан ясалган: берсенеке — «Мәрмәр», икенчесенеке — «Күңел ташлары». Бу ике шагыйрь дә чын мәгънәсендә эзләнүче шагыйрьләр. Эзләнүләре дә бушка түгел. Алар яңаны таба беләләр. Аларның беренче шигырьләре безне кинәт аптырашта калдырган булсалар да, тора-бара без аңлаштык. Укучылар белән авторлар арасында, билгеле, нинди дә булса, син миңа тимә, мин сиңа тимим, диган сөйләшү — үзара договор булмады. Эш башкачарак тора. Авторлар, ягъни бу ике шагыйрь укучыларга аңлаешлы итеп яза башладылар. Шул ук вакытта алар үзләренең «новаторлыкларыннан» да баш тартмадылар. Шигырь формасын шомарттылар, үстерделәр һәм бу аларга шактый катлаулы, зур теманы да җиңел итеп, кыска итеп әйтергә мөмкинлек бирде. Бу инде осталыкның үсүе дигән сүз. Кыскасы, алар үзләрен поэзия тимерчелегендәге сандалга куйдылар һәм тәнкыйть чүкечләренең сугыныа чыдарга тиеш булдылар. Күрәсез, чыдыйлар, ныгыйлар. Аларның темасы — Кеше. Алар, алмазны тикшерүчеләр кебек, кешенең катлаулы язмышын тик үзләре генә ачкан «микроскоп» астына куеп карарга телиләр. Тәнкыйтьчеләребез бу ике шагыйрьнең иҗатына тиешле игътибар бирерләр һәм үз сүзләрен әйтерләр әле. Хәзергә шунысы ачык: «Мәрмәр» һәм «Күңел ташлары» 1970 елдагы поэзиянең бер уңышы булып саналырга тиеш.

Талантлы яшьләребез күп. Китапларын актара башласаң, моңа ышаныч арта бара. Шуларның берсе — Гәрәй Рәхим. Аның «Хәтер» исемле китабында, бер карасаң, әллә ни тематик яңалык та юк төсле. Ләкин Гәрәй Рәхим иске тема материалын да яңача әйтә белә. Үлем белән яшәү турында, мәсәлән, һәрбер шагыйрьдә дә ниндидер юллар табып була. Гәрәй Рәхим исә бу хакта үзенең яңа сүзен әйтте:

Мин кешедән көчле диеп,
Вакыт юкка көлә,
Кабердә [illegible],
Мәетләр генә.

Ул бер шигырендә:

Дөньядан ничә мизгелгә
Әҗәткә алган көем!
Китәсең кире дөньяга
Сүзләрдән киеп кием,—

ди.

Эш әнә нәкъ шунда да шул — Дөньядан әҗәткә алып язарга! Аннан соң халыкка бирергә, үзеңә мактау сүзләре көтмәскә. Шигырьләреңне яратып укысалар — менә сиңа мактау, менә сиңа дан. Шулай да Гәрәй Рәхимгә туган телебезне тирәнрәк өйрәнергә, халык сөйләмен ныграк үзләштерергә кирәк.

Дөньяга, табигатькә, чәчәккә, матур кызга гаҗәпләнү, ямьсезлеккә, явызлыкка, усаллыкка нәфрәтләнү — шагыйрьнең төп сыйфаты. Сәләтле һәм бик актив эшләүче яшь шагыйрь Зөлфәт тә шулай дөньяга, тормышка гаҗәпләнеп, кызыгып карый. Аны үзенә шигъри студия ачты диярга мөмкин: ул туган җир күренешләрен рәсем итеп ясый. Илдәшләренең портретларын төшерә. Бу — дөрес юл. Зөлфәтнең шигырьләрен укыгач, ул — зур йортның нигезен салып торучы ташчы кебек. Ул әле зур поэмалар язмый. Ул әле шул булачак поэманың кирпечләрен генә эшкәртә. Ә кирпечләр таза, нык булып чыгалар. Чөнки шигырьләрендә рәсемнәр дә бар, кеше дә бар, кайнар хис тә бар. Иң кирәге — шигырьнең кирәклеген белеп язу бар.

Биредә барлык шагыйрьләрнең дә иҗатына тукталу, әлбәттә, мөмкин түгел. Үз иҗатларына җентекле анализны, тиешле бәяләү яки киңәш сүзләрен әле бик күпләр көтә һәм ул сүзне, һичшиксез, әйтергә кирәк. Нәкъ менә шунда инде тәнкыйтьче дусларыбызга: «Сез кайда соң, иптәшләр?» — дип аваз саласы килә.

Бер дә яшерен-батырын түгел бит: безнең совет чорындагы поэзияне кем өйрәнә хәзер? Бигрәк тә сугыш елларыннан соң иҗат ителгән поэзияне чирәм басып бара бит инде. Дөрес, бу өлкәдә Нил Юзиев актив эшли. Аның татар поэзиясе турында берничә китабы да чыкты. Әмма бу аз, бик аз.

Тагын шунысы гаҗәп, поэзия турында сүз кузгала калса, Г. Тукай, һ. Такташ, Х. Туфан, М. Җәлил, С. Хәким һәм тагы берничә исемне әйтәләр дә нокта куялар. Дөрес, кайчакта бу исемнәр артыннан «һ. б.» дип тә языла. Менә шул «һәм баш-

ый хезмәт күрсәткән кешеләр бит. Мәсәлән, Хисам Камалны кем телгә алганы бар? Ә ул бит күптән яза инде. Дистәдән артык китап чыгарган автор. Аның ихтирамга лаеклы поэмалары, шигырьләре шактый. 1970 елда да тагын бер яңа китабы чыкты. Шул ук вакытта аңа ярдәм дә кирәк. Чөнки, миңа калса, Хисам Камал элегрәк елларда матуррак, хислерәк яза иде. Китапка кергән «Минем әти кайда?» дип бик кызыктыргыч исем белән аталган поэма шундый фикергә китерә. Дөрес, темасы нәкъ безнең заман өчен, язылышы да авыр сүз әйтерлек түгел. Әмма «Атасыз бала белән җилбәзәк ана» арасындагы язмышлар дөрес чишелмәгән. Күрәсез, тәнкыйть сүзен ишетмәгән авторга барган саен юл кыенлаша. Шундый ярдәмне безнең күп кенә шагыйрьләребез күрмиләр.

дәррис, Әнвәр Давыдов, Зыя Мансур, Гали Хуҗи, Сахаб Урайский һәм тагын башкалар шулай бик тиз онытылырга тиешләр идемени? Тәнкыйть күзеннән төшеп кала торган шагыйрьләрне тагын дистәләп санап була. Г. Латыйп, С. Шакир, А. Сәләхетдинов, Г. Нәбиуллин, Җ. Тәрҗеманов, Ә. Маликов кебек күп еллар буе поэзиядә эшләгән иптәшләр турында кем нәрсә әйткәне бар?

Тагын бер фикер әйтергә җае туры килде. Бездә инде ничә еллардан бирле университетның филология бүлегендә һәм педагогия институтында укучы татар яшьләре күп кенә шагыйрьләрнең иҗаты буенча диплом эшләре язалар. Алар, нигәдер, бары киштәләрдә генә яткырыла. Шуларны, аерым китап итепме, бер альманахка бергә туплапмы, бастырырга һәм укучылар кулына бирергә кирәк иде.

## Галия Хантемирова

# БЕРЕНЧЕ АДЫМНАР

Кешелек дөньясының культура үсеше тарихында әдәби тәрҗемәнең әһәмияте гаять зур. Бу турыда әле егерменче елларда ук Максим Горький болай дигән иде: «...сүз сәнгате — матур әдәбият — кешеләрнең үзара аңлашуына ярдәм итә... төрле кабилә кешеләре бер-берсенең эчке дөньясын... никадәр яхшырак белсәләр, алар үз алларына куйган гомуммаксатка шулкадәр тизрәк ирешерләр».

Безнең илебездә яшәүче күп милләтле тугандаш халыклар үзара рухи байлык, тормыш тәҗрибәсе уртаклашып яшиләр. Өзлексез дәвам итә торган бу процесста әдәби тәрҗемәнең тоткан урынын тулырак күз алдына китерү өчен, тарихка әйләнеп карау да кирәктер.

Октябрь революциясенә кадәр татар әдәбияты рус теленә бөтенләй тәрҗемә ителмәгән диярлек. Төрки телләрне өйрәнүче рус галимнәре башлыча татарларның этнографиясе һәм авыз иҗаты белән кызыксынганнар. Шунлыктан рус фәнендә фольклор әсәрләре язма әдәбият үрнәкләренә караганда күбрәк билгеле булган.

Н. И. Ашмаринның 1901 елда Мәскәүдә басылып чыккан «Очерклар...» китабын[1] татар әдәбиятын өйрәнүдә беренче тәҗрибә дип карарга мөмкин. Бу китапка автор күп кенә табышмаклар, мәкальләр, халык җырлары туплаган, Габделҗаббар Кандалый, Фатих Халиди әсәрләренең эчтәлеген русча сөйләп чыккан. Беренче татар прозаиклары Заһир Бигиев һәм Муса Акъегет Задә иҗаты турында кыскача мәгълүматлар биргән.

Милли әдәбият әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итеп бастыру һәм пропагандалау эшенә А. М. Горький гаять зур көч куя. Пролетариатның бөек язучысы шулай ук татар әдәбияты үсешен дә өзлексез күзәтеп килә. Ул рус телендә татар әдәбияты альманахы бастырып чыгарырга җыена һәм 1912 елда бу китапның планын да төзи. 1914 елда исә, А. М. Горький тәкъдиме буенча, Көнчыгыш телләр институты Г. Тукай шигырьләренең тәрҗемәсен бастыра.

Революциядән соң татар теленнән русчага беренче тәрҗемәләр егерменче елларда күренә башлый. 1920 елда Казанда һәм Ташкентта Г. Тукай шигырьләре һәм тагын бер ел үтүгә «Шүрәле» поэмасының тәрҗемәсе бер-бер артлы аерым китаплар булып чыга. Илебез халыкларының милли әдәбиятын өйрәнүгә бу елларда гомумән зур әһәмият бирелә. «СССР халыклары иҗаты» (1924), «СССР халыклары поэзиясе» (1928) исемле гомуми җыентыклар дөньяга килә. «Совет иле» дигән әдәби альманах басыла башлый. 1927—29 елларда аның өч саны чыга. Шигъри җыентыкларга Г. Тукай әсәрләре һәм татар халык җырлары да кертелә. Г. Ибраһимовның «Табигать балалары» һәм Ш. Камалның «Сукбай» новелласы альманах битләрендә урын ала.

1928 елда РСФСР Дәүләт нәшрияты «Совет халыклары әдәбияты» исемле альманах бастырып чыгаруны планлаштыра. Шул уңай белән 1930—33 елларда татар әдәбияты әсәрләренең тәрҗемәләреннән төзелгән өч альманах дөньяга килә. Бу альманахларның беренче һәм өченче саннарына шул соңгы елларда язылган әсәрләр, ә икенчесенә Г. Тукай, Ш. Камал, С. Рәмиев, Дәрде-

[1] Н. И. Ашмарин. Очерк литературной деятельности казанских татар-мохаммедан за 1880—1895 годы.

лана.

Тәрҗемә өлкәсендә ясалган бу беренче адымнар нинди рәк булганнар соң? Ул чорларда басылып чыккан тәрҗемәләрнең сыйфаты, әдәби эшләнеше ни дәрәҗәдә?

Мәсьәләнең бу ягы әлегә бөтенләй өйрәнелмәгән һәм матбугатта яктыртылмаган. Шуңа күрә, татарчадан русчага тәрҗемә итүнең теориясе һәм бүгенге практикасы мәнфәгатендә, бу беренче адымнарны өстән-өстән булса да бер кат күздән кичерүне кирәк дип санадык.

Югарыда әйткәнебезчә, совет чорында чәчмә әсәрләрдән беренче буларак Г. Ибраһимовның «Табигать балалары» хикәясе һәм Ш. Камалның «Сукбай» новелласы рус укучыларына тәкъдим ителгән иде. Бу тәрҗемәләрнең исемнәренә генә игътибар иткәндә дә ул чордагы тәрҗемәчеләрнең теоретик хәзерлеге ни дәрәҗәдә булганын шактый ачык күз алдына китерергә мөмкин. Г. Ибраһимов хикәясенең исеме альманах эчтәлегендә «Дети природы» дип саф русча бирелгән, ә китапның эчендә исә, татар телен бераз бозып, яньчеп, «Табиат балалары» дип калдырылган. «Совет иле» альманахының өченче санында Ш. Камал новелласының исеме тәрҗемә ителмичә, «Сукбай» дип алынган. Әмма әсәрнең эчендә кабат бер генә мәртәбә дә «сукбай» сүзе очрамый, новелла героен тәрҗемәче һәркайда «бродяга» дип атый. Шулай итеп, әсәрнең исеме рус укучысына бөтенләй аңлашылмый кала.

Тәрҗемәләрне ныклабрак тикшерә башласаң, болардан зуррак «гөнаһлар» да күзгә бәрелә. «Табигать балалары» хикәясен тәрҗемәче күп кенә урыннарда үзе ничек тели шулай үзгәртә. Бишенче бүлекне нык кыскартып, алтынчы бүлек белән берләштерә. Шулай ук икенче бүлектәге Җамали карт кызы турындагы өлешне бөтенләй төшереп калдыра.

Дөрес, тәрҗемәнең кайбер уңай якларына да күз йомарга ярамый. Әйтик, әсәрдәге күп кенә мәкальләр, әйтемнәр, фразеологик әйләнмәләр шактый төгәл һәм уңышлы тәрҗемә ителгәннәр. Мәсәлән:

«Әйткән сүз — аткан ук, дигән борынгылар» — «Сказанное слово — пущенная стрела, говорили в старину». «Ир ике әйтмәс...» — «Мужчина своему слову не изменит».

Тәрҗемәдә «алла», «ходай» сүзләрен христианлаштырмыйча, үзенең мәсәлманча яңгырашында «аллах» рәвешендә калдыру так и будет». («Совет иле» альманахы. 37 бит.) Үз мәгънәсендә һәм үз яңгырашында бирелгән мондый сүзләр әсәрнең җирлеген, милли буяуларын сакларга ярдәм итәләр.

Әмма беренче карашка нәкъ шундый ук булып күренгән кайбер алымнар кайчак бөтенләй кире нәтиҗә дә бирел куялар. Әйтик, тәрҗемәче «авыл» сүзен тәрҗемә итмичә, «аул» рәвешендә калдыруны кирәк тапкан. Һәркемгә билгеле булганча, «аул» сүзе рус әдәбиятында элек-электән күчмә кабиләләр һәм тау халыклары яши торган авылларга карата кулланылган. Ә татар һәм рус авылларының төзелеше, тышкы күренеше арасында артык аерма юк. Шунлыктан бу сүзне саф русча «деревня» дип тәрҗемә итү урынлырак булыр иде.

«Мәһәр» сүзен «калым» дип тәрҗемә итү дә рус укучысында татар кәнкүреше, татар йоласы турында дөрес төшенчә бирә алмый. Чөнки кыргыз, казакъ, төрекмән халыкларында кыз бәрабәренә көтү-көтү маллар рәвешендә бирелә торган калым татар мәһәреннән нык аерыла.

Талантлы язучыбыз Ш. Камал өчен телдә төгәллек, җыйнаклык, гадилек хас. Әмма «Сукбай» хикәясен тәрҗемә иткәндә тәрҗемәче ни сәбәпледер аның мондый сыйфатларын әһәп бетермәгән, курәсең. Әсәрнең тәрҗемә телендә ул үзеннән бик күп кирәкмәгән бизәкләр кертә. Һәм шуның нәтиҗәсендә новелла күп урында ясалма булып чыга, җөмләләрнең яңгырашы гына түгел, мәгънә ягы да зәгыйфьләнә. Мәсәлән: «Карт тегермәнчедән разый түгел, әнның эресенә»... дигән җөмләне тәрҗемәче болай үзгәртергә кирәк тапкан: «Чем теперь кормиться будем. Беда!»

Тегермәнченең акланүына каршы карт тыйнак кына: «Анысы шулайдыр шул,— ди.— Хатыннарга яраса ярый инде ачуланмасалар...»

Тәрҗемәче исә бу очракта да бизәкләр кертә: «Так-то оно так, только не понравится это бабам... Ах! и будет история!» (Альманах. 12 бит.)

Бу мисаллардан ачык күренгәнчә, тәрҗемә теленең мондый зәгыйфьлегә фикер төгәллеген генә түгел, характерларның бөтенлеген дә боза. Әз сүзле, сабыр холыклы татар карты урынына кулларын бутый-бутый ах-вах кычкырына торган бер җилбәзәк бәндә күз алдына килә. Бу тәрҗемәдә язучының стилен җимерү, грамматик хаталар, мәгънә төгәлсезлекләре тулып

мисалга китерүнең кирәге юк. Тик шуны әйтергә кирәк, әлеге шактый җитди кимчелекләренә карамастан, ике зур татар әдибенең рус укучысына барып ирешүе егерменче елларда безнең халык өчен куанычлы хәл иде.

Инде утызынчы елларга күчеп, ул чордагы тәрҗемә принципларын бераз күз алдына китерергә телибез икән, 1931 елда рус телендә басылып чыккан «Татар әдәбияты җыентыгы»н ачып карарга кирәк. Югарыда әйтелгәнчә, бу санга иң күренекле әдипләребезнең революциягә кадәр язылган әсәрләре тупланган. Бу җыентыкның дөньяга килүен «Ленинград» журналы да хуплап каршы алды. Анда бу уңай белән Д. Выгодскийның зур гына мәкаләсе басылып чыга. Автор үзенең бу мәкаләсендә: «... бу ике җыентык чынлыкта татар әдәбиятының бөген тарихын үз эченә ала»[1], дигән фикергә алга сөрә.

Җыентыкта бирелгән кереш мәкаләдә дә шул ук фикер куәтләнә. Рус тәнкыйтьчеләренең татар әдәбиятын ни дәрәҗәдә белүе өнә шул сүзләрдән бик ачык күренә. Күп гасырлар буе үсеш баскычларын узган зур әдәбиятның «туган көнен» алар бары тик XX йөздән башлап кына исәпләгәннәр.

Җыентык битләреннән бер күз йөгертеп чыгуга ул чорда руслар өчен татар әдәбиятының «кара урман» булганлыгы тагын да ачыграк күзгә ташлана. Анда хәтта классик әдипләрнең исем-фамилияләре дә зур ялгышлар белән бирелгән: Галимҗан Ибраһимов — Галидман Ибрагимовка, Шәриф Камал — Шериф Кемальгә әверелгән. Шәһит Әхмәдиевнең исемен ишеткән кеше дә булмагам, күрәсең. Китапта ул «Ахмидиев» дип кенә телгә алынган.

Тәрҗемәче үзе тәрҗемә итәргә алынган әсәрнең рухын дөрес бирергә, аның милли үзенчәлегенә хыянәт итмәскә һәм шул ук вакытта мөмкин кадәр авторның стилен, хикәяләү алымын, тел үзенчәлеген сакларга тиеш. Әле XIX йөздә үк русның алдынгы әдипләре, тәнкыйтьчеләр, тәрҗемәчеләр, шул исәптән Пушкин һәм Белинский әдәби тәрҗемәгә карата өнә шундый таләп куйлар. Әмма бездә 30 елларда бу карашларны ялгыш аңлау, я булмаса алардан бөтенләй йөз чөереп, буквализм һәм формализм белән мавыгу нык сизелә. Күп кенә аерым бер төре итеп караудан бигрәк, аны геометрия, алгебра кебек төгәл фәннәргә тиңләштерәләр. Әдәби әсәрне бер телдән икенче телгә тәрҗемә иткәндә, янәсе, төгәллеккә омтылып, сүзне сүзгә авыштыручылар күбәя. Без телгә алган әлеге җыентыкның тәрҗемәчеләре дә, әлбәттә, шул карашлар коллыгыннан котыла алмаганнар.

1931 елгы җыентыкта Галимҗан Ибраһимовның «Табигать балалары» һәм «Карт ялчы» хикәяләре «авторизованный перевод» дип бирелгән, әмма тәрҗемәчеләрнең исеме күрсәтелмәгән. Шул сәбәпле, биредә без дә аларның исемен атап әйтүдән мәхрүм.

Әсәрнең фикер агышы, телдәге милли өлгеләрнең үзенчәлеге белән кызыксынмыйча, турыдан-туры сүзгә-сүз авыштыру нәтиҗәсендә, тәрҗемәдә тел шапшаклыгы, фикер буталчыклыгы күзгә бәрелеп тора. Мәсәлән, «Карт ялчы» хикәясендә: «...шуның белән чәй-шикәрлек таба», дигән юллар бар. Халык теленнән алынган бу образлы сөйләмдә сүз, әлбәттә, чәй белән шикәр сатып алу турында гына бармый. Без һәркайсыбыз аны «көз-мәз тамак туйдырырлык», «ачтан үлмәслек» мәгънәсендә аңлыйбыз. Бу мәгънәне русчада «...заработал на хлеб насущный» рәвешендә шактый төгәл һәм рус укучысына аңлаешлы итеп бирергә була. Ләкин тәрҗемәче бу турыда уйланып баш ватмый, «заработка хватало на чай-сахар» дип, сүзгә-сүз күчерә.

Мондый авыштыруларның никадәр мәгънәсезлеге әсәрдәге мәкаль һәм әйтемнәрнең тәрҗемәләрендә аеруча ачык күренә.

«Тот капчыгыңны, акылың алтын икән!» дигән фразеологик әйләнмә тәрҗемәдә: «Ну, нет, держи свой мешок, ишь какой у тебя ум золотой» дип бирелгән.

Бу очракта тәрҗемәче шушы әйләнмәнең тышкы кабыгын гына түгел, эчке мәгънәсен дә җимермичә, гариплендермичә бирә алырлык сүзләрне рус теленең үз хәзинәсеннән эзләргә тиеш иде. Һәм аны озак эзләп торасы да юк: «Держи карман шире, ишь какой умный!»

«Син ашыкканда, ул кабалана» дигән фразеологик әйләнмәне «Ты спешишь, а он опрокидывается» дип, «типсә тимер өзәрлек» дигән әйтемне «железо ногой сломит» рәвешендә тәрҗемә итүне шулай ук буквализмга баш оруның аяныч нәтиҗәләре дип карарга мөмкин.

Татарларның телен, фикерләү һәм сөйләм үзенчәлеген бөтенләй белмәгән рус

[1] Д. Выгодский. Татар әдәбияты. «Ленинград» журналы. 1931 ел. 5 сан. 121 бит.

укучысына «держи свой мешок», «кум золотой», «железо ногой сломит» кебек кальказлар, әлбәттә, бик мәгънәсез һәм көлке тоелырга тиеш. Безнең өчен «чыктым аркылы күпер» ничек яңгыраса, башка милләт өчен болар да нәкъ шулай.

Югарыда сөйләнгәннәргә кыскача сөземтә ясаганда шул ачык күренә: егерменче елларда тәрҗемәчеләр әсәрне үзләреннән үзгәртеп, бизәкләр өстәп «төзәтергә» омтылганнар. Ө утызынчы елларда исә, киресенчә, оригиналга чат ябышып, формаль рәвештә тәрҗемә итү принцибы киң таралган.

Ул чорларда басылып чыккан тәрҗемәләрнең түбән сыйфатлы булуына китергән тагын бер җитди сәбәп бар. Тәрҗемәче үзе тәрҗемә итәргә алынган әдәбиятны, ул халыкның телен, тарихын, культурасын һәм милли йолаларын тирәнтен белергә тиеш.

Ә без тикшерә торган әлеге җыентыклардан нәрсә күренә соң? Менә берничә мисал:

«Мин киткәндә атай карт икендегә тәһарәт ала калган иде» дигән җөмлә «Когда я выезжал, отец совершал омовение и икенди» дип тәрҗемә ителгән. Димәк, карт бер үк вакытта намаз укый һәм тәһарәт ала булып чыга.

Ураза вакытында таң алдыннан ашала торган сәхәр ашы тәрҗемәдә тырнаклар эченә алып, «сахар» дип бирелгән. Ә сноскада аның мәгънәсе «сахар» — ужин дип аңлатылган. «Гошер» һәм «фитыр» сүзләрен тәрҗемәче үзенчә ниндидер бәйрәм исемнәре дип аңлаган, күрәсең. «Хозяин бывал довольно щедр к Шагибеку: каждый год давал ему большой воз хлеба в Шеир и всякие обноски во время поста Фитр».

Мисаллардан ачык күренгәнчә, халыкның дини йолалары турында тәрҗемәченең әз генә дә төшенчәсе юк. Шулай булгач, рус укучысы бу тәрҗемәдән нәрсә аңлый алсын! Шул ук вакытта «Табигать балалары» хикәясенең тәрҗемәсендә җиңги сүзе кешә исеме итеп баш хәрефләр белән бирелгән. Фәрхи апа Фахригә әверелеп, кәтмәгәндә ир кеше булып калган. 1931 елгы бу җыентыкка Ф. Әмирханның «Татар кызы» һәм «Сәмигулла абзый» хикәяләре, Ш. Камалның дүрт новелласы тәрҗемә итеп кертелгән. Ныклап карагандa аларда да шундый ук кимчелекләр тулып ята. Беренче карашка, хәтта мондый тәрҗемәләрне рус укучысына тәкъдим итү төзәтә алмаслык зур хата булган икән, дигән нәтиҗә дә чыгарырга мөмкин. Ләкин бу очракта Н. А. Добролюбов сүзләрен хәтергә төшереп китү урынлы булыр. Чит телләрдән рус теленә беренче тәрҗемә ителгән әсәрләргә карата ул болай дигән:


«...матур поэманың яки драманың хәтта начар тәрҗемәсе булу да аның бөтенләй булмавына караганда хәерлерәк..., чит әдәбиятларның гүзәл әсәрләре турында иң элек гомуми төшенчә генә булса да алырга кирәк, ә аннары алардан чын ләззәт алырга мөмкин булачак».

# ПЕРМЬ ТАТАРЛАРЫ ИЖАТЫ

*1960—67 елларда СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты Пермь өлкәсендә яшәүче татарларны өйрәнү максаты белән фәнни экспедицияләр оештырган иде. Экспедиция барышында Пермь татарларының тарихына, этнографиясенә һәм авыз иҗатына караган шактый материал тупланды. Түбәндә әлеге институтның фәнни хезмәткәре Дәрриә Рамазанова тарафыннан язып алынган кайбер җырларны тәкъдим итәбез.*

## Сөрән сугу җырлары

*I вариант*




**Алтын да гынай ишек, көмеш тупса,**
**Атлый да гына атлый без кердек.**
**Җиңгәчәй белән агачайдин**
**Өрехсәтләр сорап без кердек.**

Озын да чыршы, ай, бүрәнә,
Чаналарга салсаң, сөйрәлә.
Җиңгәчәй биргән тастымалым
Буеннарга элсәм сөйрәлә [1].

*II вариант*

Җырла дисәң, бән җырлыем, җаныем,
Сүзләрең өчен азырак.
Азраклардин күпләр булсаң, җаныем,
Гаепләргә алмаң, хәзерәт.

Озын да гына чыршы, ай, бүрәнә, җаныем,
Чаналарга салсаң, сөйрәлә.
Ошбу җиңгә биргән тастымалкай, җаныем,
Буеннардин җиргә сөйрәлә.

Тастымалкайларың бигрәк нечкә, җаныем,
Килер дә генә микән биш мыскал.
Килсә дә генә килер, ай, биш мыскал, җаныем,
Җефәккәе булыр өч мыскал.

Тастымалкайларың бишәр кисәк, җаныем,
Кисәкләре аның бер сумлык.
Кисәкләре аның, ай, бер сумлык, җаныем,
Ошбу җиңгә булыр мең сумлык.

Чаба-җилә килә күк юрга,
Ходаем гомерең бирсен күп елга.
Ап-ак булып ялан төлкесе,
Сез булмассыз әдәм көлкесе [2].

*III вариант*

Ошбу ла йортның баскычлары
Барысы да бадьян агачы.
Ошбу ла йортның хуҗалары
Барысы да былбыл баласы.

Безләр килдек, ай, сезләргә,
Тастымаллар бирдегез безләргә.
Тастымаллар бирдегез, ай, безләргә,
Алла исәнлек бирер сезләргә.

Озын ла чыршы, ай, бүрәнә,
Чаналарга салсаң, сөйрәлә.
Җиңгәчәй биргән тастымалым
Муеннарга салсам сөйрәлә.

Җиңгәчәй биргән тастымалның
Җифәкләре бардыр биш мыскал.
Җифәкләре аның, ай, биш мыскал,
Укалары бардыр ун мыскал [1].

---

[1] Октябрь районы Малый Сарс авылында Ширазнов Ризван абзыйдан язып алынды. Көйләрне нотага Институт сотруднигы И. Кадыров салды.

[2] Октябрь районы Югары Шуртан авылының данлыклы сәрәнчесе Хәтмуллин Мөталап абзыйдан язып алынды.

[3] Октябрь районы Бикбай авылында Суфиев Мулла җырлады.

Ишеклэрдин керел лэ сэлам бирдем,
Теллэреңэ түгел лэ үзеңэ.
Биргэн дэ генэ сэламнэрем алмасаң,
Хурлар да гына булыр ла үзеңэ.

Озын да гына чыршы, ай, бүрэнэ.
Чаналарга салсаң, сөйрэлэ.
Җиңгэчэем биргэн лэ тастымаллар
Таяклардин җирлэргэ сөйрэлэ.

Ошбу да гына өйнең лэ идэннэре
Эллэ нигэ закруйлап алынган.
Безгэ дэ генэ диган лэ тастымаллар
Чыраклык түзлэргэ[1] салынган.

Сандугачлар сайрый ла саз җирдэ,
Алтын белэн көмешлэр бар җирдэ.
Без җырламыйбыз ла күплэр җирдэ,
Без җырлыйбыз дус-ишлэр бар җирдэ[2].

## Мэҗлеслэрдэ җырлана торган җырлар

### Кодалар җыры

Кодалар, сезгэ ни кирэк!
Мэкэрҗэ малларым юк.
Җанымны бүлеп бирер идем,
Җанымнан башка торыр хэлем юк.


Кодагый, имеш, бу кеше,
Калүэт, имеш, тун тышы.
Кодагый булып йөрмэгэ
Хэллэреннэн килми күп кеше.

Кодагыйлар, килгэнсез,
Җиңсез камзул кигэнсез.
Ашар гына өчен килмэгэнсез,
Сынар гына өчен килгэнсез[3].

---

[1] Кишгэ башы.
[2] Сөрэнчэ Юсупов Сэлим җырлады (Октябрь районы, Енопаев авылы).
[3] Ирек елгасы буендагы авылларда язып алынды.


## Сандугач баласы[1]




**Басмастендә сигез үрдәк, дусларым,**
**Сибик бодай симерсен, сандугач баласы.**
**Китик ерак, калсын җылап, дусларым,**
**Бер күрергә тилмерсен, сандугач баласы.**

**Ак калфагың күтәр-күтәр, Хәнифә,**
**Арасыннан җил үтәр, сандугач баласы.**
**Бу дөньялар үтәр-китәр, Хәнифә,**
**Татулыкка ни җитәр, сандугач баласы.**

## Кара перчатка




**Өстәл аяк, дүртләр аяк,**
**Төрле ашлар күтәрә шул.**
**Кушымта:**
**Кара перчатка,**
**Кара перчатка,**
**Сау бул бер шапка[2].**

**Безнең башлар шуңа моңлы,**
**Төрле эшләр күтәрә шул.**
**Кушымта:**
**Кара перчатка,**
**Кара перчатка,**
**Сау бул бер шапка[3].**

---

[1] Октябрь районы Малый Сарс авылында язып алынды. Ширванов Ризван башкарды.

[2] Беразга.

[3] Кунгур районы Казакаево авылында язып алынды.

**Сәвия Латыйпова,**
тарих фәннәре кандидаты

# БОРЫНГЫ КУЛЪЯЗМАЛАР ҺӘМ ИБРАҺИМ ХӘЛФИН ЭШЧӘНЛЕГЕ

Казан университетының адъюнкт-профессоры Ибраһим Исхак улы Хәлфин (1778—1829) хаклы рәвештә алдынгы җәмәгать фикере иясе, татар мәгърифәтчелегенә нигез салучы, торгынлыкка, наданлыкка, залимлеккә каршы армый-талмый көрәшүчеләрнең берсе булып тарихка кереп калды. Шуның белән бергә аның төрки халыклар тарихын өйрәнү, историограф буларак, документаль тарихи чыганаклар табу, аларны матбугатта аңлатмалап игълан итү өлкәсендә дә казанышы зур.

Ибраһим Хәлфиннең бу эшчәнлеге 1800 елда Казанның беренче гимназиясе каршында оештырылган Азия типографиясе белән бәйле. 1802 елдан алып 1828 елга кадәр Хәлфин анда цензор булып торган. Бу типография бик күп кыйммәтле тарихи һәм әдәби истәлекләрне саклап калырга, беренче татар мәгърифәтчеләренең оригиналь әсәрләрен бастырырга мөмкинлек биргән. «Борынгы төрек китабы», «Ельязмалар җыентыгы», «Әхвале Чеңгез хан вә Аксак Тимер вә тәварихлара...» — болар Ибраһим Хәлфин шул типографиядә бастырган тарихи әсәрләрнең кайберләре генә. Хәлфиннең «Татар теле конспекты»[1] фәнни һәм укыту-методик яктан әһәмияткә ия.

Ибраһим Хәлфиннең фәнни эшчәнлеген тулырак итеп күздән кичерү файдалы булыр. «Әхвале Чеңгез хан вә Аксак Тимер вә тәварихлара... сәһләт өчен җәмигъ ләгатьләрене хоруфе һиҗа үзрә тәртиб әйләеп... Ибраһим б. Исхак иҗад вә тәкърар әйләмешем» дигән әсәренең кулъязмасы көнчыгыш илләрнең тарихын һәм культурасын өйрәнүче Казан галимнәре арасында зур игътибар белән тикшерелгән. Бу әсәрне карап чыккач, Я. О. Ярцев, мәсәлән, болай дип билгеләп үтә: «Ошбу хезмәт тарихи өземтәләрне бастыруы белән файдалы, шулай ук төрек һәм татар телләрен өйрәнүчеләр өчен кулланма буларак та игътибарга лаек, чөнки кушымта итеп бирелгән сүзлектә куллнудан төшеп калган һәм яңа төрек (төрки) китапларында булган барлык кыен сүзләр һәм сүз тезмәләре бик төгәл һәм гадел аңлатылган. Монннан тыш ошбу хезмәт яңалыгы ягын-

[1] ТАССР Үзәк дәүләт архивы (ҮДА). Ф. 977. Ректор описе. Саклау берәмлеге 105. 1—20 битләр.

хуплавына лаек» [1].

Әсәр 1819 елда татар телендә, 1822 елда рус телендә [2] типографиядә 1200 данә бастырылган һәм көнчыгыш телләрен өйрәнә торган уку йортлары өчен уку әсбабы итеп тәкъдим ителгән. Китапны язганда һәм бастырганда автор фәнни һәм ижтимагый яктан мөһим булган башка максатны да күздә тоткан — ул киң халык массасында, бигрәк тә татарлар арасында тарихи истәлекләрне жыюга һәм саклауга кызыксыну тудырырга тели.

«Безнең университетның татар теле лекторы тарафыннан бастырылган «Татар хрестоматиясе»н күпчелек кыргызлар бик теләп сатып алалар», дип язган «Казанский вестник» журналы [3].

Революцион демократлар органы булган «Современник» журналы Идел буе татарлары турында мәкалә бастыра. Аның авторы «Тимер тарихының дәвамы һәм барлык ориенталистларга Хәлфин тарафыннан бастырылган өземтәләр буенча билгеле булган кульъязмадан» диган материалны файдаланган [4].

Әсәр борынгы авторларның бик әһәмиятле һәм сирәк очрый торган тарихи чыганакларын эченә алганга күрә, гадәттән тыш фәнни кыйммәткә ия. Шуңа күрә, бу хезмәт белән кульязма хәлендә танышкач, Х. М. Френ андагы тарихи өземтәләрне үзенең Болгар дәүләте һәм Биләр шәһәре турындагы мәкаләсенә керткән. Мәкалә Көнбатыш Европа ориенталистларының Венада чыга торган «Fundgruben des Orients» дигән атаклы журналында 1816 елда басыла.

Әйе, Ибраһим Хәлфин борынгы чыганакларны бик яхшы белгән. 1816 елда Френ белән бергә шул ук журналда Тимер Кутлугның тархан ярлыгын бастырудагы актив роле, аның бөтен фәнни эшчәнлеге шул турыда сөйли.

Ибраһим Хәлфиннең икенче бер тарихи әсәре — «Монголлар һәм татарлар турында Абелгази Баһадур хан тарихы» татар телендә басылып чыгуы да фән кешеләрен кызыксындыра. Тарихи-документаль чыганаклар бирергә уйланылган бу кульъязманы археографик эшкәртү һәм матбугатка хәзерләү ысулы турында академик Х. М. Френ белән адъюнкт-профессор И. Хәлфин арасында бәхәс булып алган.

Френ шәкерте П. Савельев [5] бу бәхәс конфликтка әверелде, шәхси мөнәсәбәтләрдә чагылды, дигән фикердә тора. Ләкин болай дип әйтү дөрес түгел һәм ул бәхәснең асылын да, галимнәрнең шәхси контактларын да чагылдырмый. Биш ел буе дәвам иткән бәхәс бары тик борынгы чыганаклар белән эш итү принциплары турындагы фәнни бәхәс кенә булган. Х. М. Френ Ибраһим Хәлфиннең фәнни эрудициясен, сәләтен һәм белемен хөрмәт иткән. «Хәлфин үзенең ризалыгын һәр биткә аерым биргәч кенә әсәр басылырга тиеш» [6] дип язган Френ һәм тарихи чыганакны ничек булганы килеш бастырырга, борынгы авторның сүзләрен үзгәртмәскә, хәзерге телдә кулланылмый торган сүзләрнең аңлатмасын текст астында бирергә кирәк дип тәкъдим иткән [7].

Хәлфин дә документальлелекне яклап чыга. Ләкин, «татар рухына туры килсен дисәк, шушы кульязмадагы ялгышларны шул килеш калдыру килешми», дип белдергән [8]. Френның абруе зур булуга карамыйча, ул ялгышларны төзәтү, чыганакларны җентекләп эшкәртү хокукын яклап чыккан. Германиянең шул замандагы ориенталисты Йозеф фон Гаммер Хәлфин принципларын яклаган һәм үз эшендә шуны кулланган.

Археографик яктан бүтәнчә карашлары булуга карамастан, Френ Хәлфин хезмәтләренә югары бәя бирә. «Күптән көтелгән, Азиянең иң әһәмиятле әдәбиятыннан берсе булган һәм университет типографиясендә татарча чыккан бу беренче тарихи әсәр Казан данын Россия дәүләтендә генә түгел, башка чит илләрдә дә арттырыр», дип язган ул [9].

Х. М. Френның әйткәннәре тулысынча расланды. Ибраһим Хәлфиннең фәнни хезмәтләре Көнбатыш Европада киң яклау тапты. Андагы илләрнең ориенталистлары, тарихи яктан сирәк чыганаклар җыентыгы

---

[1] ТАССР ҮДА. Ф. 977. Саклау берәмлеге 377. 32 бит.

[2] «Казан университеты лекторы Ибраһим Хәлфин тарафыннан төзелгән «Чыңгыз хан һәм Аксак Тимер тормышы». Казан. 1822 ел. 4 бит.

[3] «Казанский вестник». 1826. Декабрь. 231 бит.

[4] П. А. Шино. Идел буе татарлары. Современник. 1860. Т. XXXI. 274 бит.

[5] П. Савельев. Френ тормышы һәм гыйльми хезмәтләре турында. Спб. 1855. 38 бит.

[6] ТАССР ҮДА. Ф. 977. Идарә описе. Сакл. бер. 375. 2 бит.

[7] Шунда ук. 3—4 битләр.

[8] Шунда ук. 5 бит.

[9] ТАССР ҮДА. Ф. 977. Идарә описе. Сакл. бер. 375. 4 бит.

буларак, Хәлфин хрестоматияләренә бик еш мөрәҗәгать итәләр. Димәк, бу эшчәнлек тарихи татар әсәрләрен Россиядә генә түгел, Көнбатыш Европада да баса башларга мөмкинлек биргән була.

Ибраһим Хәлфин тапкан һәм эшкәрткән «Амат турында хикәят» исемле борынгы кулъязма Көнбатыш Европа ориенталистлары тарафыннан югары бәяләнгән. Хәлфин аны үзенең «Әхвале Чыңгыз хан вә Аксак Тимер вә тәварихлара...» хрестоматиясенә кертергә исәп иткән. Бу әсәрнең кулъязмасы белән танышкач, Френ аны «Fundgruben des Orients» журналында бастырган [1].

1818 елда Германиянең данлыклы ориенталисты Гаммер шул ук журналда «Тимер Кутлуг дипломы»н бастыра һәм аңа мондый аңлатма бирә: «Бу диплом — уйгурларның һәм борынгы татарларның иң сирәк грамоталары, иң кыйммәтле әдәби һәм дипломатик язмаларның берсе» [2].

Шунда ук Гаммер болай дип өсти: «Дипломның кулъязмасын Петербургка Френга аның дусты Хәлфин Казаннан җибәргән».

Совет тикшеренүчесе Ш. Ф. Мөхәммәдьяровның Тимер Кутлугның 1397 елгы ярлыгын бастыру Алтын Урда, Кырым һәм Казан татар ярлыкларын фәнни өйрәнүгә нигез салды, дип әйтүе бик дөрес [3].

Ибраһим Хәлфиннең һәм аның хезмәтләренең Көнбатыш Европада танылган булуына бик күп дәлилләр китерергә мөмкин. Көнчыгыш илләр тарихын өйрәнүче күпчелек галимнәр Ибраһим Хәлфин үлгәч тә аның хезмәтләренә мөрәҗәгать итәләр, сирәк кулъязмаларны фәнни куллануга кертү өлкәсендә аның беренче галим булуын таныйлар, басым ясап билгеләп үтәләр.

А. Давиде Хәлфин әсәрләренә дастаннарга чыганак буларак мөрәҗәгать итә. «Әхвале Чыңгыз хан вә Аксак Тимер вә тәварихлара» һәм аңа аңлатмаларны немец галиме Гаммер-Пургшталь файдалана. Көнчыгыш, шул исәптән Британия музее коллекцияләрендәге төрки [illegible] бик[illegible]ләп у[illegible]кәндә, Англия [illegible] Рей шул у[illegible] Хәлфин дастаннарын нигез итеп ала.

Борынгы татар кулъязмаларын эзләп табуы һәм бастыруы белән Ибраһим Хәлфин дөньядагы бөтен ориенталистларга зур ярдәм күрсәтте, чөнки аңа кадәр чит ил галимнәре алардан файдалана алмаганнар. XIX гасыр ахырында немец галиме В. Перч һәм XX гасыр уртасында В. Шпулер, монгол һөҗүме белән кызыксынган Көнбатыш Европа галимнәре башлыча Ибраһим Хәлфиннең фәнни хезмәтләреннән файдалана алалар, дип танырга мәҗбүр булдылар.

Ибраһим Хәлфин эшчәнлеге Россия ориенталистларына аеруча билгеле. Мәсәлән, Александр Казембек һәм Ф. Эрдман, үз хезмәтләрен язганда, Ибраһим Хәлфин әсәрләренә һәм хрестоматияләренә бик еш мөрәҗәгать иткәннәр.

Гаммер-Пургшталь (1774—1856) көнчыгыш илләр тарихын өйрәнүче галимнәрнең Көнбатыш Европада иң атаклысы булган. Ул төрек һәм гарәп телләрен яхшы белгән, Марк Аврелий Антонийның «Уйлар» дигән әсәрен фарсы теленә тәрҗемә иткән. Көнчыгыш илләрендә дипломатик хезмәттә булганда, шул илләр халыкларының көнкүрешен, тормышын, тарихын һәм әдәбиятын яхшы өйрәнгән. Талантлы тарихчы Йозеф Гаммер зур фактик материал туплаган һәм, «Fundgruben des Orients» журналына житәкчелек итүдән тыш, фәнни-тикшеренү эшләре алып барган, историография буенча зур мирас калдырган [4].

Гаммер хезмәтләре зур популярлык казанганнар һәм алар фәнни коммунизмга нигез салучыларга билгеле булган. Мәсәлән, К. Маркс һәм Ф. Энгельс Гаммерның «Осман империясе тарихы» дигән әсәренә югары бәя биргәннәр. 1853 елда Ф. Энгельс: «Көнбатыш Европа публикасы әле күптән түгел генә төрек эшләре турында азмы-күпме дөрес фикер йөртү мөмкинлегенә ирешә» дип яза [5]. Төркиядәге эшләрнең Көнбатышта билгеле була баруын Ф. Энгельс, аңлашылганча, Гаммерның тарихи хезмәтләре

---

[1] C. M. Fraehnii Rostochiensis. Bülariae urbis origo atgue fata, Tatarice et Latine, cura.—„Fundgruben des Orients", 1816, B. V, Wien, s. 206.

[2] Uigurisches Diplom Kutlugh Timur's von Jahre 800—1397 von Joseph v. Hammer. —„Fundgruben des Orients". 1818. B. VI, s. 359.

[3] Ш. Ф. Мөхәммәдьяров. Казан ханы Сәхип Гәрәйнең 1523 елгы тархан ярлыгы. «Илебезнең үткәне турында яңа материаллар» дигән китапта. М., «Наука», 1967. 104 бит.

[4] Geschichte des Osmanischen Reiches, grossentheils aus bisher unbenützen Handschriften und Archiven durch Joseph von Hammer. Pesth. 1827—1835, Bd. I—X; J. Hammer sur les origines Russes. Extraits de Manuscrits Orientaux. Petersburg, 1827; Его же Geschichte der Chane der krim unter Osmanischer Herrschaft. Wien. 1856. и. т. д.

[5] Ф. Энгельс. Төркия мәсьәләсе. К. Маркс һәм Ф. Энгельс. Әсәрләр. 2 басма. Т. 9. 20 бит.

нәтиҗәсе дип [illegible] турында әлеккеге фикер «тарихи фактларга карага нда (разрядка безнеке — С. Л.), күбрәк «Мин дә бер кичә» әкиятләренә нигезләнгән иде», Көнбатышның Төркиядәге махсус дипломатик вәкилләреннән берәү дә «төрек, көньяк славян яки яңа грек телләрен өйрәнергә тырышып карамады», «Йозеф фон Гаммер, Төркиянең немец тарихчысы»[1] гына, башкалардан аермалы булып тора», ди Энгельс шул ук мәкаләсендә.

К. Маркс һәм Ф. Энгельс Гаммер хезмәтләрен яхшы белгәннәр, зур һәм оригиналь материаллар туплаган булулары өчен аларны югары бәяләгәннәр. К. Маркс 1854 елның 29 мартында Энгельска язган хатында болай ди: «Хәзер миндә Гаммерның «Осман империясе тарихы» бар. Укып чыгу өчен түземлелек кирәк. (Ун томлык бу китап 6745 биттән тора — С. Л.). Тагы дүрттән бер өлеше кала әле. Әгәр ул сиңа кирәк булса, исеңдә тот»[2]. Берничә көннән Ф. Энгельс К. Маркска: «Уңае туры килгәндә миңа Гаммерны, башлыча иң соңгы чор турындагысын, җибәрче», дип мөрәҗәгать итә[3].

Гаммер хезмәтләре белән иҗади кызыксынуы тиздән К. Марксның матбугаттагы чыгышларында да чагыла. 1854 елның июнендә ул Якын Көнчыгыш кризисы уңае белән Европа державаларының, башлыча Англиянең позициясе, Төркиянең экономик һәм политик хәле турында мәкалә бастыра. Осман империясенең таркалу һәм бетүгә йөз тоту процессының башлануына кагылып, К. Маркс Гаммер тикшеренүләренә нигезләнә һәм алар «Төрек империясенең ул вакытта таркалу хәлендә булуы, моннан бераз әлегрәк оттоман дәүләтенең куәте һәм бөеклеге эпохасының бетүен кире кага алмаслык итеп раслыйлар» дигән нәтиҗәгә килә[4].

Төркиянең иҗтимагый строй характерын дөрес яктырта алмауга карамастан, Гаммер әсәрләрендә зур һәм төрле фактик материал бар, тарихи вакыйгалар тулы сурәтләнгән, булган хәлләр дөрес язылган. К. Маркс һәм Ф. Энгельс нәкъ менә шул якларга игътибар иткәннәр дә инде.

Шушы уңай белән гадәттән тыш кызыклы сорау туа. Ибраһим Хәлфин Гаммер редакцияләгән журналга язышкач, Хәлфин эшчәнлегенә Гаммер югары бәя биргәч, ул үзенең әсәрләрендә Хәлфин хезмәтләреннән файдаланмый калдымы икән? Әгәр бу расланса, К. Маркс һәм Ф. Энгельс, Гаммер хезмәтләрен укып, Хәлфин эшчәнлеге белән дә таныш булганнар дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек туа. Кызыклы, катлаулы мәсьәлә бу. Аны хәл итү юлы бер генә — Гаммерның күп санлы хезмәтләрен игътибар белән өйрәнү. Бу — тарих галимнәре алдында торган зур бурыч.

Бу уңай белән, үз хезмәтләрен язганда «Гаммер И. Хәлфин эшчәнлеге нәтиҗәләреннән файдаландымы икән?» дигән сорауны кабат куярга мөмкин.

Безнең алда И. Гаммерның «Осман империясе тарихы» дигән ун томлык әсәр. Ул 1827—35 елларда нәшер ителгән һәм 1834—36 елларда кабат басылган. Географик, хронологик һәм тематик рамкалар белән нык чикләнгән бу әсәрдә Гаммер Сәет Мөхәммәт Ризаның «Җиде планета тарихы»ннан озын-озын өземтәләрне берничә тапкыр китерә һәм аны текст астындагы искәрмәдә күрсәтә. Ибраһим Хәлфин 1826 елда Казан университеты җитәкчелегенә «Кырым тарихын чагылдыра торган татар телендәге кульъязма» бастыруны сорап мөрәҗәгать итә[5]. Попечитель Мусин-Пушкин үтенече буенча, аны профессор Ф. Эрдман карап чыга, кабул итү һәм бастыру өчен аны бик әһәмиятле һәм кирәкле дип таба, чөнки «анда Кырым ханнарының иң яңа тарихлары һәм Россиягә, Төркиягә, Польшага, Германиягә кагылышлы кызыклы вакыйгалар турында языла, ул дөнья галимнәренә зур файда китерәчәк һәм кайбер очракларда атап үтелгән дәүләтләр тарихчылары өчен материал булып хезмәт итә алачак»[6], дип яза.

Ул тапкан һәм университет сатып алган бу кульъязма Ибраһим Хәлфин үлгәннән соң Александр Казембек редакциясендә һәм аның аңлатмалары белән 1832 елда басыла. Димәк, Гаммерның «Җиде планета тарихы»ннан файдалана алуы өчен башта Хәл-

---

[1] Гаммер Австриядә яшәгән һәм хезмәт иткән. Энгельс бу мәкаләне язганда Австрия немец дәүләте булып саналган. Шуңа күрә Энгельс Гаммерны немец тарихчысы дип атый. Хәзер тарихи әдәбиятта Гаммер Австрия тарихчысы дип санала. («Зур совет энциклопедиясе». Т. 10. 195 бит.)

[2] К. Маркс һәм Ф. Энгельс. Әсәрләр. Т. 28. 280 бит.

[3] Шунда ук. 284 бит.

[4] К. Маркс һәм Ф. Энгельс. Әсәрләр. Т. 10. 262 бит.

[5] ТАССР УДА. Ф. 92. оп. 1. сакл. бер. 2696. 1 бит.

[6] Шунда ук. 7 бит.

Шуна күрә борынгы авторның әсәрен кемнең табуы һәм аны фәнни кулланышка кертеп җибәрүе зур әһәмияткә ия. Аннан алынган өземтәләрне соңыннан К. Маркс һәм Ф. Энгельс укыган.

Бу чыганактан тыш, Гаммер «Осман империясе тарихы»нда Ибраһим Хәлфин тарафыннан беренче тапкыр фәнни кулланышка кертелгән һәм «Fundgruben des Orients» журналында басылган Тимер Кутлуг диплодмын күрсәтә. «Осман империясе тарихы»ның беренче томындагы сигезенче бүлегендә И. Хәлфиннең кайбер башка хезмәтләре дә киң файдаланылган.

Моны без тарихның фән буларак формалашкан чагында Ибраһим Хәлфин дә күренекле рус һәм Европа галимнәре дәрәҗәсендә булган дияр өчен әйтәбез. Гаммер «Осман империясе тарихы»нда Хәлфинне Карамзин, Рычков, Сильвестер де Саси, Френ һәм башкалар белән бер рәттә атый.

Гаммерның Алтын Урда тарихын тикшерүгә багышланган икенче бер әсәрендә дә Хәлфин хезмәтләре шактый файдаланылган. Чыганаклар исемлегендә алар, башка авторларның әсәрләре кебек үк, конкрет атап язылганнар. Әсәрнең текстында да Гаммер күп тапкырлар Хәлфин хезмәтләрен санап үтә. Кырым ханлыгы тарихын язганда Гаммер яңадан Хәлфин хезмәтләренә мөрәҗәгать итә һәм алардан төрле чыганакларга кагылышлы материаллар ала.

Шулай итеп, үз әсәрләрен язганда Гаммерның татар мәгърифәтчесе һәм галиме Ибраһим Хәлфиннең кульязмалар өстендә эшләгән хезмәтләрен актив файдалануы аермачык күренеп тора. Шушы мәгълүматлар һәм К. Маркс белән Ф. Энгельсның Гаммер хезмәтләре белән кызыксынуы фәнни коммунизмга нигез салучылар татар мәгърифәтчесе Ибраһим Исхак улы Хәлфин эшчәнлеге белән дә таныш булганнар дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

[1] Гаммер И. Хәлфиннең түбәндәге хезмәтләрен файдалана: 1. Schedschrei türki oder Tarichi Abulghasi die allbekannte genealogische Geschichte Abulghasi Behadir's im Text gedruckt zu Kasan 1825; Ahwali Dschengischan we Aksak Timir, d. i. die Züstande Tschengis — Chan's und Aksak Timurs auch mit russischen Titel und russischen Noten, gedruckt zu Kasan 1822; Uigurisches Diplom Kutlugh Timurs von jahre 800—1397 — fundgruben des Orients", 1818, B. VI; Essebi-essijar, d. i. Die sieben Wandelsterne eine Geschichte der Chane der Krim vom Seid Mohammed. и др.

өчен Сәет Мөхәммәт Ризаның «Җиде планета тарихы»н алдыру белән генә чикләнмәгән. Ул университет китапханәсен Көнчыгыш илләр авторларының сирәк очрый торган төрле әсәрләре һәм кульязмалары, уку әсбаплары, кыйммәтле әдәбият белән комплектлау турында даими кайгыртучанлык күрсәткән. Көнчыгыш илләрнең төрле сирәк басма әсәрләре яки кульязмалары кайда икәнен, аларның нинди фәнни әһәмияткә ия булуларын ул бик яхшы белеп торган. Хәлфиннең университет китапханәсенә алдырырга кирәкле китапларны күрсәтеп, университет Советына һәм уку-укыту округы попечителенә язган берничә хаты (үтенече) сакланган [2]. Кульязмалар җыю эше белән ул бөтен гомере буе шөгыльләнгән. 1805 елда, мәсәлән, аның үтенече буенча төрек һәм татар телендә ун китап алдырыла [3]. Өч елдан соң ул тугыз гарәп, бер гарәп-төрек һәм җиде төрек китабын алдыруга ирешә [4].

Китапханәгә алына торган китаплар саны елдан-ел арта барган. 1817 елда университет китапханәсенә шул ук Хәлфин катнашлыгында алдырылган җиде гарәп, дүрт фарсы, ике татар һәм биш төрек китабы өстәлә [5]. 1826 елда татар телендә тагын 22 китап алына [6]. Шул ук елда Хәлфин Әбугалисинаның медицина һәм фәлсәфи әсәрләрен алдыру турында кайгырта [7].

«Ибраһим Хәлфин попечитель Магницкийның реакцион политикасы шартларында университет китапханәсен комплектлау буенча прогрессив чараларны ничек үткәрә алды икән?» дигән сорау туа. Моңа бер генә җавап булырга мөмкин. Ибраһим Хәлфин гадәттән тыш киң танылган галим булган. Шуңа күрә аның инициативасын патша чиновникларының политикасы чикли алмаган. Хәлфиннең татар телен яхшы белүче һәм сәләтле педагог булуын да истән чыгарырга ярамый. Гимназиядә татар телен укытуның киләчәге турында кайгыртып, гимназия

[2] ТАССР ҮДА. ф. 92. оп. 1. сакл. бер. 1596. 1 бит.

[3] ТАССР ҮДА. ф. 87. сакл. 8356. 4 бит; ф. 92. оп. 1.

[4] ТАССР ҮДА. ф. 92. оп. 1 сакл. бер. 250. 8 бит.

[5] ЦГИАЛ. ф. 733. оп. 39. сакл. бер. 209. 13—14 битләр.

[6] Шунда ук, сакл. бер. 272. 325—329 битләр.

[7] ТАССР ҮДА. ф. 92. оп. 1 сакл. бер. 124. 11 бит.

ул авырса яки үлсә, берәү дә калмый»,— дип язган [1].

Шуларга да карамастан, Хәлфиннең китаплар алдыру турындагы үтенечләре өстәмә цензура үткәннәр. Хәлфингә ышанып бетермәгәнлектән, чиновниклар Көнчыгыш илләрне өйрәнүче галимнәрнең, бигрәк тә Ф. Эрдманның, фикерен белергә теләгәннәр. Мәсәлән, 1828 елда И. Хәлфин төрек һәм фарсы телләрендәге, шул исәптән «Кырым тарихына кагылышлы татар телендәге кульъязманы[2]» алырга тәкъдим иткәч, бу кульъязмаларны алдыруның кирәклеген тикшерүне Ф. Эрдманга тапшырганнар. Ул Хәлфин исемлеген игътибар белән карап чыккан һәм тәкъдим ителгән кульъязмалар университет китапханәсендә булырга лаеклылар, дигән нәтиҗә ясаган [3].

Төрле чиновниклар һәм попечительләр Хәлфиннең шулай ук Европада да танылган булуы белән исәпләшми кала алмаганнар. Аның хезмәтләренең кайберләре, бигрәк тә татар хрестоматиясеннән өзекләр, «Fundgruben des Orients» журналында Россиядә басылганга караганда шактый иртәрәк (дүрт-алты елга) дөнья күргәннәр. Шуңа күрә патша хөкүмәтенең «хрестоматияне казна исәбенә аның (И. Хәлфин — С. Л.) файдасына бастырырга, аны һәм башка хезмәтләрне язган кешегә бриллиантлы йөзек тапшырырга» боеруы бик табигый [4]. Моны бары тик Ибраһим Хәлфиннең рус һәм чит ил ориенталистлары арасында киң танылган булуы белән генә аңлатырга мөмкин.

Ибраһим Хәлфиннең исә бөтен акылы, тирән белеме, фәнни эрудициясе, кайнар йөрәге патша файдасына түгел, ә халык интересына хезмәт итүгә багышланган. Бу — аның иҗтимагый-политик һәм мәгърифәтчелек эшчәнлегендә аеруча ачык күренә. Хәлфин үзенең фәнни эшчәнлеген һәм укыту эшен татар халкының киң массасын агарту эше белән бәйләп алып барган.

---

[1] ТАССР ҮДА ф. 92. оп. сакл. бер. 124. 11 бит.

[2] ТАССР ҮДА ф. 92. оп 1. сакл. бер. 2696. 1 бит

[3] Шунда ук, ф. 92. оп. 1. сакл. бер. 2696. 1 бит.

[4] Шунда ук, сакл. бер. 1009. 35 бит.

**Мөхәммәт Гайнуллин,**
филология фәннәре докторы, профессор

# ГАБДРАХМАН СӘГЪДИ

1908 елларда әдәбият мәйданына чыгып, татар теле һәм әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткән бу галимгә 1929 елда ук профессор исеме бирелә. Ә 1949 елда, үзбәк әдәбияты классигы Нәвои иҗаты турында язган зур хезмәте өчен, ул филология фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә ала.

Габдрахман Сәгъди 1889 елның 14 (26) мартында элекке Уфа губернасы Златоуст өязе Таймеева авылында мулла семьясында туа. Ул капитализм чорында бик күп татар шәкертләре күргән кыен һәм катлаулы тормыш юлы уза. Автобиографиясендә язганча, унике яшенә кадәр үги ана кулында тәрбияләнә. Атасы да ачың укып кеше булуына ышанмый, «синнән сукачыдан башка кеше чыкмас» дип кенә карый. 1902 елда әтисе үлгәч, Габдрахман Троицк мәдрәсәсенә килеп урнаша. Шул көннән башлап ул үз көнен үзе күрә, баерак шәкертләргә хезмәт итеп тамагын туйдыра. Мәдрәсәдә ул гарәп, фарсы, төрек телләрен яратып өйрәнә, көнчыгыш халыклары тарихы, философиясе белән кызыксына. 1906 елда Троицк мәдрәсәсен тәмамлагач, туган якларында ике ел укытучылык итә. 1908 елда Истамбулга барып, андагы университетның филология факультетына укырга керә. Анын укытучылар хәзерләү бүлеген 1911 елда тәмам итеп кайткач, Актүбә һәм Алма-Ата шәһәрләрендә балалар укыта.

Патша хөкүмәте шартларында шәкертләр хәрәкәтендә актив катнашкан бу прогрессив карашлы кешенең укытучылык эшчәнлеге дә тыныч кына бармый. Ул 1913 елдан башлап политик күзәтү астында яши. 1914 елның башларында Алма-Ата жандарм идарәсе Габдрахман Сәгъдине укытучылык эшен алып барудан да тыя, ә шул елның апрелендә инде аны бөтенләй Урта Азиядән китәргә мәҗбүр итәләр. Сәгъди эчке Россиягә кайта, Екатеринбург (хәзерге Свердловск) шәһәренә килеп балалар укыта. Үзенең әдәби-педагогик эшчәнлеген дә ул шул елларда башлап җибәрә. 1910 елда «Шура» журналында аның «Әдәбиятыбызны мәдрәсәләрдә укыту» дигән методик мәкаләсе басыла. 1911 елда «Кавагыйде әдәбият» һәм аңа «Гыйлавә» һәм 1912 елда «Әдәбият ысуллары» дигән хезмәтләре аерым китап булып басылып чыга. Татар телен укытуга караган дәреслекләре («Телебезнең сарыфы». 1912 ел; «Телебезнең нәхүе». 1914 ел) һәм 1912—1915 еллар арасында «Шура» журналында басылган «Тел вә әдәбият укыту ысуллары» дип исемләнгән мәкаләләре үз вакытында зур кызыксыну тудыралар.

Габдрахман Сәгъдинең педагогик, әдәби һәм гыйльми эшчәнлеге Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң тагын да күтәрелеп китә. Ул Октябрь революциясен Бөгелмә шәһәрендә, алдынгы укытучыларның берсе булып, шатланып каршы ала. Шул чакларда татар мәктәпләре өчен совет укытучылары хәзерләүгә зур көч куя, дүртьеллык татар-башкорт педагогия курсларында мөдир була, шул курсларда татар теле һәм әдәбиятын укыта. Бөгелмәдә торган елларында (1917—1921) Сәгъди совет, профсоюз эшләрендә актив катнаша. Шунда большевиклар партиясенең өяз комитеты

органы булган [illegible]да пу-
блицистик мәкаләләрен бастыра. Әлеге мәкаләләрендә ихлас күңелдән совет власте политикасын яклый, буржуаз милләтчеләрнең мәкерле планнарын фаш итеп яза. («Якты юл» газетасы. 1919 ел. 10 сан; 1920 ел. 31 һәм 43 саннар.)

1921 елның башында Габдрахман Сәгъди кабат Урта Азия якларына — Ташкентка барып чыга. 1925 елга кадәр Ташкентта төрле милләт (үзбәк, төрекмән, казакъ, татар) халыклары өчен ачылган мәгариф институтында, рабфакларда һәм Урта Азия дәүләт университетында эшли. Шул вакытларда үзбәк, казакъ, төрекмән һәм татар телендә чыгып килгән газета-журналларда («Кызыл байрак», «Төркестан», «Үзбәкстан», «Ак юл», «Белем учагы», «Инкыйлаб», «Төрекмән иле») актив катнаша, күп сандагы әдәби-тәнкыйть мәкаләләрен бастырып чыгара. Үзбәк, казакъ һәм төрекмән әдәбиятларына караган бу хезмәтләре аның тугандаш халыкларыбыз культурасына керткән кыйммәтле өлеше булып тора. Ул бер үк вакытта Казанда чыккан татар матбугатында да мәкаләләрен бастыра. Шундыйлардан: «Татар шагыйрьләре арасында Габдулла Тукай», «Тәнкыйтьчеләребез арасында», «Әдәбият тарихымы яки язма документлар тарихымы?» дигән хезмәтләрен күрсәтергә мөмкин.

1925 елда Татарстан халык мәгариф комиссариаты, Галимҗан Ибраһимов инициативасы белән, Габдрахман Сәгъдине Казанга чакырып ала. Ул башта Татар коммунистлар университетында татар теле һәм әдәбиятын укыта. Соңрак Көнчыгыш педагогия институтына күчә, доцент булып сайлана, анда татар теле һәм әдәбияты кафедрасын, шулай ук әдәбият кабинетын оештырып җибәрә. Нәкъ менә шул елларда аның татар әдәбияты тарихы һәм тел белемено караган әһәмиятле гыйльми хезмәтләре мәйданга килә. Гомуми тел белеменә караган «Кешелек дөньясында тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсүләре» (1926 ел), «Татар әдәбияты тарихы» (1926 ел), «Татар театр әдәбияты һәм аның үсү тарихы» (1926) һәм «Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты» (1930 ел) дигән фундаменталь хезмәтләре басылып чыга.

Үзенең зур күләмле бу китаплары белән ул безнең тел культурабыз, әдәбият һәм театр тарихыбызны өйрәнү һәм бер системага салу юлында гаять кирәкле һәм мөһим адым атлый. «Татар әдәбияты тарихы» дигән әсәрендә әдәбиятыбызны дәверләргә бүлеп өйрәнү юлында беренче тәҗрибә ясый. Китабының сүз башында күрсәткәнчә, матур әдәбият тарихын ул татарлардагы иҗтимагый фикер үсешенә бәйләнешле рәвештә тикшерә. Хезмәтнең «Фикери хәрәкәттә Курсавиның эшләре», «Татар әдәби теленең гыйльми-назари эшләнүе юлында Каюм Насыйри», «Матур әдәбиятта европалашу», «Татарда беренче роман» дигән бүлекләре аеруча кызыклы итеп һәм яңа чыганакларга нигезләнеп язылган. Китапта 1905 ел революциясеннән соң булган әдәби күтәрелешкә һәм анда катнашкан аерым язучылар иҗатына карата уңышлы гына күзәтүләр ясала. Шулай ук «Гафур Коләхметов һәм татар пролетариат әдәбиятына беренче адымы», «Г. Ибраһимов» дигән бүлекчәләр аеруча бай һәм матур бирелгәннәр. Дөрес, бу хезмәтнең уңай яклары күп булу белән бергә, башлангыч тикшеренү буларак, аерым кимчелекләре, хәтта ялгышлары да юк түгел иде. Ул кимчелекләр, беренче чиратта, Г. Сәгъдинең шул чор әдәбият белемендә күренгән вульгар социологизм тәэсиренә бирелүендә сизелә. Без аны, аеруча, Г. Сәгъдинең халык шагыйре Габдулла Тукай иҗатына биргән бәясендә ачык күрәбез. Анда: «Тукай, чыннан да, идеолог бер лирик иде. Ул үзенең шигырьләре аркылы татар либераль буржуазиясенең дини, милли идеологиясенә ачык бер систем биреште...» дигән юллар бар.

Ә бит шуннан өч ел элек кенә халык шагыйренең үлүенә ун ел тулу уңае белән «Безнең юл» журналының 1923 елгы 3 санында басылган мәкаләсендә Габдрахман Сәгъди бөтенләй башка һәм гаять дөрес карашта торган иде. Ул анда халык шагыйре Тукайга, төрле яктан килеп, объектив һәм дөрес бәя бирә алган. Мәкаләнең исеме — «Татар шагыйрьләре арасында Тукай». Тәнкыйтьче Сәгъди үз мәкаләсендә Тукайның әдәбият тарихыбызда, конкрет алганда, татар шагыйрьләре арасында тоткан югары урынын бик хаклы һәм дөрес билгели. Сәгъди мәкаләсен: «Тукайны халык үзе исән чакта ук «беренче шагыйребез» дип таныды», — дип башлый да аңа булган урынсыз тәнкыйтьләрне кире кага. Мәкаләсен ул түбәндәге рухта дәвам итә: «Тукай... татарның иң беренче көчле... йөрәк шагыйре. Йөрәк шагыйрьләрендә... күзәтелгән нәрсә: самимият, чын күңелдән булу, эчтән кайнап чыгу... Тукайда бу хосусият тәгал мәгънәсе белән бар... Тукайның шигырьләрендә аның үзлеге (шәхсияте, Тукайлыгы) бик ачык күренеп тора. Бу хосусиятъ... даһи

Тукай тезмәдә татарча яңе, садә әдәби тел эшләп бирде. Безне җиңел әдәби сөйләргә, саф рәвештә көйләргә өйрәтте. Анда чәчмәдә дә осталык күрәбез. Ул шигырь мәктәбе тудыра алды. Ниһаять, Тукайда, һәрнәрсәдән биграк, гаммәгә [1] якынлыкны, ярлыларга дуслыкны күрәбез. Менә бу хәлләр... Тукайны мәзлумнар сафына куйды...»

Менә шул рәвешчә, Г. Сәгъди 1923 елда ук халык шагыйре иҗатына дөрес һәм тулы анализ ясый алган, бүген дә сокланып укырлык фикерләр әйткән. Ә соңыннан аның Тукайга карата ялгыш фикергә килүен шул чорның вулгарь социологизмы йогынтысына бирелүдән дип кенә аңлатырга мөмкин.

Г. Сәгъди егерменче еллар әдәби хәрәкәтендәге төрле агымнарга карата да үз карашларын белдерә барган. «Безнең юл» журналының 1924 елгы 3 санында аның «Яңа әдәби агымнардан футуризм» дигән мәкаләсе басыла. Шунда тәнкыйтьче Гадел Кутуй һәм Кави Нәҗмиләрнең бу формалистик әдәби юнәлеш белән мавыгуларын яңалык һәм уңай күренеш дип карый. Ә соңрак үзе ук футуристик алым белән язылган шигырьләрнең халыктан ерак торуын да күрә башлый. 1930 елда басылган «Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты» дигән китабында бу мәсьәләдә Ленинга таяна, юлбашчының: «Сәнгать — халыкныкы. Аның тамырлары бик тирәндә, хезмәт ияләре халык массаларының калын катлавында булырга тиеш. Ул шушы массалар аңларлык һәм сөярлек булырга тиеш. Ул шушы массаларның хисләрен, фикерен һәм ихтыярын берләштерергә һәм аларны югары күтәрергә тиеш» [2],— дигән фикерләрен китерә. Бөек юлбашчының шул фикерләре яктылыгында Кутуйның футуристик шигырьләренә күзәтү ясый һәм: «Сәнгатькә Ленинча... караган кешеләр... Кутуй шигырьләренә очраганда, һичшиксез, аның күп шигырьләренең күпчелек өчен түгел, бер төркем укымышлылар өчен генә тудырылган шигырьләр булуыннан канәгать хасил итәчәк... Биграк тә аның «Җан сатамы»ыннан соң «Октябрьда», «Көннәр йөгергәндә», «Көнгә ике кул», «Май», «Пионерлылардан да ераклаштыралар» [3],— ди. Шул рәвешчә, кайчандыр футуризмга әдәбияттагы яңа адым дип караган Сәгъди соңрак сәнгать әсәрләренә Ленин әйткәнчә кила башлый. Бу инде тәнкыйтьченең шигъри әсәрләрне бәяләгәндә дөрес юлга басуын күрсәтә.

Г. Сәгъдинең 1925—1930 елларда «Безнең юл» һәм «Мәгариф» журналларында басылган мәкаләләре арасында «Беренче татар пролетариат язучысы Гафур Колахметов», «Галимҗан Ибраһимов иҗатында типлар эволюциясе», «Шагыйрь Сагыйть Рәмиев ничек һәм нинди ритм белән язды?», «Борынгы дәвер татар әдәбиятыннан яңа материаллар», «Бездә әдәби тәнкыйть» дип исемләнгән мәкаләләре үзләренең тирән эчтәлекле һәм әдәби зәвык белән язылган булулары ягыннан игътибарга лаеклылар.

Галимҗан Ибраһимов Мәрҗани турында язган бер хезмәтендә болай дигән иде: «Беренче кул мөхәррирләр моңарга кадәр тарих китапларына кермәгән хәл һәм вакыйгаларны иске һәйкәлләрдән, кабер ташларыннан, төрле кульязмалардан, халык авызыннан алып җыялар, тарихка кертәләр. Ягъни материалны беренче кулдан алалар. Икенче кул мөхәррирләр төрле китапларда булган тарихи вокугатьне (вакыйгаларны — М. Г.) үзенчә тәртип итә, яки чит телдән үзенә күчерә».

Габдрахман Сәгъди үзенең әдәбият тарихын җыюга һәм тикшерүгә караган хезмәтләрендә, нәкъ менә шул беренче кул тарихчы сыйфатында эш итеп, бик күп язучыларыбыз турында (Мәүлә Колый һ. б.) беренче башлап сүз әйтте, әдәбият тарихыбызны өйрәнү өчен бай материал калдырды. Әдәбият теориясенә һәм гомум тел белеменә караган хезмәтләрендә ул башка телләрдә булган чыганакларга таянып һәм шуларга ияреп яза. Моңа мисал итеп, югарыда искә алынган «Кешелек дөньясында тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсүләре» исемле зур күләмле китабын күрсәтергә кирәк. Сүз башында автор үзе үк күрсәткәнчә, бу катлаулы хезмәтен язганда автор Потебня, Веселовский, Рубакин, Мелиоранский, Вамбери, Радлов, Бартольд, Самойлович, Малов кебек мәшһүр галимнәрнең тикшеренүләреннән, фикер һәм карашларыннан файдалана. Габдрахман Сәгъди татар, төрек һәм гарәп телендәге

[1] Гаммә — масса, халык.

[2] Г. Сәгъди. Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты. Казан. 1930 ел. 125 бит.

[3] Шунда ук.

Мәрҗанинының «Мостафадел-әхбар»ының беренче һәм икенче кисәкләрен, «Вафиятел-әслаф»ын, Р. Фәхретдиновның «Асар»ын, Мәхмүд Кашгариның «Китабе диван әл-лөгате эт-төрек», Нәҗиб Гасыймның «Иске төрек язуы» исемле әсәрләрен таяныч итеп алганы күренә. Бу зур галимнәрнең фикерләре белән гомуми тел белемен карата үз халкын үз ана телләрендә танышытыра башлау — китапның беренче әһәмияте ягы. Шуның белән бергә, Сәгъди иярү һәм башкаларның фикерләрен үз китабына күчерү юлы белән генә дә бармый, бәлки, чыганакларга, тарихи материалларга ачык күз белән карап, берсен икенчесе белән чагыштырып язарга тырыша. Барыннан да бигрәк, гаять катлаулы мәсьәләләрне киң күпчелеккә аңлаешлы ачык әдәби телдә сөйләп бирә ала. Бу — аның хезмәтенең икенче әһәмиятле ягы. Китаптагы «Телләрнең туулары һәм аларның үсүләре» дигән бүлек аеруча яратып язылган. Телләрнең туу, ясалыш һәм үзгәрешләре турында сөйләгәндә, автор кайбер татар сүзләренең ничек килеп чыгулары турында кызыклы гына күзәтүләр ясый һәм мисаллар китереп уза (14—22 битләр).

«Халык шигъриятенең өч юлы» дигән бүлекчәдә Сәгъди күп кенә татар җырларын мисалга ала һәм аларның үзенчәлекләре турында кайбер кызыклы фикерләр дә әйтеп уза. Ул татар җырларының күпчелегендә алдагы мисраглары белән соңгылары арасындагы мәгънә бәйләнешен расларга омтыла.

Арыслан ла киек, әй, сикермәс.
Каршысында биек тау булса.
Егет тә генә кеше һич кайгырмас,
Газиз башы аның сау булса.

Менә шушы рәвештәге бәрабәрчелекте гуя ике төрле хәл бер-берсе белән каракаршы куелып, чагыштырып үтелә, ди. Шунда ул Тукай белән дә бәхәскә керә. Тукайның татар җырларының баштагы ике мисрагы белән соңгы мисрагы арасында әһәмиятле бәйләнеш булмауга мисал итеп китергән.

Сандугачлар су ташый,
Кайда икән су башы?
Безнең җанкай ялгыз башы,
Хәзер булсын юлдашы,—

дигән җырның үзен үк алып, болар арасындагы бәйләнешнең гаять көчле булганын түбәндәгечә аңлата:

чы, пәрхәлдә, матур табигать эчендә, сандугач сайравы... тәэсирендә калган бер кеше. Икенчедән — җырның әлекке мисрагындагы «су башы» сүзенә аеруча дикъкать итеп үтик... Татарларда һәм башкортларда егетнең җанашы яшь килен булып йортка төшкәч, «су юлы башлату» дигән... мәһим бер гадәт бар. Бу җырның әнә шуның белән мөнәсәбәте бар... «Сандугачлар су ташый» мисрагы исә, җырчының сандугач белән җанкае арасында охшаш табуының, яки, үзе дә сизмәстән, йөрәгенең тәэсире белән җанкаен сандугачка охшатуның нәтиҗәсе икәнен кем инкарь итәр. Менә монда нәчкә бер шигърият юкмы? Аннан, «безнең җанкай ялгыз башы, хәзер булсын юлдашы» дип куюы бик табигый бернәрсә булуы өстенә, тегe югарыгы ике мисрагы белән мәгънә ягыннан да гаять тыгыз бәгъләнган бер төп үй булып кала»,— ди [1].

Шулай итеп, Сәгъди үзе тикшергән мәсьәләләренә төрле яктан килә, үз фикерләрен белдереп бара. Бу хәл аны мөстәкыйль фикерләүче әдәбият галимнәре рәтенә куя.

Без күзәткән китапта «Халык җырларында вәзеннәр» дигән бүлекчә аеруча кызыклы язылган. Ул монда да татар җырларыннан күп кенә мисаллар китерә, үзенчә аларның ритмик төзелешен билгели. Җыр, шигырь юлы уртасында тынныш цезура булуы турында искәртә. Аныңча: «Җырларның һәр юлы ике өзектән тора. Өзек-стопа дип тезмәнең сүз басымы үзенә төшү белән аерылган өлешенә әйтелә. Өзекнең (стопаның) эченә кергән иҗекләрдән берсе басымлы, калган күрше иҗекләр басымсыз, яки басымнары бик йомшак, бер дә сизелмәслек булалар. Өзекләр ике иҗекле дә, өч иҗекле дә. Ләкин өзекләрнең иҗекләре берсе яки берничәсе кыска иҗекле була. Җырларның һәрбер өзегендә дүрт иҗек булса да, күбрәк соңгы мисрагта өч иҗек кенә була. Дүрт иҗекле өзекләрнең элеккесе озын, ягъни сузыбрак әйтелә торган, калган өчесе кыска әйтелә торган иҗекләр булалар».

Күрәсез, Габдрахман Сәгъди татар җырларында, шигырьләрендә булган үзенчәлекне күрсәтү буенча хәзер дә игътибарга лаеклы фикерләр әйтә. Ләкин ул ачык һәм ябык иҗекләрнең билгеле бер тәртиптә

[1] Г. Сәгъди. Кешелек дөньясында тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсүләре. Казан, 1926 ел, 71—73 битләр.

герә алмый. Бусын инде 30 елларда Хәйретдин Вәли, 50—60 елларда Хатип Госман (1962), Әхмәт Исхаклар (1963) әйтәләр, үз хезмәтләрендә күрсәтәләр.

Сәгъди үз фикерләрен раслауда кардәш халыкларның җырларына таянып эш итә. Моңа, әлбәттә, аның үзенең шул халыклар арасында булуы һәм күп телләр белүе (гарәпчә, фарсыча, русча, госманлыча, үзбәкчә, казакъча һ. б.), һичшиксез, ярдәм иткән.

...1930 елда Габдрахман Сәгъди яңадан Үзбәкстанга эшкә күчә. Ул шул еллардан башлап үзенең иҗат сәләтен үзбәк әдәбияты тарихын, беренче чиратта, Нәвои иҗатын өйрәнүгә багышлый. Аның 162 исемдәге барлык фәнни хезмәтләренең яртысыннан артыгы үзбәк әдәбияты тарихын өйрәнү һәм пропагандалауга караган. Үзбәк һәм рус телләрендә басылган шул хезмәтләр арасында «Творчество Навои, как высший этап в развитии узбекской классической литературы» дип исемләнгән хезмәте үзенең сыйфаты белән рус галимнәренең дә югары бәясен ала (Н. К. Дмитриев, Е. Э. Бертельс һ. б.).

...Мин үзем 1928 елның көзендә Габдрахман ага белән Көнчыгыш педагогия институтына укырга килгәч очраштым. Ул бездән керү имтиханын үзе алды. Мин аның лекцияләрен тыңладым.

1944 елның көзендә профессор Сәгъди Казанда кунакта булды. Аның шул чакта

сыйриның роле» дигән мәкаләсе «Совет әдәбияты» (1944 ел. 10 сан) журналында басылып чыкты.

Соңгы мәртәбә укытучым Габдрахман Сәгъди белән 1956 елның көзендә Сәмаркандта очраштым. Авырыксынып торуына карамастан, ул гаять тулы иҗат дәрте белән яши иде. Шунда ул үз иҗатына тәнкыйть күзе белән карап, элек язган хезмәтләрендә булган кимчелекләрне танып, галимнең ялгышларын объектив һәм намус белән тәнкыйть итеп телгә алу аның исеменә үзе зур хөрмәт була дигән фикерләрне әйткән иде. Ул безнең шул очрашуыбыздан соң бер айдан, ягъни 1956 елның ноябрендә вафат булды.

Интернациональ карашлы, барлык халыкларның культура мирасына хөрмәт белән караган бу галимне Урта Азиядәге, аеруча Үзбәкстандагы, күп санлы укучылар бүген дә бик якын итеп искә алалар, әдәбият тарихларында үзбәк совет әдәбияты белемен нигезләүчеләрнең берсе итеп күрсәтәләр. Профессор Сәгъдинең әдәби-педагогик эшчәнлеге партиябез һәм хөкүмәтебез тарафыннан югары бәя ала. Ул 1946 елның мартында Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә.

Культурабыз тарихына зур өлеш керткән галимебезнең иҗат мирасы ныграк өйрәнүне көтә әле.

# БЕР ҖИРДӘ ЮК АНДЫЙ АК КАЕННАР



Җәй башы. Чалт аяз дымык иртә. Кояш инде офык читеннән соңге буе күтәрелергә өлгергән. Идел өсте, көмеш көзгедәй балкып, күзләрне чагылдыра.

Иделнең урманлы текә яры өстендә, яшь каен төбендә, күзләрен аргы як ярларга текәп, чандыр гына бер малай утыра. Ул шул тикле бирелеп, мавыгып карый, әйтерсең әнә шул Ослан тавы иңенә үрләгән куаклар арасыннан менә хәзер, менә шушы минутта бәхет кошы очып чыгачак та дөньяның моңа кадәр беркемгә билгеле булмаган искиткеч серләрен, әллә нинди яшерен хәзинәләрен бер аңа, бары тик аңа гына ачып бирәчәк.

Әнә шулай, дөньясын онытып, бик озак утырганнан соң, малай кинәт башын иеп, тезләре өстендәге катыргы кисәгенә тотына, кулындагы пумаласын буяуга манып, ашыга-кабалана нәрсәдер сызгалый башлый...

Кызыл ярлы, ак ташлы Ослан таулары, тау ергамаклары буйлап өскә, югарыга үрләгән яшел куаклыклар, Печище ягыннан күксел-зәңгәр булып күренгән куе урманнар, су өстендә чайкалып торган ак, кызыл маяклар әкрен-әкрен катыргы кисәгенә күчәләр. Таулар өстендә күктә — биектә тукталып калган ак болытлар да, ак чабаклар аулап очкан акчарлаклар да нәкъ чын кебек булып рәсемгә төшә баралар. Тик менә ерак-еракта Идел өстенә өртелгән сыек зәңгәрсу томанны нинди буяулар белән биреп булыр икән соң!! Яр буендагы ак ташларны иркәләп сыйпаган әнә шул вак-вак көмеш дулкыннарны ничек кенә сурәтлисе икән! Күрәсең, табигатьнең бу иләһи матурлыгын тулысынча кәгазьгә төшерерлек буяулар юктыр шул әле дөньяда. Булса иде, табылса иде шундый тылсымлы буяулар!..

Малай үз эше белән шул тикле мавыккан, хәтта берәүнең куакларны аралап, Идел ярына чыгуын, үзеннән ике адым гына читтә тукталып, аны күзләп торуын да сизмәде.

Озак кына шулай торганнан соң, теге кеше, малайны кинәт өркетмәс өчен, әкрен генә тамак кырды. Малай борылып карауга, елмаеп, аның янәшәсенә чүгәләде.

— Булдырасың икән, энекәш, акчарлакларың нәкъ терс кебек чыкканнар бит! Күз тимәсен, очып китә күрмәсеннәр инде!

Ул, чыннан да, акчарлакларны куркытмыйм тагын, дигән кебек, сак кына үрелеп, малайның рәсемен алды, озаклап игътибар белән карады.

— Булдырасың икән,— дип, җитди итеп кабатлады ул аннары,— ныклап тотынсаң, чын рәссам булырсың. Кайда торасың үзең! Исемең ничек! Әтиең кем!

— Яңа бистәдә торабыз без, абый,— дип җавап бирде малай.— Исемем Әптерәй... Туйырып әйткәндә, Абдрахман инде. Әтием Садыйк исемле. Садыйк Сергузин...

Беренче карашка үтә оялчан булып күренгән рәссам малай үзенә моңарчы бөтенләй таныш булмаган бу ягымлы абый янында ничектер бик тиз чишелеп китте. Үзенең рәсем ясарга бик ихлас булуын, елның теләсә кайсы вакытында буяуларын алып Идел ярына еш килүен, урман-кырларга чыгып йөрүен сөйләп бирде.

Тик аның бу эшенә әтисе никтер кырын карый икән.

— Әнә, Күркә Вәли малае кактурда эшли башлаган. Чут төймәсе тартканда, кулына күз иярми. Вәт, исмасам, һөнәр! — дип, авыз суын корыта. Рәсем ясауны бушка



куып нәрү дип карый. Шуның өстенә, мөселман баласы өчен бик гөнаһлы эш икән әле ул. Дөньялыкта ясаган шул сыннарың кыямәт көнне якаңнан алып, үзләренә җан кертүеңне даулаячаклар икән!

Коңгырт күзләрен кыса төшеп, уйчан гына тыңлады тегә абый Абдрахманны. Аннары, тирән сулап, йомшак кына әйтеп куйды:

— Картларны гаеп итеп булмый инде, дус кеше. Элек-электән каннарына сеңеп калган. Әмма син бу эшеңне ташлама. Заманы ул түгел... Ярый, миңа вакыт...

Кузгалып, берничә адым киткәч, нәрсәдер исенә төшкәндәй, тагын борылып килде:

— Абдрахман дус! Теләгең булса, алдагы җомгада Мәдәният йортына килеп чык әле син. Беләсеңдер, Островский урамында. Мохтар абый чакырды дисәң, кертерләр.

Җомга көн кич, күз бәйләнә башлау белән, әлеге йортны эзләп тапты Абдрахман. Табуын да тапты, кертүен дә керттеләр. Әмма зур залның иңен иңләп, буен буйлап күпме килеп сарса да, тегә ягымлы абыйны һич кенә очрата алмады. Бергә җыелган бу тикле халык арасына беренче килеп эләгүе иде шул әле аның. Шунлыктан тәмам башы әйләнде. Соңра инде, бөтенләй өметен өзеп, читтәге бер урындыкка барып утырды. Куып җибәрмәгәйләре дип, куркып, калтырап утырды. Әмма пәрдә ачылып, концерт башланып китүгә, малай үз-үзен онытты. Моңа кадәр Яңа бистә малаеның төшенә дә кермәгән әнә нинди сихри дөнья бар икән бит әле! Җыр, музыка дөньясы, сәнгать дөньясы... Әнә бер абый өздерепөздереп гармун уйный, әкияттәге Зөһрә кыздай зифа сынлы бер кыз, сандугачларны таң калдырырлык итеп, матур җыр җырлый. Карлыгачтай киенгән бер егет, сәхнәгә чыгып, чираттагы башкаручыны атап әйтә:

— Мәшһүр артистыбыз хөрмәтле Мохтар Мутин!..

Зал бу артистны аеруча көчле алкышлар белән каршылый. Ә Абдрахман исә, авызын ачкан килеш, тораташтай катып кала. Шул бит! Шул үзе! Идел буенда аның белән янәшә утырган, аның белән шулай үз итеп, якын итеп сөйләшкән абый... Шундый ягымлы, шундый кешелекле Мохтар абый үзе! Икмәктер, үзе.

Әнә ул, күзләрен кыса төшеп, карашын кайдадыр еракка, зал түренә текәп, шигырь укый:

Белмим,
Әллә күпкә,
Әллә бик озакка,
Ахры, мәңге оныта алмамын.

Тамбов урманнары уртасында
Усак яфраклары шаулавын...

Абдрахманның күз алдында яшел урманнар чайкала, күе камышлар шаулый. Карт имәннәр, ботакларын селки-селки, кемнедер каядыр озата баралар... Шул урманнар шаулавы аша сихри музыка булып Мохтар абыйсының тавышы яңгырый:

Бер җирдә юк андый ак каеннар,
Бер җирдә юк андый урманнар,
Бер җирдә юк камыш сабаклары,
Андагыдай шаулый торгачнар...

Артык тәэсирләнүдән Абдрахманның тамак төбенә кайнар төер килеп утыра. Менә бит могҗиза! Буяулар белән генә түгел, сүз белән дә шундый тылсымлы дөнья тудырырга мөмкин икән.

Тәнәфес вакытында Абдрахман Мохтар абыйсын эзләп таба, әмма якын килергә кыймыйча, читтән генә күзәтеп йөри. Ә карасаң... карасаң, Мохтар абый аны үзе эзли икән лабаса! Үзе!

Күзенә чалыну белән, әллә каян кул сузып килә, әллә кайчангы якын дустын очраткандай, елмаеп сүз башлый.

— Килдеңме, Абдрахман! Концерт ошыймы! Ярый, ярый, хуп!.. Болай сөйләшик әле без синең белән: менә минем адрес. Дүшәмбе көн килеп чык. Барлык рәсемнәреңне алып кил. Вәгъдәме! Киләсеңме! Хуш, алайса! Гафу ит, әнә сәхнәгә чакыралар.

...Свергузинның рәсемнәрен Мохтар Мутин үзе генә түгел, урта яшьләрдәге чандыр гына бер кеше белән карадылар. Кайберләрен мактадылар, дусларча гына киңәшләр бирделәр.

— Иң шәбе шул: табигатьне яратасың икән, энекәш,— дип, Абдрахманга текәлеп карады теге чандыр абый,— әйе, телен аңлыйсың икән син табигатьнең. «Урман» исемле менә бу картинаңны миңа калдырып тор әле. Рәсем белгечләренә күрсәтермен.

Ун-унбиш көннән тегеләр чакырган вакытта яңадан килгәндә Мохтар фатирында тагын берничә ят кеше бар иде. Алар Абдрахманны якты йөз белән каршы алып, урталарыннан урын бирделәр. Теге чандыр абый (Гыйлемдар исемле иде, ахры, ул) өстәл өстендә яткан зур төргәкне алып аңа сузды:

— Менә, энекәш, кабул итеп ал әле шуны. Бүләк! Мин алып киткән әлеге рәсемең балалар иҗаты күргәзмәсендә беренче урынны алды бит. Котлыйбыз сине. Зур уңышлар телибез!

Бүлмәдәгеләр шаулатып кул чаптылар. Тагын кемнәрдер теләкләр теләделәр, кемнәрдер җылы сүзләр әйттеләр. Әмма Абдрахман бу кичтә әйтелгән сүзләрнең мәгънәсен төшенерлек хәлдә түгел иде инде. Ул ничек чыгып китүен, ничек өенә кайтып җитүен дә сизмәде. Кайтып, төргәкне сүтеп карагач, куанычы бөтенләй ташып чыкты. Анда моңа кадәр яшь рәссамның төшләренә кереп йөдәткән нәрсәләр — затлы буяулар, төрле-төрле пумалалар һәм рәсем альбомнары бар иде. Аларыннан да артык куандырганы, бистә малаеның хыялына очар канат биргәне — төргәктән килеп чыккан кечкенә генә язу булды:

«Кадерле Абдрахман! Рәсем сәнгатен син бик яратасың икән. Бу эшеңне дәвам ит. Мохтар абыең янына килгәлә, ул безгә хәбәр итәр. Без сиңа һәрчак булышып торырбыз. Синең киләчәктә зур уңышларга ирешүеңне телибез!

Синең дусларың».

Бу төнне Абдрахманның күзенә йокы кермәде.
Июнь төне иде бу. 1923 елның июне иде.

* * *

Казан Кремленең ак стеналары буенда, ябалдаш эрәңгеләр күләгәсендә өлкән яшьләрдәге бер кеше утыра.

Тормыш — художник, тормыш — рәхимсез реалист аның чигә чәчләрен көмешкә буяган, маңгаена буй-буй җыерчыклар салган.

Тормыш Яңа бистә малае Әптерәйне, еллар тезмәсе аша уздырып, утлар, сулар

дергән.

Абдрахман ага, күзләрен кыса төшеп, Ослан таулары ягына карый...

Тормыш кешене генә түгел, табигатьнең үзен дә танымаслык итеп үзгәрткән. Кайчандыр ул барып йөргән, кайчандыр ул Мохтар Мутин белән беренче кат очраш-кан урманлы ярлар инде су астында калган.

Зур Идел Кремль буена килеп җиткән. Әнә, ике дамба арасында, зәңгәр дулкын-нар өстендә ак җилкәнле яхталар куыша, бетонлы ярлар буйлап, «Зәңгәр күл» ягына таба кечкенә генә ак пароход узып бара.

Абдрахман ага Свергузин пумаласын буяуга сала, этюдникы өстенә иелә. Әлеге күренешләр нәкъ тормыштагыча булып, хәтта тагын да көчәеп, җыйнакланып ак киндер өстенә төшәләр. Яраткан эшеннән аерыла алмыйча, сәгатьләр буе, көннәр буе шулай утыра. Ә кичен өйдәге киштәгә тагын бер әзер картина яки бер этюд өстәлә.

Икенче көнне, таң белән торып, тагын юлга чыга Абдрахман ага. Бүгенге көнен ул Мишә елгасы буенда үткәрәчәк, иртәгә Казанка ярында, берсекөнгә Арча урман-кырларында... Зоя, Шишмә, Ык үзәннәрендә, Ашыт, Сөн болыннарында.

Туган җирнең хуш исле чәчәкләре генә түгел, көзге болыннары да, ябалак кар-лары да, көмеш бәсләре дә якын аның күңеленә...

Әнә шул элекке Идел ярлары кебек Ык үзәннәре, Сөн болыннары да тиздән диң-гез дулкыннары астында калачак. Тәнбоеклы тын күлләрне, шаулы камышларны, карлыганлы, бөрлегәнле әрәмәләрне кабат беркем дә беркайчан да күрә алмаячак, беркинди рәссам да аларга карап картина яза алмаячак... Шуңа күрә ашыгырга кирәк, өлгерергә кирәк.



Әгәр Абдрахман аганың күп ел-лар буе иҗат иткән рәсемнәрен ак-тарып карасаң, аның бөтен гомерен диярлек күз алдына китерергә мөм-кин...

Тополь агачларына күмелеп утырган, читләренә бәбкә үләне үс-кән яшел урам. Бер-бер артлы те-зелеп киткән агач йортлар, челтәрле чарлаклар, зәңгәр тәрәзәләр...

Балачак истәлеге — Яңа Бистә күренеше.

Мәктәп. Якты класс. Яшь-яшь бер укытучы, бераз каушап, укучылары-на карап тора. Күрәсең, әле ул үзе-нең беренче мөстәкыйль дәресенә кергән. Монысы да яшьлек хатирә-се. Кайчандыр Абдрахман ага үзе дә, педагогия институтын тәмамлап, Яңа Бистәдәге 13 нче мәктәпкә укы-тучы булып килгән иде. Әнә шулай дулкынланып, үзенең беренче дәре-сенә кергән иде.

Икенче бер рәсемдә шулай ук класс бүлмәсе сурәтләнгән. Ләкин парталар арасында балалар түгел, ә киндер алъяпкычлы өлкән агайлар, чуар шәльяулык бәйләгән апалар, чал сакаллы бабайлар. Алар, ка-рандаш очларын тәкерекли-тәкерек-ли, хәреф язарга өйрәнәләр. Лик-без курслары...

Әйе, гомерләре буе табагач тамга гына куя белгән бистә кеше-

өйрәтергә кирәк иде. Заманы шундый иде. Дәртле, ашкынулы заман иде. Арып, халдан таеп курслардан чыгуга, аннан-моннан капкалап, клубка йөгерәсең. Анда яшьләрнең драма түгәрәгенә репетиция үткәрә. Аннан кайткач, төннәр буе кәрфек какмыйча дәрес хәзерлисе, дәфтәр тикшерәсе бар... Икенче көнне рәттән биш дәрес, ә аннары яшь рәссамнар түгәрәге.

Бу, ихтимал, рәсем сәнгате буенча Казанда беренче түгәрәк булгандыр. Аны башлап Абдрахман Свергузин үзе оештырды, күп еллар буе үзе җитәкчелек итте. Хәзер танылган художник булып өлгергән Харис Якупов һәм Лотфулла Фәттаховлар да кайчандыр шул түгәрәккә йөреп, рәсем сәнгатенең әлифбасына өйрәнделәр.

Абдрахман аганың кәгазьләре арасында таушалып, саргаеп беткән кечкенә генә бер газета бите бар. «За Родину». 1943 нче елда чыккан. Фронт газетасы. Анда Свергузинның ул чордагы иҗатына карата әйтелгән дулкынландыргыч юллар бар:

«Лейтенант Свергузин тарафыннан эшләнгән бер серия картиналар дикъкатьне җәлеп итә. Анда 1240 елдагы Нева сугышыннан алып, Бөек Ватан сугышы көннәренә кадәр булган чор эчендә халкыбызның бәйсезлек һәм азатлык өчен көрәш тарихы ачык күрсәтелгән...».

Сугыш кырында, ут давылы астында эшләнгән рәсемнәрнең, кәрәшкә, җиңүгә өндәгән плакатларның кайберләре Абдрахман агада әле хәзер дә саклана.

Сугыштан кайтып, яңадан укытучылык хезмәтенә керешү белән Абдрахман ага һәр буш вакытын иҗатка багышлады.

Кече күңелле тыйнак бу укытучы беркайчан да шапырынмады, икенче Рембранд, икенче Репин, Левитан мин, дип мактанмады. Зур профессиональ күзлектән карагандә, үз әсәрләрендә кайбер кимчелекләр дә барлыгын яхшы белеп килде ул. Әмма, аңа карап, иҗат итүдән туктамады. Туган табигать һәм сәнгатькә булган олы мәхәббәт аны һәрчак иҗатка әйдәде. Шул омтылыш аны уңышларга алып килде.

Бистә малае Әптерәй талантлы артистның ышанычын аклады.

* * *

80 нче мәктәпнең зур залы. Залда кояш нуры. Анда кояштай балкыган йөзләр, ал галстуклар. Залда пионерлар, комсомоллар. Сугыш һәм хезмәт ветераннары, укытучылар. Алар бергә өлкән педагог, талантлы үзешчән художник Абдрахман Свергузин күргәзмәсенә килгәннәр.

Күргәзмәдә барлыгы йөз егерме картина. Күпчелеге рәссамның иң яраткан жанры — пейзаж.

Урман. Кыш. Февраль азаклары. Өлгә бар табигать кышкы йокыда. Алгы пландагы игезәк кызлардай зифа пар каен, алардан бер читтәрәк усак, ерңгә агачларына сыенып утырган чыршы малае, юка, милләш агачлары, кар астыннан башлары гына чыгып калган төбәнәк куаклар — барысы да, барысы да җылы җәйге таңнарны төшләрендә күреп, изрәп йоклыйлар...

Әмма кояш инде шактый туры, шактый рәхимле карый башлаган, кар өстенә төшкән күләгәләр шактый кыскарган. Тиздән яз, тиздән табигать таңы!

Ә менә биредә — җәй уртасы. Каенлы тау, урман аланы. Яшь каеннарның бөдрәләрен тузгытып шаян җил исә. Алан өстендә озын күләгәләр уңга-сулга шуыша. Бүген урман тынгысыз, урман шаулый. Әмма бу шау-шу бөтенләй урынсызга күпкан. Бернинди давыл, бернинди куркыныч булмаячак. Әнә күктә нинди биек өем болытлар, ак мамыктай катлы-катлы болытлар — аяз һава галәмәтләре.

Үзенчәлекле, бераз шагыйрәнә эшләнгән «Тын почмак» картинасы. Күе яшел яфракларны аралап үтеп кергән кояш нурлары тар сукмакка төшкәннәр дә алтын кубәләкләр кебек җир өстендә биниләр, бер-берсен куышып уйныйлар.

Икенче бер картинага карасаң, син күзге урманга килеп керәсең, өченчесендә — Казанка ярына барып чыгасың, яңгырдан соң шаулап аккан ташуларны, әкрен генә чылтырап аккан тау чишмәләрен күрәсең һәм шунда ук яңадан кемеш бәскә бизәлгән кышкы урманга, кемеш тынлыкка кайтасың.



Абдрахман аганың рәсемнәрен шулай бергә җыеп күргәзмәдә карагач, ирексездән, күңелдә туган якның матурлыгы белән горурлану хисе туа. Телгә үзеннән-үзе шигырь юллары килә:

Бер җирдә юк андый ак каеннар,
Бер җирдә юк андый урманнар...

Һәм шунысы кызыклы: бу картиналарның күбесендә кеше үзе юк, әмма һәркайда аның табигатькә салган эзләре уелып ята. Әнә урманлы тау иңеннән түбәнгә таба баскыч сузылып төшкән, әнә агачлар арасыннан урманчы йорты күренә. Биредән кемдер берәү чаңгыда узган булган, ә тегендә балыкчылар текә ярдан су читенә кадәр кыйгачлап сукмак салганнар. Вятка буенда кечкенә генә дебаркадер, комлы ярга каплап куелган көймә...

Кеше — табигать баласы, кеше — табигатьнең аерылгысыз бер өлеше.

Мәктәптә уздырылган бу күргәзмә Свергузинның беренче күргәзмәсе түгел. Совет властеның 50 еллыгы уңае белән аның персональ күргәзмәсе оештырылган иде. Аннан соң тагын бер-бер артлы ике күргәзмәсе булды. Аларның һәрберсен тамашачылар яратып карадылар, әсәрләргә югары бәя бирделәр.

Инде менә тиздән Абдрахман аганың бишенче күргәзмәсе булачак. Һәм анысы да соңгысы булмас, әлбәттә. Чөнки бу талантлы үзешчән рәссам әле һаман юлда, һаман иҗади эштә.

РӘХИМ САБИРҖАНОВ,
Татарстан Халык иҗаты йортының сынлы сәнгать методисты.

# ЧИШЕЛЕШ... НУЛЬГӘ БЕТМИ

Яшь язучы Азат Ганиевнең әле дөньяга чыкмаган бер повесте бар. Ул повестьтагы шундый эпизод хәтердә калган: математикадан мәсьәлә чишеп утырганда өлкән класста укучы бер кыз урыныннан тора да, «чишелеш нульгә бетә» дип, класстан чыгып китә. Артык көч куеп уку, гадәттән тыш киеренкелек бичара кызның акылына зарар салган икән. Һәм ул, кешелек тормышы турында катлаулы уйларыннан ваз кичеп, бик гади, ләкин аксиома дәрәҗәсендәге хакыйкый бер нәтиҗәдә тукталып кала.

— Синең бөтен гәүдәң атомнардан тора,— ди ул шәһәрдән килгән художник егеткә, беренче танышканда ук.

А. Ганиевнең әле дөнья шаулатып «язучы» дигән шөһрәтле исемне күтәреп йөргәне, әдәбият укучы халык алдына чыгып бу исемгә имтихан тотканы юк. Әле нибары «Казан утлары»нда бер-ике хикәя бастырган һәм 1969 елда өч табак күләмендә бер бәләкәй китап чыгарган яшь прозаик ул. Болардан тыш А. Ганиевнең Казан дәүләт университеты (Азат — шундагы татар бүлегенең 3 курсында укый) каршындагы «Ленинец» газетасында русчага тәрҗемә ителгән җыйнак кына бер-ике хикәясе басылды. Нибары шулар. Бу мәкаләнең исеме ни өчен А. Ганиевнең басылмаган әсәреннән алынды?

Әдәби практикада күргәләп торабыз: шау итеп бер шагыйрь күтәрелә. Яшь, чибәр һәм... талантлы сыман. Менә бервакыт ул газета-журнал битләрендә күренә башлый, радио-телевизорда, ничә кабызсаң — әлеге шул яшь иптәшнең исеме ишетелә, наширләр коридорда аның белән инде кул биреп күрешәләр, үзләре чакырып (!) кабинетларына алып керәләр. Яшь иптәш әнә шулай бер ел шаулый, ике ел шаулый, өч ел... Ах! Өченче елда ул кинәт кенә күздән югала. Яки бигрәк тә начары: үзенең куәте беткәнне аңламыйча, кругта буталган көрәшче кебек, мәйданда комачау итә башлый. Прозаиклар арасында да була андый хәл. Күрәсең, савытларында дары булмаган көе кулына каләм алганнар алар. Яки бер дә булмаган көе түгел, азмы-күпме булган, ләкин бер кабынган да, ялт иткән һәм шуның белән вәссәлам! Чишелеш нульгә беткән. Вакытында туктаган кешене гаеп итеп булмый.

А. Ганиев «Казан утлары» журналына беркемнекенә дә охшамаган «Янәшә» хикәясе белән килеп кергән иде. Берәүнекенә дә охшамаган дидек. Яхшымы ул, уртачамы, анысы икенче мәсьәлә. Укучылар, әлбәттә, сизми калмадылар. Яшь язучының хикәядә бирелгән персонажлары мәҗнүн кешеләр. Боларны романтик шәхесләр дип тә атап булыр иде кебек. Бу шәхесләр «Янәшә»дә генә түгел, «Өмет уты сүнмәсә», «Студент Әсгать», «Тагын күченәбез» һәм башка хикәяләрендә дә очрыйлар. Авторның барлык хикәяләрендә дә төп образ итеп яшьләр алына. Төп герой нинди дә булса берәр хиреска (рәсем сәнгатенә, ил гизүгә, үзен ил өчен иң файдалы эшкә сарыф итү юлларын эзләүгә һ. б., һ. б.) бирелгән була. Заманында Г. Нигъмәти мәшһүр язучы Г. Ибраһимов әсәрендәге каһарманнар «нинди дә булса бер хиреска бирелгән

дәрәҗәсенә җиткерелгән була», дип билгеләгән иде.

Яшь язучы А. Ганиевкә Г. Ибраһимов прозасының йогынтысы бик зур. Куанычлы күренеш бу. Югыйсә, бүгенге яшь прозаикларыбыз арасында үткәндәге әдәби мираска йөз чөереп караучыларны, әнә шуңа күрә дә агач тел белән «картон» хикәя әмәллäүчеләрне күргәләп торабыз. Матур сюжетка корылып та бары тик теле эшләнмәгән булу аркасында гына басылмыйча калган, редакцияләр тарафыннан кабул ителмичә җибәрелгәннәре никадәр тагын!

Г. Ибраһимовның «Табигать балалары»ндагы печән өмәсе картинасы яшь авторның «Өмет уты сүнмәсә» хикәясендә безнең бүгенге колхоз, бүгенге яшьләр тормышы фонында кабат бирелә. Әлбәттә, сюжетның «Табигать балалары»на якын ук килүе укучыны (һәрхәлдә, Г. Ибраһимов әсәрләрен яхшы белгән укучыны) бераз шиккә төшерә. Тегендә — крестьяннарның печән өмәсе, Хафиз, Бибиәсма һәм аның әтисе Шаһи карт. Узышка печән чабу, бәхәс, мәхәббәт. Монда — колхоз өмәсе. Мәхмүт, Гөлгенә, аның бабасы Талип карт. Тегендә Хафиз бәхәстә җиңеп чыга, кыз бирү мәсьәләсе хәл ителә. Данлыклы печәнче Кәрим карт җиңелә. Монда Мәхмүт — унынчы классны тәмамлаган егет — картны юри җиңми кала. Көч җитмәүдән түгел, ә картны җиңеп, чалгы ташлатып, аның йөрәген җәрәхәтлисе килмәүдән... Әнә шуңа күрә дә картның кызы Гөлгенә, аңа кыска, ләкин бөтен арганнарын оныттырырлык кайнар карашын бүләк итә. Г. Ибраһимовта — өмә вакытында «Агыйделнең югары башыннан йомшак мамык төсле ап-ак бер болыт күтәрелде». А. Ганиевтә «...көнбатыштан күкне иңләп, яшькелт-кара болыт килеп чыкты... Караңгыланды. Кинәт бөтен нәрсәне калтырандырып яшен яшьнәде, шуның артыннан ук җире, күге, бөтен дөньясы дөбер-шатыр килде. Хатын-кызлар, чыр-чу килеп, арба асларына кереп качтылар. Яңгыр, таш стенадай, күзгә күренеп, өмәчеләр өстенә килде». Укучылар монысын да сизгәннәрдер: Галимҗан Ибраһимовның табигать күренешләрен сурәтләүдәге куәтле каләме хәзерге яшьләр иҗатында яши, дәвам итә икән...

«Өмет уты сүнмәсә» хикәясендә А. Ганиев әнә шулай бөек әдипнең тасвирлау алымнарына янәшә бара, әйтергә кирәк, шактый хәтәр янәшә бара. Менә-менә, тел очында гына тора, әйтәсе килә: Ибраһимов юлына кереп китә. Аның каһарманы Мәхмүтнең кайгысы өмәдә җиңүче булып кыз алу түгел. Мәхмүт әле тормышта үз урынын тапмаган егет. Аның әле әллә нинәрләр күрәсе бар. Аның «Байкал күленең чыннан да тирәнме икәнен, Кавказ тауларындагы бозның җәй көнендә дә эреми икәнен, диңгез дулкыннарының, Себер тайгаларының шаулавын үз колаклары белән ишетәсе килә: үн ел буе укыдык, укыдык, ә бәлки алар берсе дә дөрес түгелдер».

Менә шулай Мәхмүт билгесез сәфәргә чыга. Әсәрнең төп персонажы булган Мәхмүт — героик шәхес түгел. Ул бернинди дә батырлык эшләми. Бары тик шул яшьтәгеләргә хас булганча, аның күңеле эзләнә, ул үзенә урын тапмый. Ул институт дип ябышып ятмый, бик тырышса, ихтимал, керә дә алган булыр иде. Ил-җир күреп йөрү яшь егеткә кыйммәткә төшә: ул фаҗигагә очрый һәм аяксыз кала. Озакка сузылган эчке көрәш, тирән кичерешләрдән соң сәламәт кешеләр сафына кайта. Аның бөтен курыкканы — кешеләрнең аңа инвалид дип кызганып караулары. Ләкин кешеләр аның протезлы икәнлеген бөтенләй сизмиләр икән! Шашкын йөрәк үзенең эзләгәнен тапкандай була. Авылга кайткан көнне үк Мәхмүт идарәгә кереп председательдән трактор даулый. (Берничә ай гына элек колхозны ташлап киткән егет.)

— Яңа тракторлар кайтарырга тора идек,— ди аңа председатель.— Каян механизатор табарга белми аптыраган идек әле. Ә хәзергә Салих белән иске тракторны аякка бастыра торыгыз.

Бу эпизод егетнең кичергән трагедиясенә тәмам чик куя: ул өенә канатланып кайта. Чаңгы шуып карарга була. Гарип түгеллегенә ул үзен дә ышандырырга тели. Тауда, бәлки, Гөлгенә дә бардыр? «Син җендер, улым!» — ди Талип карт аның чаңгыда йөргәнен күреп. Мәхмүтнең фаҗигасен хат аша белгән Гөлгенә тау башында чаңгыда басып торган егетне күреп өнсез кала. Аяксыз Мәхмүт чаңгыда! Ике аягы да сәламәт кыз таудан төшеп җитә алмыйча, каушаудан, карга мәтәлә. Мәхмүт тә тау түбәсеннән үк төшә. Әлбәттә, ул да егыла. Ләкин никадәр бәхетле ул!

— Күптән шуган юк иде, онытылган,— дигән була егет.

«Гөлгенә йөгереп килгән уңайга аның кочагына атылды»,— ди язучы соңгы җөмләсендә. Егет белән кыз әнә шулай очрашалар.

Мәгънәләрне [illegible] кебек агу) һәм мәгънә төсмерләрен (үз алдына) күрсәтү белән бергә тәгъбирләргә стилистик, грамматик һ. б. ш. аңлатмалар, аныкламалар бирелә:

КАШЫК КҮТӘРҮ. 1. Ашау, туену. *Көрәшсез генә кашык күтәрә торган заманнар җитмәгән әле, чибәр егет!* М. Шәйми. *Зурысы унөчкә чыкты. Байга бирер идем, теле юк. Болары яңа гына кашык күтәрә башладылар* [*дип зарланды әни*]. Г. Садрый-8.

2. Сан һ. б. ш. сүздән соң. Өй эчендә, семьяда шунынча ашаучы булу. *Әлегә ике генә кашык күтәрәбез.* Н. Исәнбәт, 2-363. *Биш кашык күтәрә идек. Шуннан мине дә фабрикага бирергә булдылар.* А. Әхмәт-113.

ҺӘМ БАШКАЛАР. Гадәттә ирон. яки шаярт. Шушы сүз астында телгә алынучылар: төп исемлеккә кертелмичә, соңыннан-ахырдан, гомуми генә искә алынучылар. *Романда ким дигәндә 25—30 герой телгә алына. Аларның байтагы, сәхнә арты теле белән әйткәндә, «һәм башкалар» ролендә генә кала.* Б. Камалов, 7. *Моңарчы яшь прозаикларыбызның — исем-фамилияләре гадәттә исемлек ахырында, «һәм башкалар» алдыннан гына телгә алынып үтелә иде.* КУ, 69-4-141. *Әл танылган әдипләр иҗаты турында фикер йөртү белән генә канәгатьләнмичә, кайбер тәнкыйтьчеләр «һәм башкалар» рәтендә йөрткән шагыйрьләр иҗатына да күз сала.* Соц. Тат., 67-75-3.

КОММЕНТАРИЙ КИРӘКМИ (артык). Китаби. Болай да аңлашыла, нәтиҗә ясау кирәкми. *Бу шигырьне аңлатып торасы калмаган. Мондый чакта комментарий кирәкми дилэр.* Н. Дәүли, 16-148. *Бу вакыйгаларга, шәт, комментарий кирәкмидер, ул үзеннән үзе аңлашыла.* АХ, 68-9-16. *Бу чыгышларга комментарийлар бирүнең кирәге юктыр дип уйлыйм.* Ж. Тәрҗеманов, 2-50. *Биредә комментарий артык булыр.* КУ, 66-9-131.

КОРСАКНЫ ТИШМИ. Гади сөйл. к. Кесәне. [*Камали — никах укудан баш тарткан муллага:*] *Никах та укымагач пычагымамы хәзрәт булып, ил өстендә үгез булып йөрисең?.. Бер бозау корсагыңны тишеп чыгар идемени?!* Ф. Бурнаш-209. *Запас корсакны тишми.* Х. Гобәйдуллин, 4-111.

Бик кыска бер белешмәдә йөз табаклык хезмәт хакында тулы мәгълүмат бирү кыен, билгеле. Сүзлек дөньяга чыккач, укучылар аның белән якыннанрак танышырлар дип өмет итәбез.

— Мал асрамый ничек яшәйсең! Ни белән дөнья көтәсең! Чәркә күтәреп көн дә кешедән сөт сорап йөрерсеңмени, исәр. Без гомер буена малсыз тормадык, аллага шөкер. Абзар тутырып сарыгын асрадык. Икешәр сыер сауган чаклар булды. Аның янында тагын танасы, бозавы. Сугыш вакытында да ниндәен нәрәт кайтса, иң башта безгә килеп керделәр, бездән алдылар. Җизнәң Сталинград фундына гына да дүрт сарыкны җитәкләп илтте. Йоннары да алынмаган иде.

— И түтәй, кичә син үрдәк тазартып йөргәндә яңа гәҗит кайтты. Җизнәй укып күрсәтте. Япун белән Кытай ягында әле дә бик каты сугыш бара дигән.

— Әмерикәнме?

— Әмерикән. Шул тагын бик нык сугыша икән. Бер бәләкәй генә Вьетнам дигән халыкны буйсындырам, дип әйтә ди. Сез кайчан да булса бер барыбер минем кул астымда булырсыз, дип әйтә ди, мөртәт.

— Ходай күрсәтмәсен! Бәләкәй халыкка рәт юк бу дөньяда. Алла ярдәм бирсен мескеннәргә! Бу Әмерикәне дә яшь әтәч төсле гел сугышырга кыҗырай да тора, кыҗырай да тора. Өендә тыныч кына чәй эчеп утырса ни булган!..

— Беләмени алар чәй тәмен! Ул якларда иртән торсаң — күфи ди бит... Кара әле җизнәйне. Нәмәгә безгә карап торасың, җизнәй? Әзрәк ял итеп ал!

— «Мине сөйләми микән болар», ди инде. Аңларга тырыша. Юк, юк, сине сөйләмибез — сугышны сөйлибез, сугышны. Сугышлар булмасын, тынычлык, иминлек белән яшәргә язсын, дибез. Сиңа әйтәм, син бар кер, чәй эчеп чык. Самавыр суынмагандыр әле, яңа гына гөжләп утыра иде.

— Берүзе эчмәй бит у-ул.

— Ю-ук! Эчерерсең аны! Мин кич ашка китәм. Самавырга күмер салып кайнатып китәм. Эч тә ят, интегеп утырма, йокла, димен. Тәки мине көтеп утыра. Нигә мин берүзем чәй эчеп ятаем, дие. Менә, дивана түгел диең син аны.

— Дивана булыр ул! Күңеле тартмый. Нишләп ялгыз башы чәй эчеп утырсын! Илле тугыз җыл бергә яшәп, бер түшәктә җоклап икегез бер кешегә әйләнеп беткәнсез инде. Ходай тагын гомерегезне бирсен! Ул балаларыгызны әйтәсеңме! Берсеннән-берсе уңган, берсеннән-берсе тәүфыйклы, берсеннән-берсе олы урыннарда эшләйләр. Миннән булмады инде. Утыз яшьтән ятим калып. Укыта алмадым. Үзләре дә ялкау булды, каһәр суккан нәмәкәйләр. Мин укырга китте диеп торыр идем, ул кибән артында тәмәке тартып ятар ие, иптәшләре кайтканда гына шуларга ияреп кайтыр ие, бер нәмәкәй дә булмагандай күзен тондырып, инә-әй, үләм, корсагым ачты, давай, ашарга бир, диеп. Имансыз! Менә-терә, бүгенге көндә бозау көтеп йөри үз башын үзе кадерсез итеп. Укыса, зур урыннарда эшләмәс идемени! Өстәл башында тилефүн челтерәтеп кенә утырыр ие. Үзе кешеләрне кушып...

— Нахак бәләләр тагасың. Бик әйбәт эшләй бит. Тагын ни кирәк? Эчмәй. Катын-кыз димәй, азмай-тузмай.

— И түтекәем, анысына мең шөкер итәм инде. Намаз артларыннан теләем, катын-кызлары аның хәзер катын-кыз төслемени! Заман ахыры житкәндә, ире, катыны хайван сурәтенә кереп бергә йөрер диган сүзләр дөрескә килдеме — килде!

— Килми ни! Менә минем Акбай киленен ал. Югыйсә, карап торуга акыллы гына төсле бит инде. Укыган кеше дә. Былтыр шуларның Кәме буендагы дачаларына бардым. Анадан тума шыр-шәрә тик йөри. Ике түшенә тар гына ике чүпрәк каплаган. Карап торсаң — әдәм тәгәнәсе менә! Тьфү, тьфү, ташка үлчим. Түшеңә кэрә күрмәсен. Киленкәем, дидем, ник болай йөрисең әдәм араларында оялмыенча, дидем, алла

күлмәккәйләрең юкмы, ана бит, күзең күрмәймени — күпме ирләр йөри тирә-ягында, дидем. Бар, тизрәк, кеше-кара нәгәләт укыганчы, өстеңә киен, дидем. Әллә миңа кояшка кызынырга да ярамаймы диеп мыгырданып, такта өйләренә кереп китте. Менә, исәр, күрәселәрең булса, күрәсең аны. Картайгач та күрсәтә.

— Шулай булмай, түтекәем. Әйттенме соң, без яшь чакта бер дә шәрәләнеп кызынып ятмадык, диденме? Өстә чүбек җебеннән үзебез сугып кигән күлмәк-ыштан, аякта тула оек белән чабата булыр ие, кулда йон бәләкчә, башта — төшереп бәйләгән яулык. Шуның белән көн буена кызу кояшта урак урасың бит әле, инәкәеңнән башыкае, бала имезәсең. Анысы бакырып чүмәлә төбендә ята. Кайда ул кояшта кызынып ятулар! Ә хәзер ирәяләр, түтекәем, авызларына бөтен нәрсәне хөкүмәт каптыргач. Шулай ирәя, шулай бозыла бала-чага.

— Сабан туеннан соң, әбекәем, бабыкай, бик сагындым диган булып Нәфиганың олы кызы Хания кайтып киткән булды бит әле. Инде дүрт-биш ел кайтканы юк иде. Менә шул әдәм рисвае итеп китте бит имансыз нәрсә. И илаһым, җизнәңнен дә, минем дә нерваларыбызны калдырмады, исәркәем. Төн буена капка төбендәге утыргычка утырып чыгалар. Иртән мин кәҗә саварга торгач кына кереп ята. Күлмәккәе бөтенләй юк диеп әйтерлек — арт йомрыларын да капламаган ристанның. Җизнәң шуны күрде дә кайтып керүенә эт итеп сукте. Алланың каһәре суккан нәрсәкәй, әбиең белән бабаңны картаймыш көннәрендә бөтен авылга рисвай итәргә кайттыңмыни күзеңне-башыңны тондырып, дие, менә эпекәйдер! Самавыр да куя алмыйсың, идән дә юа алмыйсың, бер нәмәкәй дә эшләй алмыйсың бит — иелдеңме шәрән күренә, болай йөремә минем алдымда, кайтып кит бүген үк, намаз артыннан каргармын, дие.

— Ә үзе нәмәкәй дие шуннан соң җизнәйнең сүзенә каршы?

— Нәмәкәй дисен! Хәзер җегерменче вик, дие дә тора, имансыз.

— Вик дигәне нәмәкәй микән соң аның? Әллә ниткән политик сүз булмасын.

— Белмәем. Сорарбыз әле. Көчкә кайтарып җибәрдек. Инәсеннән хат килде. Картая-картая котырып беткән икән наше дедушке диеп кайтып әләкләгән.

— Аларны әрләп тә, кыйнап та булмый хәзерге вакытта. Суксаң, хәзер бакырып кәнсәгә чабалар. Закун үзе шулай диеп тора.

— Бабалары шикелле житмеш жыл дөнья көтсәләр ни әйтерләр ие микән? Бабай дүрәк түгел, акыллы — без үзебез дүрәкләр, диеп әйтерләр ие, нибуч.

— Карале, түтәй, шушы атнада Әзербәйжанга да илле яшь тулган дие. Радио әйтте.

— Кайсы ул тагы?

— Теге... бар бит әле тау халыгы. Нифтене дә бик күп чыгарган жир. Минагратлы як. Кафиянең кызы шуннан бер тартма минәграт жибәргән иде бит. Килгәнче череп беткән — утынлыкларына чыгарып түктеләр...

— Ә-ә-ә, аны әйтәсең икән. Дәүләт булып оешуларына илле жыл булган шул. Шул көнгә хөкүмәт бурычларын да үтәп бетерделәр, дие, укытучы әйтә.

— Тилевизер дә сөйләгән бит.

— Нигә аны тиле диделәр икән соң? Хәтәр акыллы сүзләр сөйләй бит ул.

— Син әле нией әйт, пучтыга кереп тиле грам сугыйм дисәң, анысы тиле. Челтерәтәем дисәң — тиле фуны — тагын анысы да тиле.

— Бала-чага куша инде аны, юри, мыскыл итеп. Үзләрен генә акыллыга чутлап йөриләр.

— Шулайдыр ул, түтәй, чыннан да. Былтыр Оркыяларга барып ай ярым торып кайттым бит. Шунда моның мин барган көнне үк ярты миске сөтле ашы калды. Җылытып бирсә үзем дә ашаган булыр идем, әрәм итмәсием. Ә үзем гәзләрен бора белмәдем, курыктым. Эштән кайтты да шул ярты миске ачымаган-нитмәгән менә дигән тәмле ашны туәлит дигән бүлмәләренә керде дә, гөпердәтте дә тишеккә салды. Кызым, дидем, минем бу туәлиткә керергә бүтән йөрәгем җитмәй, моннан бүтән тишегенә дә утырасым юк, дидем, аш өстенә утырсаң, корышып катармын, давай миңа билет ал, килгәндәге шикелле тәкси дигән машина чакырт, минут тормаем, хәзер үк кайтып китәм, дидем. Менә бит, диванакай, гәзне борала бит ул. Җылытып бирсә, үзем ашаган булыр идем. Ә Оркыя көлә, аңа көлке. Инәй, кайгырма, ул токмачлар әллә кайчан Кәмегә агып китте инде, дие. Беләсеңме, түтәй?!.

— Белмәй ни! Безнең киленнәр дә шулай. Әй, ташыйлар мәгәзиннән ситке-ситке, сумкы-сумкы нигъмәт. Калбасасын, балыгын, прәнниген, маен-шикәрен, җимешен, төрле-төрле кәнсирләрен. Аша, әнкәй, дигән булалар. Аша диюләренә рәхмәт инде. Яртысын ашап каламмыюкмы, кич кайталар да калганын барын җыеп, каткан инде болар диеп, тыштагы тартмага чыгаралар да түгәләр. Үзләре тагын ситке тотып мәгәзингә чыгып китәләр. Ә ул калган продуктыга нимә булган? Аны миңа ашарга ярамыймыни? Элек ярты сынык эпекәй күрмәенчә ачка интегеп яткан чаклар да була иде дип сөйләсәң, берсе дә ышанмай, көлә генә. Дөньяда шундый тормыш буламыни, әкият бу, әбекәй, диләр.

— Карале, түтәй, әкият дигәннән, безнең рәките айга менеп кесәсенә ком салып алып төшкән, дие. Син ишеттеңме?

— Ишетмәй ни! Кичәдән бирле бөтен радиу, тиле визер шаулап тора.

— Чыннан да, шул нәрсәкәй дөрес микән?

— Ай ул бер нур гына бит. Анда ниндәй ком булсын?

— Рәките ничек менеп җитсен, диең. Ничәмә-ничә млиун чакрым бит ул. Иге-чиге юк бит аның. Әбугалисина әфсенен генә өйрәнмәгән булсалар. Һи-һи-һи...

— Рәкитәсе менсә дә, кайда аның лумы балчык ватарга?! Һә-һә-һә!..

— Лум белән ватып түгел — бораулап алган, диләр, түтәй.

— Борауларга айда нинди борау булсын!.. Һә-һә-һә-һә!

— Балчыгын учлап алсын да ди! Кая ул рәкитәнең кесәсе — балчыгын салырга?! Һи-һи-һи-һи!..

Язалар бит, сөйлиләр! Әкият!.. Һә-һә-һә!..

— Томаналар ышана инде аңа. Бала-чагасы гүпчим ышана. Тач шулай булган икән, дие... Һи-һи-һи!..

Яшь әби белән карт әби, җир йөзендә теләсә нәрсәгә ышанып йөрүче беркатлы кешеләрнең булуына гаҗәпләнеп, үзләренең андый кешеләрдән акыллырак, хәйләкәррәк булуларына куанып, бәрәңге алуларыннан туктап рәхәтләнеп кет-кет көләләр. Болар нигә көлә микән, шуны беләсе иде, дигән шикелле кызыксынып, күзләренә карап торган бабайга да, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә, кычкыра-кычкыра, хәлне төшендереп бирәләр.

— Ә-ә-ә, аны сөйлисез икән. Рәкит айга барып кунып, ай туфрагын алып төште шул, төште, — ди бабай. — Анысы дөрес. Булдырып тора хәзерге халык, булдырып тора-а.

Шулай ди дә, капчыгына өч чиләк бәрәңге салып, кайбер урыннарында көнбагыш төпләренә абынгалап, лапаслар ягына юнәлә.

Әбиләр тагын сүзгә керешәләр:

— Сиңа әйткән идем микән, Айбикәнең түтәсе килеп - китте бит әле, — ди карт әби, буразна арасыннан алабута чүпләштереп. — Мәсүфәсе, Карамалы күлдән.

— Юк әле, түтәй, ишетмәгән идем.

— Шул Мәсүфә беркөн безгә килеп утырды. Сарыкларны яңа гына ябып кереп ашка утырган идек. Нәмәкәй эшләп хәжәйстуасын бер дә карамай ул Айбикә? дие. Бөтен әйберләре ватык та җимерек, дие. Сәгатьләрен җибәрим дигән идем — сәгатьләре йөремәй, тукмагына трахтыр тимерләре тагып бетергәннәр. Тик утырганчы яулыгымның читен бөгеп алыйм әле дисәм — машиналары текмәй, алганнан бирле май чырае күрмәгән, калтыр да колтыр, энәсе күгәреп беткән. Ятып тораем дисәм — караваты кәкшәннәп беткән, пружинасы янбашыма кереп китте, дие. Убырныйлары уң якка кыйшайган, дер-дер селкенеп авып китәргә генә тора, хәзер басып үтерә бу мине диеп куркып, кергән җиремнән кире чыгып йөгердем, дие. Радиуларын сөйләтәем дип борсам — сөйләмәй, эченә үрмәкүч оялап беткән. Сикереп кенә менеп атланаем да урман буйларыннан бер чаптырып урап кайтаем әле дисәм — лилсәпитләренең тыны чыгып беткән, дие. Менә, җүләр, ише тәсе колакларың булгач...

— Э-э-э, Мәсүфәнеке шикелле умарта гәүдә белән сикереп кенә лисәпиткә менеп атланырсың! Җиде пот бит ул...

— Нишләп дөнья күтәргә тырышмай ул Айбикә? — дие.

— Ничек көтсен! Бар тапканын малае талап алып эчеп баргач.

— Шулай шул. Аның бәләкәй кызы, бабыкай, әбекәй, диеп гел бездә ята. Бөтен нәрсәләрен сөйләп бара. Әтән кая китте, дисәң, Мөслимгә, дие. Нигә китте, дисәң — эчәргә, дие. Әтәң кайттымы, дисәң — кайтты, дие. Нишләй, дисәң — әбекәй белән талаша, дие. Нәмәкәйгә талаша, дисәң — эчәргә акча сорый, дие.

— Эчкән кешедә өмет юк инде. Убырның түгел — өең авып төшәр. Безнең авылның да чын леснигы эчә-эчә алькожуликка әйләнде бит. Хәзер бүлнискә барып беләгенә укул кадатып йөри.

— Нигә эчмәскә, эчәм шул. Урмандагы агачларның һәр ботагы саен бер бутилкә эленеп тора миңа, диеп әйтә диеп сөйләгәннәр ие — шулмы?

— Шул үзе. «Хатыным кеше белән йөргән сыман тоела. Шуны үтерәсем килә», диеп әйтә дие тагын. Ходаем, үзең сакла!.. Чамасын белеп эчәргә кирәк, чамасын. Белеп эчсәң — дару, белмәсәң — агу бит ул дөмеккере нәмәкәй.

— Мин аның пивасын үзем дә эчәм. Кунакка барган саен малайлар акча бирә. Мә, инәй, урамда йөргәндә рәхәтләнеп пива эчеп йөре, курыкма, монда синең белән ашка йөргән ахирәтләрең юк, диләр. Иплэп кенә урамга чыгам да берәр бакал пива эчәм дә кайтам. Килен сизми дә кала. Аларның фатиры парк дигән бакча янында гына. Шуның капка төбендә генә гел пива сатып торалар.

— Булса бик эчәр идек тә, монда кайтармайлар шул пиваны...

— Кичә Мәсәянны эт урынына сүгеп кайттым әле.

— Бәрәч, нигә тагын? Бик акыллы малай диләр бит аны.

— Амбар алдына барсам, яңгыр коя. Амбар ишек алдында тау хәтле тары өелеп ята. Өстенә, ичмасам, салам да капламаганнар. Җырганак белән агып ята. Үзе каравыл өенә кергән дә утырган кладавшик башы белән.

— Нәмә диде соң, син әйткәч?

— Бар, бар! Үбирәйсә, кайтып кит! Дилаң булмасын монда, дие. Менә имансыз!


— Алланың каһәре сугасы нәстә икән!

— Тәүфыйксыз! Әллә нәмә күреп үләр әле.

— Эпекәйнең кадерен белмәгән кеше — кешемени ул. Ыштыр бит ул!

— Прсидәтелгә әйтәм әле мин аны. Әләкләде дисә дияр. Ник куркып тораем аннан. Прсидәтел капка төбеннән үткән саен машина-

## Хәкимҗан Халиков



### Кояшбикә челтәре

Кояшбикә
Бигрәк унган.
Кара, ничек
Иртүк торган.
Тау битенә
Ап-ак кардан
Көмеш челтәр
Үреп куйган.

Уянган да
Йокысыннан,
Кар челтәрнең
Уртасыннан
Умырзая
Карап тора,
«Яз житкән бит!»
Дигән сыман.

### Барый

Бигрәк инде
Шушы Барый,
Чикләвеккә
Үзе бармый.
Җыеп кайтсаң —
Ала-каба,
Капкан саен
Гаеп таба:
— Төше дисәң —
Ярым-йорты,
Кабыгы, — ди —
Таштан каты.
Җыйгач-җыйгач
Аны, кызый,
Җыярлар,— ди,—
Кабыксызын.
— Анысынмы?
Үзең җый син!
Бар, бар! — диеп.
Өммегөлсем
Чикләвеген
Тартып алды —
Барыебыз
Телсез калды.



## Нишләдем мин?..

Шундый оста атам мин,
Үзем дә шаккатам мин.
Читәндәге чүлмәкне
Күз йомып та ватам мин.

— Шул песнәкнең күзенә
Тидеримме, Зилә? — дим.
Зилә елый: — Нишлисең?
Тимә инде, тимә, дим!

— Бар икән! Нәкъ апаң син,
Атам дигәч атам, — дим...
Рогатканың резинын
Бар көчемә тартам мин.

Сынды шулчак аткычның
Ике ябе шарт итеп,
Маңгаема уң кулым
Берне бирде шап итеп.

Күздән утлар күренде,
Нишләдем мин — күр инде.



## Әле төште хәтергә

Иртән торып чыгуга,
Урап алды чебиләр.
Әй сөйлиләр, сөйлиләр:
— Чи-чи, чи-чи, чи...— диләр.

Казлар әйтә: — Га-га-га,
Ә үрдәкләр: — Бак-бак-бак.
Нәни бәбкәләр дә:
— Пип-пип,—диләр такмаклап.

Аңладым — ни сөйлиләр:
— Хәерле иртә! — диләр.
Аптырадым-йөдәдем,
Җавап бирә белмәдем.

Башка килмәгән бер дә,
Әле төште хәтергә:
Әнигә дә шулай дип
Онытканмын әйтергә.



## Әллә инде беләләр...



Кайтып киләм мәктәптән,
Шатлыгыма күмелеп.
Карап тора гөлләрем,
Тәрәзәдән үрелеп.

Барысы да ал, кызыл
Чәчәкләргә төренгән.
Нәрсәгәдер алар да
Куанышкан-сөенгән!

Яфракларын чәбәкләп
Елмаялар, көләләр.
Минем «биш»ле алганны
Әллә инде беләләр?

## Бәбкә саклаганда

Тилгән дисәң тилгән,
Тагын берсе килгән.
Көш-шү! Көш-шү!
Көш-көш!
Юк, юк, әйдә, төш-төш!

Кара, кара, тиле,
Китеп бара кире.
Китмәс иде бер дә —
Кылычым бар билдә,
Ә мылтыгым кулда.
Әти килеп шунда
Сөеп куйды иңнән:
— Солдат чыга синнән!..



Тилгән хәтле тилгән
Курыккачтын миннән,
Чыгып куяр хәтта,
Бәлки, космонавт та.
Әйе бит?

## Зәки Нури

# БУ УКЛАР КЕМГӘ ТИЯР?

*Балалар һәм зурлар турында*

### Кем кемне чәнечте?

— Әгәр балаң кире беткән булса,
Чәч агарта диләр — хак икән.
— Белдем, әни, минем әбиемнең
Шуңа күрә чәче ак икән.

### Сүз бирә

— Һич тормыйсың әйткән сүземдә син,
Ачуланам, шуңа күрә, балам.
— Ачуланма, әни! Мин бит сүзне...
Әллә ничә тапкыр бирә алам.

### Эштә һәм өйдә

— Бер кроссворд, эти, чишеш әле!
Өч көн ята журнал киштәдә...
— Булмый, улым,— мин ул кроссвордлардан
Туеп беткән инде эштә дә.

### Гыйльми бәхәс

— Балык сөйли белә дисең,
Сөйләтеп кара тот та!
— Ә син үзең сөйләп кара
Башыңны суга тык та!

— Әй, әткәсе, ишет һәм куан син:
Матур итеп балаң көлде иртән!
— Шундый сабый нинди нәрсә уйлап,
Кайсыбыздан безнең көлде икән?

## Бер рәсемгә карап

— Бу кем, әби? — Фәрештә ул, бәбкәм,
Ул күкләрдә асрый изге җанын.
— Ә ник аның ракетасы юк соң,
Скафандрасы ник юк аның?

## Базарга бергә баргач

— Адашырсың! Итәгемә тотын.
Бер адым да калма үземнән!
— Буем җитми. Синең итәкләрең
Өстәрәк бит, әни, тезеңнән.

## Автобуста

— Ник утырдык? Безнең өй якын бит,
Китабыңны кайткач укырсың.
Мине, әни, итәгеңнән төшер,
Теге бабай әнә утырсын!

## Радик Исаев

# ҖОР МАЛАЙ

— Әни, мина велосипед кирәк иде.
— Алырбыз әле, улым. Бераз сабыр ит.
— Гел шулай дисең,— диде Хәмидулла, әнисенә үпкәләп.
— Ярар, улым, алырбыз. Менә бу айда бәлкем план да үтәлер.
— План үтәлсә акча күп буламыни? — диде малай.
— Әлбәттә.
— План ничек үтәлә, әни?
— Күбрәк товар сатсаң.
— Һем,— диде Хәмидулла, кулларын чалбар кесәсенә тыгып. Аннан ихатага чыкты. Велосипедта йөргән шикелле аякларын алмаштыра-

арбасын урыныннан кузгатты. Аның күчәрен майлады. Купкан арата-сын кадаклады. Соңыннан, арба өстенә ящик утыртып, әнисе эшләгән магазин ягына юл алды.

Кибет белән йорт арасын бер урады, ике, өч. Моны күзәтеп торган Хәдичә карчык та түзмәде: «Нәрсә ташый икән бу бала?» — дип Хәмидулла каршына чыкты.

— Улым, ни алып кайтасың?

— Әллә... Әни нәрсәдер төяп җибәрде шунда,— диде малай, тирләгән маңгаен сөртеп.

— Кибеттән бирдеме?

— Әйе.

— Баягынак нәрсә алып кайткан идең?

— Белмим. Ящигы кадакланган иде.

«Күрәсең, бер-бер хәл бар. Акча алышыныр алдыннан халык кибет-тәге товарны шулай ташып бетергән иде»,— дип уйлады карчык. Аннан, малайдан берәр хәбәр әйттерү нияте белән, күлмәк кесәсенә тыгылды. Һәм Хәмидуллага конфет алып бирде. Малай теләмичә генә конфетны алды. Әмма рәхмәттән башка сүз әйтмәде.

— Әйт, улым, әйт! — диде карчык, колагын малайның авызына ук китереп.

— Әни әйтергә кушмады,— диде Хәмидулла, пышылдап.

— Йомырка да бирермен, улым. Әйт кенә!

— Тоз,— диде малай, тирә-якка каранып.— Әни тагын килергә кушты. Әллә заводы янган, ди.

— Әстәгъфирулла! Әйтәм, төшкә дә бик мәзәк керде. Урам тулып сыерлар үтте. Дөньялар имингә булсын инде. Ярар, бар, бәбкәм,— диде карчык. Үзе дә атлый-йөгерә йортына кереп китте.

Тиздән Хәдичә әби, кулына зур сумка алып, магазинга килде. Икенче мәртәбә чиләк белән керосинга барды. Урамда очраган үзе шикелле карчыкларга да серен чиште. Шулай итеп магазин каршында зур чират барлыкка килде.

Ике-өч көн үтүгә авыл магазины бушап калды. Хәмидулланың әнисе янадан товарга китте. Бу юлы улына велосипед та алып кайтты. Ә Хәмидулла һаман арбасын ташламый. Магазин артындагы ящиклар арасына керә дә нидер төяп чыга. Хәдичә карчык та малайны күздән ычкындырмый.

— Кара син аны. Үзләренә ташыган гына җитми, мәктәп директорына да илтә бит. Шкул капкасыннан кергән була да директор йорты янындагы сарайга борыла.

«Тукта!» — диде карчык, уйга калып. «Бөтен мал-мөлкәтне ташып бетерә бит бу малай... Сорыйм әле, карыйм әле, нәрсә ташый икән».

Карчык Хәмидулла каршына чыгып басты.

— Тукта! Әйт! Тагын ни алып кайтасың? — диде ул, калын тавыш белән.

Хәмидулла ык-мык итте.

— Әйт, димен, әйт! Әйтмәсәң, районга барырмын. Уписка кертермен.

Малай шүрләде. Калтырап:

— Нигә? План үтибез, задание,— диде.

— Нинди план? Нинди заданжа?

— Тимер-томыр җыю планы,— диде Хәмидулла, арба өстендәге чыптаны ачып.

Арбада зур гына тимер кисәге ята иде.

# ТӘНКЫЙТЬ

Минем Гаптери атлы дустым бар иде Соңгы вакытта әллә нишләде шул Гаптери. Бөтен эшен әшнәләр аркылы җайлый башлады. Шунсыз булмый, хәйләсез дөнья файдасыз, ди. Әле бер көн минем янга килгән дә:

— Ахири, туйдым эшемнән, үз тирәңә, берәр җылырак урынга урнашырга булышчы, ди. Нәчәльнигеңә җайлап-майлап сүз салсаң, син, билләһи, булдырасың,— дигән була. Салпы ягыма салам кыстырмакчы. Чистый үчекте. Эчемдә эт булып өрергә әзер торган ачуымны чак тыеп, акыл өйрәтеп карыйм үзенә:

— Ташла бу гадәтенне, Гаптери, майламый-җайламый гына яши башларга вакыт сиңа,— дим.

Колагына да элми: «Шунсыз булмый. Әтдил кадр янына барып бактым инде. Анда я токарь, я слесарь бул, диләр. Тимер кыйнап, тимер каезлап ятарга мин әллә тилеме? Тимердә ни ачуым калган минем»,— ди.

Үзенекен ишә генә Гаптери. Нишләргә соң? Акылга утыртырга кирәк бит малайны. Бөтенләй бозылып китүе бар.

Тоттым да яздым үзен газиткә: «Әшнә-мәшнә уйнарга ярата, нәчәлләр тирәсендә бутала, шуларга ярарга тырышудан гайре бер эш кылганы юк Гаптеринең»,— дидем.

Язган әйберем газиткә басылып бер-ике көн үтеме, юкмы, минем янга Гаптеринең дуслары тупырдап килеп житте.

— Син Гаптерине гәзиткә язгансың икән,— ди озын буйлысы. Ә күзләре ут кебек яна.

Шүрләп куйдым: куллары да чамалы гына күренә. Җилкә тамырына бер менеп төшсә...

— Теткәнсең икән үзен,— ди кыска буйлысы.

Аннары болар икесе берьюлы телгә киләләр:

— Безнең дә Гаптеридән артык жиребез юк, дус кеше, әйдә, безне дә тәнкыйтьлә, тетмәбезне тет, бөтен халык алдында фаш ит. Алар икесе дә ялагай, диген, нәчәльниккә тәлинкә тотучылар, диген...

— Тукта, ник бәйләндегез әле, егетләр? — дим мин, ни көләргә, ни еларга белмичә.

— Ник бәйләнмик,— диләр тегеләр, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә.— Әнә, син гәзиткә язгач, Гаптерине нәчәльник үзенә зам итеп билгеләгән...

## ИЖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Татарстан язучыларының иҗат секцияләре үзләренең эшләрен тагын да кызыклырак һәм файдалырак итеп төрләндерә баралар. Апрель аенда, мәсәлән, шагыйрьләр секциясенең чираттагы утырышы булып, анда шигырьдәге тоник система турында кызыклы һәм бәхәсле сөйләшү барды.

* * *

Балалар әдәбияты секциясе үзенең апрель аенда булган утырышын Татарстан комсомолының өлкә комитетында үткәрде.

Утырышта Татарстан укытучыларының белемен күтәрү институты директоры Мидәт Гомәрович Ягъяев уку-укыту системасында туган яңа проблемалар һәм аларны тормышка ашыру юллары, республикадагы алдынгы мәктәпләрнең эш тәҗрибәләре белән таныштырды. ВЛКСМ өлкә комитеты секретаре Валентина Николаевна Липужина В. И. Ленин исемендәге Бөтенсоюз пионер оешмасының 50 еллыгына хәзерлек барышы турында сөйләде.

Язучылар чыгыш ясаучыларга бик күп сораулар бирделәр, ике арада җанлы әңгәмә башланып китте.

Соныннан Г. Бакиров, Л. Ихсанова, Г. Латыйп, К. Латыйповлар чыгыш ясап, яшь буынны тәрбияләү бурычы йөкләнгән бу ике оешмага үзләренең теләкләрен белдерделәр.

* * *

Прозаиклар секциясе үзенең утырышын яшь язучы Кояш Тимбикова иҗаты турында сөйләшүгә багышлады. Габдрахман Минский, Габдрахман Әпсәламов, Барлас Камалов, Газиз Мөхәммәтшин, Аяз Гыйләҗев һ. б. Тимбикованың хикәяләренә анализ ясап, аның уңышларын һәм кимчелекләрен күрсәттеләр.

## ШАГЫЙРЬНЕ ИСКӘ АЛУ

Бу елның февраль аенда күренекле татар шагыйре Һ. Такташның тууына 70 ел тулган иде. Халкыбыз аны хөрмәтләп искә алуны әле булса дәвам итә.

Мәскәүдә 9 нчы апрельдә әдипләрнең Үзәк Йортында Такташка багышланган зур кичә үткәрелде.

Кичәне РСФСР язучылар союзы правлениесе председателе, Ленин премиясе лауреаты Сергей Владимирович Михалков ачты. «Такташның эшчәнлеген партиядән аерып булмый. Такташ чын мәгънәсендә партияле шагыйрь иде»,— дип әйтте ул үзенең сүзендә.

Шагыйрьнең иҗаты турында Казан дәүләт университеты профессоры Хатип Госман сөйләде.

Казаннан килгән язучылардан Дәүләт премиясе һәм Тукай премиясе лауреаты Сибгат Хәким, шагыйрь Әхмәт Исхак, язучы Габдрахман Минский, Татарстан язучылар союзы секретаре Гариф Ахунов, шагыйрьләрдән Гәрәй Рәхим, Николай Беляев, башкорт халык шагыйре, Дәүләт премиясе лауреаты Мостай Кәрим, башкорт шагыйре Нажар Нәжми, әзербайҗан шагыйре Хәйрулла Абдуллаев, рус шагыйре Михаил Львов, шагыйрь һәм тәрҗемәче Вил Ганиев, Һади Такташның шигырьләрен рус теленә тәрҗемә итүче Дәүләт премиясе лауреаты Леонид Мартынов, шагыйрь һәм тәрҗемәче Семен Липкин чыгышларын әдәбият сөючеләр зур дулкынлану һәм кызыксыну белән тыңладылар.

Халкыбызга гүзәл әсәрләр калдырган Һади Такташ шигырьләре рус, татар, башкорт һәм әзербайҗан телендә бер үк темперамент, бер үк ялкын белән яңгырады.

Кичәнең икенче бүлегендә Илһам Шакиров, Айрат Арсланов, Эмиль Җәләлетдинов, Зарнус Шахмурзаева, Гали Ильясов, Вафирә Гыйззәтуллина һ. б. катнашуында Һади Такташ истәлегенә багышланган зур концерт булды.

Бу кичәдә КПСС Үзәк Комитеты культура бүлегенең матур әдәбият секторы мөдире А. А. Беляев, КПССның Татарстан өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, РСФСР язучылар союзы секретарьлары Л. К. Татьяничева, А. Алексин, РСФСР Министрлар Советының җаваплы работнигы В. Н. Звягин һәм шагыйрьнең туганнары катнашты.

* * *

Төркмәнстан язучылар союзы органы булган әдәби журнал «Совет әдәбияты» Һади Такташның тууына 70 ел тулу уңае белән шагыйрьнең «Урман кызы» поэмасын бастырып чыгарды.

* * *

Үзбәкстан язучылар союзы органы булган әдәби журнал «Гөлстан» да Һади Такташның туган көнен билгеләп үтте. Ул шагыйрьнең өлкән улы Рафаэль Такташның истәлекләрен һәм «Киләчәккә хатлар» поэмасыннан өзек урнаштырды.

## АЧЫК ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫНДА

Татарстан язучылар союзының партия оешмасында иҗат мәсьәләләре турында сөйләшүләр еш була. Апрель аенда үтка-

язучының эш вакыты турында кызык кына сөйләшү барды. Бу утырышта чыгыш ясаган өлкән буын язучылары үзләренең эш тәҗрибәләрен сөйләделәр, иҗат процессында туган фикерләре белән уртаклаштылар. Татар һәм рус әдәбиятына күп санлы әйбәт романнар бүләк иткән Габдрахман Әпсәләмов яңа әсәрләре өчен ничек материал туплавы, үзен илһамландырган тормыш, халкыбызның фидакарь хезмәте турында сөйләде. Тормышыбыздагы иң авыр вакытларда, авырып урынга егылган чакларында, үзен саклап калган көч — иҗаты икәнен әйтте. Хәсән ага Туфан үзенең чыгышында социаль заказларның әһәмиятенә тукталды. «Инде эшләп арган буласың, ә шул вакытта я радиодан, я телевидениедән, я газетадан бик ашыгыч заказ килә. Шунда син үзеңне кирәк кеше дип, синең хезмәтең кемгә булса да бик зарур дип уйлыйсын, ул кайдадыр яшеренеп яткан эчке көчләрне, запас куәтне кузгатып җибәрә. Син тагын эштә, син тагын иҗат итәсең»,— диде ул.

Халыкка кирәклегеңне тою, хезмәт нәтиҗәсенең үз кешесе икәнеңне белү гаять зур илһам көче бирүе турында Аяз Гыйләҗев сөйләде. Ул нефтьчеләр белән дуслыгыннан мисаллар китерде, аларның хезмәтенә багышлап яңа пьеса язуын белдерде.

«Язучының ил язмышы, халык борчуы белән януы яңа әсәр язарга көч бирә» — диде Сибгат Хәким. Дөньяда бәрелеп, сугылып, көрәшеп, кыйналып, сөрелеп яшәгән Пушкинны мисалга алып, ул бөек әдипнең Михайловскоеда өч-дүрт ай эчендә язган үлемсез әсәрләренә тукталды. Тормышның асылына төшенү, әсәрендә зур проблемалар күтәрү өчен җәмәгать эшләрендә кайнау бик кирәк, диде.

С. Б. Радзиевская иртә профессионаллашуның яшь язучыга зарары, язучы Г. Ахунов һәм тәрҗемәче С. Фәйзуллин үзенне бер регламент белән эзлекле рәвештә эшләргә күнектерүнең әһәмияте һәм Х. Сарьян үз иҗатына комачаулаган кайбер мисалларга кагылып үттеләр.

Җыелыш язучының хезмәтенә ярдәм итәрлек мәсьәләләр турында карар кабул итте.

## ГАЛИМНӘР ЯНЫНДА

Язучылар, композиторлар, художниклар һәм Казан театры артистлары март аенда СССР Фәннәр академиясенең Казан институтлары Актлар залына җыелдылар. Биредә партиянең Татарстан өлкә комитеты тарафыннан иҗат көчләре өчен оештырылган семинарның чираттагы утырышы булды.

Семинарда катнашучылар Мәскәү дәүләт университеты профессоры А. П. Буеваның «Хәзерге заман һәм фәнни-техник революция» дигән лекциясен тыңладылар. Академик Б. А. Арбузов Казан химикларының нинди проблемалар өстендә эшләүләре һәм ул хезмәтләрнең халкыбызның көнкүрешендәге әһәмиятләре белән таныштырды. Казан медицина институты профессоры В. Е. Анисимов эчке авырулар өлкәсендә эшләүче галимнәрнең хезмәтләре турында сөйләде. Профессор Н. П. Медведевның йөрәк ... яңа ... зур кызыксыну белән тыңланды.

## «ЯДКАРЬ» БЕРЛӘШМӘСЕНДӘ

Партиянең XXIV съезды ачылган көнне, ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты каршындагы «Ядкарь» иҗади берләшмәсе Казан дәүләт педагогия институтында, илебез тормышындагы бу бөек вакыйгага багышлап әдәби-музыкаль кичә үткәрде.

Кичәдә язучылардан Җәлил премиясе лауреаты Илдар Юзеев, Рафаэль Мостафин, Гөлшат Зәйнашева, Роберт Батуллин, Шамил Мәхмүдов, Ренат Харисов, Рөстәм Мингалимов, Гәрәй Рәхим, Рәшит Әхмәтҗанов, Зөлфәт һәм бер төркем яшь шагыйрьләр үзләренең әсәрләрен укыдылар. Съездга багышланган бу сәнгать бәйрәменә Татарстанның халык җырчысы, Тукай премиясе лауреаты Илһам Шакиров, ТАССРның атказанган артисты, Тукай премиясе лауреаты Ринат Тажетдинов, Рәфгать Гомәров җитәкчелегендәге «Саз» халык ансамбле, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрыннан Флера Хәмитова һәм бер төркем артистлар, КХТИның «Сәйяр» эстрада труппасы килгән иде.

Казан дәүләт педагогия институты студентлары институтның партия, комсомол оешмалары һәм ректораты исеменнән, туган партиябез съездын шундый зур сәнгать бәйрәме белән каршы алуны оештырганы өчен, «Ядкарь» берләшмәсенә рәхмәт белдерделәр һәм катнашучыларга бүләкләр тапшырдылар. Бу кичә республикабыз яшь иҗатчыларының съездны каршы алуга зур өлеше булды.

## БӨТЕНСОЮЗ ӨМӘСЕНДӘ

Ул көнне бөтен Казан урамда иде. Иртәдән үк бәйрәмчә җанлылык хөкем сөрде. Урамнар язгы чүп-чарлардан арынып-чистарынып калдылар. Шәһәр предприятиеләрендә дә Бөтенсоюз өмәсен зур күтәренкелек белән үткәрделәр. Бу көнне эшчеләр аеруча күңел күтәренкелеге белән эшләделәр. Өмәгә чыккан коллективларның бик күбесенә Татарстан язучылары килделәр һәм әдәби чыгышлар ясадылар.

Казан педагогия институты студентлары Рәдиф Гатауллин һәм Аяз Гыйләҗев чыгышларын яратып тыңладылар. 33 нче номерлы техник училищеда Зәки Нури, Юрий Белостоцкий, Нәби Дәүли, хәрбиләр янында Геннадий Паушкин, Михаил Скороходов, Александр Вольновлар көтелгән кунак булдылар. Вахитов исемендәге химкомбинат эшчеләре Фатих Хөсни, Әхсән Баян, Гариф Ахунов, Гөлшат Зәйнашева чыгышларын алкышладылар. Ләбибә Ихсанова, Рәйсә Ишморатовалар 80 нче мәктәп укучылары алдында чыгыш ясадылар.

Ленин исемендәге җитен комбинаты эшчеләренә Шамил Рәкыйпов, Шәүкәт Галиев, Фаил Шәфигуллиннар, моторлар төзү заводы эшчеләре янында Галимҗан Латыйп, Газиз Мөхәммәтшин, Зөлфәт Маликовлар булды.

Язгы каникуллар вакытында укучыларның язучылар белән очрашу традициясе елдан-ел дәвам итә. «Китап атналыгы» дип исемләнгән бу бәйрәм мәктәпләргә, пионер сарайларына, клубларга бик күп укучыларны, язучыларны һәм артистларны җыя. Бу бәйрәмне Казанның Абдулла Алиш исемендәге Пионерлар сараенда да зурлап үткәрделәр. Балалар китапның ничек дөньяга чыгуын күрү өчен К. Якуб исемендәге китап басу комбинатында экскурсиядә булдылар, татар әкиятләренең яраткан геройлары белән очраштылар, балалар язучыларын кунакка чакырдылар.

Укучылар белән очрашуга Максим Горький исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Сибгат Хәким, Муса Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты Илдар Юзеев, шагыйрь Шәүкәт Галиев, шагыйрь Рөстәм Мингалимов, балалар язучысы Роберт Батуллиннар барган иде. Алар укучыларга үзләренең яна әсәрләрен укыдылар. Күп төрле сорауларга җаваплар бирделәр.

## КҮҢЕЛЛЕ СӘЯХӘТ

Март ахырларында Казан дәүләт музеена республикабыз мәктәпләреннән күп кенә пионерлар җыелды. Алар — сәяхәтчеләр. Ләкин урманнарга, далаларга, тауларга түгел, «Матурлык дөньясына» сәяхәт итүчеләр. Казылма байлыклар эзләп йөрүчеләр дә, географик карталардагы ак урынны тикшерүчеләр дә түгел, китаплар дөньясына барып, әдәби геройларның язмышларын өйрәнүчеләр, әдәби музейлар оештыручылар, төрле өлкәдәге язучылар белән элемтәдә яшәүчеләр. Әнә шул сәяхәтчеләрнең республика слетына килгән пионерлар үзләренең эшләрен сөйләделәр, иптәшләрен кызыклы һәм гыйбрәтле вакыйгалар белән таныштырдылар. Казан шәһәренең 55 нче мәктәп пионеры Абдулла Алиш музеен, 26 нчы мәктәп укучысы Муса Җәлил музеен оештырулары турында сөйләделәр.

Арча районы бөек Тукайны, танылган язучылардан Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, нефтьчеләр тормышыннан зур күләмле әсәрләр язган Гариф Ахунов, лирик повестьлары белән күңелгә кергән Рафаил Төхфәтуллин һ. б. язучыларны биргән җир. Арчаның 2 нче мәктәп укучылары якташ язучылары белән элемтәләре турында сөйләделәр. Краснодон шәһәренә барып, якташлары Мәрьям Бикбаева белән очрашулары турындагы сүзне укучылар бик нык дулкынланып тыңладылар. Яшь гвардиячеләрне яхшы белгән Бикбаевлар семьясы Арчадан килгән пионерларга күп кенә кызыклы хәбәрләр сөйләгәннәр.

## ХӘРБИЛӘР БЕЛӘН ОЧРАШУ

Партиянең XXIV съезды ачылган көннәрдә Татарстан язучылары күп кенә урыннарда укучылар белән очраштылар. Алар үзләренең иҗат планнары белән уртаклаштылар, татар әдәбиятының казанышлары турында сөйләделәр.

...лыгы исемендәге танк училищесында Н. Дәүли, З. Нури, М. Зарецкий, В. Ганиевләр әдәби кичә уздырдылар. Бу очрашуда алар СССР язучылар союзының V съездына хәзерлек унае белән республикабыз язучылар оешмасындагы эшләр турында да сөйләделәр. Үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

Кичәдә Казанда булган Мәскәү кунаклары шагыйрь С. Викулов, балкар халык шагыйре Кайсын Кулиев катнашты.

* * *

Казан Офицерлар йортында «Кызыл ромашка» клубы эшли. Шул клубка йөрүче хәрбиләр үзләренең бер утырышларына шагыйрьләрдән М. Садри, З. Нури, прозаиклардан Г. Паушкин, Ю. Белостоцкийларны чакырдылар. Ватан сугышы утларын кичеп кайткан бу язучылар белән очрашу күңелле үтте. Сугышка каршы көрәш мотивлары белән тулы ялкынлы шигырьләрне, хикәяләрне офицерлар дулкынланып тыңладылар.

## ФӘННИ СЕССИЯ НӘТИҖӘЛӘРЕ

СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәрләре үзләренең IV фәнни конференцияләрен уздырдылар.

Галимнәрнең ел йомгакларына багышланган бу конференция 4 көн дәвам итеп, анда филология фәннәре докторлары Г. Халит, Х. Ярмөхәммәтов, тарих фәннәре докторлары Х. Хәсәнов, А. Халиков, М. Мөхәррәмов, филология фәннәре кандидатлары Х. Хәйри, А. Әхмәдуллин, Л. Мәхмүтова, Х. Курбатов, Ш. Абилов, И. Надиров, тарих фәннәре кандидатлары С. Алишев, Р. Фәхретдинов, Р. Мөхәммәдова һ. б. иптәшләр докладлар белән чыктылар.

Конференциядә чыгыш ясаучылар эшләгән эшләргә йомгак ясадылар һәм 1971—75 елларда эшләнәчәк эшләр турында сөйләделәр.

Институтның әдәбият секторы буенча, мәсәлән, алдагы бишьеллыкта түбәндәге эшләр эшләнәчәк: татар әдәбияты тарихының V томлыгы төзеләчәк. Бу хезмәт XII гасырдан бүгенге көнгә кадәр булган вакытны эченә алачак. Г. Тукай әсәрләренең IV томнан торган академик басмасы төзеләчәк. Тел секторы буенча татар һәм чуваш телләренең чагыштырма өйрәнелүе турындагы хезмәт, татар теленең диалектологик атласы, аерым сөйләм һәм диалектлар буенча, татар теленең полисемия, синонимнар һәм омонимияләре буенча монографияләр һәм башка хезмәтләр эшләнәчәк.

Халык иҗаты секторында Идел буе татарлары халык иҗатының төп үзенчәлекләре турында монографик тикшеренүләр булачак. Татар халык иҗатының 10 томлык фәнни басмасы әзерләнәчәк.

Сәнгать секторында хәзерге заман татар театры (1960—1970) турында өйрәнүләр, революциягә кадәрге татар театры ту-

татарларының музыкаль фольклоры турында монографик тикшеренүләр булачак. Көйләр җыентыгы һ. б. хезмәтләр төзеләчәк.

Тарих секторында Татарстанның эшче сыйныфы һәм промышленностеның тарихы турында, республикада культура революциясенең (1917—70) тормышка ашуы буенча монографияләр эшләнәчәк, «Татарстан АССР Бөек Ватан сугышында» дигән монография язылачак, һ. б. хезмәтләр дөнья күрәчәк.

Археология һәм этнография секторы хезмәткәрләре «Казан ханлыгы һәм Идел буе болгарларының культурасы һәм этник составы» дигән ике томлык монографияне язу, ТАССРның V томлык археологик картасы һәм татар халкының этнографик атласын төзү өстендә эшләячәкләр.

## Г. ТУКАЙ МУЗЕЕ

Бөек шагыйрь үзенең балалык чагын уздырган Кырлай авылында музей ачылды. Экспозицияләрдә Тукайның кулъязмалары, аның беренче әсәрләре, гомеренең соңгы елларында төшкән фоторәсемнәре, китаплары, тормыш-көнкүреш әйберләре куелган. Күп кенә язучыларның Тукай турында әйткән сүзләре, Тукай премиясе лауреатларының фоторәсемнәре, Казанда һәм Ташкентта Тукай исемен йөрткән урамнарның фотолары экспозицияне баетып, бүгенге көн белән бәйләп торалар.

Музейны ачу тантанасында язучылар, композиторлар, галимнәр, колхозчылар, укытучылар, мәктәп балалары катнашты. Митингта ТАССР культура министры урынбасары М. Т. Низамиев, партиянең Арча райкомы секретаре Т. Нуриев, Татарстан язучылар союзының җаваплы секретаре Гариф Ахунов, Габдулла Тукайның замандашы А. Мәгъсүмов, мәктәп директоры Г. Яруллин, Г. Тукайның туганнарыннан Х. Зәбировлар чыгыш ясады.

## ӘДӘБИ ОЧРАШУЛАР

Драматург Риза Ишморат Минзәлә районында булып, колхозчылар һәм укучылар белән күп санлы очрашулар үткәрде, авыллардагы драмтүгәрәкләргә практик ярдәм күрсәтте.

«Яңа юл», «Гигант» колхозларында очрашулар аеруча истәлекле булды. Бу очрашуларга 700 гә якын кеше килгән иде. Драматург аларга Г. Кутуй, М. Җәлил, һ. Такташ, К. Тинчурин, Т. Гыйззәтләр турында истәлекләр сөйләде. Үзенең иҗат планнары белән уртаклашты.

* * *

Композитор Заһид Хәбибуллин һәм язучылардан Мәхмүт Хәсәен, Мәлик Хәмитовлар Зеленодольск районы Ильич исемендәге колхозның 40 еллык юбилей тантанасында катнаштылар.

* * *

Гариф Ахунов, Рафаэль Мостафин, Ләбибә Ихсанова, Гөлшат Зәйнашева, Рәшит

ләре янында бу[illegible] татар тугызынчы бишьеллыкны үтәүдә язучыларның өлеше һәм үзләренең иҗат планнары турында сөйләделәр. Тыңлаучылар язучыларга күп төрле сораулар бирделәр.

## ДУСЛЫК ФЕСТИВАЛЕ

Чувашстан башкаласы Чабаксарда И. Н. Ульянов исемендәге чуваш дәүләт университетының Актлар залында шигърият һәм дуслык фестивале уздырылды. Фестивальгә татар, башкорт, чуваш, мари һәм мордва иҗатчы студентлары катнашты. Казаннан килгән яшь язучылардан Азат Ганиев, Фәннур Сафин һәм Роберт Миңнуллиннар бу очрашудан зур тәэсирләр белән кайттылар.

## ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАР СЕМИНАРЫ

РСФСР һәм Мәскәү язучылар союзы тарафыннан башкалабызда яшь язучылар семинары үткәрелде. Семинар җитәкчеләреннән В. Боков һәм М. Львовлар яшь язучылардан Разил Вәлиев, Әхмәт Гаделләрнең әсәрләренә җентекле анализ ясадылар. Семинар яшь шагыйрьләрнең әсәрләрен Мәскәү нәшриятларына тәкъдим итәргә дигән карар чыгарды.

## АКТЕРЛАР ЙОРТЫНДА

Март ахырларында Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге члennары XI республика конференциясенә җыелдылар.

Бүлекнең эше турында правление председателе М. З. Булатова чыгыш ясады.

Фикер алышуларда артистлар, режиссерлар, театр тәнкыйтьчеләре катнашты.

Конференциядә Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге правлениесенең яңа составы сайланды. РСФСРның халык артисткасы Р. А. Җиһаншина правлениенең председателе итеп билгеләнде.

* * *

Мандолиначы Исмәгыйл ага Һилалов татар музыка сәнгатендә алтмыш ел эшләп килә. Ул татар халык көйләрен мандолинада уйнауның виртуозларча осталыгына ирешкән музыкант.

Исмәгыйл аганың замандашлары, Казан шәһәренең музыка сөючеләре Актерлар йортында аның хезмәтенә алтмыш ел тулган көнне билгеләп үтәргә җыелдылар. Кичәдә И. Һилаловның эшчәнлеге турында кереш сүз, кызыклы истәлекләр сөйләнде.

Соңыннан юбилярның катнашында зур концерт булды.

---

**Төзәтү:**

Журналның 6 санындагы (192 бит) «Татар халык җырлары» дигән информациядәге Мәхмүт Әхмәтҗановны Мәхмүт Нигъмәтҗанов дип укырга кирәк.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210